# КАЗАН УТЛАРЫ

1. 1984



# КАЗАН УТЛАРЫ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

**АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ**

**1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА**

**1**

**1984**

**КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ**

**КАЗАН**

## *Бу санда*

АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕНХАЛЫК ЭШЕ

Г. И. УСМАНОВ. **Бүгенгедән киләчәккә карап** . . 3

С. ХӘКИМ. **Күги.** Поэма . . . . . . . . . . . 15
Б. КАМАЛОВ. **Өметең өзелмәсен.** Роман . . . . 22
Г. ГӘРӘЙ. **Йөрәктәге учаклар.** Шигырьләр . . . 91

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

**Казанда Тукай урыннары** . . . . . . . . . . 96
З. РӘСУЛЕВА. **Тукай эзләреннән** . . . . . . . . 97

Г. ГАЛИЕВ. **Карлыгачлар оя кора.** Хикәя . . . . 110

КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ИЮНЬ (1983 ЕЛ) ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА

М. ФАРУКШИН. **Җиңүчән чынбарлык һәм дошманы уйдырмалар** . . . . . . . . . . . . 121

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

Х. ГАЙНЕТДИНОВ. **Кеше кадере** . . . . . . . . 128

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

Ш. ӘХМӘДУЛЛИН. **Максатка реаль нигез** . . . 133
Ф. ХӨСӘЕНОВА. **Әле дә күз алдымда** . . . . . 135

БИБЛИОГРАФИЯ

Т. ГАЛИУЛЛИН. **Җиргә бер сүз** . . . . . . . . 139

РИЗА ФӘХРЕТДИНЕВНЕҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

М. ГОСМАНОВ. **Катлаулы чорның каршылыклы вәкиле** . . . . . . . . . . . . . . . 142
Ә. ХӘЙРУЛЛИН. **Галимнең кульязма мирасы** . . 157
**Риза Фәхретдиневнең эшчәнлегендә халыкара иминлек мәсьәләләре.** Документлар . . . . 162
М. ӘХМӘТҖАНОВ. **Риза Фәхретдинев шәҗәрәсе** 164

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия:*

**ШАМИЛ БИКЧУРИН**
**МАНСУР ВӘЛИЕВ**
**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**РӘИС ДАУТОВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**ЗӨЛФӘТ**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**ЗӘКИ НУРИ**
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**АТИЛЛА РАСИХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**НИЛ ЮЗИЕВ**

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

ФӘРИТ ЯРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

**Музыка сәнгатебезнең горурлыгы. Истәлекләр** (Р. Яхин, Х. Гобәйдуллин, З. Хәйруллина, Ф. Ильская, Г. Литинский, Г. Таһиров.) . . . 169

РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

А. ХӘСӘНОВ. **Уйлап язсаң гына** . . . . . . . 180

БЕР СОРАУГА БЕР ҖАВАП

Р. ФӘХРЕТДИНОВ (120), ЗӨЛФӘТ (138), Н. ФӘТТАХ . . . . . . . . . . . . . 184

Х. ХАЛИКОВ. **Балалар өчен шигырьләр** . . . . 185

**Кызыклы хәлләр** . . . . . . . . . . . . . . 187

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . . 189

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

Статья Первого секретаря Татарского ОК КПСС **Г. И. Усманова** о проблемах переустройства современного села.
Поэма **С. Хакима** «Куги», роман **Б. Камалова** «Не теряй надежду» (начало), стихи **Р. Гарая**, **Х. Халикова**, рассказ **Г. Галиева** «Ласточки вьют гнезда».
«К 100-летию Тукая»: публикация **З. Расулевой** «По следам Тукая» (начало), рис. **Т. Зуевой** из цикла «Тукаевские места в Казани».
Статья **М. Фарукшина** «Побеждающая действительность и враждебная клевета». Зарисовка **Х. Гайнутдинова** с литературного поста журнала — со строительства ТатАЭС.
Продолжение дискуссии «Современная проза: герои, проблемы»: статьи **Ш. Ахмадуллина**, **Ф. Хусаиновой**. Рецензия **Т. Галиуллина** на книгу стихов Р. Мингалима.
«К 125-летию Р. Фахрутдинова»: статьи **М. Усманова** («Противоречивый представитель сложного времени»), **А. Хайруллина** («Рукописное наследие ученого»), исследование **М. Ахметзянова** («Родословная Р. Фахрутдинова»), документальные материалы («Вопросы международных взаимоотношений — в деятельности Р. Фахрутдинова»). «К 70-летию Ф. Яруллина»: композитор — в воспоминаниях **Р. Яхина**, **Х. Губайдуллина**, **З. Хайруллиной**, **Ф. Ильской**, **Г. Литинского**, **Г. Тагирова**.
Статья **А. Хасанова** о творчестве Р. Тухватуллина (к 60-летию писателя).
«Вопрос — ответ»; «Занимательные истории» (из жизни выдающихся деятелей татарской культуры); «Новости культуры»; «На наших обложках» — творчество художника И. Рафикова.

Техник редактор *Р. Сөләйманова*    Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина.*

Производствога бирелде 27.10.1983 ел. Басарга кул куелды 22.12.1983 ел. ПФ 02489. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 63349. Заказ Я-437. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1984 ел.

**Г. И. Усманов,**
КПССның Татарстан өлкә комитеты
беренче секретаре

# БҮГЕНГЕДӘН КИЛӘЧӘККӘ КАРАП

Моннан нәкъ ярты гасыр элек Татарстан, автономияле республикалар арасында беренче булып, Ленин ордены белән бүләкләнде. Мондый зур бүләккә ул авыл хуҗалыгын кумәкләштерүнең ленинчыл планын тормышка ашыруда, авыл хуҗалыгы эшләрен уңышлы башкарып чыгу һәм кырларыбыздан продукция алуны арттырудагы казанышлары өчен лаек булды. Чоры өчен күрелмәгән, элекке крестьянның уена да килмәгән рекордлы уңыш үстерелде. Татарстан басуларының һәр гектарыннан 13 әр центнер ашлык җыеп алынды.

Бу — кумәк крестьян хезмәтенең, коллектив хезмәтнең гаҗәеп зур мөмкинлекләргә ия булуын күрсәтүче тәүге җиңү иде.

Ул көннәрдән безне ярты гасыр вакыт аерып тора. Кеше гомереннән дә кимрәк булган чорда республикабыз авыл хуҗалыгы җитди үзгәрешләр кичерде, авылның кумәк хезмәттә чыныккан яңа хуҗасы формалашты. Бу чор чын мәгънәсендә зур сынаулар, олы көрәш еллары булды. Шул илле елның байтак өлеше илебезнең азатлыгы, бәйсезлеге өчен көрәшкә, сугыштан соң халык хуҗалыгын торгызуга багышлануын исәпкә алганда, бүгенге уңышларыбыз тагын да колачлырак булып күз алдына баса.

Игенчелекне генә алыйк. Моннан ярты гасыр элек һәр елны бер миллионга якын крестьянның маңгай тире белән эшкәртелгән кырлар бүген нибары алтмыш мең чамасы механизатор кулына тапшырылган. Димәк, бер механизатор ул чордагы унҗиде кешене алыштыра, бер үзе зур гына бер авылны туендырырлык икмәк үстерә. Тагын бер сан: узган ел бер центнер ашлык җитештерү өчен нибары 1 сәгать 48 минут эш вакыты сарыф ителгән. Димәк, бер кешене ел буе туйдырырлык икмәк үстерү өчен бүгенге механизаторга нибары ике сәгатьлек эш вакыты җиткән. Ә бит кумәк хуҗалыкка кучкәнче, крестьян, бөтен гаиләсе белән караңгыдан караңгыга эшләп тә, очын-очка ялгап туенырлык кына икмәк җитештерә алган.

Шушы кечкенә генә күрсәткеч тә кумәк хуҗалыкның, коллектив хезмәтнең, социалистик тормыш рәвешенең гаять зур өстенлекләре, мөмкинлекләре турында сөйли. Моны тулырак күз алдына китерү өчен республикабыздагы социаль-экономик үзгәрешләргә игътибар итик.

Партиябез, бөек Ленин тәгълиматларына таянып, авыл хуҗалыгын үзгәртеп кору һәм аны үстерүдә гигант колачлы эшләргә җитәкчелек итте. Бу эш гаять кыен да, катлаулы да булды. Әмма Ленинның кооперация планын тормышка ашыру безнең алга барыр юлларыбызда якты

маяк булып торды һәм ул бүген дә шулай булып кала. Республикабыз авыл хуҗалыгы үткән юл һәм анда ирешелгән казанышлар да моңа ачык бер дәлил.

Чагыштыру өчен исебезгә төшерик: моннан егерме биш еллар элек кенә әле республикабыз авыл хуҗалыгы нинди хәлдә иде? Күз алдына китерүе дә читен — Татарстан кебек алга киткән индустриаль республикада көн ихтыяҗларына җавап бирә алырлык бер генә терлекчелек комплексы да юк иде. Бүгенге кебек механикалаштырылган фермаларны игенчеләр һәм терлекчеләр ул вакытта хыялларына да кертмәгәннәрдер.

Ә изге туфрак, безне туендыручы җиребез? Аның да хәлләре мөшкел иде: уңдырышы-гумусы елдан-ел кими барды, туфрагы ярлыланды.

Нииндидер борылыш ясарга, хәлне кискен үзгәртергә, гомумән, авылны яңабаштан үзгәртеп корырга кирәк иде. Партиябезнең март (1965 ел) Пленумы безнең тормышыбызда әнә шундый борылыш ноктасы булды. Ул авылны һәрьяклап үстерү максаты куйды, авыл хуҗалыгын күтәрү өчен гаять киң мөмкинлекләр ачты. Пленумнан соң үткән унсигез елда бу юнәлештә республикада зур аграр программа гамәлгә ашырылды.

Бүген Татарстан агропромышленносте комплексының авыл хуҗалыгы секторын 558 колхоз, 272 совхоз, 9 кошчылык фабрикасы, терлекчелек продукты җитештерү буенча алты хуҗалыкара берләшмә, куәтле теплицалар, промышленность берләшмәләренең 140 ярдәмче хуҗалыгы тәшкил итә.

Мәгълүм булганча, бөтен байлыкның чыганагы — җир һәм намуслы эш. Татарстанда авыл хуҗалыгы җирләренең мәйданы 4 491 мең гектар, шуның эченнән 3 746,7 мең гектары сөрүлек җирләр. Бу җирләрдә 3 400 чамасы авыллар, поселоклар һәм аларда бер миллион бер йөз егерме өч мең кеше яши.

Хезмәттә катнашучы авыл кешеләренең һәркайсы 1982 елда уртача 4182 сумлык продукция җитештерде. Бу күпме, әллә азмы? Мондый чакта тулырак җавап бирү өчен үткәнгә мөрәҗәгать итәбез, чагыштырып карыйбыз. Гадәттә, чагыштыру өчен авыл тормышындагы борылыш елы — тарихи март (1965 ел) Пленумы булган елны алабыз. 1965 елда һәр гектар җирдән 220 сумлык продукция алынган булса, унынчы бишьеллыкта ул 370, ә 1982 елда 391 сум тәшкил итте. Уртача һәр колхозчы һәм совхоз эшчесе 1982 елда, 1965 ел белән чагыштырганда, ике тапкыр диярлек, ә 1950 ел белән чагыштырганда, 4 тапкыр күбрәк продукция җитештерде, ягъни республикабыз авыл хуҗалыгында хезмәт җитештерүчәнлеге дүрт тапкыр күтәрелде.

Моңа бигрәк тә нинди факторлар исәбенә ирешелде соң?

Иң беренче чиратта бу еллар эчендә авыл хуҗалыгының материаль-техник базасы ныгыды, сыйфат ягыннан ул яңарыш кичерде. Соңгы 18 ел эчендә моның өчен 5,7 миллиард сумлык капитал салым үзләштерелде. Авыл хуҗалыгы бу елларда халык хуҗалыгының техника белән тәэмин ителгән, югары дәрәҗәдә механикалаштырылган тармагына әверелде. Аның төп производство фондлары 4 миллиард сумга җитте, ягъни 1965 ел белән чагыштырганда алты тапкыр диярлек артты. Трактор паркының гомуми куәте биш тапкыр үсте, ә хезмәтнең энергия белән кораллануы дүрт тапкырдан күбрәккә күтәрелде. 1983 елда авыл хуҗалыгында эшләүче һәр колхозчы һәм совхоз эшчесенә егерме алтыдан артык ат көченә тиң энергия куәте туры килде.

Ат көче дигәннән, республикабыз Ленин орденына лаек булган елны барлык эшләр нигездә ат ярдәмендә башкарылса, бүген инде безнең ару белмәс баһбайларыбыз барлык энергия куәтенең нибары 0,4 процентын гына тәшкил итә. Тракторларның гына гомуми куәте дә өч миллион ат көченә тигез.

Болар барысы да игенчелектә генә түгел, терлекчелектә дә кул көче таләп итеlә торган күпчелек эш процессларын механикалаштырырга һәм хезмәт җитештерүчәнлеген шактый күтәрергә мөмкинлек бирә.

Авыл хуҗалыгын тагын да интенсивлаштыру юнәлешендә гаять зур эшләр башкарылды. Соңгы елларда республикабызда яңа тармак — сугарулы үсемлекчелек барлыкка килде һәм ул ныгый. Колхоз һәм совхозларда 240 мең гектар сугарулы җир бар. Мелиорацияне үстерүгә барысы 400 миллион сумнан артык капитал салынды. Һәм бу чара үзенең уңай нәтиҗәсен бик тиз күрсәтте — коры килгән елларда да терлек азыгы хәзерләү һәм терлекчелекне тотрыклы алып барырга, терлекләрдән продукция алуның күләмен, аларның баш санын саклап калырга мөмкинлек бирде.

Химияләштерү буенча башкарган эшләребез дә аз түгел — соңгы унбиш ел эчендә органик ашламаларны куллану ике тапкыр, ә минераль ашламаларны кертү җиде тапкыр артты, ике миллион гектардан артык сөрү җире известьланды.

Киләчәктә мелиорация һәм химияләштерүгә тагын да зуррак игътибар бирәчәкбез. Җирләребез ашламаны күбрәк алачак — моңа ирешүдә инде төзелә башлаган Менделеевск ашламалар җитештерү заводына да ышаныч баглыйбыз.

Болар барысы да безнең шартларда авыл хуҗалыгын тотрыклы үстерүнең, терлек азыгын, яшелчә һәм башка төр үсемлекчелек продукциясен гарантияле җитештерүнең нигезе булып тора.

Авыл хуҗалыгын күтәрүнең комплекслы программасының состав өлешен производствоны оештыру формаларын камилләштерү, бигрәк тә аны концентрацияләү һәм специальләштерү тәшкил итә. Бу — берөзлексез дәвам итә торган процесс. Аерым төр продукцияләр җитештерү буенча специальләшкән предприятиеләр, әйтик, кошчылык фабрикалары, теплица комбинатлары, ит, сөт җитештерү буенча куәтле комплекслар төзелә.

Бүгенге этапта производствоны концентрацияләү һәм специальләштерүнең төп яңа һәм мөһим формасы булып агропромышленность интеграциясе исәпләнә. Икенче төрле әйткәндә, авыл хуҗалыгы продукты җитештерү белән бер үк вакытта, аны эшкәртү, саклау һәм реализацияләү эшләрен дә үзләре башкара торган предприятиеләр һәм берләшмәләр төзү — ул бүгенге көн таләбе. Безнең республикабызда шундый юнәлештәге беренче карлыгач — «Татплодоовощхоз» берләшмәсе һәм аның предприятиеләре.

Шулай итеп, яңа этапта авыл хуҗалыгы производствосын концентрацияләү һәм специальләштерүнең төп үзенчәлеге шунда, бу процесслар авыл хуҗалыгы предприятиеләренең генә түгел, хәтта тармакның үз чикләренә дә сыеша алмыйча, тармакара характер алалар.

Җыеп кына әйткәндә, авыл хуҗалыгында материаль-техник базаны ныгыту, идарә итү һәм планлаштыруны камилләштерү, хуҗалыкларга проблемаларны үзлегеннән хәл итүгә мөмкинлек бирү, колхозчыларның, совхоз эшчеләре һәм авыл хуҗалыгы белгечләренең иҗади активлыгын үстерү республикабызда терлекчелек һәм игенчелек продукциясен җитештерүнең шактый артуына китерде. Һәм мондый нәтиҗәгә бөтен ил күләмендә ирешелде. Тикмәгә генәме безнең дошманнарыбыз әлеге уңышларны күрмәмешкә салышалар, шик астына алырга, яки киметеп күрсәтергә җай эзлиләр. Илебездә Азык-төлек программасы кабул ителү уңае белән буржуаз пропаганда төрле уйдырмалар уйлап чыгара башлады. Имеш, март (1965 ел) Пленумы карарлары көтелгән нәтиҗәне бирмәгән, һәм шуңа күрә, янәсе, яңа чаралар үткәрү таләп ителә... Чынлыкта бу шулаймы соң? Илебез күләмендә дә, Татарстан күләмендә дә моның киресен күрәбез, ягъни фактлар баш-

качарак сөйли. Нәкъ менә март (1965 ел) Пленумында билгеләнгән чараларны тормышка ашыру авыл хуҗалыгы производствосының житди үсүенә китерде. Илебез күләмендә икмәк житештерү жиденче бишьеллыктагы 130 миллион тоннадан унынчы бишьеллыкта 205 миллион тоннага, ит 9,5 тән 14,8 миллион тоннага, сөт 64,7 дән 92,7 миллион тоннага, йомырка 36 дан 67 миллиард данәгә житте. Безнең республикабыз мисалында да шундый ук үсеш, шундый ук закончалык саклана.

Бу чор эчендә халык саны 15 процентка артса да, җан башына продукция җитештерү илебездә 28, ә Татарстанда уртача 30 процентка күтәрелде.

КПСС Үзәк Комитетының март (1965 ел) Пленумында эшләнгән аграр политика тормышка уңышлы ашканга күрә дә илебездә Азык-төлек программасын эшләү мөмкинлеге туды. Бу программа илебезне азык-төлек һәм авыл хуҗалыгы чималы белән тәэмин итү мәсьәләсен кардиналь хәл итәргә тиеш. Уңышларыбыз зур булса да, әлеге мөһим мәсьәлә тулысынча хәл ителгән, көн тәртибеннән алынган дип әйтергә иртәрәк: безнең туклану рационы калориялелеге буенча физиологик нормага туры килсә дә, аны төрләндерү ягыннан әле житди яхшыртасы бар. Бигрәк тә әлегә ит һәм ит продуктларына булган ихтыяҗ тулы канәгатьләндерелми, яшелчә һәм җиләк-җимеше дә житәрлек түгел. Туклану продуктларына булган ихтыяҗ аларны житештерү темпларына караганда тизрәк үсә. Бу, беренчедән, азык-төлек бәяләре шул килеш калып, халкыбызның акча доходларының артуы белән аңлатылса, икенчедән, экономиканың аграр секторында эшләүчеләрнең елдан-ел кимүе, шәһәр халкының үсүе белән дә аңлатыла.

Республикабыз халкының табынын тагы да яхшырту өчен 1990 елга ит куллануны җан башына 1982 елдагы 52 килограмм урынына 72 килограммга, сөтне 291 урынына 386 килограммга, йомырканы 281 данә урынына 302 данәгә, яшелчәне 79,5 килограмм урынына 132 килограммга, җиләк-җимешне 16,3 урынына 73 килограммга җиткерергә кирәк. Куелган максатка ирешү өчен иң элек авыл хуҗалыгын тагын да интенсивлаштыру, аның нәтиҗәлелеген күтәрү, төп байлыгыбыз булган җирнең уңдырышын арттыру таләп ителә. Безгә бу бишьеллыкның ахырына ук инде бөртекле культураларның уңышын кимендә 21—22 центнерга, ә 1990 елда 23—25 центнерга җиткерергә кирәк. Уникенче бишьеллык ахырында дәүләткә ашлык сатуның күләме 1 миллион 750 мең тоннага, шикәр чөгендере 830 мең, бәрәңге 334 мең, яшелчә сату 155 мең тонна тәшкил итәчәк.

Зур бурычлар тора, әмма алар — реаль бурычлар. Элегрәк: «Яңгыры булса, елы килсә...» дип сөйләшергә яраталар иде. Соңгы елларда безнең республикабыз игенчеләрен, дөресен әйтергә кирәк, һава шартлары куандырмады. Әмма алдынгы хуҗалыклар тәҗрибәсе күрсәткәнчә, хәзер инде һава шартлары, стихия иң мөһиме түгел, ә иң мөһиме — Карл Маркс әйткәнчә, һәр гектар җиргә күбрәк хезмәт һәм капитал салу, фәнне эшкә җигү, стихиянең тискәре йогынтысын киметү.

Җир кешеләр өчен. Ул үзенең чын хуҗасы булуын, үзе турында кайгыртуын тойганда кешеләрне киендерә дә, туендыра да. Моны беркайчан да истән чыгарырга ярамый. Кешеләр бу җирдә үзләрен никадәр бәхетлерәк, шатлыклырак тойсалар, крестьян хезмәте аларга никадәр канәгатьлек хисе өстәсә, без изге максатыбыз — коммунизмга шул кадәр якыная барабыз дигән сүз.

Җирнең табигатен, таләпләрен аңлап эш иткән игенче хәтта иң уңайсыз елларны да икмәксез калмый, әйбәт уңыш җыя. Балтач районы «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге колхоз председателе Х. Г. Галимуллин, Столбище тәҗрибә-производство хуҗалыгыннан У. Х. Вәлиуллин, Тукай районы «Гигант» совхозыннан Н. З. Зыятдинов,

Актаныш районы «Таулар» колхозыннан И. К. Камалетдинов, «Коммунизмга»дан К. Г. Гарипов, Мөслим районы «Урожай» колхозыннан М. С. Сәләхов һәм башка уннарча хуҗалык җитәкчеләренең эше, уңышлары белән бөтен республика горурлана. Түбән уңдырышлы җирләрдә дә Балтач районы «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге колхоз игенчеләре 1983 елда бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 30, ә «Столбище» совхозында 32 шәр центнер уңыш үстерделәр. Рекордлы уңышны исә «Гигант» совхозы үстерде. Бу хуҗалыкта унынчы бишьеллыкта уртача уңыш 34 центнерга якын булды. Талантлы оештыручы, белгечләр, механизатор, игенчеләр күңелен яхшы аңлаучы, кешеләрне җиңүгә оста туплый белүче Н. З. Зыятдинов — иген игү серләренә чын мәгънәсендә төшенгән җитәкче. 1982 елда биредә бөртекле һәм кузаклы культураларның һәр гектарыннан 50,7 шәр, ә 1983 елда 42 шәр центнер уңыш җыеп алдылар. Ә бит әле кайчан гына Татарстан шартларында 35—40 центнер уңыш алу мөмкин түгел дип исбатларга тырышалар иде. Күрәсез, тиешле хезмәт куйганда, фән казанышларын киң кулланганда, күбрәк капитал салганда җиңүнең мөмкинлекләре чикләнмәгән. Юкка гына халкыбыз «Башлы кеше ташны аш итәр» димәгән шул. Һәр мәсьәләгә, агротехник алымны үтәүгә иҗади якын килү, кирәк чакта фән кешеләре белән ныклы элемтә булдыру, игенчелек системасын төгәл үтәү алдынгы хуҗалык җитәкчеләренә яңадан-яңа үрләр яуларга мөмкинлек бирә. Игенчелекнең яңа системасын колхоз һәм совхоз производствосына акыл белән, җирле шартларны исәпкә алып кертү җирнең куәтен арттыруда мөһим фактор булып тора. Шуңа күрә дә алдынгы хуҗалыкларның белгечләре, җитәкчеләре аны тиз арада төп кулланма итеп алдылар. 1982 ел һәм узганы кебек чагыштырмача әйбәт килгән елларда да 9—10 центнер уңыш белән калган хуҗалыклар бар әле. Узган ел, мәсәлән, 60 колхоз һәм совхоз 13 центнердан да кимрәк уңыш үстерде. Бер үк шартлар, бер үк кояш, бер үк зәңгәр күк, шундый ук бонитетлы кырлар. Ә уңыш юк. Чөнки шушы кырларга «хуҗа» булып яшәүче кешеләрнең олы омтылышлары, бүгенге көн таләпләренә тиң эшләре юк, ә эше юкның, халык әйткәнчә, ашы да юк.

Дөрес, бу хуҗалыкларда да кырлар чәчелми калмый. Чәчелә, тәгәрмәчләр әйләнә, ягулык сарыф ителә, хезмәт хакы түләнә. Тик эшнең ахыргы нәтиҗәсе генә куанырлык булмый. Чөнки җирнең чын хуҗасы юк, механизатор бирედә башак мул тулсын дип түгел, ә тәгәрмәчләр күбрәк әйләнсен дә, гектарлар күбрәк язылсын, кесәләр калынайсын дип эшли...

Куәтле техника белән коралланган бүгенге механизатор күңелендә колхозлашу елларына хас булган коллективизм, патриотизм рухын тагын да көчәйтеп җибәрсәң, шикләнмичә әйтергә мөмкин, куелган хезмәтне кырларыбыз тагын да юмартрак бүләкләячәк. Ягъни бүгенге механизаторның бәһасы урылган гектарлар белән түгел, ә амбарга салынган конкрет тонналар белән бәяләнергә тиеш. Моның өчен коллектив алдына олы максат куелуы, шул максатка ирешү юлында һәркемнең эшнең ахыргы нәтиҗәләре белән кызыксындырылуы шарт. Бу яктан КПСС Үзәк Комитетының май (1982 ел) Пленумында хупланган хезмәтне оештыруның подряд ысулы бөтен таләпләргә җавап бирә.

Соңгы ике елда безнең республикабыз авыл хуҗалыгында да бу ысул киң колач алды. Быел колхоз һәм совхозларда 2 600 бригада һәм звено яңа ысул белән эшләде. Бу коллективлар хәзер 19 меңгә якын механизаторны берләштерә. Сөрү җирләренең бер миллион 680 мең гектары, ягъни яртысы диярлек, шул исәптән бөртекле культуралар мәйданының 41, терлек азыгы культураларының 58, шикәр чөгендеренең 84, бәрәңгенең 81 проценты подряд ысулы белән эшләүче коллективларга тапшырылды.

Подряд ысулы белән эшләүче коллективларның хезмәтен ахыргы нәтиҗәләргә карап бәяләү төп критерий булып тора. 1983 ел йомгаклары бу прогрессив ысулның югары эффект бирүе турында сөйли. Кагыйдә буларак мондый коллективларда уңыш мулрак, хезмәт чыгымнары кимрәк, ә хезмәт җитештерүчәнлеге югары. Зеленодольск районы Ленин исемендәге колхоздан Г. Ф. Хыялиев, «Бөреле» совхозыннан А. Г. Прибылов җитәкчелегендәге звенолар һәм башка күп кенә коллективлар бөртекле культуралардан югары уңыш алуга ирешteләр. Иң беренче чиратта бу коллективларда җирдән файдалануда тәртип урнаштырылды, агротехника таләпләрен төгәл үтәүгә, чәчү әйләнешен саклауга, чүп үләннәренә каршы көрәшкә зур игътибар бирелә. Механизаторлар туфрак эшкәртү алымнарына иҗади киләләр. Нәтиҗәдә Хыялиев җитәкчелегендәге звено җиде йөз гектар мәйдандагы бөртеклеләрнең һәр гектарыннан планда каралган 24 центнер урынына 30,8 центнер уңыш үстерде, терлек азыгы культураларыннан да югары уңыш алуга иреште. Биредә техникадан файдалану 18 процентка, ә хезмәт җитештерүчәнлеге 28 процентка күтәрелде. Механизаторның уртача айлык хезмәт хакы 220—280 сум тәшкил итте. Ахыргы нәтиҗәләр буенча механизаторга аванс тәртибендә алган хезмәт хакының һәр сумына 50 тиен өстәмә түләү бирелде.

«Бөреле» совхозыннан А. Г. Прибылов җитәкчелегендәге звено планда каралган 23 центнер урынына 30,6 центнер уңыш үстерде, бөртекле ашлыкның үзкыйммәте 11 процентка кимрәк булды. Звено членнарына ахыргы нәтиҗәләр буенча, планнан тыш җитештерелгән продукция өчен премия һәм экономияләнгән туры чыгымнарын да кертеп, алдан алынган авансның һәр сумына 1 сум 31 тиен өстәмә түләү бирелде.

Терлекчелектә дә подряд ысулы киң кулланылыш таба бара һәм коллективлар әйбәт кенә күрсәткечләргә ирешәләр. Азнакай районы «Урманай» совхозының подряд ысулында эшләүче сарыкчылык фермасы йон җитештерү планын 104 процентка үтәде, андагы 9300 баш сарыкның һәркайсыннан планда каралган 4,2 урынына 4,5 килограмм йон кыркып алынды.

Азык-төлек программасында, алда әйткәнебезчә, туклану структурасын камилләштерү төп бурычларның берсе итеп куелды. Кеше үзенә кирәкле булган калорияне хәзер күбрәк ит һәм сөт продуктларыннан, яшелчә һәм җиләк-җимешләрдән алырга омтыла. Шуңа күрә дә соңгы елларда җан башына тотылган бәрәңге һәм икмәкнең күләме шактый кимеде. Терлекчелек продуктларына ихтыяҗ исә артканнанарта бара.

Бу тенденция гасырлар буе макталып килгән икмәк үстерүченең абруен киметмәсме соң дигән урынлы сорау туа. Минемчә, киметми! Игенченең оста куллары әле гасырлар буе мактап җырланыр, дистәләрчә поэма һәм романнар язылыр. Икмәк никадәр мулрак булса, терлекләр шулкадәр туграк, өстәлләр шул чаклы баерак булачак. Бөртекле ашлык җитештерү киләчәктә дә мөһим проблемаларның берсе булып кала. Тик аерма шунда, игенче үстергән продукция терлекчелеккә елдан-ел күбрәк юнәлтеләчәк, күбрәк ит, сөт, йомырка җитештерү максатына хезмәт итәчәк.

Мәгълүм булганча, сөт җитештерүне, шәхси хуҗалыкларны да кертеп, уникенче бишьеллыкта 1,5 миллион тоннага, итне 456 мең тоннага җиткерү бурыч итеп куела. Моның өчен һәр сыердан сөт савып алуны елына 3 мең килограммга, ә шәһәр яны зоналарында 3 200—3 400 килограммга җиткерергә кирәк. Бу үтәлмәслек бурыч түгел. Саба районы, Ленин исемендәге тәҗрибә-производство хуҗалыгыннан Социалистик Хезмәт Герое Гөлбикә Кәримова инде күп еллар буе һәр сыердан 5 000 килограмм һәм аннан да күбрәк сөт сава. Шунысы куанычлы,

кайчандыр кайбер савымчылар гына ирешкән биеклекләргә тулы бер колхоз, совхозлар күтәрелә. Бөгелмә районы «Восточный» совхозы, мәсәлән, 1982 елда сыерларның продуктлылыгын 6078 килограммга җиткерде һәм 1983 елда да әйбәт нәтиҗәләр бирде. Бу совхозның Карлыгач Хөснетдинова һәм Роза Лотфуллина кебек савымчылары һәр сыердан 6100 килограммнан да күбрәк сөт алдылар.

Тулысынча барлык хуҗалыклары белән югары күрсәткечләргә ирешкән районнар да бар. Балтачлылар, мәсәлән, районнагы барлык сыердан уртача 3 300 килограммнан артык сөт савып алдылар.

Болар безнең резерв түгелмени? Әгәр дә республикабызның хуҗалыкларында һәр савымчы балтачлыларның уртача күрсәткеченә генә җитсә дә Азык-төлек программасының сөтчелек өлеше бернична елга алданрак үтәлер иде. Ә һәр савымчы Гөлбикә Кәримова, Карлыгач Хөснетдинова, Роза Лотфуллина кебек эшләгәндә Татарстаннан илебез табынына йөзләрчә мең тонна сөт һәм сөт азыгы өстәлер иде.

Әйе, ашлыкны сөткә, иткә, майга әверелдерү шулай ук җиңел эш түгел. Терлекләр белән эшләү икмәк үстерүгә караганда бәлки авырraктыр да әле. Чөнки терлекчелектә урак өсте 365 көн дәвам итә, конвейер ел әйләнәсе эшли. Монда тере организм белән эш итәргә, һәр терлекнең җаен, характерын белергә, карарга, ашатырга, тәрбияләргә, дәваларга кирәк... Ә азык та җитәрлек булмаса... Никадәр өстәмә мәшәкатьләр китерә ул терлекчегә.

Беренче шарт итеп терлек азыгын кую очраклы хәл түгел. Аның күләме генә түгел, сыйфаты да төп таләпләргә җавап биргәндә генә мул продукция алып була. Шул чакта гына бер центнер азык берәмлегеннән бер центнер сөт җитештерергә мөмкин. Терлек азыгын җитәрлек һәм яхшы сыйфатлы итеп хәзерләү буенча әле күп эшләргә, тырышырга кирәк. Ә өйрәнү өчен тәҗрибә бар. Алдынгы хуҗалыкларда терлек азыгын үстерә дә, аны яхшы сыйфатлы итеп ала да беләләр. Аларда сугарулы болын һәм көтүлекләрнең торышы, үлән составы төп таләпләргә җавап бирә, сугару эшләре фәнни нигездә алып барыла. Мул азыкны үз вакытында җыеп алу өчен техника да, үз эшен җиренә җиткереп башкаручы кадрлар да бар.

Терлекләрнең продуктлылыгына кагылышлы тагын бер мисалга тукталыйк. 1982 елда без сыерлардан сөт алу буенча моннан ун ел элек ирешелгән дәрәҗәгә җиттек. Дөресрәге, үзебезне үзебез куып тоттык — һәр сыерның продуктлылыгы 2 361 килограмм тәшкил итте. Ә бит шул ук вакытта, инде әйткәнемчә, өч мең килограммга ирешкән һәм шуңа якынлашкан районнар, дүрт мең килограмм чиген үткән хуҗалыклар да шактый республикабызда. Районлашкан «Холмогор», «Бестужев», «Кара-чуар» токымлы терлекләрнең генетик мөмкинлекләреннән тулы файдаланганда, һәр сыердан уртача 3,5—4 тонна сөт алырга мөмкин. Шуны истә тоткан хәлдәме, авыл хуҗалыгы белән кызыксынучы кайбер язучыларыбыз, журналистлар бәхәсле сорау куялар: республикабызның колхоз һәм совхозларында 410 мең сыер асраганчы, шуның 300 меңен генә калдырып та, Азык-төлек программасында каралган сөтне җитештерергә, шуның бер миллион тоннасын дәүләткә сатарга мөмкин түгелме соң? Болай өстән генә караганда, алар хаклы да кебек. Өстәмә 110 мең баш сыерны асрау шактый кыйммәткә төшә. Бу терлекләрне саву өчен дүрт мең савымчы һәм шуның кадәр үк терлек караучы таләп ителә. Башка төр ярдәмче эшләрдә катнашучыларны да исәпкә алсаң, кимендә ун мең кешенең кулы бәйләнгән. Моның өстенә һәр сыерны туйдыру өчен кимендә ике гектарда терлек азыгы үстерергә, җирен сөрергә, чәчәргә, җыярга, хәзерләргә кирәк. Барысы 220 мең гектар! Ә никадәр торак төзергә кирәк? һәр терлекне тоту урыны ике мең сум. Барысы 220 миллион сумлык «түбә» таләп ителә. Бу өстәмә сыерлар әнә күпмегә төшә!

Үзебезгә үзебез проблема тудырабыз түгелме? Өстәмә эшче көчләр каян алырга?

Әмма мәсьәләгә болай бер яклы гына килү дөрес булмас иде. Азык-төлек программасындагы бурычларны уңышлы башкарып чыгу өчен безгә шул 410 мең баш сыерның һәрберсеннән елына кимендә 3100 килограмм сөт алырга кирәк. Ягъни, терлекнең баш санын да саклау һәм шул ук вакытта аларның продуктлылыгын да кискен арттыру таләп ителә. Моның өчен мөмкинлекләр бар — тик резервны хәрәкәткә китерергә, һәр җитәкчедән, һәр белгечтән үз эшен намус белән башкаруны таләп итәргә кирәк. Максатка ирешү өчен эшне балтачлылар кебек, «Восточный» совхозы савымчылары һәм башка бик күп алдынгылар кебек интенсив нигездә оештыру һәм алып бару зарур.

Аннары бит без сыерларны сөт өчен генә түгел, ит өчен дә асрыйбыз! 110 мең баш сыер — ул кимендә йөз мең бозау, ә ел ярымнан — 38—40 мең тонна ит дигән сүз. Бу да Азык-төлек программасында каралган.

Интенсивлаштыру — Азык-төлек программасында каралган төп бурычларның берсе. Ул аз чыгымнар белән күбрәк продукция җитештерүне күздә тота. Шуңа күрә производствоның нәтиҗәлелеген күтәрү буенча бүгенге көн проблемаларын хәл иткәндә, киләчәк көннәрнең максатын ачык күз алдында тоткан хәлдә, һәр көнне, һәр нәрсәдә сан ягыннан гына түгел, сыйфат ягыннан, нәтиҗәлелек ягыннан уңышка ирешергә омтылырга, акыл белән, һәр тиенне санап эшләргә өйрәнергә кирәк.

Сүз дә юк, азыгы җитәрлек, малларның нәсел сыйфаты яхшы булган, кул хезмәтен күп таләп итүче эшләр механикалаштырылган хуҗалыклар һәр елны терлекчелектән мул продукция алалар, сөт җитештерү дә табышлы тармак булып әверелә. Терлекчелек тармагын үстерүдә дәүләтебез хуҗалыкларга гаять зур булышлык күрсәтте, сатып алу бәяләрен камилләштерде, шуның исәбенә генә дә республикабыз хуҗалыклары миллионнарча сум өстәмә табыш алдылар. Моны без партиябезнең май (1982 ел) Пленумы карарларының уңай йогынтысы, анда эшләнгән чараларны тормышка ашыруның күркәм нәтиҗәсе дип карыйбыз. Әмма безгә, ирешкән нәтиҗәләргә ныграк таянып, бөтен резервларны эшкә җигеп, табыш белән эшләргә, заман таләпләре югарылыгында хуҗалык итәргә өйрәнергә кирәк.

Бу юнәлештә үрнәк эшләр, хуҗалык итү культурасы үскән колхозлар, совхозлар безнең республикабызда инде бар. Табигать, һава шартлары тудырган кыенлыклардан сабак алып, күп кенә хуҗалыкларның җитәкчеләре, белгечләре җирдә эшләргә чын мәгънәсендә остардылар. Үткән урып-җыю чорын гына алыйк. Йөзәр мең гектар мәйданда иген суктырган көннәр, ашлык кабул итү пунктларына, беренче тапкыр буларак 75 мең тонна ашлык чыгарылган тәүлекләр булды. Зеленый Дол игенчеләре, беренчеләрдән булып, урып-җыюны кыска срокта үткәрүнең һәр гектардан өстәмә центнерлар бирүенә нык төшенеп, һәр комбайнга җөгәрне 92 гектарга җиткерделәр, агрегатларның көнлек югары җитештерүчәнлегенә ирештеләр, югалтуларга юл куймадылар. Нәтиҗәдә, район игенчеләре тарихта беренче тапкыр буларак, бөртекләрнең һәр гектарыннан 23,2 центнер уңыш җыеп алдылар, традицион икмәк үстерүче районнарны, Тукай районыннан кала, шактый артта калдырдылар. Димәк, уракны ике атнада төгәлләү өчен бездә мөмкинлекләр бар. Алдынгы тәҗрибәне һәр хуҗалыкта, һәр районда кулланганда, Татарстан икмәк тапшыру чорында көнлек графикны йөз мең тоннага җиткерә ала дигән сүз.

Билгеле, һәр төр эшне кыска срокта, сыйфатлы итеп башкару өчен хезмәт ресурсларының җитәрлек булуы шарт. Бүген республикабыз

халкының 32 проценты авыл җирендә яши, 9 проценты турыдан-туры авыл хуҗалыгы производствосында катнаша, икмәк, ит, сөт һәм башка төр продукция җитештерә. Ризык муллыгы булдыручыларның саны елдан-ел кими бара. Димәк, крестьян хезмәтен тагын да интенсивлаштыру таләп ителә. Бу проблемага ике позициядән торып — бүгенге көн таләбеннән һәм киләчәккә карап — якын килү дөрес булыр. Бүгенге көн проблемасы — эшче куллар турында, аларның җитәрлек булуы турында кайгырту, ә иртәгәсе көнneке — һәр кешенең югары җитештерүчәнлегенә, ферма һәм кырларыбызда эшләүчеләрнең эффектлы эшләвенә ирешү.

Азык-төлек программасының иң көчле, иң мөһим якларыннан берсе шунда, ул шәһәрне туклану продуктлары белән тәэмин итү һәм авылның көнкүреш шартларын кискен күтәрү кебек ике әһәмиятле бурычны бер-беренә бәйле рәвештә хәл итүне күз алдында тота. «Авылда торак, культура-көнкүреш объектлары, юл төзү эшләре белән никадәр колачлырак, төплерәк шөгыльләнсәк, крестьян хезмәте шул кадәр җитештерүчән булачак», диелгән иде КПСС Үзәк Комитетының май Пленумында. Сиксәненче елларда шушы максатка илебез күләмендә 160 миллиард сум билгеләнүе очраклы хәл түгел.

Социаль мәсьәлә бүген безнең өчен иң өлгергән, иң мөһим, иң кискен мәсьәләләрнең берсе. Соңгы унике елда гына да, республикабызның халкы арта барган вакытта, авыл халкы 394 мең кешегә, ә узган бер ел эчендә 33 меңгә кимеде. Авылдан күбесенчә яшьләр, нигездә кызлар китә. Шулай итеп, «киленнәр проблемасы» барлыкка килде. Әгәр дә моннан ун ел элек авыл хуҗалыгында эшләүче хезмәткә яраклы кешеләрнең 52 проценты хатын-кыз булса, бүген ул 42 проценттан артмый. Шунысы характерлы, авылдан китү культура-көнкүреш, медицина хезмәте күрсәтү түбән булган, мәктәп һәм йорт-җир белән тиешенчә тәэмин ителмәгән төбәкләрдә социаль мәсьәләләр яхшы хәл ителгән хуҗалыкларга караганда 1,6 тапкыр күбрәк.

Әгәр дә миграция процессы әлеге темплар белән дәвам итсә, 1990 елда авыл халкы бер миллионнан да кимиячәк. Мондый күренеш, колхоз һәм совхозларның яртысыннан артыгы эшче көчләр белән тулы тәэмин ителмәгән бер вакытта, мәсьәләне тагын да катлауландырачак.

Шуңа күрә партия өлкә комитеты авылда социаль мәсьәләләрне хәл итүне бүгенге көндә тормышка ашырылырга тиешле кичектергесез бурыч итеп куя. Бу мәсьәлә КПСС өлкә комитетының 1983 елның октябрь аенда булып үткән Пленумында бөтен тулылыгы белән каралды һәм аны хәл итүдә мөһим чаралар билгеләнде.

Авылны социаль үзгәртеп кору максатында соңгы елларда гына да төзелеш эшләрен алып бару өчен өстәмә 20 оешма барлыкка килде. Хәзер һәр районда дәүләт һәм колхозара подряд оешмалары эшли, күп кенә төзелеш эшләре колхоз һәм совхозларның үз көчләре белән башкарыла.

Республикабыз авылларында торак йортлар төзү шактый колач алды. Соңгы 18 ел эчендә генә дә авыл җирләрендә 7 миллион квадрат метрдан артык торак файдалануга тапшырылды. Күп кенә совхоз эшчеләре, колхозчылар, белгечләр — нигездә яшьләр, — көнкүреш уңайлыклары булдырылган йортларга күчтеләр. Гомумән, авылда төзелеш эшләре елдан-ел киңрәк колач җәя бара.

Соңгы ике ел ярым эчендә генә дә республикабызның авыл төзелешендә 700 миллион сумлык төзү-монтаж эшләре башкарылды, шул исәптән 37 терлек комплексы, Брежнев шәһәрендә катнаш азык җитештерү заводы, Тукай, Лаеш районнарында кошчылык фабрикаларының яңа куәтләре, Буа һәм Борындык элеваторы, 800 мең квадрат метр торак йорт төзелде. Авыл җирендә торак фонды 14,5 миллион

квадрат метрга җитте. Бу һәр кешегә 12 квадрат метр туры килә дигән сүз.

Республикабызның күп кенә районнарында дәүләт исәбенә, бөтен коммуналь шартлары булган, бүгенге көн таләпләренә җавап бирә торган поселоклар калкып чыкты. «Гигант», «Майский», «Красный ключ», «Ворошилов» совхозларының, Биектау районы «Урак һәм Чүкеч» колхозының үзәк усадьбалары әнә шундыйлар. Хәзерге вакытта Балык Бистәсе районының «Масловка», Тукай районының «Чаллы» совхозларының үзәк усадьбалары, Зеленодольский районының Осипово авылы, «Юбилейный» кошчылык фабрикасы поселоклары авыл архитектурасының соңгы казанышларын исәпкә алып төзелә.

Авыл төзелешендә беренче адымнар ясаганда кайбер хуҗалыкларда күп катлы йортлар төзү белән мавыгу очраклары да булды. Болай эшләп, өченче, бишенче катка күтәреп, дөресен әйтергә кирәк, без крестьянны җирдән аердык. Аның квартирасында барлык шартлар да тудырылган, әмма терлек, кошлар, асрау өчен каралтысы-җире юк. Дөрес, хәзер аңа кайдадыр читтәрәк участок биргәннәр. Ә менә сыердан бер аерылгач, колхозчы яки совхоз эшчесе сөтне читтән сатып алырга мәҗбүр. Бу, билгеле, социаль проблеманы уңай хәл итү түгел.

Моны истә тоткан хәлдә, республикабыз хәзер нигездә усадьба тибындагы авыл йортлары төзүгә юнәлеш алды. Мондый йортларда яшәү шартлары шәһәр йортларыннан ким түгел. Кайбер хуҗалыкларда йортларны ике яссылыкта төзү практикага кереп бара. Кайберәүләр савымчыга яки механизаторга йортны нигә ике этажлы итеп төзергә, нәрсәгә ул аңа? — дигән сорау куялар. Ә нигә төземәскә? Механизатор, терлекче — безнең алтын фондыбыз. Аларга әле бәлки өч яссылыкта төзергә кирәктер. Бер катында әти-әниләре, икенчесендә балалары, ә өченчесендә оныклары яшәсен. Бөтен шартлары тудырылган, бөтен якыннары янәшә генә булган мондый йорттан беркем дә шәһәргә китмәячәк.

Аннары бит без йортларны дүрт-биш ел өчен генә төземибез, анда инде егерме беренче гасыр кешесенә яшәргә туры киләчәк. Алар алдында да безнең буынга шулай ук кызарырга туры килмәсен.

Йортларның проектын сайлап алу, авыл җирендә производство төзелешләрен, торак йортларны, культура-көнкүреш объектларын кайда урнаштыру мәсьәләсе буенча авыл Советлары, хуҗалык җитәкчеләре бик җитди шөгыльләнергә тиешләр. Архитекторларның нинди дә булса «гадәттән тыш матур» проектын көтеп ятмыйча, үз башыңны эшләтергә, колхозчылар, совхоз эшчеләре белән киңәшеп, чын мәгънәсендә иҗат итәргә кирәк. Шул чакта авыллар бер-берсенә охшаш, игезәк булмаслар, күңелне җәлеп итеп торырлар.

Татарстандагы авылларны үзгәртеп кору буенча эш, билгеле, бүген генә башланмады. Иң элек колхозларның һәм совхозларның үзәк усадьбаларын яңарту, төзү буенча төзелеш эшләре алып барылды. Чөнки крестьянның күпчелек өлеше шунда яши, төп эшче көчләре шунда тупланган. Үзәк усадьбаларда беренче чиратта ферма һәм комплекслар, машина утарлары, мастерскойлар, 1966—80 елларда 130 мең урынлы клуб һәм культура йортлары, 187 мең урынлы 677 мәктәп һәм 17 мең урынлы балалар бакчалары, больницалар төзелде, хуҗалык үзәге урнашкан авылларны яхшы юллар тоташтырды. 1971—80 елларда гына 116 колхоз һәм совхоз үзәкләренә асфальт юллар сузылды. 683 хуҗалыкның, ягъни барлык колхоз һәм совхозларның 84 процентында хәзер үзәк усадьбаларга әйбәт юллар бар. Кайда гына барып чыксак та, колхоз-совхоз үзәкләренең күренеше, андагы шартлар начар түгел.

Әмма шул ук вакытта кайбер төбәкләрдә, производство объектларын, торак йортлар, культура-көнкүреш объектларын төзүне бер урын-

га гына туплау белән мавыгып, башка авылларны перспективасыз авыллар рәтенә кертеп, алардагы халыкны күчерү эшен алгы планга куйдылар. Читтәрәк урнашкан бу авыллар ничектер үзәктән аерылдылар. Ә бит авыл тормышының тамыры — шул авылларда. Аларда күңелле, тату гаилә булып Татарстан туфрагын үз иткән төрле милләт вәкилләре — җиргә бөтен күңеле белән бирелгән чын игенчеләр, чын терлекчеләр яши. Нигә без аларны урыннарыннан кузгатабыз, тамырларыннан аерабыз?..

Соңгы җиде елда күп кенә авыл күчте. 1983 ел башына республикабызда 3 406 авыл калды. Аларның да шактый өлеше «перспективасы булмаган», ягъни күчерелергә яисә бетәргә тиешле авыллар исәбендә йөрде. Әмма мондый караш бүгенге көн таләпләренә җавап бирep бетерми. Май Пленумы карарлары яктылыгында бу мәсьәлә җентекләп өйрәнелә һәм тиешле чара күрелә. Колхоз һәм совхозларыбыз территориясендә урнашкан барлык авыл һәм поселоклар безгә кадерле.

Авылны социаль үзгәртеп кору буенча башкарылган төзелеш эшләре бүгенге көн таләпләренә җавап бирми әле. Бигрәк тә индивидуаль төзелеш эшләре нык кимеде. Бу юнәлештә халыкка индивидуаль йортлар төзүдә зур булышлык кирәк. Колхоз һәм совхоз җитәкчеләреннән, республика оешмаларыннан индивидуаль торак төзелешенә карашны үзгәртү таләп ителә.

Авылларны социаль үзгәртеп кору, һәр коллективны Азык-төлек программасын уңышлы хәл итәрлек шартлар белән тәэмин итүдә эшлисе эшләр байтак әле. Унберенче һәм уникенче бишьеллыкта авыл төзелешенә юнәлдерелә торган средстволар үткән ике бишьеллык белән чагыштырганда 2,5 тапкыр артачак. Социаль бурычларны хәл итү өчен бу кадәр средствоның безнең республикабызда бирелгәне юк иде. Дәүләт һәм колхозлар исәбенә 1984—1985 елларда гомум мәйданы 600 мең квадрат метр булган торак йортлар төзеләчәк. Урман хуҗалыгы министрлыгы колхозларга һәм совхоз эшчеләренә ел саен ике меңгә якын бура әзерләп сатачак.

Төзү индустриясе предприятиеләре җыелма тимер-бетон һәм столярлык әйберләре, стеналар өчен газобетон блоклар эшләячәкләр. «Татстройбыт» тресты, «Татколхозстрой» берләшмәсе һәм «Татсельстрой» идарәсе авылда шәхси йортлар торгыза башладылар инде. Авыл төзүчеләрен проект документлары, цемент, кирпеч, агач, шифер һәм башка кирәк-яраклар белән тәэмин итү буенча да эшлекле чаралар күрелде. Киләчәктә ел саен авыл җирендә һәр колхоз, совхозда уртача унҗидешәр квартира төзергә мөмкинлек бирәчәк.

Авылда үзләренең шәхси йортларын булдырырга теләүчеләр өчен партия һәм хөкүмәтебез тарафыннан төрле льготалар, уңайлыклар каралган. Андый кешеләр Дәүләт банкыннан ссуда алып, колхозлары, совхозлары ярдәмендә, йорт салалар. Алынган ссуда төзелеш эшләре тәмамланганнан соң 25 ел дәвамында кире кайтарыла, ләкин 50 проценты гына. Ә калган өлешен түләүне колхозлар яки совхозлар үз өсләренә алалар.

СССР Министрлар Советы үзенең 1983 елгы карары белән колхоз, совхозларга дәүләт яки үз исәпләренә төзелгән йортларны үзләрендә эшләүчеләргә ярты бәясенә генә сатарга рөхсәт итте. Шунысы мөһим, шул ярты бәясен дә сатып алучы 25 ел дәвамында түләячәк.

Юллар төзү эшен дә нык җанландырасы бар, чөнки юл — авылны социаль үзгәртеп коруның иң мөһим чараларының берсе. Бу бишьеллык ахырына барлык колхоз һәм совхозларның да үзәк усадьбаларын яхшы юллар белән тоташтыру, ә уникенче бишьеллык ахырына хуҗалык эчендәге юллар төзүне тәгәлләү бурычы куела. Моның өчен безгә 1990 елга кадәр 3200 километрдан артык өсте каты юл төзергә

туры килә, шуның 1500 километры хуҗалык эчендәге юллар булачак.

Социаль һәм культура-көнкүреш төзелеше буенча алда зур эшләр тора. 1990 елга кадәр 63 мең урынлы мәктәп, 26 мең урынлы мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре, 50 мең урынлы клуб һәм культура йортлары төзеләчәк, колхоз һәм совхозлардагы поселокларны тулысынча үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү, барлык йорт һәм квартираларга газ кертү эшләре тәгәлләнәчәк.

Бу юнәлештә башланган эшләр уңышлы гына дәвам итә. Унберенче бишьеллыкта гына, мәсәлән, 90 мәктәп, 107 мәктәпкәчә балалар учреждениеләре, 10 аптека, 70 культура йорты һәм клублар төзелде. Авыл җирендә хәзер 2 500 культура йорты һәм клуб, 1 400 китапханә, музыка һәм сәнгать мәктәпләре, студия һәм халык театрлары эшли, авылга культура хезмәте күрсәтүдә 4,5 мең әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре катнаша. Шулай итеп, авылны социаль үзгәртеп кору юнәлешендә дә эшләнгән эшләр, уңышларыбыз бар. Әмма эшлисе эшләр тагын да зуррак, тагын да җаваплырак.

Азык-төлек программасын хәл итүдә әдәбият һәм сәнгатебез, язучыларыбыз, композиторларыбыз, рәссамнарыбыз алдында гаять зур бурычлар тора. Авылга йөз белән борылырга, шуның эчендә кайнарга, чынбарлыкны, киләчәгебезне реаль яктыртырга, ышандырырлык итеп ачарга кирәк. Авылларыбызның, колхоз һәм совхозларыбызның бүгенге торышы, аларның кадрлар, эшче көчләре белән тәэмин ителүе, миграция процесслары һәм башка социаль, экономик үзгәрешләргә әдәбият һәм сәнгатьнең йогынтысы аз булмады. Авыл яшьләренең производство һәм тормышыбыз таләп иткән һөнәрләр сайлавына ирешүдә язучылар, сәнгать эшлеклеләре дә зур өлеш кертә алалар.

Без тормыш белән әдәбият арасындагы элементләрне ныгыту турында сөйләргә яратабыз. Әдәбият-сәнгать әсәрләренә бәя биргәндә төп критерий итеп бүгенге чынбарлыкның матур әдәбият әсәрләрендә дөрес яктыртылу дәрәҗәсе алына. Минемчә, бу гына җитми. Матур әдәбият әсәрләренә бәя биргәндә аларның бүгенге тормышыбызга, производство атмосферасына ни дәрәҗәдә йогынты ясавын да исәпкә алырга вакыт түгелме икән? Әйтик, татар әдәбияты соңгы елларда авыл эшчәннәренең кызыклы гына образларын тудырды. Ә алар авыл кешеләренең рухи яктан камилләшүенә ничек йогынты ясыйлар? Механизаторны, терлекчене, авыл яшьләрен тормышыбызның иң мөһим проблемаларын хәл итүгә туплардай, үз артыннан ияртердәй уңай әдәби геройларыбыз күпме соң безнең?

Язучыларыбыз, рәссам һәм композиторларыбыз, театр һәм кино сәнгате эшлеклеләре алдында бүген яңа, үткән чорлардагыдан күп ягы белән аерыла торган бурычлар тора. Заманыбызга тиң темплар белән үсүче авыл кешесе чынбарлык куйган мәсьәләләрне тормышчан коллизияләр, тирән эчтәлекле образлар аша яктыртуны таләп итә. Ул әдәбият һәм сәнгать әсәрләрендә үзен, замандашларын гына түгел, социалистик авылның киләчәген тасвирлаган, аны рухи яктан баетырлык үрнәкләр дә күрергә тели.

Илебезнең Азык-төлек программасы туксанынчы елларны күз алдында тотып эшләнгән булса да, анда без тагын да ераграк киңлекләрне, мактаулы һәм авыр юлның яңа чакрымнарын күрәбез. Шуңа күрә бүгенге эшләрне, бүгенге бурычларны хәл иткәндә ераграк перспективаларны күз алдында тотабыз, социаль-экономик үсеш компасын киләчәк җиңүләр ягына юнәлтәбез. Ә ул җиңүләрне якынайту өчен һәркайсыбызга — игенче һәм терлекчегә дә, галимгә һәм төзүчегә дә, нефтьче һәм язучыга да — илебезнең куәте һәм чәчәк атуы өчен икеләтә энергия белән эшләргә, иҗат итәргә кирәк. Безнең буразналар Бөек Ватанның уртак иген басуына кушылалар. һәм һәркайсыбызның фидакарь хезмәт җимешләре ил табынын баетуга өлеш булырга тиеш.

## Сибгат Хәким

# КҮГИ

ПОЭМА

I

Күги — мари көтүчесе.
Килде бер җыр күңелгә,
Багышларга булдым аны
Истәлеккә Күгигә.
Ватан сугышына чаклы,
Мин, Казан студенты,
Сагынып кайткан елларда
Нигезне — иске йортны,
Иртән бер әйләнеп чыккач,
Киме базарын күреп,
Йөрдем су буйлап болында
Теге Базаров кебек.
Йөрдем көтүдән көтүгә,
Сый-җырларыма карап.
Белдем хуҗасы кемлеген
Сыерларына карап.
Тукталып Касыйм, Гыйлемхан,
Барый көтүләренә,
Аннан барып чыга идем
Мари көтүләренә...
Артымда татар зираты,
Мәктәбем, өйләр рәте...
Алдымда чиркәвә русның,
Мариның кирәмәте.
Әйтерсең узган ачлыктан
Бирле юк җим күргәне,
Канаты салынган коштай
Урдә җил тегермәне.
Татар һәм мари чигендә
Эченнән таллыкларның
Җырларын тыңладым шунда
Улина, Тарлюкларның...
Акты күп сулар, күп еллар,
Моңа хәзер күп инде.
Очрата идем болында
Шунда белеш Күгине.
Сузылып учак янында,
Сөйләшеп Күги белән,
Сөйләшеп бу якның серле
Бала чак күге белән,
Сөйләшеп карт таллар белән,
Текәлеп аккан суга,
Текәлеп утта сикергән
Чәйнекнең капкачына,
Уздырдык көнне, мари ул
Кырыс һәм тырыш адәм:
Эчеп чәй барлык болыннар
Аңкыган кружкадан,
Уздырдык көнне болында,
Мин, Казан студенты,
Яшьлек, мәхәббәт кабызган
Бәхетле эчкә утны
Шигырьгә салган елларда,
Әйе, бер күрү белән
Дуслаштым урман, табигать
Баласы Күги белән.
Ярыштык телдә, рифманы
Башласам «акча» белән,
Акчага акча дигән күк
Бетерде «укса» белән.
Син, дидем, минем замандаш,
Син, дидем, минем чордаш.
«Чордаш»ка җавап шикелле
Каршыма басты чодраш.
Чодраш ул — урман, төп йорты
Тарихта үгиләрнең,
Кайчандыр шушы якларга
Куылган Күгиләрнең
Сыенган урны ул — чодраш.
Анда кем соң кумнаган.
Чи мари дисә диярләр,
Барыбер чукынмаган.
Сөйләде Күги куркыныч
Әкиятләр күп кенә ул,
Урманын телгә алуга
Әйләнде күкегә ул.

Сөенгән урман, сөенгән
Җәйге таң аны күреп,
Күгинең хәтта тамагы
Күке тамагы кебек.
Кычкырды Күги, караңгы
Ел-гасыр буйларыннан,
Авазы яңгырап Иләт
Елгасы буйларыннан
Кайтты әйләнеп, болында
Тугай саен кәтүләр...
Урман, кирәмәт өстендә
Купты бөтен күкеләр.
Ишетелеп куйды еракта
Бик тоныклык күкрәгән

Тавышлар, әйтерсең, урман
Тора шул күкеләрдән.
Ашаудан туктап шул якка
Борылды бар маллары,
Уянды кебек Күгинең
Борынгы бабалары.
Учакка теләр-теләмәс
Чәердән сагыз тамды,
Карт имән ботагы төсле
Тырнады сагыш җанны.
Кояшның нурлары инде
Киму ягына таба.
Кузгалды көтү... Мин киттем
Киме ягына таба.

2

Бу җирдә миналар кайда
Ятканын күрми бәләм,
Икенче тапкыр Дугада
Очраштым Күги белән.
Яз иде. Кырык өченче
Ел язы. Яшел Дуга.
Мылтыкны тезләргә куеп,
Текәлеп язгы суга,
Утырдык Ерик читендә,
Һаман да җырламактыр,

Ерик ул бәлки безнеңчә
Ерыктыр, ерганактыр.
Авылны искә төшердем,
Сугышны каргап алдым,
Бу җирдә кара миналар
Яз кара каргаларның
Ясаган оясы кебек,
Шартлыйлар, җоннар тузгый,
Юк, җоннар түгел, шул язгы
Һавада җаннар тузгый...

3

Ерик камышлар эченнән
Сызылган бер кыл сыман,
Сугышкан ике пәһлеван
Арасына кысылган
Әйтерсең өченче кеше...
Уртасыннан Дуганың,
Икегә бүленгән, ике
Капма-каршы дөньяның
Ага уртасыннан Ерик,
Җырлап бөек заманын,
Алда сыналасы көне
Утта Дуга-даганың.
Һәркайсын таный күк Ерик,
Батып язгы чыкларга,
«Тел» эзләп, көн дә шушыннан
Узган разведчикларга
Кала хәерле юл теләп.
Яз әле, бата кырлар...
Фронт штабыннан башлап,
Полклар, батальоннар

«Тел» көтә... Шундый саф,
чиста,
Нәкъ сабый инде Ерик,
Карасаң, келт итеп искә
Төшә кадерле ирек.
Кайталар арып, «тел» алып,
Ике яктан мылтыклап,
Кайталар алып, яралы
Иптәшләрен култыклап.
Кичеп миналы кырларны,
Я сөйрәп аркасында,
Я сөйрәп шунда солдатның
Плащ-палаткасында,
Кайталар алып көрәштәш
Дусларын бәһа-ирләр,
Сталинградта, Дугада
Яралган баһадирлар...
Үзем дә күп күрдем, ләкин
Алар батырлыгына
Сокландым, алар алдында
Баш иде үзе Дуга.

4

Алдынгы сызыктан алда
Шырпыны сак сызып та
Өскә туплар уты алган
Сугышчан сакчылыкта
Күп булдым. Ике сакчылык
Уртасында, бушлыкта,
Тик сусэн, кылганнар үскән,
Хәтта җәнлек, кош-корт та
Читләтеп үткән бушлыкта
Күп булдым, кабер төсле

Шәп-шәрә, аксыл сусэннәр
Тоташ бер кәфен төсле.
Кылганлы шушы араны
Ялгыш атлап чыгудан
Сакла, язмышым, сакла син
Җанымның бушлыгыннан.
Алгы пост... Ватан куйган пост...
Анда бер салкын, җылы...
Ул минем иҗатның да бит
Сугышчан сакчылыгы...

5

Алда, бишенче июльдә
Дошман танкларыннан
Тип-тигез булыр бу ярлар,
Ерик таллыкларыннан
Бернәрсә калмас... Әле яз...
Чыккач та көйри үлән...
Яшьлегем дусты, фронтташ
Снайпер Күги белән,
Юып аяк чолгауларын,
Буш арада, таллыкта,

Киек казлар өне килгән
Кыска, шомлы тынлыкта
Утырдык Ерик читендә,
Яшь бөреләр зиректә,
Алда Дуга үзәгенә
Әйләнәчәк Ериктә
Очраштырыр әле язмыш,
Мылтыгын, кулын изи.
Кычкырам Ерик ярыннан:
Чиверын — сау бул, Күги.

6

Солдатның сугышта нидән
Кәефе кырылганын
Кем әйтер? Сугыша, диярләр.
Ял итми Кырымда ул.
Сөйләшми, боек, төшенке,
Ниндидер авыр халәт.
Сырхаудыр? Авырмый солдат,
Я герой, яки һәлак...
Юк монда иркәләр кешең,
Юк монда атаң, кодаң...
Чыккандыр бәлки уңышсыз
Һөҗүмнән, атакадан?
Бар төрле вакты солдатның
(Кемнәрне очратмыйсың),
Тоттыр шул чакта солдатка
Хатның өчпочмаклысын,
Баласын кочаклаган күк
Кочаклар, ике кояш

Уйнар йөзендә, тураер,
Башта пилотка кыйгач.
Бар төрле вакты солдатның,
Җор, шаян чагын күрдем,
Иптәшен күмгәч, далада
Җылаган чагын күрдем.
Бар төрле вакты солдатның,
Тезләнеп брустверга,
Бирелеп, орынып тәмам
Маңгае белән җиргә,
Күрдем нәрсәдер укуын,
Борчыймы җан сыкравы?
Очканда тирә-юнендә
Туп, мина ярчыклары,
Ни укып үзен юата?
Киткән күк сәҗдәгә ул,
Бу канлы мәхшәр эчендә
Табына нәрсәгә ул?

7

Бар төрле солдат, динлесе,
Бар күке шикеллесе,
Моңлысы, урманнар кошы,
Шул Күги шикеллесе.
Сугыш, билгеле, фаҗига,

Торса да фаҗигадан,
Әйтмә, укучым, солдат дип
Боеккан да җылаган.
Бушаса бераз, баянны,
Тальянны ала кулга,

Берничә минутка шунда
Таңнарны ала кулга.
Курск сандугачларының
Сугыш чоры моңнарын
Сөйли шул тальян, шул баян,
Сәхнәсе зур Дуганың.
Урнаша Ериктә тынлык,
Яз биткә сынап карый,
Солдатлар күңел кылында
Разведка ясап карый.
Җавап бирерме дошман як
Авыз гармуны белән?
Гармуны гармун, ә үзе
Явыз барлыгы белән.
Чыдамый, көнләшә фриц,
Узыша ике сәнгать,
Ярыша кайчак сугышта
Үзешчән ике сәнгать.
Фриц авыз гармунында
Үзенчә зеңелдәтә.
Җиңелсә, ярсып ачудан
Көн буе дөпелдәтә.
Төрлесен күрдем солдатның;
Бераз җир киптергәчтен,
Ясап киндердә, эңгердә
Өстерәп Гитлер рәсмен
Күрдем мин алып барганын
Ике яшь снайперның,
Миналар өстенә яшел
Үләннәр үскән кырның
Түренә атлады алар,
Аларның берсе Күги,
Ул минем взвод урнашкан
Ериктән үтеп йөри.
Мәскәү һәм Сталинградның
Кырларыннан бу рәсем;
Сөйрәде алар җир буйлап
Гитлерның күләгәсен.
Шуышты җирдән шәүләсе.
Кайда ул үткән даны!
Дошманның алгы сызыкта
Торган ут нокталары
Каршына китереп элделәр,
Элделәр полотноны.
Мин шаһит, шаһит бу кырлар
Һәм Дуга наратлары.
Яшел наратлар эченнән
Кара мыегы Гитлерның
Тырпайды, язның бар яме
Югалды, я, ник элдең?
Тұрар таң... Ачык билгеле,
Калганы безгә хәер...
Уянып, куркудан фриц
Кычкырыр: Гитлер, хайль!
Үрмәләр наратка, читтән
Күзәткән снайперга
Бик уңай фрицне теге
Дөньяга озатырга.
Төшкән наратның төбенә
Күләгәсе киндернең.
Шулай каршылады Күги
Туган көнен Гитлерның...
Бу рәсем — Күги тапкан эш.
Үзенә газап кына.
Күгине үлем уены
Тартты үз азартына.
Узды Ерик күпереннән,
Бүген дә узды Күги,
Мылтыгын өскә күтәреп,
Марича дәшеп юри.

8

Яз иде, кырык өченче
Ел язы, блиндажда,
Посттан бушаган солдатлар
Чумып уйга беразга,
Сүз кузгаттылар: бу сугыш
Җимерде илне, юньсез,
Булмасын иде кабат дип,
Кимендә илле елсыз.
Татлы соң солдат хыялы.
Йөрәк ник ярсымасын,
Диделәр шаккатып шунда:
Илле ел... Ярты гасыр!..
Кайтсалар исән, аларны
Берсе дә итмәс үги.
Әйтик, син мари туена
Очрасаң юлда, Күги?
Эләксәң мари туена,
Инде өеңә шуннан
Кайту юк, уртага сине
Көчле өермә сыман
Бөтерер, авыл башында
Купкан янгын-утка син
Эләктем диген, тик җырла,
Юк бисмилла, юк амин,
Утны көчәйткән хәмер-җил
Хисләрне ялгап бара,
Көчә туй — ялкын бер өйдән
Бер өйгә, ялмап бара.
Урамда утыз йорт икән,
Беткәнче туйга шунда;
Тына бәрелеп туй-давыл
Соңгы йорт коймасына...

Хыялда туй итә Күги,
Кулына коймак тоткан:
Илле ел!.. Юк, диде алты
Көпшәле минометлар...
Илле ел, диде солдатлар,
Тынып торып бер мәлгә,
Тыныч тормышның кадерен
Белеп бетермәгәнгә

Үкенде алар, кадере
Үсте һәртөрле эшнең.
Мең гафу — хатыннарының
Калган хәтерә өчен...
Яз әле. Кырык өченче
Ел язы, яшел Дуга.
Иттеләр карар солдатлар:
Кимендә илле елга...

9

Ул нинди блиндаж, землянка—
Землянка мичләресез,
Ул нинди сугыш: батырлык,
Легенда, истәлексез.
Тиз генә ташлыйкмы алып,
Сызыйкмы шуны чуттан;
Көрәкнең очы тиюгә
Пылт итеп суы чыккан
Калинин җирен онытыйкмы,
Булып бер көчле ташкын,
Шул җирнең өстеннән узган
Йөз илле җиде частьның
Аяк эзләре эчендә
(Уйлыйм кайчакларымда)

Бардыр югалмас эзләре
Минем аякларның да.
Баткакта, пычракта язын
Һәм көзен интеккәнне
Искә алып, салып дагалы
Шул кирза итекләрне,
Кайнар мич ташына терәп,
Төн буе аякларны,
Фронт юлы кебек тыгылган
Трәмбалы аякларны,
Яшь бала кебек кадерләп,
Бөтенен, яртылашын,
Җылытасы иде бер тапкыр,
Җылытасы ярты гасыр...

10

Сорады берсе, күз алмый
Күгинең көдрәсеннән:
Туктату шушы сугышны
Килә кем кодрәтеннән?
Туры килүе үз уе
Белән менә бу уйның,
Кузгатты хисен, күптәнге
Тонык хисен Күгинең.
Уянды ул хис бары тик
Җай көтеп торган кебек;
Өстенә бастым дигәндә
Уянган тургай кебек.
Атарга җитмәс кодрәте
Җир-табигать күркенә,
Туктатыр сугышны Күги
Әйләнсә шул күкегә.
Туктата иде бит әлек,
Кычкырса күке булып.
Тыңлый, кузгалмый, селкенми
Бит көтү, көтү булып.
Кычкырса түмгәккә кунып,
Урныннан күчә-күчә,
Сыерлар уйлана иде
Ашамый, күшәмичә.
Яз иде. Кырык өченче
Ел язы, Күгигә ул
Соңгы яз, әкренләп аны

Китерде үлемгә ул.
Кычкырды күке нараттан
Наратка куна-куна,
Туктады сугыш, ничәдер
Минутка тынды Дуга.
Кырык... Кырык бер... Саташмас,
Күгиме сакау күке?
Тутырыр иллене, саклар
Җир-суны, саклар күкне.
Булмаса ярар иде дип,
Чиге, бу сан актыгы,
Күги артыннан кабатлап,
Солдатлар санап торды.
Җир-траншея казыдылар
Тын алмый кичкә кадәр,
Сузсаң җитәрлек Мәскәүдән
Владивостокка кадәр.
Иген игәргә сусаган
Көрәк тоткан куллары,
Мондагы солдат ничәмә-
Ничә тапкыр Дуганы
Казып иген чәчәр иде,
Сугыштан коткар, Күги,
Сана туйганчы, бәхетле
Елларны тели-тели.
Кычкырды кырык тугызны...
Бәхет — җир иминлеге...

Яңгыратыр сыман иде ул
Менә-менә иллене...
Күзәткән сугыш-снайпер,
Мылтыгын оста корган,
Илле дип әйтүгә Күги,
Юк, диде, снайперлар...
Көттеләр егылып төшкәнен...
Күги дә, күке дә ул...
Шул соры спай бер кошта
Күпме моң, күпме дәвер...
Көттеләр егылып төшкәнен.
Үлемгә күңел күнми,
Аттылар махсус мылтыктан,
Чыннан да кайда Күги?

Узды яшьлектә мариның
Урманында күп көнем,
Эзләдем кунган агачын
Шунда ялгыз күкенең.
Эченнән кара урманның
Каршыма якты акты.
Очраттым көндез моңаеп
Утырган ябалакны.
Тирәннән агылган якты
Урманны ярып узган...
«Адаша башлар безнең...» дип
Кем җырлап яныбыздан
Юыртты? Таныш түгел, юк,
Монда беркем дә безгә.
Утырды күке еракта
Якты бөркелгән төштә.
Яралган Күги — яшь күке
Шул урман яктысыннан...
Аттылар, тетрәде урман...
Ә якты? Якты сынган.
Күгинең артында басып
Тора кара урманы,
Халкы бөккән һәм турайткан
Ул ничаклы Дуганы.

II

Изге җир Дуга... Барам дип
Юк, әйтә алмыйм хаҗга.
Җан тыныч түгел, сагаеп
Керәм кырыгынчы язга.
Иске ориентирларымны
Күрсәтә атап Дуга.
Керәм Дугага кергән көк
Беренче атакага.
Ак таулар артында яңрап,
Әкренләп сүнгән «Ура»
Тамактан чыгып бетмәгән
Сулышым кебек тора.
Миндә төртелгән «Ура»ны
(Бөек дан — солдат даны)
Алды күтәреп соңыннан
Вьетнам солдатлары.
Палестина чүлләрендә,
Шыр Галан сыртларында
Ул кабатланды, Ливанның
Тын калган йортларында
Йөрде борчулы авазым —
Сахра-чүл, ят илләрнең;
Мәңге төзәлмәс яралы
Сабра-Шатилаларның
Керде хәрабәләренә
Каңгырып, сусап суга.
Рейхстаг стеналарыннан
Әй, бәреп чыккан ура,
Кайда син хәзер? Җанымның
Бер ягын били Дуга,
Икенче ягында аның
Яши Никарагуа.
Керәм кырыгынчы языма,
Борчуым үсә барган,
Үз рухым ирешмәгәнне
Эзләп шул Мусалардан
Йөрсәм дә Европа буйлап,
Җан тынмады, күп дәвергә
Җитәр әрнүем, сыендым
Кайтып ил күкрәгенә.
Бу җирнең күкрәге — Дуга,
Күпергән ястык кебек.
Кая бассам да уңайсыз,
Нәрсәдер язык кебек.
Бүген аякта, сугыштан
Сау-исән калганнарның
Чәчләре кебек башлары
Дугада кылганнарның.
Кылганнар кырда... Плащлар
Җилдә кабара кебек,
Кылганнар монда бездән дә
Тизрәк агара кебек.
Элекке даны Дуганың
Онытылып бара димә:
һәр авыл Прохоровка,
һәр кайсы Бородино!
Үзәге — Прохоровка.
Үзе тик разъезд гына.
Атаклы Бородино көк
Керде ил язмышына.
Прохоровка үзәненә
Мең дә биш йөз танкны
Куды ике як, күзәтеп
Торсын өчен тарихны
Бастырды шунда, әйтерсең,
Тимер паркы елларның

Тупланды шунда, үзәнгә
«Тигр», «Пантера»ларның
Кара күләгәсе ятты,
Ярсыган үгезләрнең
Көтүен өерделәр күк,
Чарпылган мөгезләрнең
Уты чәчрәде үзәнгә.
Июльнең уникесе.
Тик ике шәүлә яланда
Калыкты: үлем-кеше...
Барам шул үзәннәр буйлап,
Гомремнең разъездына —
Прохоровкага, әйтерсең,
Паспортым язды Дуга.
Үземә генә билгеле
Тагын бер билге тора;
Кайнар июлен бу җирнең
Дуга партбилетыма
Теркәде үз кулы белән,
Җырлап мин шул язымны,
Дугадан, бөек еллардан
Санап партстажымны,
Атлыйм, минем яз, без яулап
Алган яз, кырыгынчы.
Кинәт күз алдымда шунда
Үзгәрде кырның төсе,
Урнашты сабырсыз тынлык,
Сызлатты җанны җирсү,
Сагаеп калды наратлык,
Сагаеп калды җир-су.
Җир, арба, ат кебек гади
Кыңгыраулы дугада,
Чуалтып бөтен хисләрне,
Бер өн кебек томанда,
Чыкканда уйланып таңда
Таныш Ерик күперен,
Иске наратлык ягыннан
Тавышы килде күкенең.
Кычкырды күкесе ерак
Мари урманнарының.
Күкесе тыныч язларның,
Бар ил урманнарының.
Санады узган елларны,
Котлады язның башын,
Кычкырды бөтен дөньяга:
Тиздән дип ярты гасыр.
Аттылар, тузгыды урман,
Күренде очкан җоннар,
Икенче континентлардан
Аттылар снайперлар.
Көттеләр егылып төшкәнен,
Кызык снайперларга...
Яңгырады күке авазы
Тагын бер гасыр алга!
Борчылып язмышы өчен
Халыклар, күп илләрнең,
Илтәм хыялын җир буйлап,
Вәкиле Күгиләрнең.

Июль, 1983.

## Барлас Камалов

# ӨМЕТЕҢ ӨЗЕЛМӘСЕН

**РОМАН**

## Шатлык эчендә кайгы



Кунакханә бүлмәсендә тыныч кына телевизор карап утырганда, Илфат Маннуров кинәт тоньк гөрелте ишеткәндәй булды. Гөрелте бик тиз көчәйде, куркынычка әйләнде. Илфатның колаклары тонды, күзләре шартлап чыгардай булып сызлый башлады, чигәләренә ниндидер чүкечләр белән бәреп торалар шикелле иде. Көн яктысы юкка чыкты, тирәюньне дәһшәтле караңгылык басты. Күк гөмбәзенең дөм-кара чыбылдыгын ертып, бер генә йолдыз — Таң йолдызы гына ялтырап күренде. Әмма ул да сүнде шикелле. Ә юк, сүнмәгән. Сүнмәскә тиеш! Өметне өзмик әле...

Аңга килгәч, Илфат төшенде: каһәр чир ябырылуы икән бит бу! Гәүдәсенең уң ягы хәрәкәтсез. Кулы да, аягы да тыңлаусызга әйләнгән, кыймылдамыйлар да. Авызы уң якка чалышайган. Телен әйләндереп сөйләшер җае да калмаган. Ниндидер зәгыйфь авазлар гына чыга түгелме? Күз аллары томанлы. Баш чирәбенә кургашын эретеп тутырганнар диярсең, башны күтәрер дә, хәрәкәтләндерер дә хәл юк.

Илфат гомерендә беренче тапкыр үлемнең ничегрәк килү мөмкинлеген чамалады. Әҗәлнең кешене гел көтмәгәндә якалап ташлавы бик тә ихтимал икәненә инанды.

Уйлана торгач, Илфат аз-азлап бу көннениләр булганын хәтерли башлады.

Республика авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәсендә ул райкомның беренче секретаре Кави Салихович Сәмәрханов белән янәшә утырды. Партия өлкә комитетының беренче секретаре Илфатка Ленин ордены белән алтын «Урак һәм Чүкеч» медале тапшырды.

Бүләкләү тантанасыннан «Татарстан» гостиницасына кайтканда аны алтынчы катның холлында, киң иркен көтү бүлмәсендә, авыл хуҗалыгы институтының дүртенче курсында укучы өлкән улы Варис каршылады. Егет читтәрәк баскан кешеләрдән дә тартынып тормады, әтисен кысып кочаклады да үбеп алды.

— Котлыйм, әткәй, котлыйм! Мең яшә!— Шул сүзләрне әйткәч, ул кинәт тынып калды. Аннары тирән көрсенеп пышылдады.— Әнкәй генә күрә алмады бу шатлыкны...

Икесе дә тамакларына килеп утырган яшь «чумарын» кыенлык белән генә йотып җибәрделәр һәм мәрхүмә турындагы сүзне шунда өзделәр. Ирләр булу кирәк иде.

Бүлмәгә кереп, өс-башны салгач, аулактан файдаланып, Варис кечкенә балалар кызыксынуы белән этисе пинжәгенең түшендәге Ленин орденын һәм Алтын Йолдызны карады. Этисенең беләкләреннән тотып, башын арткарак ташлады, «Урак һәм Чүкеч»нең балкышына сокланды.

— Шәп бит, эткәй, ә?— диде Варис аннары, шатлыгын эченә сыйдыра алмыйча.— Мин дә сиңа охшый алсам икән...

— Бәхетең үз кулыңда, улым!— Илфат та бик сөенә иде, ләкин гадәтенчә сабыр, тыйнак булырга тырышты. Хәер, тырышу түгел, табигый халәте иде ул аның.

Телефон чыңлады. Илфат түр өстәл буена ашыкты. Аның зур гәүдәсе тәрәзәне томалап куйгандай итте. Буйга да озын ул, җилкәсе дә киң. Бәдәне нык. Телефон трубкасы Маннуров кулында балалар уенчыгына әйләнеп калды. Беренче секретарь Кави Салихович шалтырата икән. Кай арада чишенеп өлгергән, ни арада телефонга ябышкан. Шаяра, көлә.

— Әбәд ашап алырга кирәктер безгә, кордаш. Ябыгып кайтсак, районда кабул күрмәсләр,— ди.— Ресторанга төшәбезме? Анда да кеше күп инде... Олы бүләкләрне юмый да ярамый! Минем номерга төшәсеңме әллә?

Райком секретареның бик үз итеп, хөрмәтләп сөйләшүе Илфат күңеленә хуш килде. Механизаторның кара туткыллы итләч йөзенә эчке канәгатьләнү галәмәтләре чыкты. Калын иреннәрендә елмаю күренде. Зур коңгырт күзләрендә шаян чаткылар биешеп алды. Борыны өстендә кушылырга торган куе кашлары да ике чигәгә таба тартылгандай иттеләр. Уң кулына трубканы кыскан килеш, сул кулы белән юкарып калган кара чәчләрен сыпыра-сыпыра җавап бирде:

— Минем студент егет килеп җитте бит, Кави туган. Без икәү диюем. Иренмәсәгез, гаеп итмәсәгез, минем бүлмәгә үзегез менмәссезме рәхим итеп... Бер генә дә ресторанга төшәсем килмәгән иде.

— Сызгырганга йөгереп килүче мин ул,— диде Кави Сәмәрханов, уйный-көлә сөйләнеп.— Варисны да күреп төшәрмен. Биш-алты минуттан, яме...

— Көтәбез, Кави туган!— Трубканы куйгач, Илфат акча бирде дә Варисны буфетка җибәрде.

Ун-унбиш минуттан алар өчәү — ике ветеран һәм булачак инженер-механик — гөрләшеп утыралар иде инде. Варис коньякка бөтенләй кагылмады. Этисе һәм район башлыгы алдында итагать саклавы гына түгел иде егетнең. Бу нәрсә белән, чыннан да, татулыгы юк аның. Курсташларыннан кайберәүләрнең эчемлеккә хиреслеген дә аңламый ул. Аңларга теләми.

Өлкәннәр дә фасоны килсен өчен генә авыз итеп куйдылар. Мондый чакта, чәчәкләп-чуклап тормасаң да, бөтенләй тостсыз гына да булмый бит. Ә турысын гына әйткәндә, хәмер гайрәтенә мохтаҗ түгел иде алар. Дөнья ансыз да гаҗәеп матур, сокланып туймаслык. Саулык — үзе чиксез шатлык. Хезмәтеңне ярату, аны җиренә җиткереп башкара алу куанычына ни җитә?! Тырышлыгыңны ил югары бәяләсә, моннан да зуррак бәхетне көтү кирәкме? Балаларың да синең тормыш сукмагыңны дәвам итәбез дип торсалар, бу кадәресе килер көннәреңдәге олы сөенечләреңә дә гарантия түгелмени?! Болардан да түгәрәгрәк бәхет була аламы?

Аларның кәефен тагын да күтәрергә теләгәндәй, урамда февраль кояшы елмая иде. Кыш, килешмәгәнне кыланган кебек, яңгырлап сәерсендерсә дә, азаккы чутта, үз сукмагын тапты. Ун-унбиш градус суык

күрсәтергә чамасы житте. Төннәрен Татарстанда егерме биш градустан узган салкыннар да булып алды. Кар да бөтенләй төшмәде түгел. Ашлык яуды дигән сүз, байлык яуды. Алда әле февральнең яртысы бар. Март юмартланмасмы дигән өмет тә бөтен...

Кави Салихович Илфат бәхетенә сокланып туя алмый иде.

— Бик вакытында менден син, кордаш, тауның түбәсенә. Куәтлекодрәтле чагыңда,— диде райком секретаре, механизаторның таза җилкәсенә кулын салып.— Алтын Йолдызың әнә: «Бу иптәш — икмәк фронтының батыры да, профессоры да!» дип сөйләп тора, кордаш...

Бүлмәдә эссе булып китте шикелле. Башта — Кави, аннары хуҗа пинжәкләрен салып, урындык аркасына элделәр. Илфат ак ефәк күлмәк өстеннән таккан галстугын күптән өнәми утыра иде. Аны салырга җай чыгуына сөенгән төсле булды. Өйрәнелмәгән, җанны тыгызлый сыман.

Әңгәмә салмак кына ага бирде. Варис өлкәннәрнең сөйләшүен бик бирелеп тыңлап утырды.

— Кеше, кордаш, табигатьнең яшерен серләренә төшенә-төшенә мәңгелек бишегеннән төште, Галәм киңлекләренә чыкты, атом төше эчкәресенә үтеп керде. Шулай да икмәк һаман газиз икмәгебез булып кала бирә. Изге икмәктә селекционерның да, машина төзүченең дә, химик белән биологның да көче тупланган. Тик хәләл ризыгыбыз, барыннан да бигрәк, игенче хезмәтенең җимеше. Шуның белән мактанырга тулы хакың бар синең, Илфат...

Сәмәрханов бу сүзләрен уйланып кына, салмак итеп чиратка тезәтезә әйтте. Ниндидер бик абруйлы имтихан комиссиясе алдында җавап бирә иде диярсең. Гомумән, ул ашыкмый-кабаланмый гына сөйләүчән. Гүя һәр фикерен пичәтләп бара. Кул хәрәкәтләренә саран кеше, очынмый-кагынмый, ара-тирә генә уң йодрыгы белән өстәлгә кагылгалап куя. Йөзенә карасаң, чамалыйсың: әйткәннәрен күз карашы белән дә раслап бара. Сизелер-сизелмәс кенә ияк тә кага.

Кави Салихович — егетләрчә какча гәүдәле, төз буйлы, ябык яңаклы ир. Аның чырае татарлардан битәр Балтик буе кешеләренекенә тартым. Аксыл йөз, салам төсле чәч, озынча борын, зәңгәр күзләр, сыек саргылт кашлар, саргылт керфекләр. Борынының уң яфрагына бәләкәй генә миң оялаган. Юка иреннәре һәрчак диярлек кысылган булыр. Кыскасы, кискен бер кыяфәт. Шушы төгәллекне тырпаебрак торган колаклары гына бозадыр төсле. Ул һәрвакыт ыспай йөри. Тузанлы юллардан кайтып кермәсә дә, үзен гел чиста-пөхтә тота. Куе шәмәхә төстәге костюмы, ак күлмәк, костюмына иш галстук аңа гаҗәеп килешеп тора.

Ашап-эчкәч, Кави Салихович сигарет көйрәтәсе итте һәм коридорга чыгарга җыенды.

— Тартыгыз монда гына,— диде Илфат.— Ирләр исе чыксын азрак. Мин өйрәнә алмадым инде. Малайларның да күрсәткәннәре юк.

Варис көлеп җибәрде.

— Тартмаганның ниен күрсәтәсең аның?

Сәмәрхановка ияреп, Илфат белән Варис та холлга уздылар. Сүз Маннуровларның кичесенә күчте.

— Каникуллар беттеме, Варис?— Кави әлегәчә бик аз сөйләшкән егетне әңгәмәгә тартырга уйлады.

— Түгәрәкләдек кышкы ялны, Кави Салихович. Озакламый дүртенче курска нокта куябыз.

— Җәйгелеккә планнар нинди рәк? Гөл-Төркемгә кайтасыңдыр бит быел да? «Интернационал»га?

Варис форсаттан файдаланып әйтә куйды:

— Үземә аерым комбайн бирсәләр, кайтам, Кави Салихович.

— Әтиең белән эшләү туйдырдымы әллә?— Сәмәрханов Илфатка күз кысты. Варис бу сорауның күңел кытыклау өчен генә бирелгәнлеген аңлады, әлбәттә.

— Әткәй белән Харис эшләячәк. Энем.

— Ул быел аттестат ала бит инде сезнең?

— Әйе, унны бетерә төпчек тә...— Илфат бу җөмләне «Уза гомерләр!» дигән сымаграк әйтте.— Армиягә кадәр колхозда эшләр инде.

— ВУЗга җыенмыймы?

— Солдат хезмәтен тутырып кайткач укыйм ди, Кави Салихович. Ихтыяры...

— Алай да начар түгел. Гаскәри хезмәтне яшьрәк чакта узган хәерле.

Шул сүзләргә ялгап, Варис үзе турында да әйтте.

— Миңа менә диплом алгач барып кайтасы була әле.

— Ничава, улым, дөньялар тыныч торганда, солдатта булып кайту— үзе бер академия ул.— Илфат өлкән улына яратып, үз итеп карады.

Варис төскә-биткә, килеш-килбәткә койган да куйган әтисе иде. Аңа текәлеп карагач, Кави Илфатның егет чагын, илленче еллардагы Маннуровны күз алдына китерде дә: «Еллардан да аяусыз нәрсә бармы?»— дип уйланды.

Ташбуага төнге поезд белән кайтырбыз, дип килештеләр. Төштән соң вак-төяк йомышлар белән кибетләргә чыгып керербез, дип планлаштырдылар. Үз бүлмәсенә, бишенче катка китеп барганда, Кави абыйсы Варисның исенә төшерде.

— Иртәгә Казан телевидениесе программасын карарга онытма, яме,—диде.—Егерме дә унбиштә. «Һәркемнең үз йолдызы», телеочерк. Әтиеңне күрерсең. Бүген төшергән кадрларны да файдаланабыз, диделәр.

Илфат райком секретаренең һәммәсен хәтерендә тотуына гаҗәпсенеп куйды. Хәтта читенсенде дә шикелле. Күз алдында мактаудан кыенсына Илфат, оялчан кызлар шикелле, үз-үзенә урын таба алмый башлый. Үзе турында тапшыру хакында сүзне дә тизрәк очларга ашыкты.

— Белә ул аны, Кави туган,— дип, улы өчен җавап бирде.— Авылда минем белән бергә аларны да төшерделәр бит кинога. Варисны да, Харисны да. Зөбәйдәне дә чакыртып китерттеләр. Кызымны.

Шулай сөйләшеп аерылышуларына ярты сәгать уздымы икән, юкмы, Варис бишенче катка, Сәмәрханов абыйсы номерына йөгереп төште. Кара тутлы егетнең йөзе киндер төсенә кергән, тыны кысылган иде.

— Кави Салихович! Эти... Әтине!..— диде ул, сулышына буылып.— Әтине...

Сәмәрханов, катапульта атып җибәргән төсле, ишеккә томырылды һәм, Варисны көтеп тормастан, алтынчы катка менә торган баскычка ташланды. Күз ачып йомган арада ул Илфат бүлмәсенең шар ачык ишегеннән килеп керде.

Улы Илфатны караватка сузып салырга, изүләрен чишәргә, тәрәзәне ачып куярга өлгергән иде инде. Кави, кордашының йөзенә карау белән, хәлнең җитдилеген аңлады һәм шул мизгелдә телефонга ябышты.

— Скорая! Скорая! Бик тиз «Татарстан» гостиницасына килүегезне үтенәм. Алты йөз унике. Илфат. Ил-фат...— Райком секретаре яшьтәшенең әтисе исемен хәтергә төшерергә азапланды. Бүлмәгә кайтып, Кави абыйсы артына килеп баскан Варис ярдәм итте.

— Фәйзрахманович!— диде.

— Илфат Фәйзерахманович Маннуров. Илле бер яшьтә. Илле бер. Тугыз йөз утызынчы елгы. Инсульт, минемчә. Зинһар, тизрәк булыгыз. Каршылыйбыз...

Ашыгыч ярдәм машинасы Маннуровны Соцгородка, Социалистическая урамы чатындагы уникенче больницага алып китте. Икенче кат-

тагы палаталарның берсенә урнаштырдылар. Варис үзе генә озата бармакчы иде, Кави Салихович ике сүзгә урын калдырмады, такси туктатып, ашыгыч ярдәм машинасы белән бер үк вакытта больницага килеп житте.

Илфатны койкага салгач та, Сәмәрханов неврология бүлеге мөдирен күреп сөйләште. Аннары, чират көтеп утырса утырды, больницаның баш врачы белән дә күреште.

Больницадан Кави Сәмәрханов партия өлкә комитетына китте, авыл хужалыгы бүлегендәге иптәшләргә Илфат Маннуровның сәламәтлеге китү турында хәбәр итте.

Вариска баш врач имзасы белән әтисе янына тоткарлыксыз керү өчен даими пропуск яздылар. Басса бакыр изәрлек булып йөргән Илфатка һәр минут саен кеше ярдәме кирәк иде. Тиз арада гына аңа торып утырырга да рөхсәт булмаячагын әйттеләр.

Илфат аңын озакка югалтмаса да, исен жыя алмыйча байтак ятты. Үзенә дәррәү ябырылган чир зәхмәтен башына сыйдыра алмый иде. «Ничек була соң инде бу? Гомерендә врач хозурына бармаган килеш типсәң тимер өзәрлек булып йөр имеш тә, аяк астында идән сайгаклары сыгылып торсын һәм — мә сиңа! Моторлы пычкы белән кисеп аударган имәнмени, ят инде менә. Артыгын кыймылдарга да ярамасын.

Әй-е... Үлем дигәнең дә шулай киләдер, мөгаен. Васыятеңне әйтергә дә өлгерә алмассың, иптәшкәем. Каш белән күз арасында ул әҗәл, диюләре юкка түгелдер. Жыела торгач, көчкә килдеме икәнни соң? Ятим балачак. Үсмер елларда, унбер-унике яшьтән, ачлы-туклы көчәнеп эшләүләр: үгез жигүләр, үзеңнән авыр капчык ташулар, язгы суга бата-чума чәчүлек орлык кайтарулар, сукага жигелеп бәрәңге утыртулар, туңы качмаган басу балчыгына тездән батып, черек бәрәңге крахмалы жыюлар... Тормыш инде эзенә төште, тамак ипигә тиенде, дигәч тә ялсыз-туктаусыз тырышып-тырмашулар, керфеккә керфек тә ормый уздырган тәүлекләр, кыр вагоннарында узган атналар, айлар. Һәммәсен чутка салсаң, байтак икән шул... Хатирәнең вакытсыз гүр иясе булуы да игәде бугай инде бәгырьне, астан игәде. Ә вообще-то, бирешергә ярамый бит әле миңа, ярамый! Иртә әле тиражга чыгарга, иртә! Малайларны ныгытып аякка бастырасы бар, туйлар итәсе бар. Артыгына нәфсемне сузмаска да ризамын, аз да түгел, күп тә түгел, бишьеллыкларның унберенчесен, уникенчесен сафта килеш узарга иде. Ул чагында да жиденче дистәне ваклый гына башлыйм бит әле мин. Аннары күз күрер иде әле...»

Илфатның нык борчылуын, кәефе начараюын Варис врачларга әйтми булдыра алмады. Сестра кереп, укол кадады.

## Таныш түгел белеш һәм онытылган таныш

Илфатның хәтер почмагына малай чактан ук кереп калган бер жыр бар:

Кулъяулыкны тузмый, диләр,
Почмагыннан туза икән;
Яшь гомерне узмый, диләр,
Искән жилдәй уза икән...

Яшь гомернең аккан судай, искән жилдәй узуына иман китергән иде инде ул. Күптән. Гомумән, гомер дигәнеңнең бик тиз узуына да ышана. Язгы чәчүне төгәлләп, ары карарга, бире багарга да өлгермисең, үләң вакыты, печән өсте житә. Мал-туарга кышлык азык хәстәрләдек, дип куанып йөргәндә, уракка төшәр көннәр якынлаша. Борча-

гын, арышын, ужым бодаен җыеп алдык, дип тә бетерә алмыйсың, соңгы культуралар өлгерә. Аннары туңга сөрү, бәрәңге-яшелчә, шикәр чөгендерен алу. Аларны да башкарып чыккач, чиратка ремонт эшләре баса. Әүвәле тракторларны өр-яңадан сафка кертү эше. Корыч айгырларга кышын да шөгыль бихисап. Кар тоту дисеңме, ашлама ташумы, төзелеш материаллары, ягулык кайтарумы — очы-кырые юк. Шуннан соң комбайннарны хәзерлек сызыгына кую...

Механизатор, терлекче кебек үк кай арада яңа ел житкәнен дә, ни арада елның үтеп киткәнен тоймый да кала төсле. Хуҗалык елын түгәрәкләгәндә, чутлап карагач кына гомернең заяга үтмәгәненә шөкерана итә. Тырышлык җимеше күз алдында — центнерлар, тонналар... Ил табынына ризык-нигъмәт...

Бәхетсезгә димәсәң, гомернең узмый интектергән җирләре дә бар икән, кана. Менә больница дигәннәре шундый икән. Вакыт агышын нииндидер кодрәтле бер көч туктатып куйган диярсең. Илфат, уколлар кадагач, төнгегә тынычландыра, йокыга кыстый торган дарулар эчергәч, төн уртасы авышканчы йоклап алгандай итте. Сәгать икеләр булдымы икән, уянган иде, шуннан соң, керфекләрен шырпы белән терәтеп куйган төсле. күз йома алмады. Ап-ак булса да, карачкы булып күренгән түшәмгә текәлеп ятты, башын азрак борып, палата тәрәзәсенә караштыргалады. Онытылып китеп, кул-аякларын кыймылдатырга маташса да, уң кул бөтенләй тыңлаусыз иде. Уң аяк исә сүз чынлыгы өчен генә хәрәкәтләнде. Сул кул хәрәкәтләнә, сул аяк исән-имин. Авыз чалышаюы кәефне бик китәрә, сөйләргә комачаулый.

Февраль төннәренең озынлыгын Илфат илле бер яшенә житеп тәүге тапкыр тойды. Хезмәттән арып кайтып, киңәнеп, тирән итеп йоклаган чакларында ул декабрь төннәренең узганын да абайламый кала иде. Эшсез-мәшәкатьсез, ятакка ябыштырып куйган хәлдә интегүдән дә, сәгатен түгел, минутларын ничек үткәрим, дип изаланудан да мәгънәсез һәм әчпошыргыч, җан көйдергеч халәт юктыр ул!

Бүген дә таң бик акрын сызылды, көн авырлык белән генә туды. Иртәнге эңгердә тәрәзә аша больница бакчасындагы шәрә каен кәүсәләрен һәм як-якка тырпаешкан ботакларны шәйләрлек булгач, Илфат иркен сулап куйды: «Ятыра, ниһаять!» Гомер-гомергә кояштан алда торып хезмәткә җыенырга өйрәнгән кеше төннең көнгә авышуында гирән мәгънә, зур канәгатьләнү таба.

Тавышын бик кысып куйган репродуктордан Кремль курантларының чыңы ишетелә башлаганда, Илфатның палатадагы күршесе — Гайсин фамилияле абзый да уянган иде инде. Иртәнге җидедә, ач карынга дип анализ өчен кан алырга керәселәр. Шуңа кадәр хәлеңнән килгәнчә юынасы-таранасы бар.

— Хәерле иртә, бүлмәдәш!— диде ул Илфатка.

— Сезгә дә, абзый!

— Хәбиб атлы мин, Илфат энем.

Хәбиб абзыйның йөрәге борчый, кул чукларының түбән ягы ойый, тоемсызлана икән. Шуннан дәвалануы. Ул больницага алданрак кергән, озакламый чыгарырларына өмет итә.

Беравык юыну-кырыну бүлмәсендә булып кергәч, Хәбиб карт, урындык алып, Илфат караваты буена килеп утырды.

— Әйбәтләнәме кәефегез бераз, Илфат энем?

Фамилиясен әйтеп эндәшсә, Маннуров бер дә сәерсенмәс иде. Монда медсестралар да, врачлар да авыруларга гел фамилияләре белән мөрәҗәгать итәләр. Абзый менә инде икенче кат аның исемен әйтеп эндәшә.

— Ярыйсы кебек инде, Хәбиб абзый... Йокыны гына урладылар менә, анысын мактар хәл юк...

— Баштарак мәлдә җәфалар инде ул, Илфат энем, җәфалар. Анысын белеп торганыгыз һәм артыгын хафаланмаганыгыз хәерле. Йокы даруына да ияләшмәү ягын карарга киңәш итәр идем... Сез Ташбуадан икәнсез бит, Гөл-Төркемнән, ә?

— Әйе шул. Сез дә безнең якларны беләсез, булганыгыз бармы әллә безнең төбәктә?

— Беләм. Дөресрәге, белә идем. Соңгы елларда бик күптәннән инде, барып чыкканым юк.— Хәбиб карт урындыгын караватка якынрак күчерде.— Танышырбыз әле, гәпләшербез. Әлегә сезгә күп сөйләшү ярамас... Шуны гына әйтим, мин сезнең бишектә чагыгызны беләм. Минә бит гомер дигәнең ничаклы үткән! Әтиегез Фәйзерахман белән яхшы иптәшләр идек. Бабагыз Габдрахманны да хәтерлим...

Шул сүзләрдән соң Илфат миендә бер нур сызылып үткән шикелле булды. Шул нур калдырган яктыда бу абзыйның исем-фамилиясе бик таныш мәгънә алды. Хәбиб Гайсин... Хәбиб Гайсин... Әтисе аның хакында Илфатка еш кына сөйли иде. Тик сүзләренең асылы малай чакта Илфат аңына барып җитмәгән. Авыл картларының бүген дә булса искә алуларыннан Маннуров белә: Хәбиб абзый, Ташбуа районы оешкач, утызынчы елның августыннан партия райкомының беренче секретаре булган. Колхозлашу барган чорда Гөл-Төркемгә дә еш килгән. Шулай итеп, кайчандыр таза, мәһабәт гәүдәле булган, хәзер инде сәлперәеп, бөкерәебрәк калган бу агай — Илфатлар авылында колхоз төзешкән коммунист. Бик гайрәтле булган, диләр аны заманында. Тулы түгәрәк битен ачып торган зур соргылт күзләре әле дә сүнеп түгелләр. Карчыганы хәтерләткән борын, алга чыгып торган ияк яшьлегендә тәвәккәл, кискен кеше булганлыгына шаһиттыр төсле. Әле дә җил-җил килеп ала ул. Күн тужурка, күн кепка, галифе чалбар һәм күнитекләр киеп, наган таккан килеш, ат менеп авылларга чыгып киткәндә, карап кына тормалы булгандыр. Инде битен җыерчыклар чәрдәкләгән. Күз аслары капчыкланып чыккан. Авызындагы тешләр дә протез остасы кулыннан үткән. Ә чәчләре — ни гаҗәп!— бөтенләй коелмаган диярлек. Маңгай өстендә генә ике яктан ике уйдык бар. Куе чәче бүрек сыман тора. Бу баш төнлә дә тирә-юньне яктыртадыр дип уйлап куярлык.

— Кичә сез йокымсырап ята идегез, Илфат энем,— диде Хәбиб абзый Гайсин.— Мин кызыл почмакка кереп, телевизор карадым. Беләсез булыр, сезнең хакта зур тапшыру ясадылар. Шунда әтиегезне, бабагызны искә төшердем. Яшьлеккә кире кайткан төсле булдым үзем дә. Кызык та, ямансу да... Авылыгыз бик матурайган икән. Зөя бормаларын күрсәтмәсәләр, кай тирә бу дип утырырсың, танырлык та түгел... Улларыгызны бик ошаттым. Молодецлар! Монда килеп йөрүчесе институт бетереп бара икән бит инде. Ярый, ярый, бик әйбәт,—Хәбиб абзый үз караватына китеп утырды, кичә оныгы китереп киткән газеталарның берсен алып, нидер укырга ябышты. Җитмеш алтыны тутырган карт күзлексез укый. Кызыкмаслыкмы? Партиягә Ленин призывында, мең тугыз йөз егерме дүртенче елда, унтугыз яшендә кергән. Партия стажы гына да илле җиде ел! Шулай да җаны картая белми бу абзыйның. Шәһәр, Татарстан, ил тормышы, халыкара хәлләр белән һәр тумыш көнне җентекләп танышып баруны үзенең көндәлек ихтыяҗы иткән. Белмәгәне, ишетмәгәне юк...

Сәгать сигез тулуга, Варис килеп җитте. Ул бу араларда беренче лекцияләрен калдырырга мәҗбүр. Деканатка кереп хәлне аңлатты, рөхсәт алды. Группадашлары, билгеле инде, иптәшләрчә теләктәшлек иттеләр.

Урын өстендә яткан авыруны караучы кеше сырхау яныннан тәүлек әйләнәсенә китмәсә дә, таманга гына килә: кулын-битен юеш сөлге белән сөрт, чәчен тараштыр, көн аралаш булса да кырындыр, мендәр-

юрганын җайлап бир, даруларын эчерт, тамагына ашат, чыгарасы-бушатасыларны өстендә үк башкарып куй... Авыруның күңеле төшкән, җаны теләгән тансык ризыкка дип кибетенә йөгер, базарына чап. Икенче көнгә бер авыруның өстен-башын алыштырырга да кирәк.

Варис әтисе янына иртән һәм кичке аш алдыннан килүчән булды. Төшке ашны нянялар, сестралар карап ашаталар иде. Ярый әле, күрәчәкне сизенгән шикелле, Илфат яшь чактан ук сул кулы белән дә байтак эшне эшләүчән иде. Мондый бәлагә дучар булгач, сулагай да аптырап тормавы алыштыргысыз нәрсәгә әйләнде. Ашны сул кул белән ашарга дип кашык алганда, Илфат уйлап куйды: «Японнар юкка гына яшьтән үк сул кул белән дә язарга өйрәтмиләр икән шул...»

Улы әтисенә сөт кайнатып китергән иде. Илфат, сөт дигәндә җаны фида кеше, моны үзе сорап алды. Алма алып килгән, өрек, кара җимеш. Әнисе чәйне әбиләр шикелле куе итеп, җиләк-җимеш ямсә әлү кагы белән эчәргә ярата, я мәтрүшкәләп-сөтләп эчә.

— Минә иң кирәкләре шулар. Булдыргансың!— дип мактады улын Илфат.— Бүтән һич нәрсә кирәкми. Туйга килгән кунак шикелле ашаталар монда. Симереп селкенә алмас булмасам ярый.

— Ашаган кешедә өмет зур, Илфат энем,— дип сүзгә кушылды Хәбиб абзый.— Сезгә батырып ашарга кирәк, батырып...

— Хөрәсән ялкавы төсле, аркылыны буйга алып салмый яткач, аппетиты да югалып тора бит әле аның, Хәбиб абзый,— диде Илфат.— Чыннан да, аның тамагы нечкәреп калган иде.— Кыл-тамак чире генә йокмасын.

Хәбиб абзый аталы-уллы Маннуровлар янына килде.

— Алай булмый әле ул, булмый...— Карт, икеләнүгә урын калдырмыйча, нык ышандырырлык итеп сөйли иде.— Әлегә аппетитыгыз кимеп тору организмның тетрәнеп калуыннан. Уза ул, һичшиксез уза. Сугыш вакытында Ташкент госпиталендә ятканда, шулай бер рус егете кулы гарип калу ихтималы кайгысыннан ашаудан бизгән иде. Тынычлангач, күңеле бер юаныч тапкач, тегермәне шундый тарта башлады егетнең, сыеңны төткәз генә... Сезгә дә, Илфат энем, барыннан да элек, тынычланырга кирәк, ты-ныч-ла-ныр-га!— Гайсин абзый уң кулының имән бармагын югары күтәрде.— Сезгә әле нибары илле яшь...

Илфат ирен чите белән генә елмаеп куйды. «Нибары...» Ул үзен инде ярты гасыр яшәгән олы кешегә исәпләп йөри иде. Хәбиб карт, үз каланчасыннан карап «нибары» ди. Һәр нәрсә чагыштырмача карала шул.

— Илле яшь — егет чак әле ул, энем. Сез бик тиз аякка басачаксыз. Хәбиб карт әйткән иде диярсез. Дөньяны актарып эшләячәксез әле, иманым камил... Шуннан соң бер мәсьәләдә үтә игътибарлы булу зарур: режим. Ул да булса — ре-жим! Ашау-эчүдә, организмга ял бирүдә...

— Аякка басмый ярамый да миңа, Хәбиб абзый, что сез?!— Илфат бу хакта ике фикер булуы мөмкинме әллә дип, картка үпкәләгән төсле кырысланып әйтте.— Бу яшьтән адәм имгәге булып калсаң тегеләй...

Гайсин абзый аның уй-кичерешләрен, күңел талпынуын, җаны бөтерелүен аңлый иде. Шуңадыр, бик уңайга-җайга гына сөйләп торды:

— Бөтенләй сәламәтләнүегезгә тулы гарантия — минә минем күрәзәлек, Илфат энем. Сезгә хәзер үзегездә нык ышаныч булдырырга гына кирәк. Үз-үзеңә ышанычтан да көчлерәк, шифалырак бәлзәм юк. Госпитальдә дә булгалый иде андый канат салындырган егетләр. Үз киләчәкләренә ышаныч тудыммы, пар канатлыга әйләнәләр иде.

Илфат Хәбиб абзыйдан сорашмый чыдамады:

— Сезгә госпиталь койкасында байтак аунарга туры килгәндер, ахры, Хәбиб абзый,— диде.

— Ике тапкыр булдым мин госпитальдә.— Карт, өстендәге пижамасының төймәләрен каптыра-каптыра, җавап бирде. Коридорга чыгарга җыена иде бугай.— Берсендә кыр госпиталендә булу белән генә котылдым. Агымдагы ремонт кына иде. Аякка... Икенчесендә Ташкентка эләктем. Контузия дә, баштагы яра да. Капиталь ремонт кирәкте... Узды. Уза ул! Өмет кенә өзелмәсен!

Хәбиб карт палатадан чыккач, Варис сер сөйләгән кебек сорап куйды:

— Әкәмәт бабай, әйеме? Картлык баскан үзен, ә күңеле көр. Тавышын гына ишетеп торсаң, япь-яшь комиссар сөйли диярсең.

— Комиссар булгандыр да ул. Атап сораганым юк әле, шулай да сугышта политрук булгандыр, дип чамалыйм. Утызынчы елны Ташбуа райкомында беренче секретарь. Аңа кадәр канткомны җитәкләгән. Мин сабый чакта безнең өйдә булганы бар икән. Бабаңны әйбәт белә, минем бабайны да яхшы хәтерли.

— Кызык!— Варис гаҗәпләнү катыш мавыгу белән әтисеннән янә яңалык көтте.— Менә Мафусаил карт, әй!

— Кем диден? Хәбиб исемле ул. Хәбиб абзый Гайсин,— диде Илфат. Ә Варис малай-шалай сыман көлеп җибәрүдән чак тыелып калды.

— Юк ла!— диде ул аннары.— Мин чагыштырмада гына әйттем. Мафусаил карт — Библия мифындагы бер образ ул. Имештер, ул карт тугыз йөз алтмыш тугыз ел яшәгән. Озын гомерле кешеләрне шуңа тиңлиләр...

— Ә-ә, алаймы?— дию белән әтисе канәгатьләнде.

Әтисен иркенләп кенә ашаткач, Варис чәй кайнатты. Илфат ул чәйне өйдәгечә шартын китереп, үзе дигәнчә тәмләп, ләззәтләнеп эчте. Авыруның кәефе чагыштырмача ару икәнлегенә ышангач, Варис апасы Зөбәйдәдән телеграмма алганлыгын, сишәмбедә аның Казанга киләсен әйтте.

— Кави Салихович хәбәр салгандыр, шуннан соң юлга җыенгандыр,— дип куйды Илфат.— Аңа фермадан арынып чыгасы да ансат түгел бит әле. Елның язга авышкан чагы, сыерлары берәм-берәм бозаулый башлагандыр...— Шулай диде, ә эченнән кызының больницага килүен бик тели иде. Кызын күргән саен аның күз алдына яшь чагындагы Хатирәсе килеп баскандай була. Кызы уңган булып чыкты Илфатның, бик булдыклы. Унынчыны бетереп чыкканнан бирле, сигезенче елы инде, сыерлар сава, өч ел рәттән колхозда беренчелекне биргәне юк. Ташбуа районы буенча да ун алдынгының берсе булып килә. Өендә дә һәммәсенә өлгерә. Багалмадай ике ул үстерә, ир карый. Алай гынамы? «Бәләкәйләрем уңны-сулны аерырлык булдылар инде, әткәй, сезгә китергәләп калдырсам да була. Читтән торып техникумга керимсәнә. Гомер үтә, еллар уза тора, диплом алып чыгармын», дип әрсезләнмәкче. Алынса, булдырасы... Ире дә — кулыннан эш килә торган кеше, Илфаттан калышмый диярлек эшләүче механизатор. Тик бер ягы җанны ашый, йортына күңелен беркетеп бетерә алмый, уңга да, сулга да кагылгалап ала торган гадәте бар. Яшьлек тыелгысызлыгымы, холкы шулмы — кем генә белсен!? Шул гадәте белән Зөбәйдәнең бәгыренә ут сала. Кыз күп чакта эндәшми уздыра, авызга су кабып та карый. Әмма көннәрнең берендә гаиләдә барыбер тавыш чыга. Җәнҗал куптымы — кияү янә үрсәләнә башлый, тамак чылатырга да күп сорамый. Үзе болай бик әдәпле кебек, җыр сөйләп кенә йөри... Сишәмбедә килә алайса Зөбәйдә. Иртәгә дигән сүз инде. Балалар янында кемне калдыра икән соң инде? Кодагый да иртәрәк дөнья куйды, бәләкәчләрне канат астында җил-яңгыр тигезми генә үстерешерлек иде әле. Ике кодагый икесе дә гомерсез булдылар, канә. Чүкердәшеп яшәр чаклары иде югыйсә...

Варисның тагын бер хәбәре бар иде: бүген үк әйтергәме, әйтмәскәме, дип торды егет. Сәеррәк хәбәр ул.

Кичә кичкырын институтның тулай торагына, Варис Маннуров дигән студент кирәк иде миңа дип, олы яшьләрдәге бер хатын-кыз килеп чыкты. Варисны чакырдылар. Әлеге апа аны ерактан ук танып алды һәм:

— Тач әтиең икәнсең, энем... Мең кеше арасыннан ялгышмыйча танып була үзеңне,— дип, егетнең каршысына килде. Бик чая, очкын бөркеп тора. Үзе башлап кул бирде, мөлаем исәнләште.— Мин якташыгыз булам, энем. Рәмзия апаң Туктарова. Тумышым белән Ураздан. Байтактан бирле Казанда торам. Буй җитеп килгән елларымда Гөл-Төркемдә укыткан идем. Әтиеңне шул гомердән бирле беләм...

Ни дияргә дә җайсызланды Варис. Авыз йомып тору да килешкән эш түгел иде.

— Рәхмәт,— диде, аннары туп-туры сорарга булды.— Йомышыгыз ни иде, апа?

— Йомыш дип әйтерлек йомышым да юк, энем. Герой Йолдызы тапшырылганны соңгы хәбәрләрдә әйткәч, мөгаен, «Татарстан»дадыр Илфат дип, гостиницага барган идем, күңел сүытырлык хәбәр әйттеләр. Больницага салганнар икән ләбаса! Синең авыл хуҗалыгы институтында укыганыңны белә идем, менә сорашырга дип килдем. Кайсы больницада әтиең? Хәле ничек?

— Рәхмәт, бер көе генә. Әлегә мактанырлык түгел.

Рәмзия чыраендагы балкыш тәмам сүнде, йөзен уйчанлык басты, күзләренә сагаю галәмәте чыкты.

— Куркыныч ук түгелдер бит?— Рәмзия апасы Варисның йөрәгенә керердәй булып сорады.

— Куркынычы үтте дип саныйлар инде, дәвалау гына озакка барыр, диләр.

— Син аның янында еш буласыңмы соң, энем?

— Һәр көнне барам. Иртән дә, кич тә.

— Алайса, энем, кем, Варис бит әле... Варис, син әтиеңнән рөхсәт сорап кайт әле, миңа аның янына керергә мөмкин булырмы? Ни көнне, сәгать ничәдә, шунысын да сора. Килергә ярый торган булса, мин иртәгә кич синең яныңа килеп белешермен, яме? Рәмзия апа диген, Туктарова диген...

— Ярый, Рәмзия апа, сез әйткәннәрне әтигә тапшырырмын.

— Мин иртәгә бирегә сугылып чыгармын. Ярый, хуш! Борчыганым өчен, зинһар, гафу ит.

— Зыян юк, Рәмзия апа. Нинди борчылу ди...

Алар тулай торак бусагасы буенда саубуллаштылар...

Менә шуны әйтергәме, юкмы? Әтисенә борчу булып төшмәсме көтмәгәндә пәйда булган Рәмзия апасы Туктарова? Шулай да әйтергә кирәк дигән фикергә килде ул. Әманәткә хыянәт булмасын, бердән. Икенчедән, Рәмзия апасы кичкә тулай торакка килми калмас. Аңа да җавап бирәсе бар.

Илфат, улыннан бу хәбәрне ишеткәч, бермәл сүзсез торды, ак димәде, кара димәде. Варис әтисенең нәрсә уйлаганын тырнак очы кадәр дә чамалый алмады. Сөендердеме бу хәбәр аны? Борчуга салдымы? Илфатның йөзендәге бер генә мускул җепселе дә селкенмәде, кыймылдамады. Бөтенләй битараф идемени соң ул бу яңалыкка?

Менә әтисе йокыдан уянып киткән төсле булды.

— Рәмзия Туктарова диденме?— Ашыгыч җавап даулагандай, каударланып куйды.— Кара тутлы чибәр генә хатынмы?

— Әйе инде, Рәмзия апа Туктарова.— Варис исем-фамилиягә басым ясап әйтте.— Үзе төп Уразныкы икән. Әйтәм ич, сугыш елларында

безнең авылда укыткан. Чибәр булгандыр ул, эткәй. Әле дә бик сөйкемле, чая. Чегән чибәре кебек.

Илфат юклы-барлы хәле белән көлеп куйды.

— Нигә көлемсерәдең, эткәй?— Егет шулай дими чыдамады.

— Тарих кабатлана икән, улым. Шунысы мәзәк булып китте. Беләсеңме, моннан утыз биш ел элек мин Рәмзия апаңа син әле генә әйткән сүзләрне әйткән идем.— Улы һаман да этисенең тел-төбен төшенми торгач, Илфат ачыклап бетерәсе итте.— Чегән чибәре дигән идем мин дә...

— Яшь чагында чегән кызына охшаган булган, алайса.

— Әйе. Шомырттай кап-кара зур күзле иде ул. Озын куе керфекле иде. Чигәләрендә кара бөдрәләр бөтерелә иде. Тавышы көмеш тәңкәләр чылтыраган кебек иде.

— Синең аны шуннан бирле күргәнең юк идеме, эткәй?

— Армиядән кайткан елны поездда бер очрашканым булды. Илле икенче елны. Шуннан соң сукмаклар аерылды.

— Онытылган таныш булып чыгамыни инде?

— Шулай дисәң дә була.— Илфат тынып торды. Утыз елга якын очрашма да, онытылмасын, дип уйлады. Инде дә дөресен әйтсәң, һич онытылмады Рәмзия. Беренче танышканда йөрәкнең әллә кайсы бүлеменә кереп урнашты да, гомергә шунда яшәп калды. Калмаска тиеш була торып калды. Илфат аны гафу итәргә дә тиеш түгел иде кебек. Исемен дә ишетергә теләмәскә тиеш иде төсле. Юк, Рәмзияне каһәрли дә алмады, исемен әледән-әле тәкрарлап йөрде. Якташ шагыйрь дөрес язган: онытылмый беренче саф мәхәббәт. Ураз кызы Рәмзиягә гашыйк булгач татыган иде бит Илфат мәхәббәтнең беренче газапларын. Тиң күрмәвен кыз, читләтеп-уратып булса да, аңлаганга аңларлык итеп сиздерә килде, ә Илфат үчләнә-каныга барып, төшенергә теләмәде. Чөнки ул үзенең шул тикле яратуына бер көч тә киртә була алмас, булырга тиеш түгел, дип исәпли иде. Аныңча, Рәмзиянең тәкәббер күңеле генә түгел, таш булып таш та эрергә, саф җан каршында мәңгелек таш та мәхәббәткә әйләнергә тиеш иде. Ялгышты. Хисләр кайнарлыгы тудырган өмете чынга ашмады. Таш та, кеше күңеле дә алай тиз генә эреми икән...

Дөрес, Хатирәгә Илфат күңеле тартуына буйсынып, ошатып өйләнде. Илле өчнең көзендә, уңыш бәйрәменә туры китереп, туй иттеләр. Солдат хезмәтен тутырып кайткан танкист-өлкән сержантны күрше кызының тыйнаклыгы, самимилеге әсир итте. Уңганлыгы-булганлыгы сокландырды. Биеккә үрелеп, авыз пешергәннән соң тыйнаклык, гадилек дигән төшенчәләр аның өчен бөтән яктан ачылган төсле булды. Үрелүсузылуларны да гаеп итәр хәл юк, билгеле. Яшьлек пырдымсыз ич ул, күктән йолдыз чүпләүне дә мөмкингә саный. Яшьлектә карның аклыгы да җаннарны җылыта. Яшьлек хәсрәтне-кайгыларны да акка мана. Ә кызларның тыйнаклары, сабырлары, әдәп саклап, бер читтәрәк калучан була, «чегән чибәрләре» исә егет-җиләнне гыйшык утына аяк-кулларын бәйләп сала. Андыйлар ут төртеп йөрәкне дөрләтәләр дә, су сибәргә онытып янсә сибәргә теләмичә, китеп тә баралар. Рәмзия — Илфатны нәкъ шулай җәзалаган кеше. Иң авыры шул: азак килеп, кыз аны ятимлеге, ярлы-ябагайлыгы өчен тиң итмәде. Күлмәк-ыштан ямаулы булса да, яшь йөрәк ямаулы түгел иде бит, күңелгә ямау салынмаган иде. Әмма кием ямаулары буй җиткән кызны өркеттеләр шул тегє елларны. Шуңа карамастан, юлда киртәләр очраса, җан җәрәхәтләнсә, егет «чегән чибәре»н искә ала иде. Логикасызлыкмы? Бәлки. Ә мәхәббәт логика кануннарына гына буйсына дип кем әйтә?!

Илфатның уйга уралып ятуы озакка китте бугай, Варис кайтарып сорарга мәҗбүр булды.

— Әткәй, Рәмзия апага нәрсә дип җавап бирим соң мин? Килсенме монда?

Улының кырт кисеп куйган соравына каршы ата да кып-кыска җавап бирде.

— Килсен. Иртән уннан соң. Врачларның обходы беткәч. Шулай дип әйт. Ә үзең, улым, институтыңа ашык. Троллейбуска чык, тизрәк булыр...

Бүген, дәвалаучы врач белән бергә, неврология бүлеге мөдире Геннадий Иванович та керде. Башта алар Хәбиб абзый белән бөтен шартын китереп сөйләштеләр. Аннары Илфат белән әңгәмә кордылар.

— Алга барабыз, иптәш Маннуров,— диде бүлек мөдире.— Бик акрын, вак адымнар белән, мәгәр алга... Да, әйтергә онытып торам, тугызынчы яртыда телефоннан иптәш Сәмәрханов шалтыратты. Сезгә бер кочак сәлам тапшырырга кушты һәм Ташбуа райкомы исеменнән, безгә, ике коммунистка, партия поручениесе бирде: сезгә — бик тиз савыгырга, миңа — сезне тиз арада савыктырырга! Сезне сафка бастырырга! Шулай булгач, Илфат Фәйзерахманович, бу эштә сез үзегез медикларга нык булышырга тиешсез. Нык итеп...

Врачлар чыккач, Илфат үз күңелендә туган хисләрен Хәбиб абзый белән уртаклашты:

— Шәп безнең райком секретаре, Хәбиб абзый. Хезмәт кешесенең кадерен белә...

## Яңарган хатирәләр

Сәгать ун тулды. Унберенче биш минут китте, ун минут, унбиш минут... Рәмзия килмәде. Авырып-мазар калдымы икән? Сменалы эштә булып, хезмәтеннән бушый алмадымы? Әллә үзенең кыюлыгыннан үзе үк курыктымы? Ул бит Герой исемен алу белән котларга җыенган булган, карават үлчәп яткан Илфат янында нием калган соң әле минем дип, кире уйлап куйдымы? Килсен иде инде, йөрәкне җилкендергәч. Килеп китсен иде, аваз салып, хәбәр биреп ымсындыргач. Бер күрешү — үзе бер гомер. Олыгайдымы икән, тормыш җил-яңгыры хәйран кагылдымы икән аңа да? Тегү эшендә икән дип колагына кергәне булды Илфатның. Артыгын белми. Килсә, сорашкан булыр иде. Бу килеш Рәмзия аңа һаман элеккеге Рәмзия кебек. Чегән чибәре!

Кызык күренеш: кеше үзенең уйларында үткәненә кире кайта ала! Адәм баласы хыялланырга, үз киләчәген күз алдына китерергә, туар көннәренә булган өметләрен үз аршынына салып планлаштырырга сәләтле. Моның белән көчле ул. Шулай да кеше үткәннәргә әйләнеп карамыйча яши алмый. Хатирәләрсез, истәлекләрсез, үз нәсел-нәсәбе турында, туган туфрак, туган җир хакында мәгълүматларсыз, узган гомердән алган гыйбрәт-сабаксыз кеше исәпкә бар, санга юк. Еллар, дистә елларның чуерташ дәрәҗәсенә җитеп тыгызланган тәҗрибәсеннән башка кеше кул аяксыз бер зат.

Илфатның уйлар йомгагы да ерак-еракка, тормышның зәңгәрсу-кургаш болытлары артында күмелеп калган яшьлек елларына тәгәрәде. Яшүсмер чагына. Җаны-тәне белән ашкынып буй җитәсе килгән дәверенә. Егетлек бусагасын атларга җыенган еллары аның күңеленә шул тикле якын, шул тикле газиз, аларны хәтерләгәндә Илфат үзендә көч артканын тойган кебек була, дөнья тагын да ямьлерәк, яшәү тагын да мәгънәлерәк күренә. Хатирәләр мәңгелек суы белән сугарылганнармы соң әллә?!

...Кырык дүртенче ел иде. Язы ачлык белән җанны кыйнаган ел. Башта яшь кычытканга, аннары чүгендер яфрагына табындырган, соңрак яңа яшь бәрәңгесен җәннәт сые иткән ел. Илфат өчен, апасы Илһамия, сеңелесе Илшадия өчен кара матәм елы. Зөянең язда сугып, кара көздә сөтеп калдыра торган күпере аша чыкканда, ноябрь азагында тракторы агымсуга капланып, әниләре үлгән, өч баланың сыңар канатлы булып калган еллары. Канатның икенче сыңары Бөек Ватан сугышы фронтында иде. Кырык икенче елның февралендә МТС аша бирелгән броньнан баш тартып, тракторын танкка алыштырган Фәйзерахман Маннуров бу вакытта, илебезнең дәүләт чиген үтеп, вәхши фашист өерләрен үз ояларына таба куып бара иде. Әтиләре өчен балалар сөенеп туймадылар, әниләре үлеменең хәсрәте чиксез булды. Кырык бишенче ел житмичә Фәйзерахманга хатынының үлеме турында язмадылар. Яза алмадылар. Куллары бармады. Аннары язмый да булмады. Фәйзерахманның җавап хаты күз яшенә манчылып килгән иде. Фронтовик-танкист: «Мәңгелек үкенечкә каласыларым булганга, өйрәткәнмен икән Маһибәдәр бәгырькәемне трактористлыкка»,— дип язган иде. «Түзегез, чыдагыз инде, газизләрем, фашист дигән агулы еланны сытып изгәч, исән-сау кайта алсам, ничек тә тернәкләнеп китәр идек. Бер үк чыдагыз, балакайларым. Җиңүгә ерак калмады инде...»— дип юаткан иде.

Ачлыгына, мохтаҗлыгына бакмастан, әнисе үлгәнгә кадәр Илфатның кәефе әллә ни боек түгел иде. Район үзәгенә бара-кайта укып (һәр көнне егерме чакрым!), кырык дүртнең җәендә сигезенче классны бетерде ул. Аннан соң үгез җигеп, җәй буе колхозда эшләде. Урак өстендә катлаулы сугу машинасы янына, ындыр табакларына көлтә ташыды, Ташбуа элеваторына (аны «Заготзерно» дип йөртәләр иде) — ашлык, Лашчы разъездына бәрәңге, яшелчә заданиесе илтте. Кордашларыннан калышмый эшләде. Балалар йортындагы Женя Логинов кына — кырык беренче елның августында Белоруссиядән эвакуацияләнеп килгәндә үтә күренмәле малай, тора-бара ныгып, тазарып киткән яшүсмер — житезлектә, чыдамлыкта аны уздырса уздыргандыр. Авылныкылар «Детдом Женя» дип атаган шәһәр ятименең сала эшләренә кулы бик ята иде. Гөл-Төркем картлары аны мактап туймыйлар. «Атасы булмаса, бабасы чын крестиян булгандыр бу баланың»,— диләр иде.

Маннуровлар гаиләсе өчен шомлы булып беткән кырык дүртенче елның көз башы Илфат йөрәгенә шашкын дәрт керү белән истә калган.

...Кояш иңеп бара, көне буе катлаулы сугу машинасына көлтә ташыган «үгезләр эшелоны»ның ташбака адымы белән колхоз ихатасына кайтып барышы.

Үгез дигән җан иясе белән эш иткән кеше белә, ул мәхлуктан (чү, мәхлук микән?) ашыгып атлавын өметләнеп ялгышмаска кирәк. Сал инде син аңа йөгеңне: көлтәме ул, ашлыкмы, бәрәңгеме, кирпечме яисә утынмы — барыбер, төя икеләнмичә, тартачак «МУ-2» дигән («үгез — ике мөгез») транспорт, әмма ашыктырма син аны. Анысы — файдасыз шөгыль. Кыр капка төбендәге басудан да ярты сәгать кайта. Бу юлы «эшелон» авылдан өч чакрым чамасы тимер юл буендагы ындыр табагыннан кайтып килә иде. Кыр ышыклау полосасы яныннан авылга таба сузылган туры юлга чыкканда, үгез җигеп каешланып беткән малайлар өеренә, кулына чемодан күтәреп, бер якка иңкәеп атлаучы кыз очрады. Илфат беренче олауда, саф башы булып бара. Саф башы булып йөрүне берәү дә өнәми. Ник дигәндә, үгезне һаман әйдәп, кычкырып барасы була, ә арттагы арбаларда малайларның гамендә дә юк, авыл башына кайтып җиткәнче алар йокы симертәләр. Шуңа күрә саф башында чиратлап йөрү килешенгән.

— Исәнмесез! Кайларга юл тотуы икән берәүләрнең?— дигән булды Илфат, кыздан җавап сүзе өметләнеп.

Шомырт кара күзле, нечкә кыйгач кашлы, төз борынлы, бит урталары багалмадай алсу, йомры гәүдәле, озын чәч толымын артка үреп салган кыз күңел җилкетерлек итеп көлемсерәде дә әйтте:

— Гөл-Төркем егетләре булсагыз, сезнең авылга барышым,— диде һәм янә җан тәслим кылганнарны да терелтерлек итеп ак тешләрен балкытып елмайды.

— Бик ашыкмасагыз, утыртып кайтам үзегезне. Чемоданыгыз да авыр күренә. Әйдәгез, иң әүвәле аны арбага салыйк!

Илфат каеш чыбыркысын көлтә арбасының үрәчәсенә элде дә, җиргә сикерде, эһ дигәнче кызның чемоданын арбага урнаштырды.

— Утырыгыз!— диде аннары.— Менә шулай аякларны салындырып кайтабыз инде. Җәяүләгәннән алдарак була...

— Рәхмәт, егет! Үзегезне кем дип белим?

— Минме? Мин Илфат булам инде. Сез кем менә?

— Мин — Рәмзия.

— Менә таныштык та. Илфат бүгенгесе көннән яңа бер танышлы булды дисә, хаталанмыймы, Рәмзия?

— Иптәш Илфат хаклы булачак.

— Бүтән бер нәрсәгә дә мохтаҗлык юк, болай булгач. Ашыйсы килсә, бодай куырабыз. Эчәсе килсә, сусынны басарга чишмә сулары бар. Ә күңел өчен дигәндә — Рәмзия янәшәдә...

— Сез шигырьләр язасызмы әллә, Илфат?

Бу сорау егетнең көймәсен чак-чак кына комга утыртмый калды. Нишләп тикгомалдан мондый сорау бирде әле иптәш Рәмзия? Күп сөйлисең диюеме? Такылдама, тасма телләнеп маташма, мин синең ишеләрне күп күргән димәкчеме? Тик тоз ашаган тавык кебек миңгерәп калырга ярамый иде, җавабын әмәлләде (күп тә, оста да сөйләүче Илфатмыни соң инде! Әле чибәр кыз күргәч кенә «ычкынып» китүе иде):

— Шигырьләрне укырга бик яратам мин, Рәмзия. Язу кулдан килми. Шигырь чыгарырлык чамам булса, үгез арбасында парлап кайтуыбыз турында бер шигырь әйтер идем инде әйтүен.

Кыз тагын мәгънәсен тиз генә тотып булмаслык сүзләр әйтеп салды.

— Романтикасы зур болай юл йөрүнең...— Шуннан соң гына Илфат кәефенә ярашлы сүз чыкты.— Чемоданны күтәреп атлый калсам, интегәселәрем була икән. Ярый әле, сез очрадыгыз.

Илфат хәзинәсендәге сүзләрнең һәммәсен кырып-себереп булса да, тел тегермәне тартырга әзер иде:

— Әти-әниләрегез хәер-дога укып озатканнардыр, Рәмзия. Шул догалар кабул булгандыр, югыйсә без караңгы төшкәч кенә кузгалабыз өйгә,— диде.

— Әти-әниләр чыннан да борчылып калдылар. Хат язармын инде, бер ялгызыма унбиш олау очрады, диярмен. Сөенерләр бичаракайларым...

— Миннән чук-чук сәламнәр язарга онытмагыз. Гөл-Төркемнең Габдрахман күке оныгы, Фәйзерахман тракторист улы — үгез машинисты Илфаттан күптин-күп сәлам, шуның арбасына утырып килеп ирештем мин бу авылга, диегез, ямә.

Рәмзия рәхәт бер көлү белән көлеп җибәрде.

— Сәламен язармын, анысыннан эш тормас. Бабагызның, әтиегезнең исемнәрен бер кәгазьгә язып бирмәссезме...

Илфат та шаяру комарына бирелде.

— Кызлар хәтере кыска диләр шул... Ну сез кушаматны онытмаска тырышыгыз. Безне шул кушамат аркылы беләләр тирә-юнь авылларда.

— Үз кушаматын үзе әйтеп торган кешене беренче очратуым, кызык!— диде Рәмзия һәм тагын җанга рәхәт өстәп көлеп җибәрде. Илфат исә кушаматы белән горурланганын әйтеп калырга тели иде. Аңлатасы килә иде.



*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

— Безнең кушамат, иптәш Рәмзия, жилдән килгән мыскыл сүзе түгел бит. Бабай күкеле сәгатьләр ясаган минем. Әткәй дә ясый белә иде. Бик тырышсам, үзем дә булдырам мин аны. Частьларга гына кытлык...

— Кызык!— дип кабатлады Рәмзия.— Бер чакрым юл узмадык, мине бөтен нәселегез белән таныштырдыгыз, Илфат. Күңелле егет икәнсез, рәхмәт!

Илфатның бу чибәр күңеленә ятышлы нидер әйтәсе килә иде. Күкеле сәгать ясап бирәм мин сезгә дип, мәсәлән. Ләкин мондый сүзне уңны-сулны чамаламый ычкындырып, дивана Җәләлетдин хәленә калуың бар. Вәгъдә биреп куюыңнан алда урабрак килеп, разведка ясаган хәерле булыр. Шул фикергә килгәч, Рәмзиядән ул туп-туры сорады:

— Безнең авылга кемгә киләсең соң? Әгәр дә инде житмеш йозак белән саклый торган сер булмаса, мин дә белер идем.

Рәмзия, ай-һай әрсезләнәсең, егет, дигәндәй, шаян да, кисәтүле дә караш ташлап алды да җавап бирде:

— Сез моны белә алмыйсыз, Илфат. Чөнки... чөнки мин аны үзем дә белмим әле.

Илфатка тәтелдәргә тагын җай өстәлде.

— Алайса мин сезне үзебезгә алып кайтам, яме? Килештекме?

Инде Рәмзия сагая калды.

— Сезгә килеп төшәргә мин килештем дә, ди. Өйдәгеләр ни әйтер.

— Хуш киләсез, диярләр. Бүтәнчә ни әйтсеннәр. Безнең өйдә хатын-кызлар батальоны гына. Әнкәй, апам, сеңелем.— Озакка киләсезме соң сез?

— Озакка, Илфат.

Егет тәмам үзләшеп китте һәм, ялгышам дип фикеренә дә китермәстән, ярып салды:

— Белдем бит, болай булгач! Сез — медсестра, Рәмзия иптәш.

Кыз кинәт килеп кагылган жилдән күтәрелә башлаган күлмәк итәген кулы белән басып, җайлап куйды да, Илфатның хаталануын, үзенең медсестра булмавын, укытырга килүен аңлатты. Егеткә монысы да бик ошый иде.

— Алайса күңелегезгә язып куегыз инде: сез Гөл-Төркемгә бөтенләйгә киләсез. Безнең авылга килгән укытучы кызлар китми. Сезнең язмыш та шундый булачак...

Рәмзия башын кыңгыр салып, дилбегәсен тарткалап үгезне ашыктырырга маташкан Илфатка сәерсенеп карап алды.

— Күрәзәчеме әллә сез? Мине монда төпләнеп калырга мәҗбүр итәрлек нинди көч бар дип беләсез?

— Мин күрәзәче түгел, ырым-шырымнарга да ышанмыйм, ну күңел сизә минем, изге тамыры бар. Сезне Гөл-Төркемгә тартып алачак магнитны беләм мин.

— Кай тирәләрдә икән ул магнит? Андый көчлесе Курск тирәсендә диләр түгелме соң?

— Менә монда, минем йөрәктә ул, Рәмзия!

Шулай диде дә, егет шүрли үк калды. Кызый ачуланып, көлтә арбасыннан төшеп калмасын тагын. Тигәнәк кебек сарылу ярап беткән эш түгелдер ул, әй!

Бәхеткә, Рәмзия боларның һәммәсен уенга алды һәм тагын бер матур итеп көлеп куйды. Илфат моңа чын-чыннан шатланды. Шунда баядан бирле теленнән тартып килгән сүзгә ирек куйды.

— Озакка килгәч, бөтенләйгә килгәч, мин сезгә күкеле сәгать ясап бирәм дә бирәм инде, Рәмзия,— диде.— Дәрескә кичекмәскә бик шәп булачак. Күке моңланып алтыны кычкыруга — подъем! Җидене кычкыргач, мәктәпкә җыену башлана... Әкәмәт булачак, Рәмзия, менә күрерсез!..

Илфат күңелендә сабан туй иде. Тик аның арбасы артыннан тезелгән ундүрт олаудагы малайлар теш агартырга, тәтелдәргә керешеп, ашка таракан була яздылар. Моны шундук абайлап алган Детдом Женя (ул икенче арбада кайта) торып басты да, юлдаш кызның авыл ягына караган чагын туры китереп, арткы олаулардагы малайларга кояшта янып, җилдә яргаланган йодрыгын селкеде. Үгезчеләр «гвардиясе»ндә Илфат белән Женя сүзе — закон. Алар урнаштырган кануннарны бозарга батырчылык иткән малайга йодрыкларны тату ихтималы да ерак йөрми. Моны Гөл-Төркем малайлары яхшы белә.

«Үгез машинистлары», тел шомартмый калудан эчләре күгәрер дәрәҗәгә җитсәләр дә, тындылар. Беренче арбада аяк салындырып утырган чибәрнең гайрәтен чигерерлек маймылланулар булмый калды. Бөтенләй үк дәшми булдыра алмагач, кара чутырлыгы өчен Чуен кушаматы алган Гариф җыр башлады:

> Сары каеш, җизле йөгән
> Безнең атларда гына;
> Рәхәт йокы йоклап калдык
> Сабый чакларда гына.

Аңа күрше арбадагы Фырт Гарәфе кушылды. Икесенең дә тавышы тыңлап туймаслык матур, моңлы, күкрәктән чыккан тавыш иде.

«Безнең атларда гына...» Пыяла белән кырып булса да мыек чыгарырга азапланган егет кисәкләренең хыялында ат иде. Атның да канатлысы. Кайчак Тәтешкә, Ташбуага, Тарханга задание ашлыгы ташучы атлар җигелгән арбага утыру тәтегәндә, алар үзләрен самолетта ук булмаса да, автомашинада җилдергән сыман хис итәләр иде. Ат адымы үгез көе түгел шул инде!

Колхоз йорты-ихатасына кайтып, мөгезле кашканы тугаргач, дирбияләрне сарайга кертеп элгәч, Илфат Женяга күз кысты да, бер кулына чыбыркысын, икенчесенә кызның чемоданын тотты. Туташны үзләренә алып китте. Бу вакытта кунарга кая барсын инде кыз бала?! Казаннан Ульяновскига баручы поездддан төшеп калган бит ул, Гөл-Төркемгә беренче кат аяк басуы.

Үгезчеләр тамак кырган, бер-беренә ым каккан булып, тел шартлатып озатып калдылар. Илфат белән Рәмзия шактый юл алгач кына нидер гапләшергә керештеләр, ләкин арттан акырып-бакырып калучы булмады. Женя анда иде шул, Илфатның ахирие. Телеңә салышып кара ул барында!

— Менә кунак алып кайттым!— диде Илфат, әле генә басудан кайтып, юынып йөрүче әнисенә. Шул тавышка Илһамия белән Илшадия дә болдырга чыктылар. Кунак кыз белән өйдәгеләр тиз таныштылар. Рәмзия узган уку елында педучилищеның беренче курсын бетергән дә заочнога күчкән, читтән торып укыячак икән.

Һәммәсе бергә өстәлне урап утырып, туйганчы бәрәңге ашадылар. Сөткә дә изгән булгач, патша сые сыман тоелды. Шөкер, август кергәч, тамакка тилмерү газаплары онытыла башлады. Мул көз җитте. Җәй, Тукай абзый әйткәндәй, матур килде: җил дә вакытында исте, яңгыр да вакытында яуды. Шунлыктан, җиргә ни төртсәң, шул күкрәп үсте.

Колхоз эш көненә аванс бүлгәч, шаулап бәрәңге һәм яшелчә өлгергәч, кешеләрнең йөзләренә төс керде. Фронттан килгән шатлыклы хәбәрләр нур өстенә балкыш булып, кешеләрнең кәефен күтәрде. Уракны да узган елларга караганда кыскарак тоттылар.

Әйе, язгы ашыйсы килеп тилмерү-өзгәләнүләр, шомлы төшкә охшап, каядыр чигенгән кебек булдылар. Мәгәр хәтердән китмәделәр, тиз генә китәргә дә охшап тормыйлар иде. Илфатның йөрәген телем-телем итеп кискәләгән бер хәл, мөгаен, гомеренең ахырына кадәр тынгы бирмәс-

тер. Язгы ачлык китереп кыскач, этисенең куш көпшәле мылтыгын сатты ул.

Үч иткәндәй, апрель уртасында Илшадия авырып түшәккә ятты. Курайга дип киптергән гөл сабагыдай ябыкты сабый. Азрак савыга башлагач: аның: «Ипи булса, ашар идем азрак. Хәл кермәс идеме икән?» дип, өзгәләнүен тыңлап тору Илфат өчен иң зур газап иде. Шуңа күрә, бик кызганса да, мылтыкны сатарга булды. Авызыннан шул хәбәр чыкканның иртәгесен Сәйфи Илгизе килеп тә житте. Бик кәефле иде. Йөзе чалт аяз. Тамак туклыгы шулай итәдер инде. Эре генә сөйләште:

— Дөрес сүзме, мылтыгыңны сатарга булгансың, диләр.

— Сатмыйм, онга алыштырам,— диде Илфат та артыгын мескенләнмәскә тырышып.

— Күпме дисең?

— Ике пот бодай оны.

Илгиз көлгән булды. Аннары:

— Сатарныкын сорамыйсың, Илфат агай-эне. Утыз кадак дисәң, бир бишне, ун булсын.— Илгиз кулын сузып кыстарга керешә. Чырае аптыраган кешегә изгелек кылучыныкы кебек иде.

— Көлмә кешедән!— диде Илфат төксе итеп һәм өйгә керергә борылды. Илгиз аны туктатты.

— Әйдә бир бер потка!

— Пот ярымнан грамм да киметмим.

Шул рәвешле килештеләр. Онны барып ал дигән иде, Илфат:

— Юк инде, мылтык сиңа кирәк, хакын син күтәрә кил,— дип кырт кисте.

Илгиз пот ярым бодай оны күтәреп килде. Мылтыкны алай әйләндерде, болай тулгандырды, бик ошатты. Капкадан чыкканда капылт кына туктады да мактанып алды.

— Мылтыксыз калдың бит, Илфат агай-эне!

Намусына тукынуны, мохтажлыктан кылган эшкә сөенүне Илфат күтәрә алмады, Илгиз кулыннан мылтыкны тартып алырга, онын кире күтәртеп жибәрергә дә ниятләгән иде, сеңелесенең хәлсез тавышы, бәгырь телгәли торган күз карашы исенә төшеп, дуамал уеннан кире кайтты. Шулай да тел тешләп калмады:

— Мылтык китсә, алтатар табылыр, Гаделниса малае! Белеп тор!— дип, капка төбендә горур гына басып калды.

Көннәр үтә, гомер сүтә, ертык киңәя дигәннәр. Ертык, чыннан да, киңәйде. Яңа ашлыкка, яңа бәрәңгегә ялганырга байтак иде әле. Мылтыкка алышкан он бик тиз юк булды. Сеңелесенең хәле әллә ни арулanмады. Тагын икмәк дип тилмергәч, Илфат бу юлы инде әнисенә дә әйтмичә (әнисенең тракгордан кайтып кергәне юк диярлек), этисе биреп калдырган куен сәгатен алды да тимер юл разъездына китте. Поезд килгәч, эшчеләргә икмәк бушатканда алмаштыручы табармын дигән өмет белән барды.

Юлы уңды. Әрнесә дә, уңды дип хисаплады. Әрнү кадәресе көчле иде. Истәлек сәгать ич! Вагон-лавкадагы агай йөрәгеңне умырып алырдай комсыз. Илфат кулына ике кирпеч икмәк тоттырды да: «Әйтер сүзем бетте, энем, бигайбә!» дип, сәгатьне алып калды.

Сеңелесенең куанычы хакына чыдарга туры килде Илфатка. Мондый хәлләр хәтердән тиз генә жуелмый шул, жуелмый...

Инде йокларга ятабыз дигәндә, әлеге дә баягы Илшадия йөгереп керде дә:

— Әни! Мунчада ут бар! Кем микән?— дип куркынды.

— Нинди ут булсын? Күзеңә күренгәндер.

— Ышанмасаң, арт бакчага чыгып кара,— диде кече кызы, әнисенә үпкәли язып.

Әниләре мунчага барып ук карады. Әйләнеп килгәч, Илһамия белән Илшадия бер авыздан:

— Кем анда?— дип сорадылар.

— Кем булсын инде, Илфат. Сәгать белән женләнеп утыра,— диде ана. Тавышында борчылудан битәр улы белән мактану сизелде.— Мин аны чоланга чыгып яткан дип торам бит. Көне буе эшләп тә арый белми. Яшьлек шул, яшь чак, армас чак!..

Иртәгесен Рәмзия мәктәп өендә ялгызы гына торучы укытучы кыз янына күчте. Шунда үзеннән өлкәнрәк хезмәттәше белән торырга булды. Илфат йөрәгендә исә ул басу юлында очраган сәгатьтән үк яши башлаган иде. Йокысын качырды Рәмзия Илфатның. Йокы нәрсә? Бер туймаса, бер туяр. Җан тынычлыгын җуйды егет. Башына — уй, йөрәгенә ут капты. Ай тулганын белмәс, егет булганын белмәс, диләр. Рәмзия очрамаса, гыйшык сәгате сугарын белми генә йөрер иде әле малаең. Урак башланганнан бирле тальянын онытып йөргән Илфат моң тартмасын кулына еш алучан булып китте. Рәмзияләргә дә күтәреп киткәли башлады.

Илфат әрсезләнеп йөри торгач, шуны ачыклады: яшь укытучы да хәйран җырлый икән. Галиябану диярсең. Хәлиле булу гына кемгә насыйптыр?

Илфат үзе уйнап, үзе җырлаганда Рәмзия дә килеп кушылгач, булмәдәш укытучы кыз тыңлап торыр-торыр иде дә, соклануын яшерә алмыйча:

— Пар алмадай пар килгәнегезне беләсезме сез, яшьләр?— дияр иде. Аңа каршы Рәмзиянең:

— Илфат энекәш әле ул миңа,— дигәне дә булды.— Безнең ара ике яшь.

Шулай дигәч, Илфат чәчрәп чыкты.

— Кәгазьдә. Еллар язылышы белән чутласаң,— дияргә ашыкты егет.— Чынлыкта безнең ара, бик беләсең килсә, ундүрт ай. Син (алар «сез» дип җәфалану дәверен үтеп, якын кешеләрчә «син» дип сөйләшә башлаганнар иде инде) ноябрь башында тугансың. Шуннан бер ел гомер үтүгә, январь башында мин дөньяга килгәнмен...

— Тырышма, яме, тырышма! Ничек кенә исәпләсәң дә акны карага чыгара алмассың,— дип куйды кыз.

Рәмзия шулай уенын-чынын бергә кушып, Илфат хисләрен кабул күрмәскә тырышса да, егет аңардан бизәргә уйламады. Яратканнан яра алу да татлы дип тикмәгә әйтмәгәннәрдер, кызның рәнҗетүләрен дә бәхеткә чутлый иде ул. Рәмзия аның белән мәш килеп сөйләшә, уйный-көлә ич. Гармун сайратуын онытылып китепләр тыңлый. Ир-егетләр яуга китеп беткәч, авылның бер дигән гармунчысы булып калган Илфат аның саен өздерә генә. Хәер, Ураз авылы чибәренә ошыйм дип кенә түгел, тыңлаучыга — уйнаучы инде ул. Егерме бишенче елгыларны фронтка озатканда, аны саубуллашу мәҗлесләренә йөрттеләр, аулак өйләргә алып бардылар. Тыңламаса үпкәлиләр, рәнҗиләр, хәтта яныйлар иде. Кемнең инде гармунсыз мәҗлес үткәрәсе килсен? Ут эченә чыгып китәсе авылдашларының гозерен ничек аяк астына саласың?..

## Хатирәләр дәвамы

Августның егерме сигезе иде. Башлангыч класслар өч көннән укый башлыйлар. Рәмзия дә өч көннән чын укытучы була, икенчеләрне укытырга керешә (өлкән классларда дәресләр октябрьда гына башлана, укучылар авыл хуҗалыгы эшләрендә). Иртәгә, ягъни егерме тугызында,

Рәмзия белән педучилищеда бергә укыган күрше авыл кызы, Тәтешкә укырга барганда, Гөл-Төркемдә тукталачак. Кич кунгач, Рәмзия аны Ташбуага озатырга булган. Аннан ул кыз автомашинагамы, аткамы эләгеп, Тәтешкә китәчәк. Шушы уңайдан Рәмзия Илфатны кичке тугызга үзләренә чакырды. Гармунын алып килергә кушты. Кич утырмакчылар.

Укытучы кызның әлеге гозере дип әйтикме, әмере дисәк тә хата булмастыр, Илфатка канатлар чыгарды. Ул иртәгесе көнне житкерә алмый изаланды. Егерме тугызы көнне кояш та бүтәнчәрәк балкып чыкты, үгез дә тыңлаулыга әйләнгәндәй тоелды, күзләре начарлыктан сугышка алынмый калган председатель Кәлимулла абый да бүтән чаклардагы төсле тупас сөйләшмәде кебек.

Ул көнне катлаулы молотилкага көлтәне Зөя аръягыннан ташыдылар. Хикмәт шунда иде: агымсуның аргы ярына тракторны да, катлаулы сугу машинасын да чыгарып әмәл юк. «Үгезләр эшелоны» йөргән дерелди-калтырый торган күпергә техника кертергә МТС башлыкларының да, колхоз председателенең дә башына тай типмәгән. Зөя буе басуы ашлыгын сукмый калдырып та булмый. Фронт икмәк көтә!

Төшкә туктарга дип, көлтә төялгән олаулар белән тезелешеп кайтып килгәндә, умарталык буенда председатель Кәлимулла белән мәктәп директоры, колхоз парторгы Нәвар каршы очрадылар. Күксагыз үстерүчеләр янына барулары икән.

«Кәрван»ны туктаттылар.

— Нихәл, егетләр, бик йончытмыймы?— ди председатель.

— Егетләр сынатырлык түгел,— ди Нәвар апа-парторг. Салпы якка салам кыстыра. Үзе малайларга елмая.

— Кыстырыгыз, апа, кыстыра бирегез, әйдә!— ди өченчеме, дүртенчеме олаудагы малайларның берсе.— Салам безгә көлтәсе белән сыя...

— Ардыруын ардырмый, Кәлимулла абый,— ди икенче бер теллесе,— ну чүтеки кичкә якта көлтә баса башлый.

— Үзең көлтә буе булганга ул!..

Теге малайның юкка теш агартуы түгел, председатель белән житди сөйләшмәкче.

— Рас әгәре, көлтә баса, Кәлимулла абый,— ди ул кырыс кына,— әле бүген дә хәл бетеп тора менә. Үгез жигүчеләргә ипине сигезәр йөз грамм итәсе иде...

Кәлимулла абыйлары да бик житди.

— Аванс бирдек кенә бит әле, наный,— ди.

Малай кул гына селти:

— Өреп очырырга да житмәде лә ул... Умартачы Гаяз бабайдан бурычка алган ике потны түләдек тә умачка да чутлы гына калды...

— Дәүләткә ничегрәк тапшыруыбызга карап, тагын бераз аванс бирә алмабызмы дибез менә. Эш сездән дә тора, тырыша төшегез!

Председатель шулай ди инде ул, аның белән сөйләшкән малай да моны аңламый түгел, тик ашказанына әмер биреп булмый. Ул ипи даулый. Кыштан өшәнеп чыккач, язын адәм балаларының тәнендә май тәмам сызып бетте, яңа бәрәңге белән генә үсеп, ныгып бара торган жанны-тәнне алдап бетерә алмыйсың. Әйтәләр бит, бәрәңге алып барам дип ышандыра, алып кайтырына сүз бирми, ышандырмый икән...

Аллы-гөлле башланган көннең киче Илфат өчен күңелсез булып бетте.

Аръяктан соңгы рейсны ясаганда, Илфатның үгезе «кәрван»ның койрыгында кайта иде. Күпергә соңгы булып керде. Күндәм генә атлый иде. Үзе чыгып житкәч, көлтә арбасы да күпердән чыгып житкәндер дип юрады булса кирәк мөгезбай, капылт кына уңга борылды да, сөзәк ярдан су эчәргә жыенды. Бәхетсезлеккә, арбаның кендеге кыска иде. Алгы уң көпчәк арба астына керде һәм арбаны сул якка әйләнде-

реп ташлады. Бер олау көлтә белән бергә, Илфат Зөягә очып төште. Гомере барга, җәрәхәтсез каласына сәбәп — ике яшьле көлтә сәнәге аның башы яныннан узып китте һәм суга чумды. Ә үгез, бер ни булмагандай, барып су эчә башлады. Корсагы бүлтәеп чыкканчы эчте. аннары озак итеп чишмә челтерәтте. Арбаның алгы көпчәкләре тугымының судагы өлешен ком баса башлаган иде инде.

Малайлар башта шыркылдаша-шыркылдаша көлделәр, аннары күлмәк-ыштаннарын салып, акрын гына агып баручы һәм су сеңеп батарга җыенучы көлтәләрне җыярга кереп киттеләр. Чапайча бер кул белән йөзә-йөзә, көлтә кочаклап ярга чыга тордылар. Көлтәләрне яр буена тезеп салгач, күпердән арбаны сөйрәп китерделәр. Су читеннән арбаның алдына гына җигелгән үгезне алып килделәр. Ул күзләрен шарландырып, «Бәла килеп чыктымыни соң? Булмас ла? Мин менә туйганчы су эчтем, бушандым» дигән шикелле исе дә китми тора бирде.

Илфат суга төшкән тавык белән бер иде. Киемнәренең коры бер җебе дә юк, шуның өстенә комга, балчыкка буялып беткән иде.

Бермә-бер авырайган көлтәләрне бергәләшеп төягәч, Илфат Женя Логинов белән сөйләште. Евгений үз олавын да, Илфатныкын да бушатачак, сусынын баскан үгезне тугарып, камыт, йөгән, ыңгырчак, аркалык, дилбегәне сарайга кертеп бикләргә булды. Илфат чыбыркысын гына алды да, өйгә элдертте. Аның болай ашыгу серен Детдом Женя гына белде.

«Дилбегәне нык тотсам, бу хурлыкка калмаган булыр идем»,— дип уйланды егет. Тормыш дилбегәсен тотарга да гомер дигәнең шулай каккалап-суккалап өйрәткәнен уена китерми иде әле ул.

Өйләренә кайтып җиткәч, егетне яңа хәсрәт басты. Рәмзияләргә бу чалбар белән барып булмаячак. Плащ-палаткадан бозып теккән бу ыштан (ике балак дисәң дә хак) суда бүртеп, торба кебек катып киткән иде. Тиз генә кибәренә өметләнмә дә. Ә ул — карап торган бердәнбер чалбар. Кешелеккә дә шул, эшкә дә. Дөрес, тагын берәү бар диярго була. Ләкин ул бик кыскарган, тубыктан гына. Анысына да риза-бәхил булыр иде, тик ике тезендә ике ямау әллә каян кычкырып торалар. Артында да ямаулыксыз гына типчеп куйган биш тиен бакыр кадәр бер тап бар. Көл дә, җыла да! Җыларга ярамый, җылау егет эшемени?! Көләр хәл юк, сугыш елларында өсте-башы таланмаган кеше аз калып бара. Чакырган җиргә бармый калуны уйга керту дә юк. Нишләмәк кирәк, Илфат кыскарган ямаулы чалбарын, искелеге белән чалбарга тиң, төсе уңган зәңгәр күлмәген киеп кызлар янына китте. Чәчләре кара бөдрә дә соң, арасыннан хафалы җил өрә, кыяфәт тә чамалы. Иңгә аскан тальян да фасонны коткара алмый. Ыштансыз артка каеш билбау төсле...

Эчтән көйрәп, чиксез пошынулары юкка булмаган. Рәмзия гармунчыны сәерсенеп каршылады. Тел күтәреп кыерсытулы сүз әйтмәде ул, мәгәр Илфат килеп кергәч, күзе белән баштанаяк капшап чыкты да чырай бозды. Илфат җир убылса, җир упкынына кереп китәрлек булды. Алай да югалып калмаска тырышты, Зөя буендагы әкәмәтләрне мәзәк калыбына салып, түкми-чәчми сөйләде. Яраткан күңелдә ялган булмый бит.

Бу кичне дә гармун чыңлады, җырлар җырланды, уен-көлке дә булмый калмады. Тик гөлчәчкәгә охшап киенгән Рәмзиянең күңел офыгыннан болытлар таралып бетмәде (гаиләдә төпчек кыз Рәмзиянең киенерлеге бар. Әти-әнисе исәннәр. Әтисе өлкән яшьтә, сугышка бармаган. Умартачы. Тормышлары бөтен — җитеш, түгәрәк).

Саубуллашып, кайтырга кузгалганда, Илфат кунак кызның Ташбуага сәгать ничәләрдә кузгаласын сорашты. Дусты өчен Рәмзия җавап бирде:

— Көтү куганда.

— Иртәрәк тә ярыймы?
— Нигә соравың? Үгез белән илтеп кайтырга җыенмыйсыңдыр бит?
— Үгезгә калса, эш мөгезгә кала инде ул, Рәмзия. Ник соравым әлегә секрет.
Илфатның теләге кызларга бер күңеллелек ясау, яхшылык итү иде. Шул нияте барып чыкса, Рәмзиянең кәефе килми калмаячак. Рәхмәт тә укыр әле. «Менә ичмасам егетлек эшләгәнсең!» диярю..
Өйгә кайткач, кәҗәнкәдәге сандыктан, җыен шара-бара арасыннан кечкенә бер капчык алды. Аның төбендә байтак кына самосад тәмәке бар иде. «Моны бирсәмме, моны бирсәм, Ташбуага гынамы, Тәтешнең үзенә илтеп куячак!»
Илфат аларга килеп җиткәндә, колхозның нәсел айгырларын карачы Низами карт капка биген эшереп, кереп ятарга чамалап тора иде.
— Ни хәлләр, Низами абзый?— диде Илфат килә-килешкә.
— Хәлләр, наный, ару, ну интегүемә юк дару...
Илфат аңлап тора: тәмәкесе беткән, үлеп тартасы килә картның. Анда сугылып баккан инде ул, монда кагылып караган, төпчек тә таба алмаган. Авылда тәмәке кытлыгы башланганга әллә ни гомер. Базарга чыксаң, чуваш хатыннарыннан табып була булуын. Алары да акчага сатмый, он сорыйлар, ярма сорыйлар. Үзендә байлык барын алдан ук сөрән салмыйча, Илфат һаман хәл-әхвәл белешкән булды.
— Йокларга җыенып йөрисеңме?— диде.
— Йокысы качмас иде әле, мать якасына!— диде абзый, борсалана биреп.— Йокы ишәккә тансык. Тартырга юк, энем, үләм, билләһи. Тәтен иму бәхетләренә ирешә алмыйча дөньялардан китте Низами диярләр инде, мәйтәм...
— Һи-и-и! Пүчтәктән тора икән эшең, Низами абзый. Шуның өчен үләләр димени? Мә, тәр берне юан итеп.— Илфат күлмәк астында бүлтәеп торган кечкенә капчыкны тартып чыгарды.
Картның күңеле тәмам күл булды. Каерып ипи кисеп бирсәң, бел дә тор, шул тикле сөенмәячәк. Авызы колакка җитте бит. Чалбар кесәсеннән таслап-бөкләп куйган газета алып ертты, капчык төбенә кул батырып, юан бармак очлары белән самосадны умырды, төрде, төкреклэп ябыштырды да, бармак битләре белән ышкып торгач, «кәҗә боты»н авызына капты. Юан төргән, тешсез авыздан да төшәрлек түгел. Икенче кесәсеннән буш патрон гильзасына тыгылган мамык филтә, чакма таш һәм рашпиль сыныгы алды. Чакма чагып ут әлдерде, көйрәтеп җибәрде. Комсызланып суырган иде, тончыкты, буыла башлады. Кәк-кох килеп йөткереп алгач, Илфаттан сорамый түзмәде:
— Каян тиендең бу байлыкка, наный? Үзең тартмыйсың да бугай бит. Сугыш заманында шул хәтле хәзинә!
— Сорама каян алганын, басмас йөрәк янганын, диләр, Низами абзый.— Илфат тантана итә иде.— Сиңа күчтәнәчкә дигәч, таптым инде.
— Айгырны җигикме?— дип сорады карт барысын да аңлап алып.
— Хәзер түгел, Низами абзый...— Егет эшнең асылын төшендереп бирде.
Низами, килешер-килешмәсен уйлап тормастан (капчык төбендәге самосад аны сихерләгән иде!), тешләгән җирдән өзмәк нияте белән сорады:
— Ничә стакан монда?— Күп дип әйткәнне көтә иде, билгеле.
— Алты. Артыгы белән.
— Мә бишне, бир янчыкны! Кунак кызын Ташбуада калдырам, яшь мөгаллимәне кире алып кайтам. Люцерна чабарга Наратбаш куаклыгына барасы барыбер...
Дус кызын айгыр җигелгән тимер хут арбада озату вакыйгасыннан соң, Рәмзия Илфатка чыннан да нәзакәтлерәк карый башлады. Саран

хисләр күзгә кояш кебек кадерле, егет үзе өчен моннан да артык булуны уена да китерә алмый иде.

Октябрьда Илфат Ташбуага йөреп тугызынчы класста укый башлады. Үгез белән тарткалашудан котылды. Әмма һәр көнне ун километрны барып, унны кайтуы алай ансат ук түгел иде. Тарих, география, әдәбият шикелле фәннәрдән дәресләрне юлда укып-хәзерләп кайта иде ул, язу-сызулары белән өйдә маташты. Чишә алмаган мәсьәләләрне иртәгесен мәктәпкә килгәч, математиканы «су кебек эчә» торганнардан күчерергә калган чаклары да еш була торды. Квартирда торып укыса, Илфат та фән нигезләрен ныграк кимерер иде бәлки, аңа чама юк, юрган кыска. Нәрсә белән түлисең квартир хакын? Налогларны да бәрәңге сатып кына ерып баралар.

Көз шактый пычрак килде. Мәктәпкә кия торган туфли кисәген юлда да сөйрәсәң, атна-ун көн дигәндә «авызын ачачак». Шуңа күрә Илфат, авылны чыгу белән, туфлиларны сала да ялан аяк сыпырта, Ташбуага керер алдыннан, тәпиләрне юып-сөрткәләп, янә кия. Салкын балчык ерып килгән аяклар беренче дәреснең буеннан-буена кымырҗап тора. Аннары онытыла тагын.

Илфат авылны көн яктысында күрми дә. Караңгыда китә, район үзәгенә килеп кергәндә генә яктырып җитә. Караңгыда кайта. Күз бәйләнгәч, юл уңаенда Наратбашның көнбагыш басуына кагыла. Көнбагышларның кечерәк таба кадәр башларын өзеп, орлыгын противогаз сумкасына уа (портфельне шул сумка алмаштыра). Кайткач, бик шәплэп кыздыра көнбагышны. Иртән юл буе шуны чиртеп бара. Юл да кыскара төсле, туклыклы да! Тик кар төшәр алдыннан көнбагыш басуы да бушап калды. Монысы Илфат файдасына түгел иде инде.

Кич кайтып, Илһамия апасы пешергән умачны чөмергәч (әнисе тракторыннан арына алмый), йокы баса. Ә баш астына баллы кашык куярга ярамый! Дәресләр бар, мәктәптә сер бирәсе килми. Ташбуа малайлары, кызлары болай да килеп укучыларга «Авылныкылар!» диебрәк карыйлар. Алар шәһәрнеке, янәсе. Шәһәр дигәннәрендә ике-өч ташпулат бар да, базары зуррак. Хәер, тагын тимер юл станциясе...

Дәресләрне хәзерләп бетергәч тә шөгыль бар. «Нишләсәм дә нишлим, үземнекен эшлим!» дип тотынган шөгыль. Иске күкеле сәгатьне ноябрь башына сайрап тора торган итеп өлгертү мәшәкате Илфат җилкәсенә карчыга булып кунган. Чистартасы, буйыйсы, ялтыратасы да — мә, сиңа булсын!

Тырышкан таш яра дигәннәре хак. Рәмзиягә уналты тулган көнне күкеле сәгать мәктәп квартирасының түр стенасына менеп тә кунаклады. Рәмзия дә, аның өйдәше дә тәти күлмәк кигән сабыйлар кебек шатландылар. Ул күкенең моңлануы! Циферблат түгәрәге өстендәге кечкенә генә капкач ачылып китә дә, бәләкәй күке шуннан башын тыгып тавыш бирә.

Рәмзия үзенең рәхмәтен «Төнге уникене гел көтеп ятырмын инде мин, болай булгач. Туйганчы тыңларга. Иллә дә матур кычкыра соң!» дигән сүзләре белән әйтте шикелле. Илфат Кавказ тауларының да иң биегендә, болытлардан да югары иде бу көнне.

Октябрь бәйрәменең егерме җиде еллыгына дип спектакль әзерләделәр. Мирхәйдәр Фәйзинең «Асылъяр»ын сайлаганнар иде. Борырга да вакыты юк дип тормадылар, моңарчы да сәхнәгә менгәнең бар, үзең җырчы, үзең гармунчы, дип, Илфатны да спектакльгә катнашырга күндергәннәр иде. «Тавышың да моңлы, яшең белән дә нәкъ Шәрәф» диделәр. Бер-ике көн репетициягә килә алмаган иде, парторг Нәвар апа үзе сөйләште:

— Репетициягә йөрергә вакытың калмый бугай, Илфат. Чыннан да бик талчыгасың булса кирәк,— диде.

— Бүген килермен инде, апа...— Илфат гаепле кеше сыман партоешма секретареннан күзләрен яшереп кенә җавап бирде.

— Килсәң, әйбәт булыр. Бәйрәм җитте бит. Спектакльне өлгертәсе, халыкның күңелен ачасы иде азрак. Беләсең ич, кайгы-хәсрәт хәттин ашкан.

— Килермен, апа...

Болай дигәч, Нәвар апасы аны тагын да рухландырып куйды.

— Рәмзия һәр көнне йөри. Партнерсыз бик читен, ди...

Егет партоешма башлыгының тел төбен әйбәт аңлап торды. Рәмзиягә тыныч күңел белән карый алмаганын чамалый парторг. Шуңа ерактан суктыра. Ах, Рәмзия чыннан да шулай дип торса икән!..

«Их Рәмзия!— дип өзгәләнде Илфат.— Йокыларымнан син дип уяна башлаганга җитмеш көннән артты бит инде. Син игътибар итми калмасын дип, җырлыйм, уйныйм, шигырь ятлап сөйлим. «Сәхнәдә башың белән йөр!» дисәң анысын да эшлим. Кар өстеннән Ташбуага кадәр яланаяк йөгерергә куш, йөгерәм... Миңа гына ошаса икән ул. Алай түгел, бөтен егет-җилән аның тирәсендә чуалырга җай эзли. Барысы да аңа яхшылык итмәкче, булышмакчы. Илгизне әйткән дә юк... ыспай киенгән, куен кесәсендә сәгать. Буй-сын сабан туе батырыныкыдай. Җиткән егет шул инде ул. Миннән өч яшькә өлкән...»

Партоешма секретарена вәгъдә биргәннең иртәгесен, хәленнән килгәнчә киенгән-ясанган булып, Илфат клубка юнәлде. Сирәк була торган хәл: спектакльдә катнашасы барлык кеше җыелган иде. Ишектән башы күренүгә, Нәвар апа кычкырып әмер бирде.

— Булды, Илфат та килде. Башлыйбыз! Иптәшләр, тынычланыгыз, башлыйбыз,— диде.— Шунда ук Илфатка төбәп:

— Нихәл, Илфат? Килдеңме? Роль күчергән дәфтәреңне онытмадыңмы?— дип сорашып алды.

Тик аның хәл белешүе дә, күзләрен тутырып, җылы караш сирпүе дә Илфатны сөендермәде. Ник? Түр өстәл буенда, Рәмзия янәшәсендә, тимер юлда обходчик булып эшләүче Илгиз Сәйфуллин утыра иде. Тик кенә утырса бер хәл, яшь укытучы янында булуыннан бөтенләй кәефе күккә ашкан. Тулган ай кичәседәй түгәрәк йөзе көлә, имән бармактай юан кара кашлары да, симерүдән ярык кына булып калган күзләре дә көлә.

Илфатка игътибар да итмәгән булды. Тәкәббер! Үзеннән яшьрәкләрне гел малайсытып карый. Рәмзиядән дә ике яшькә өлкән бит. Сугыш тиз генә туктамаса, берәр елдан солдатка эләгәсе.

«Асылъяр»ны укып, рольләр бүлешкән көнне дә, кырыкмаса-кырык сылтау табып, азакта Рәмзия янында бөтерелгән иде. Илфатка хәтта: «Бар, чыгып тор әле, минем сүз бар»,— дип төрттереп куйган иде. Илфат та аңа: «Хәйләң акка кара ямау шул. Секрет-микритларыңны мич башында сөйләшерсең»,— дип, җавап биргән иде. Ярый әле спектакльдә дус егетләрне уйнамыйлар. Илфат — Шәрәф, Илгиз — Габдерәшит. Соңгы пәрдәдә: «Ләлә миннән талак, талак, талак!»— дип, каравыл салдырта Илфат аны. Ләкин анысы сәхнәдә генә булачак. Тормышта әнә ничек, бер өстәл артында кич буе чүкердәшteləр. Ошый, күрәсең, ул Рәмзиягә. Хәер, көнчелекне бер якка куеп исәпләсәң, Илгиз ошамаслык егет мени?! Буй дисәң, буй бар. Төскә дисәң, берәүдән дә ким түгел. Тормышлары таза. Сугыш елында да сыртлары сынмаслык. Шунлыктан өс-баш та шәп, күңел дә көр. Мисыр күгәрченедәй гөлдерәп кенә тора. Плащ-палаткадан теккән бердәнбер чалбарлы егет кисәкләренә тышкы як белән ялтырау кайда! Йөрәк дигәнең генә гаҗәп нәрсә, синең күлмәк-ыштаның фәлән-төгән дип тормый, яратам дип тибә, яратыласы килә дип сулкылдый.

Яшьләр спектакльне әйбәт башкарып чыктылар. Сүзләрен ятлаган иделәр, залга суфлер тавышы бик сирәк ишетелде. Декорацияне дә чама җиткәнче маташтырганнар. Кием-салым эзләп, Гөл-Төркемнең генә түгел, күрше авылларның да астын өскә китерделәр. Аның каравы авыл халкы канәгать булды.

Беренче пәрдәнең иң азагында Илфат:

Бара торгачтын утырдым
Бадьян төпләренә.
Әнекәем бәхил булсын
Имезгән сөтләренә.

— дип Шәрәф җырын җырлаган чакта хатын-кызлар җылап утырдылар.

Спектакль беткәч, парторг апасы Илфатның кулын кысып мактады. Ләкин егет күңеленең шул тикле канатлануының чын сәбәбен төшендеме икән? Ул, барыннан да битәр, Ләләне башкаручы Рәмзия белән кара-каршы уйнау бәхетеннән исергән иде. Илфат спектакльнең озакка, бик тә озакка сузылуын теләсә дә, бетәсе нәрсәнең очы бер җитә икән.

Кичә тәмамлангач, Илфат Маннуров дигән егетнең хыялында табигатьнең иң матур төсләренә манылган бәхете, кул белән сыпырып алгандай, юкка чыкты. Илгиз Рәмзияне озата китте. Алар уеннарга да калмадылар.

Илфат та кайтып ятты. Йокы гына алмады. Әле бер якка, әле икенчесенә әйләнеп ятса да, тынычланмады. Гарьлек буа иде аны, көнчелек калтырата иде. Илгиз белән Рәмзиянең татлы сөйләшүләренә таракан булу теләге кыбырсытты. Бераздан капылт бер карарга килеп, Илфат сикереп торды. Әнисен уятмас өчен мыштым гына киенде дә, чоланга чыкты. Шул минутта мылтыкны сатканына өзгәләнә-өзгәләнә үкенде. Нишләргә? Кәҗәнкәдән иске ачкыч эзләп тапты, вак-төякләр әрҗәсеннән кадак һәм иске шнур алды. Шырпыга кытлык дип тормады, ярты кап шырпының башын кырып, күкертне ачкычка төйде. Шнурның бер башын — ачкыч тоткасына, икенчесен кадакның эшләпәле башына бәйләде. Шуларның барсын телогрейка кесәсенә салып, тыкрык буйлап тегермән очына атлады.

Төн караңгы. Күзгә төртсәң күренми. Йолдызларны болыт юрганы томалаган. Муенга кереп җылынырга өметләнгән төсле, суык җил исә. Аяк тавышы чыгармаска тырышып кына атлады. Бер ара баргач, туктап тыңлады, шылт иткән тавыш та юк иде. Карт-коры изрәп йоклый инде, яшьләр клубтан таралмаган әле.

Рәмзияләр яши торган йорт тыкрык башында, кырыйда. Йортка якынлашкач, Илфат җиргә сузылып ятты. Чекрәеп озак карый-карый, урыс капка буена сыенган ике күләгәне абайлады. Шулар! Илгиз белән Рәмзия! Акрын гына нидер сөйләшәләр, сүзләрен аңлар хәл юк иде. Илгиз ара-тирә көлеп куя. Рәмзиягә берәр кызык сөйли иде, ахры. Кем белсен, бәлки Илфаттан көләләрдер. Йөзем җимешенә үрелергә буе бәләкәй, кулы кыска диләрдер. «Башта күлмәк-ыштан ясап кисен, аннары сөйләшеп карар», диләрдер әле...

Алар күгәрченнәрдәй гөрләшеп торсыннар, ә Илфат салкын җирдә ике бәхетленең рәхәтен сайлап ятсынмы? «Булмас!— дип сөйләнде эченнән генә Илфат.— Егет эше түгел бу!»

Ачу йоту — тау йоту диләр. Маннуровның тау түгел, төймә йотарлык та түземе юк иде. Һич югында өркүләреннән телсез калсыннар, тотлыгып сөйләшә торган булсыннар, дип, күкерт төйгән ачкычка кадакның очлы башын тыкты да, койма буена килеп, кадакның эшләпәле очын коймага китереп бәрде.

Карангылыкны тишеп ут бәйләме бөркелде. Төнге тынлыкны бозган шартлау авазы Зөя буена кадәр таралгандыр сыман булды. Гашыйкларның нишләгәнен уйлап тормастан, Илфат арт бакчалар буйлап өйгә сызды. Кайтып житкәч тә бер кавым колак салып торды. Тегермән очында этләр өргәне ишетелә иде.

Егет чишенеп ятарга жыенганда, Илһамия апасы да кайтып керде.

— Клубта юк идең, кайда йөрдең?— дигән булып төпчәнә башлады. Илфатның ансыз да тыелгысыз ярсыган чагы, ачулы кешегә песи койрык күтәреп йөрсә дә ярамый бит, Илһамиягә тупас кына:

— Синең егетләр белән серләшкәнеңне күзәтеп йөрдем,— диде.

Апасының моңа әллә ни исе китмәде. Үкенеч, зар аралаш мыскыллы көлемсерәде дә, энесенең авызына тастымал тыккандай, бүтән сөйләшергә юл калдырмыйча:

— Бик серләшер идем әле, йөрәк серләремне бүлешер идем, егетләр юк... Сезнең ише малай-шалай белән генә юанмасаң,— дип кырт кисте. Илфатка үч итеп әйтелгән ул сүзләрдә Илһамиянең тирән уфтануы сизелә иде. Әйе, аңлаганга аңларлык...

Әнисе дә уянды. Мәһибәдәр Илһамия белән сөйләшеп алды.

— Әллә ферма буена бүре төшкән инде. Мылтык аттылар, этләр улашты,— диде Илһамия.

— Алла сакласын. Каза ялгыз йөрми. Авыр елларда ни булмас,— дип әнисе дә сукранып куйды.

Иртәгесен мәктәптә ял иде, ә Илфатка ял итәргә туры килмәде. Бригадир Һимматбану апасы таң яралганда ук килеп, тимер юл разъездына кәбестә илтергә баруын гозерләде. «Үгезләр эшелоны»ндагы малайларның берсе авырып киткән икән, аягын каймыктырган диме. Эшләмәгән эшмени, китте Илфат. Кич кайтканда кәбестә алып кайтырмын, ичмасам, диебрәк тә күңүе иде.

Арбалар янәшәсеннән чыбыркы сабы белән кирза итек кунычын кыйный-кыйный атлаганда, малайларның бар сүзе кичәге «театр» һәм Рәмзияләр тыкрыгындагы «атышу» тирәсендә булды.

Күп сөйләгән аз белер. Белгәне дә тыкылдады, белмәгәне дә. Янәсе, Илгизнең Рәмзияне култыклап озата кайтканын Яңавыл егетләре саклап торганнар. Яңавылда Рәмзия дип акылын жуярдай бер егет бар икән. Ул быел армиягә китәсе, ди. Өйләнеп китәм дип әйткән, имеш. «Арабызга кереп, тыкшынып йөрсә, Илгизгә бер пуля житә аңа» дип сөйләгән, ди. Кичә төнлә дә үтермичә китмисе икән дә, клубтан кайтып баручылар комачаулаганнар икән...

Янәсе. Яңавыл егете наганын тоз белән генә корган икән. Илгизнең йомшак жиренә бәреп, адәм рисвае итмәкче, ди.

Тагын әллә ниләр, әллә ниләр... Күп сүзнең даруы — бер сүз. Әмма Илфат чынын әйтә алмый иде ич инде. Тыңлап кына барды.

Яшелчә кабул итү пунктында чират иде. Арттырып та әйтсәң, йөз генә олау тезелгәндер. Атлы олаулар аз, һәммәсе диярлек мөгезле айгырлар. Гөл-Төркем малайлары да, үгезләрне чиратка куеп, лабазлар ышыгына жыелдылар һәм карта «сугарга» керештеләр. Шул араны рельслар буеннан биленә зур гайка ачкычы тагып, кулына чүкеч тоткан Илгиз килеп чыкты. Күнитеге кунычына кечкенә сары флаг урап тыккан. Сары флаг эчендә кызылы да бар.

— Нихәл, авылдашлар!— дип көлеп сәлам бирде ул.— Ярык тояклы айгырларның башы бик каты түгелме?

Очынып-очынып карта уйнаучы Гарәф (шуны уйнап туган диярсең, хәтәр дә кылана), башын күтәреп, Илгизгә карады.

— Безнең хәл ничава, авылдаш.— Гарәф, күзләрен челт-челт йомып торгач, кеткелдәп көлеп жибәрде.— Синең хәл ничегрәк? Чыдарлыкмы? Кичә төнлә Яңавыл егете арт күмәчеңә тоз мылтыгы белән ямаган диләр бит...

Малайлар, командага буйсынгандай, гөрләтеп көлешә башладылар. Илгиз бер кызарды, бер агарды. Аннары теш арасыннан сыгып кына:

— Кем әбисе сөйләде?— дип сорады.

Гарәф бер читкә караган булып:

— Ишетелә ул...— дип төрттерде.

— Минә монысы ишетеләме соң?— Илгиз каерылып Гарәфнең яңак буена чалтыратты. Яңаклау шул тикле көтелмәгәндә килеп чыкты, көлке, шау-шу шып өзелеп калды, малайларның сыны каткандай булды. Гарәфнең ямьсез тавыш белән чинап җибәрүе генә барысын да кузгатты.

— Нигә сугасың син, карун тәресе!

— Әй, карун, чамалабрак маташ. Кулыңны кыскартырбыз без синең!— Чуен Гариф Илгиз каршына җилтерәп килеп басты.— Көчең белән масаясыңмы, карун кыйпылчыгы?!

— Минә моның белән масайсам, ни әйтерсең, чегән арбасыннан егылып калган зина бәрән!

Обходчик егет Гарифка тибеп җибәрде.

Эшләр андыйга киткәч, Илфат та чыдамады, Илгизнең якасына барып ябышты.

— Каян килгән пәһлеван булдың әле син, карун малае? — Илгиз тез башы белән Илфатның корсагына чамаламакчы иде, тегесе баш белән иягенә тамызып өлгерде. Шулай да аңлап торды Илфат: Илгиз бөтереп салачак аны. Шуңа күрә Гарәфләргә кычкырды:

— Гарәф, Гарәф! Килегез, кабыргасын саныйбыз!..

Илгиз чүкече белән селтәнә башлады, ике-өч малай аны аяк чалып егарга, аударгач та күгәргәнче тукмарга исәплиләр иде. Әмма аларга эш калмады. Җир астыннан ярып чыккан төсле, юртагына атланып бригадир, Гарәфнең абыйсы Фәтхерахман килеп туктады. Атыннан сикереп төшүе булды, Илгизнең авызын сугып туздыруы булды. Күрәкүрә килгән икән.

— Әгәр минем братка тагын бер ялгыш орынып киткәнеңне ишкәрсәм, Сталинград ясыйм мин сиңа, карун! Тешләреңне чутларга Бохарадан йолдызчы чакыртырсың. Югал күз каршымнан, җиргә сең! Сине түгел, фашистларны «Әпипә»гә биеттем мин, селәгәй! Баш чүлмәгеңне артка борып куярмын тегеләй!— дип кычкырынды да, ай күрде, кояш алды дигән төсле, юртагына атланып китеп тә барды. Разъезд күршесендәге Петровка поселогы марҗасына самогон эчәргә генә килгән булган, ахры.

Илгиз өчен кешедән көлмәк — үзенә килмәк булып чыкты. Малайлар иркен сулады, тик кәефләре барыбер иртәнге кебек шәп түгел иде инде. Ничек кенә димә, бозылыштылар ич. Фәтхерахман абыйлары да килеп кушылды өстәвенә.

Әкәмәт холыклы ул Фәтхерахман. Дары кебек кабынып китә. Яралангач, акылы-фигыле тагын да текәрәккә әйләнгән. Сул яктан ике кабыргасы юк аның. Аяклары арыш иләгенең төбе кебек, чәрдәкләнеп беткән. Госпитальдән узган кышны, кырык дүртнең башында кайтты.

Разведчик булган. Сөйләвенә караганда да шулай, уң кулының баш бармагы төбенә кытай карасы белән чәнечкәләп язып та куйган. «Развищик» дигән. Фашистларны «биетүе» хактыр, күкрәгендә «Дан» ордены һәм «Батырлык өчен» медале. Аларны һәрвакыт тагып йөри. Кызу көнне майкасына күчерә, кышын юлга чыкканда толыбына кадый.

Бик тырыш кеше. Көнне төнгә ялгап эшли. Гадел үзе, сәбәпсезгә кычкырып эндәшмәс тә. Әммә чәкүшкәң хаксызга кагылса, мәрхәмәт көтә торганнардан түгел. Өендә дә шулай. Бер караганда — ходаның мәхлугы. Канына чеметем генә тоз салдылармы — өермә. Хатыны Миң-

ниса аны чәч уңаена гына сыйпап тора. Кунак ашы — кара-каршы. Фәтхерахман юеш керләрне чемоданга төяп, бәкегә чайкарга төшә, сыер сава, тавык-чебешләрне туендыра. Бәби искеләренә хәтле юа. Әмма җенен кузгатмасыннар! Кызса — кайнар сумала.

Лашчы разъездында булган хәл, төнге «атыш»ның койрыгы кебек, Гөл-Төркемдә бер канат җәеп алды да тынды. Алай да бер-ике көннән уку өендә очрашкач, Рәмзия Илфатка ачуланды:

— Комсомоллар бит сез. Тимер юл буенда тукмашып йөрмәсәгез,— диде.

— Мондый батырлыкка рухландыручы кеше иптәш Сәйфуллин бит, Рәмзия. Аңа киңәш бирергә кирәк,— диде Илфат.

— Бәлки аның белән күптән сөйләшкәнмендер,— Рәмзия Илфатка төксе генә карап куйды.

Шулай да бер атнадан, ягып җылыт, ачып суыт, дип йөртә торган клубта, халык уеннарында очрашкач, Рәмзия Илфатны каршыга биергә чакырды. Егет бу хәлне үзенә күктән төшкән мәрхәмәт буларак кабул итте. Шул төнне Рәмзияне тыкрык башына тикле озата да барды. Тыныч йокы, тәмле төшләр теләп саубуллашканда аңа:

— Мин гомерем буе синең янәшәңдә булыр идем, Рәмзия. Кулымнан килсә, сине бер минутка да янымнан җибәрмәс идем,— диде.

Тәвәккәлләп әйтте әйтүен, ләкин шул мизгелдә чиксез куркуга төште. Хәзер, менә хәзер тупас җавап биреп, бөтен өметләрен кисәр төсле тоелды. Юк, Рәмзия алай итмәде. Илфатның кулын каты кысты һәм:

— Беләм бит мин моны, күптән беләм, Илфат,— дип пышылдады. Гүя шушы пышылдау аның эреп юкка чыгуына әмер иде. Кар көртенә сеңеп, күздән югалгандай булды кыз. Капка ябылу тавышы гына Илфатны татлы хыял дөньясыннан казыкларын тырпайтып утырган читән буена кайтарды.

«Беләм бит мин моны, күптән беләм, Илфат!» Нинди мәгънә яшерелгән иде икән соң бу сүзләргә? Беләм, ләкин син, Илфат, гамемдә дә юк дисеңме? Белсәм ни хәл итим, минем үз дигәнем бар ич инде, дип әйтүе идеме? Әллә булмаса, беләм дә соң, үзең кыюсыз бит, егет булсаң, һаман ут бул син, диебрәк назлануымы?

Илфатның тәмам башы түнде. Озак уйлана торгач, бик яратып укый торган шагыйренең сүзләрен язып, Рәмзиягә кош теледәй генә хат белән эндәшеп карарга булды.

Иртәгесен Ташбуадан укып кайту юлында Рәмзиянең квартирасына сугылды һәм өйдәш кыз да шунда булуга да исе китмәгән кыяфәт белән илче-кәгазьне Рәмзиянең кулына тоттырды. Анда:

...Синең карашыңа бары ут тиң,
Я син аны миннән яшер, кит,
Кырт кисеп әйт миңа: «Булмый»,— диген.
Я ал мине... үзеңә әсир ит!

— дигән юллар язылган иде.

Рәмзия дүрт юлны дүрт тапкыр укыгандыр. Аннары күзләрен тутырып Илфатка карады да, каймактай ак тешләрен күрсәтеп көлде. Шуннан соң:

— Рәхмәт, Илфат! Бу шигырьне мин дә бик яратам,— диде.

Илфат шушы минутларда үзен күз буучы, сихерче алдында басып торган кебек хис итте. Ул эченнән: «Менә аңлап кара син кызларны!»— дип өзгәләнә иде.

Илфатның Рәмзиягә булган тойгыларын дәвасыз сырхау дип атарга гына калды. Шулай да хәтта бу сырхау да тәссезләнеп, каядыр еракка, рәшә артына чигенеп торды бер мәлгә. Әниләре Мәһибәдәрнең үлеме балаларның барсын — Илһамияне, Илфатны, Илшадияне — то-

раташка әйләндерә язды. Көйгән кисәүгә охшап, каралып ябыктылар. Кызларның күз яше түгүләренә тәкать булмады. Илфат исә иренең чәйнәп, бирешмәскә тырышты, ир-ат затыннан икәнлеген исбатларга теләде. Аулакта җылап аның яшь чишмәләре кипкән-корыган иде инде. Газаплы, михнәтле елда килгән шушы бәхетсезлек балаларның канатын аяусыз каерды. Өлештеләр дә калдылар. Йортны тоту унҗиде яшен тутырып кына узган Илһамия иңнәренә төште. Барлык белән калсалар, бихисап мәшәкатьләрдән, моң, сагыштан ул кадәр сыгылмаслар да иде, нужа очына ат кылы таккан чыбыркысы белән арканы каезлаудан туктамый иде шул!

Бәланең башы башлыклардан килеп чыкты.

Зөя аръягында «Яшәр» колхозында катлаулы сугу машинасын эшләтергә трактор калмаган. Җимерелгәннәр, сафтан чыкканнар. Ә запчастьларның әҗәл даруыннан да кыйммәтрәк чагы. Юк алар, табар җае да юк. Тимер чүмәләсе булып утырган җимерек тракторларны ремонтлап, эшкә яраклы иткәнче кимендә ике атна гомер узасы, ди. Шуңа күрә МТС агайлары «Интернационал» колхозындагы тракторларның берсен, нәкъ менә Маһибәдәр Маннурова эшли торган көпчәкле тракторны, ашлык суктырып беткәнчегә «Яшәр» колхозына биреп торырга карар кылганнар. Ул колхозга юл бары тик Зөя аркылы гына. Эшне тиз тотарга әмер бирелгән. Фронт таләпләре исеменнән, сугыш чоры законнарын искә төшереп сөйләшкәннәр. Ашлык була торып, сукмый яткыруның җинаять белән бер икәнлеген әйткәннәр. Менә шул киеренке ситуациядә валлаһига ышанып кына торган күпергә трактор кертергә булганнар. Берәү дә каршы эндәшмәгән, сугыш вакыты кырыслыгы белән күреләсе чараны үз иңенә күтәрергә теләмәгән. Тәвәккәллисе иткәннәр. Күпер өстенә, трактор көпчәкләре астына дип, идәнлек такталар җәйгәннәр. «Кермим бу күпергә!»— дип каршы торса да, бәлки Маһибәдәрне мәҗбүр дә итә алмаганнар булыр иде. Һич югында рульгә ир-аттан берәрсен утыртырлар иде. Маһибәдәр үзе дә, гомере бетәргә язгандыр инде: «Барам, суктырып кайтам «Яшәр»нең ашлыгын. Ирләребез фронтта, аларның тамаклары тук булсын, тизрәк җиңеп кайтсыннар фашист тилчәсен!»— дип батыраеп киткән. Кергән тракторы белән шул күпергә, агымсу буен мотор үкерүенә күмеп алга үрмәләгән. Чыгып җиттем дигәндә генә күпернең текә ярга тоташкан башы ишелгән дә төшкән. Анда, билгеле инде, ат йөзмәле тирән. Трактор тикле тракторның суга ничек чумганын күз алдына китереп була... Маһибәдәр читкә сикерә алмаган. Кычкырырга да өлгермәгән, диделәр. Гәүдәсен су төбеннән көч-хәл белән алып чыкканнар. Тракторны елгадан чыгара алмыйча атнадан артык интектеләр. МТС башлыкларын ай буе прокуратурага йөрттеләр. Төрмәгә утырган кеше булмады булуын. Фронтка икмәк бирик дип тырышканлыкларын искә алганнардыр инде. Ә Маһибәдәр дөньядан китте. Өч баласын, фашистларга каршы якага-яка килеп сугышып яткан фронтовик ирен калдырып китте. Нибары утыз өч яшендә иде әле.

Шундый тетрәткеч фаҗигадан соң, Рәмзия Илфатның якын дусты, сердәшенә әйләнгән кебек булды. Ихластан әйткәндә, яшь укытучының теләктәшлеге канаты каерылган, күңел эчкәресенә кара шом үрмәли башлаган егеткә терәк булды. Тотынып тоткага, таяныр таянычка әверелде Рәмзия. Янәшәсендә кыз булган минутларда Илфат озын, бик озын төннең үтүен, таң сызылуын тойган кебек була иде. Ә таң — ышаныч, әлегәчә күрмәгән, ләкин, әлбәттә, күрми калмаячакмын, дип өметләнгән ләззәт һәм шатлыклар...

Мәгәр шушы куанычка да тутык табы төште. Мәктәп директоры Нәварның Рәмзиягә: «Син Илфатка рухи юлдаш булырга тиешсең, сеңелем, бу көннәрдә. Аның бит син димәгән сулышы юк» дип әйткәнен кайсыдыр китереп җиткерде. Шуны ишеткәч, Илфат янә үртәлә калды:

«Сәдака кошы дип саный мени соң ул мине? Минем мәхәббәт теләнчесе буласым килә мәллә?»

Әмма бу имеш-мимешләрдән үртәлүләр генә Рәмзиягә якты һәм җылы бирергә кабынган учакны сүндерә ала торган булса, аны ярату димәсләр дә иде. Рәмзия Илфатның ятса — төшендә, торса исендә булды.

Декабрь азагында Рәмзиянең Тәтештәге читтән торып уку сессиясенә китәсен белгәч, Илфат кинәт нииндидер салкын бушлык сизгән төсле булды. Кар төшкәләп торган матур гына көн, гүя зәмһәрир суыгын чәчте. Караңгылык та вакытыннан алда төшкәндәй тоелды.

Уку өендә Рәмзияне күргәч, Илфат үзе дә абайламастан:

— Озата барыйммы соң, Рәмзия, үзеңне?— дип сорады.

Кыз шундый итеп карады, аның күз карашында рәхмәт тә, тәкъдимне кире кагу да берьюлы чагылды.

— Рәхмәт, Илфат. Кирәкмәс. Мәшәкатьләнмә. Бүтән кеше озата,— диде.

Илфат җиргә сеңгәндәй булды. Шулай өзелмәгән татлы өмет, чынга ашмаган хыял белән ирешелмәгән максат моңсулыгына уралып яши торгач, кыш та узды, яз килде.

Табигатьтә дә һәрбер яз охшаш булмый. Ил тормышындагы мең тугыз йөз кырык бишенче елның язы, аның май ае исә моңа кадәрге язларның берсенә дә тиң булмады. Безнең ил тормышында гына түгел, бөтен дөнья зиһенендә уелып каласы май иде ул. Җиңү ае, Җиңү язы!

Майның тугызы көнне иртәнге сәгать биштә Илфат аяк өстендә иде инде. Юлда иде, Ташбуага барышы. Мәктәпкә беренче булып килдемме дисә, юк икән. Тоныксу авылыннан классташ дусты Гамил Нургасимов аңардан иртәрәк килеп җиткән. Аның велосипеды бар. Шосседан ун чакрымны ярты сәгатьтә әйттерә генә! Кышларын ул квартирда тора (Илфатның да күз ачкысыз бураннарда һәм язгы юл өзегендә аның янында кунып калган көннәре булгалады).

Бүтән чакта басынкы гына йөрүчән бу мишәр малае бүген үрлекырлы сикерергә әзер иде. Аның иякка таба очлаеп төшкән какча йөзе эчтән нурланып балкый, борын өстенә учлап сибелгән сипкелләренә кадәр биешергә торалар иде. Соры күзләре шатлык чәчә. Куллары да бүген берөзлексез хәрәкәттә. Кыскасы, ябык гәүдәле, озын буйлы бу малай бөтерчек булып бөтерелә. Алар семьясындагы тугыз баланың икесе — өлкән абыйсы Галим һәм зур апасы Сылу фронтта булдылар. Гамилнең абыйсы капитан, өч орден иясе. Сылу апасы — медицина хезмәте лейтенанты, кыр госпиталендә эшли. Сугыш бетү хәбәре Гамил өчен абыйсы белән апасының исән калуы дигән сүз. Ул шуңа чиксез куана. Гадәтенчә, сүзен ярты юлда ташлый, икенчесен, өченчесен башлый.

— Абый да, апа да кайта... Гитлер чыннан да капут...— дип өзми дә куймый сөйләнә. Мәктәп болдырының баскычына бер утыра, бер тора, аннары велосипедына атлана да мәктәп йортын әйләнеп килә, тагын егеттән шатлык ургый башлый.

— Бетте сугыш! Бетте! Кайталар безнекеләр! Их, тормыш!

Җиңү бәйрәме уңаеннан дәресләр булмады. Сөенүнең бик-бик зуры — зарыгып көткән җиңү килүдән, сугышның, ниһаять, бетүеннән иде. Тагын бер сөенү,— ул көнне дәресләр булмады... Өйләргә таралыштылар.

Авылда гадәти эш көне. Селкенердәй тракторлар җир сөрә, бураз-нада кыймылдарлык атлар да сабан сөйри, хатын-кызлар язын чәчәсе мәйданны көрәк белән казыйлар. Колхоз председателе Кәлимулла Алимов хатын-кызларга дәрт өстәмәк булып йөри. «Җиңү бәйрәме хөрмәтенә тагын да тырышыбрак эшлик, иптәшләр! Армиябезнең тарихи

җиңүенә безнең яхшы хезмәтебез җавап булсын!» — дигәнрәк сүзләр сөйли.

Кешеләр сагыш катыш шатлык, юксыну аралаш сөенеч, әрнү белән өретелгән куаныч кичерәләр. Йөзләрдә елмаю, күзләрдә яшь...

Килер көннәргә фараз бер генә: сугыш бетте, тормыш тиздән яхшырачак! Кырык алты, кырык җиденче елларның ничек тилмертәчәген берәү дә уена китерми.

Илфат та, унбишне тутырып узган егет, авыл апаларыннан артыгын күп хыяллана алмады. Төп теләге — әтисенең тизрәк кайтуы, тамак тую, алмашка күлмәк-чалбар булдыру иде. Бу көнгә каршы төндә Берлин янындагы Карлсхорстта, элеккеге Инженерлык училищесы бинасында Гитлер Германиясенең берсүзсез капитуляциясе турындагы Актка кул куелганлыгын тәгаенләп ишетмәгән иде әле ул (авылда радио юк иде). Шулай да җиңүчеләрнең иң мактаулыларыннан берсе безнең маршалыбыз Георгий Константинович Жуков булачагын яхшы белә иде.

Сугыштан исәнлек хатлары килеп торганнарны бүген-иртәгә кайтыр дип көтә башладылар. Хәбәрсез югалды дигәннәрне дә, хәтта дошманга каршы аяусыз сугышып, батырларча һәлак булды, фәлән төштә туганнар каберлегенә җирләнде, дип язу килгәннәрне дә көттеләр. Аналар көтте, яшь киленнәр көтте, балалар көтте. Үлгәнгә чутланганнарның авылны таң калдырып, кайтып төшкән очраклары булды. Хәбәрсез югалып торганнарның исән калганнары булгалады. Мондыйлар өчен шатланулар хәттин ашты. Ә менә сугыш бетте инде дигәндә гомерләре өзелгәннәрнең хәбәре авырның авыры иде. Туксан беренче аерым танк бригадасы составында сугышып, Сталинград һәм Курск дәһшәтләрен кичкән, Днепрның уң ярындагы өермәдә катнашкан, Польшаны азат итешкән, Берлинны штурмлашкан танкист Фәйзерахман Маннуровның Прага операциясендә һәлак булуы турындагы рәсми язу Гөл-Төркемдәге балаларының өчесен бергә дөрләп янган утка ташлады. Хәсрәт ялкынында куырылган бәгырьләргә дәва бар идеме?

Илфатның гармунын алып, тавыш кысып кына уйный-уйный, дивана Җәләлетдиннән откан җырны җырлап утырганын күреп, авылдашлары: «Я хода, бу бала әллә исәрләнәме инде?» дигән чаклар да булды. Җыры йөрәкне пычаксыз телгәли иде:

Казан белән Мәскәү арасы,
Ничә төннәр кичеп барасы;
Бәгырькәйләр чыдый, янмый дөрләп,
Түзсә түзә адәм баласы.

Рәмзия бер ел укытты да үз авылларына китте. Ураз мәктәбендә эшли башлады. Илгиз белән дә аралары өзелгәнгә охшый иде.

Яңа уку елы башлангач, Илфат аңа хат салды. Хат дигәне каяндыр укып истә калдырган дүртьюллык иде.

Йөрәгемдә син, бел, теләгемдә син, бел!
Булсаң икән ике канатым.
Мин бит сине бүгенлеккә түгел,
Гомерлеккә диеп яраттым.

Җавап килмәде...

## Учак көлендә утлы күмер

Илфат, очы-кырые булмастай тоелган хатирәләрдән арынып, больница палатасындагы халәтенә кайтты. «Мәхәббәт бер булса да, ике йөрәктә яшәргә тиеш. Йөрәктән йөрәккә юл яра алмаганга, җавапсыз

гыйшык газабы кичергәнмен мин»,— дип, нәтиҗә ясап куйды ул. Бүген генә ясалган нәтиҗә түгел иде инде бу. Янә бер кат иман китерде.— Шуңа күңелдә яра җөе калган. «Кызыгу да соклану, дәрт кабынгач — утлану» дигән әйтем бар. Әлбәттә, соклanудан башланган мәхәббәт уты иде ул. Күз гыйшкы бер эш, бер-берене тора-бара сынап, белеп ярату гына аңлы да, тирән дә ярату була торгандыр. Олыгайган, салкын акыл белән, яшьлек тыелгысызлыкларын бер читкә куеп торып уй йөртсәң, теге чакта талпынуларның җавапсыз калуы, кем белсен, хәерлегә дә булгандыр. Акылы-фигыле, бүтәннәргә мөнәсәбәте, якынына мөгамәләсе ягыннан еллар Рәмзияне нинди кеше итеп калыплыйсын күрәзәлек итеп белеп булмый иде ич. Бәлки ул гомере буе Илфатка өстән карап яшәр, башны күк гөмбәзенә терәп дөнья көтмәкче булыр, шулай җәзалар иде. Бәлки яшьлек кырыслыгы узар, тормышның касыкка суккалый торуы аны да һавалану чиреннән аралар иде. Бәлки... Ә шулай да ниндирәк икән ул хәзер? Тормыш кешенең фикерләрен генә түгел, холкын да үзгәртүчән. Кайчак үзгәрүләргә айлар, еллар кирәк, кайвакытта атна яки берничә тәүлек тә җитә...»

Рәмзия сәгать дүрттә генә палата ишеген шакыды. Ул беренче сменага эшкә барган иде. Больницага сәгать икегә килеп җитте, ләкин аны кертмәделәр, авыруларның төшке аштан соң ял сәгатьләре иде.

Бусагадан атлауга, Рәмзия туктап калды. Бүлмәнең сул стенасы буендагы караваты янында газета караштыргалап утырган Хәбиб абзыйга, уң яктагы караватны тутырып яткан Илфатка баш иеп сәлам бирде.

— Хәерле көн! Исәнмесез!

— Исәнмесез, исәнмесез, сеңел! Әйдәгез, узыгыз. Илфат янына килүегездер ич?— Хәбиб абзый, бүлмәдәше янына кеше килгәч, гадәтенчә чыгып тору ягын карады. Коридорда байтак әңгәмәдәшләре бар аның. Һәрвакыт шулай: иркенләп сөйләшергә җай калдыра белә, кешеләргә комачау булмаска тырыша.

— Исәнме, Рәмзия!— Илфат аны баш калкытып сәламләде дә, сул кулын изәп, үз янына чакырды һәм карашы белән читтәрәк торган урындыкка ымлады. Шуны алып утыр дию иде.

Рәмзия авыруның янына килеп утырды, кулына тотып кергән сумкасын тумбочка буена куйды, палатаны күздән кичерде.

— Хәлең ничек, Илфат?— Ул сырхауга шул дәрәҗәдә теләктәшлек итеп текәлде, гүя үз саулыгын биреп, бу ир-егетне урыныннан торгызырга, шәһәрнең шаулы урамына алып чыгарга, аннары сөйләшеп туйгач, туган авылы басуларына озатырга җыена иде. Илфат та, аңа күзләрен тутырып, сагынып карады. Механизатор, ихтыярсыздан, еллар томанын ера-ера, үз янына килеп юлыккан хатынны яшьлегендә үк йөрәгенә тамырланган илаһи зат белән чагыштыра иде.

— Хәлләр баһадирларча, Рәмзия, гариплек белән генә сизелми... Ял итәргә куштылар миңа. Минем кияү әйтмешли, айларгамы, елларгамы, әллә гомерлеккәме?..

— Авызыңнан җил алсын, Илфат!— Рәмзия куллары белән ниндидер шомлы җил кагылуыннан сагайган сыман хәрәкәт ясады.— Сәламәтләнерсең, савыгырсың, Илфат. Күңел курыкмый, ышана. Минем күңел алдамый торган иде. Синдәге көч белән, синдәге ихтыяр белән...

Маннуров: «Рәмзия хәзер «синдәге әрсезлек белән» дип тә өстәр, мөгаен», дип уйлап куйды һәм тизрәк егет буласы килеп ашыккан замандагы мәхәббәт әрсезлеген хәтерләп елмайды.

— Карап карыйк инде.

— Врачлар ни диләр соң, Илфат?— Рәмзия сөенечле җавап көтте.

— Өч атнадан безнең хозурдан китүең ихтимал, диләр алар. Өйдә

байтак маташырга туры килер әле. Язгы чәчүгә чыкканчы кеше булып булмастыр, пожалуй...

Рәмзия булдыра алган кадәр Илфатка яшәү дәрте өстәргә тели иде:

— Чәчүгә булмаса, уракка савыгырсың. Артыгын борчылма син, Илфат. Тынгы кирәк сиңа хәзер, тынгы. Мин врач булмасам да әйтә алам, нык йончыгансың син. Рәтле-юньле отпуска да күрмисез бит сез, авыл механизаторлары.

— Отпускысы бар аның хәзер, Рәмзия. Сугыш еллары түгел, сугыштан соңгы еллар да түгел. Юньләп ял итә белмибез, өйрәнмәгәнбез. Ял йортыннан качып кайтканнарым булды.

— Менә шулар чыга инде... Алдагы көндә акыллырак булырсың.

— Һе...— Илфат тагын көлемсерәде.— Йөрәккә приказ биреп буламыни, Рәмзия?!

— Башыңа төшсә, бирерсең. Саулык — байлык, ул булмаса, күктән йолдыз чүпли алмассың...

Тора-бара сүз агышы үз үзәненә төште. Рәмзия Илфатны хезмәт юлындагы гаҗәеп истәлекле вакыйга уңае белән тәбрикләде. «Үземә Герой исеме биргән кебек шатландым!»— диде. Ул Маннуровның һәммә хәлләреннән хәбәрдар икән. Хатирәнең моннан ике ел элек ашказаны рагыннан гүр иясе булуын да, Зөбәйдәнең кияүдә икәнлеген дә белә. Аның кул астында (Рәмзия смена мастеры икән) Илфатлар авылыннан бер кыз эшли. Ул кыз һәр айда Гөл-Төркемгә кайтып йөри, Рәмзия исә аңардан авыл хәлләрен, белешләрнең ничек яшәүләрен бәйнә-бәйнә сораштырып тора икән.

Рәмзия, яшьлегендәгечә, күңелгә ятышлы матур, тик беркадәр сабырлана төшкән бәрхет тавыш белән сөйли. Әүвәлгечә, җанга рәхәт өстәп елмая. Аерма шунда гына, каймактай ак тешләре арасына алтын тешләр кереп оялаган. Тик ул аларны «Авызым тулы хәзинә!» дип мактаныр өчен, сәламәт тешләрне җимертеп куймаган, зарурияткә буйсынып эшләгән. Шомырт кара күзләре дә гел шул. Әмма аларда ниндидер сагышмы, моңсулыкмы, әллә алҗумы бар. Кашлар һаман кыйгач, чәч толымы әле дә булса сокланып карарлык. Гәүдәгә юаная төшкән. Сугыш елларындагы нечкә билле кыз түгел инде. Чигә чәчләре көмеш җепләр белән аралаша башлаган. Кара чәчтә кырау тизрәк сизелүчән. Яшьлегендә Рәмзия иннек-пудрага табынмый иде, бизәнмичә дә чибәр икәнен аңлагандыр. Хәзер әнә косметиканы ят итмәгәне күренә. Әлбәттә, чама югалтмаган, киртә сикермәгән. Шулай да җуела башлаган төсләрне тулыландыруны кирәк санаган. Ни хәл итәсең, еллар уза, яшь олыгаю ягына каера. Гомер дәфтәреңнең илле өченче битен ачкансың икән, бу дөньяда байтакны кичергәнсең дигән сүз. Чигәләргә еллар кыравы кунса да, маңгайда сырлар күренсә дә, рәнҗер хәлең юк. Әмма Рәмзия сулырга-сүрелергә уйламый да әле. Бик куәтендә.

Киемнәре гәүдәсенә бик ятышып тора. Зәвык белән киенгән (шунсыз гөнаһ булыр иде, җөй остасы, осталарны да өйрәтүче!). Мине күрми калмагыз дип кычкырып торган чәчәк-бизәкләрдән кача икән, тыйнак, чәченә-кашына, йөзенә-күзенә иш килә торган төсләр сайлаган.

Илфатның шулай текәлеп каравыннан ул җайсызланып калды һәм аның игътибарын башкага күчерергә теләп, сүзне икенчегә бормак булды.

— Мин сөйлим дә сөйлим, син тын гына ятасың. Үзеңдә ниләр бар соң, Илфат?— дип куйды ул һәм костюм-күлмәгенең тезбаш тирәләрен сыпырды. Илфат тагын көлемсерәде.

— Әлегә син минем хәлләрне сөйлисең бит, Рәмзия. Минем хакта белгәннәреңне. Үз тормышың турында бер ни дә диярлек әйтмәдең. Ә вообще-то мин — хәбәрсез кеше... Тегү эшендә икәнеңне ишетә белә идем, бүген смена мастеры булуың аңлашылды. Тагын нәрсә? Тормыш-

ка чыккансың да, гафу ит, яшәп китә алмагансыз диебрәк тә колагыма кергән иде. Тормышынданиләр булып бетте, Рәмзия?

Маңгайга бәреп сорау килеп чыкты бугай ла! Илфат шулайрак уйлады. Мәгәр Рәмзия моны сөйләргә мәҗбүр итү дип аңламады, яшьлек танышының үз язмышы белән ихластан кызыксынуы дип кабул итте. Шуңа күрә, тартынмый-тарсынмый сөйләп китте.

Уразда өч ел укыткач, шул авылның Казан төзелеш трестларының берсендә прораб булып эшләүче егеткә кияүгә чыккан Рәмзия. Туйны гөрләтеп иткәннәр, бәхетле яшәп китәргә өметләре зур булган. Тик матур төсләргә манылган ул өметләр чынга ашмаган. Кырый-кылтыктан акча керә торгач, прораб типтереп көн итәргә күнегеп киткән. Семьядан күңеле купкан. Үзе, минем күңелгә киртә юк дип, узынган, өстәвенә көнче күбәләк булып тинтерәткән. Нахакка бәйләнеп, шикләнүләреннән арына алмыйча хатынының җанын кыйнаган. Уллары тугач та тынмаган.

Рәмзиянең кояшлы көннәре томанлы төнгә әйләнгән. Авызым тулы кан булса да төкермим, сер бирмим, кеше көлдермим, дип чыдаган. Шулай да көннәрнең берендә сабыр канатлары сынган. Ирсез хатын исемен күтәрүнең таш йөту белән бер икәнен бик белсә дә, Рәмзия, баласын алып, прорабтан китәргә мәҗбүр булган. Ярый диген, улы туганчы тегү фабрикасында өйрәнчеклек чорын үтеп, тегүче һөнәрен үзләштергән, разряд алган. Педучилище белеме булса да, шәһәр мәктәбендә эшләүне уйламаган да ул.

Яше тулып кына узган сабый белән тулай торакта яшәүнең ни икәнен үзе татып караган кеше генә белә. Баласы яслегә бер көн барса, өч көн авырып тилмерткән. Яшь ананың башы больничныйда йөрүдән арынмаган. Ул кәгазьгә тигән акчаның күләме мәгълүм инде. Ярый әле әти-әниләре ярдәмнән ташламаганнар.

Прораб Рәмзия артыннан килми булмаган, килгән. Килешик дип караган, яхшы торырбыз дип вәгъдәләр биргән. Кискән икмәк кире ябышмаган, Рәмзия кабат кушылмаган.

— Шулай итеп, егерме ике яшьтән, ихтыяри-мәҗбүри дигәндәй, тол калдым мин. Синең каргышың төште, ахрысы, Илфат...— Рәмзия, шаяртуым бу дигән төсле, матур елмайды, әмма шушы елмаю артына поскан моңсулыкны яшерә алмады.

— Сине каргый алмавымны беләсең, Рәмзия.— Илфат моны чын күңелдән һәм үтә җитди әйтте.— Хәтердән китеп тормадың, анысы хак. Күктәге йолдыз төсле дип әйтимме... Көндез күренми, ә барын бар бит ул. Болытлы төндә дә күренми, барын бар...

Бу чагыштыру, рияланмый гына әйткәндә, Рәмзия күңеленә хуш килде. Ул моны сер итмәде дә.

— Кызык сөйләп куясың кайчак, Илфат. «Күктәге йолдыз... Барын бар...»

— Минем сүзем түгел, кайсыдыр китаптан укыган идем. Минем уйга таман килеп торганга әйттем.

— Шигырьләр кыстырып сөйли торган гадәтең барын беләм.

— Тик ул шигырьләр мин теләгән җавапны алып кайтмыйлар иде.— Илфат кинаяле сүзләрне озайтырга теләмәде, озак еллар буе өметләнеп йөргән соравын бирде.— Яшьлектә барып чыкмаган хәлләргә үкенмисеңме, Рәмзия?

— Шуны бик беләсең киләме, Илфат? Үткән-беткән эшләрне...

— Үзем өчен ачыклыйсым килә.

— Терсәк ерак инде, Илфат... Син әйткән йолдыз минем өчен дә кабынды кабынуын. Соңлабрак ләкин. Аякка сыер баскач...

Еллар үткәч, иң катлаулы хәлләр турында да шактый ансат сөйләшеп була икән. Аңлаштылар. Шунда Илфат һич тартынусыз әйтте:

— Ялгызыңа бала үстерү ансат булмагандыр, Рәмзия.

Рәмзия дә бизәп-төзәп тормый гына җавап бирде:

— Әти-әни исән чакта мохтаҗлык күрмәдек. Материаль яктан интегеп яшәмәдек, Илфат. Иң авыры Хәйдәр үсә төшкәч булды. Аның: «Әти белән ник яши алмадың соң, әни?» дип сорап куюлары бәгырьгә пычак сызып җибәргән төсле була иде. Егет булып житкәч, төшенде шикелле. Мине җәзаларлык сораулар бирми башлады. Бик дус яшәдек.

— Ала-а-ай... Хәзер кайда инде улың? Кем ул? Нинди һөнәр сайлады дөньем.

— Түбәндә эшли. Төзелеш инженерлары институтын тәмамлап китергән иде. Утызда инде. Оныгым бар...

— Әби, бабай булу бер дә ерак йөрми икән ул, Рәмзия. Минем кыз да ике егет үстерә.

Моңсу теманы кузгаттылар, гомер кояшының кичке якка авышуы турында сүз китте. Йөрәк дигәнең һич кенә дә картаю белмәсә дә, оныкларың тирәндә чуала башлагач, картлыкны әледән-әле исеңә төшерми булмый шул.

— Картаябыз инде,— диде Рәмзия.— Аңардан качып котылыр хәл юк. Картаерга акча да, акыл да кирәкми...

— Акча кирәкми, анысы — дөрес.— Илфат Рәмзия сүзләренең бер өлешен генә кабул итте.— Акыл кирәк. Бик кирәк. Акыллы булып картайсак икән, Рәмзия. Картлар акылга таманрак булса, яшьләргә көч килә...

— Сүз чыккач кына әйтүем...

Илфат үзен кызыксындырган сорауларга җавап алып бетермәгән иде әле.

— Яшәвең кай тирәдә?— дип сорады.

— Мәскәү районына керәбез хәзер. Декабристлар урамында. «Таң» кибете артында ук. «Химиклар культура сарае» тукталышында. Кооператив белән салган йорт. Ике бүлмәле квартира.

— Зурдан купкансың.

— Чират торып квартирлы булулар карап күренмәгәч, тәвәккәлләдем инде, Илфат. Гомер буе тулай торак чыр-чуында яшәп булмый лабаса. Әлеге дә баягы әткәй карт күтәрешге инде...

— Бик бирнәле, бай кәләш булгансың икән, Рәмзия. Яучылар килми тормагандыр?— Илфат уенын-чынын бергә кушып сорады. Рәмзия дә уенга сабыштырып җавап бирде.

— Ансыз булмый инде, Илфат. Бөтенләй үк төшеп калганнардан түгел идек лә!— Алай да житди итеп өстәп куюны да кирәк санады.— Икенче оя корасым килмәде, дөресен әйтим. Баламны кыерсыта калсалар, ни хәлләр итәрмен, дигән уй тоташ тукып торды. Бүген шул мәсьәләне кайтып уйласам да, әйтәм үзем-үзем, дөрес иткәнмен, дим. Улым алдында йөзем ак, вөҗданым тыныч. Инде туйлар узды, туннар тузды...

Әңгәмә байтакка сузылды бугай, һәрхәлдә Илфат талчыгу сизә башлады. Ләкин ул моны Рәмзиягә сиздермәде. Үзенең дә сөйләшәсе килә иде, Рәмзиянең озаграк торуын теләде. Иреннәрен генә ялаштырып алды да, сүзне җай гына дәвам итте:

— Туйлар узды, дөрес. Туннар гына тузмады, Рәмзия. Юк, тузмады. Аларны киеп, өздереп эшлисе эшләр бик күп әле безнең!

— Эшләмәдек түгел инде, безнең хезмәт стажлары, картлар әйтмешли, бисмилла әйтсәң — туярлык. Утыз биш елдан артып китте.

— Бик иртә башладык, рас әйтәсең. Заманы шундый килде. Хәзер кайберәүләр унөч-ундүрт яшендә шыңшымыйча ипи ашый белми, ә без икмәкне үзебез үстердек ул яшьтә. Дөресен әйткәндә, файдадан гайресе булмады аның. Эшсез яши белмәскә өйрәнеп калдык. Ну, алда да эш тау кадәр әле!

— Бик үк тау булмаса да ярамас микән, дим мин. Азрак рәхәт тә кү-

рәсе килә бит...— Рәмзия юри генә, Илфат белән бәхәсләшү кызык булганга гына шулай диде бугай. Әллә чынын әйтәме? Алай дисәң, пенсия сүзен теленә ялгыш та кертеп чыгармый әле үзе. Гомере буе эшләргә риза-бәхил кеше төсле.

— Тау чаклы әле алда эш,— дип кабатлады Илфат.— Дөньядан әҗәтле киту — күңелсез хәл... Үзебез өчен генә түгел, яудан кайтмый калганнар өлеше итеп тә тырышасы бар безнең. Әткәйләр өчен.

— Саулык булсын дип телик, тазалык барында ниятләгәнне эшләрбез.— Ханым, үзе дә сизмәстән, авыр сулап куйды.— Хәзергә сиңа тыныч кына дәваланырга, Илфат. Ярый, мин китим. Килеп йөрермен, ярыймы? Вариска икешәр кат урау читендер, укуы кала бит. Чиратлашып килә торган булсак яныңа?

— Һай, бик мәшәкать булыр ул сиңа, Рәмзия. Алай килешмәс тә, кирәкмәс тә...

— Килештерү кадәресен миңа калдыр, яме. Варис белән расписание төзербез әле без. Аның лекцияләрен, минем сменаны чамалап. Мена бераз күчтәнәч...

Рәмзия, Илфатның ай-ваена карамыйча, алып килгән сый-нигъмәтне сумкасыннан тумбочкага күчерде. Саубуллашып китәргә җыенды. Нәкъ шул вакытта палатага Зөбәйдә килеп керде. Ул да сумкасын бүлтәйтеп күчтәнәчләр, әтисенә кием-салымның чисталарын алып килгән иде.

Рәмзия, гомерендә күргәне булмаса да, Зөбәйдәне бик тиз чамалап танып алды. Маннуровларның олы баласы әнисенә ике тамчы су төсле охшаган иде. Хатирәнең күчермәсе инде менә: аксыл чырай, соргылт куе чәч, зур зәңгәр күзләр. Ике бала анасы димәссең, буе-сыны яшь каен сыман зифа. Хатирә дә шундый иде.

Илфат аларны таныштырды.

— Сез мени инде ул Рәмзия апа? Өлкәннәр авылда әле дә сөйлиләр, укыткан иде бездә бер чибәр Рәмзия, диләр...— Зөбәйдә беркатлылык белән туп-туры шулай әйтте дә салды.

— Яшь чагым иде, сеңелем! Яшьлек үзе чибәр була бит инде ул,— диде Рәмзия, күз алдында кычкыртып мактаудан җайсызланып. Ул китәр җиреннән беразга тоткарланды, Зөбәйдәнең кайда тукталуын сорашты. Уфа поезды соңгарып килгәнгә, Зөбәйдә туры больницага ашыккан иде. Шул ачыклангач, Рәмзия аны үз квартирына чакырды, кәгазь кисәгенә адресын язды, трамвай-троллейбустан төшкәч, үз йортларын ничек табасын тәфсилләп аңлатты. Аннары, ата белән кызның икесен генә калдырып, кайтып китте.

Зөбәйдә, әтисенең кул-аягын күргәч, бөтенләй күңелсезләнеп, боегып калды. Күңеле тулды, күзләренә яшь килде. Авыз ямьшәйтеп, балавыз сыгарга, әтисен борчырга һич ярамаганны Каюм Салихович каткат тукыган иде аңа. Шул кисәтүләрне истә тотып, дөньяны дер селкетеп йөргән әтисенең хәле бик кызганыч тоелса да, батыраерга мәҗбүр булды.

— Узар, әткәй, узар. Карап торырга сәламәт кул-аягыңнан бер аермасы да юк, тиз терелерсең,— дип, сөйләнде кызы. Илфат койкасына терәлеп үк утырган кызының беләгенә үрелде һәм сыйпап алды:

— Син дә юатасыңмы инде, кызым? Юатып азапланма да, бик бетеренмә дә, кызым. Терeләчәкмен мин, шикләнмә. Аякка да басачакмын, тракторын да, комбайнын да йөртәчәкмен, ышанам, ышанычым җилгә очмасын беләм. Вариска да шулай диген. Ул нишләп ята инде бер үзе төп йортта?

— Әйбәт кенә укып йөри. Кичә генә пилмән пешереп ашаттым үзенә.— Кызы Илфатка әйбәт хәбәрләр генә сөйләргә булды.— Аннары безнең ул энекәшнең бөтен эшкә дә кулы ятып тора. Әнкәй булмагач,

өйрәнде ул. Керен дә уа, идәннәрне дә ялт иттереп юа, аш-суны да менә дигән пешерә...

— Өйрәнгәне үзенә,— диде Илфат.— Заманасы булдыксызларныкы түгел, уклау йотып йөргәннәргә чут юк хәзер...

Зөбәйдә этисенә олылар хатына бер дә охшамаган сәлам-хат күрсәтте. Оныкларының өлкәненнән иде ул. Зөбәйдәнең олы улы, дүртенче яшенә аяк баскан Рафистан. Бабасына сәлам юллауның юлын тапкан сабый. Ак кәгазь битенә уң кулын куйган да, әнисе шул кулны карандаш белән йөртеп чыккан. Илфатка бу «сәлам-хат» бик күңелле булды.

— Маладис минем оныгым!— дип җибәрде бабай кеше.— Әнә ничек тырышкан ул!— Баланың баласы балдан татлы дигәннәре хактыр, Илфат оныкларын кайнар бер ярату белән ярата иде. Кеше күңелле аздан була, бик аздан да кала. Ак кәгазьдәге бәләкәй кешенең кул сурәте дә кәефен күтәреп җибәрде Герой бабайның...

— Әтиләре ни эш бетерә соң? — Бу соравын Илфат сагая-сагая гына бирде. Сорашмасаң, килешмәс, дип уйлады ул. Сораша башлап, Зөбәйдәнең күңел сызлавына кагылмагаем, дип тә шикләнде. Әмма кызының җавабы борчуга салырлык түгел иде.

— Әйбәт эшли. Исән-сау. Бу арада станциядән ашлама ташыдылар.

— Тынычлык, иминлекме соң?

— Шөкер әткәй. Зарланырлык берни дә юк.— Зөбәйдә әлеге сүзләрен кәефле әйтте, чыны шулайдыр. Иренең күңеле алгысыган чакларда сөмсере бик коелучан була аның.

— Үзеңнең хәлләр кай тирәдә? Фермада ниләр бар?

— Гадәттәгечә, әткәй. Быел курмыга иркенлек бит, печән елдагыдан байтакка артык. Сөтне яхшы савабыз.

— Шул кирәк тә инде. Менә минем белән ятучы Хәбиб абзый куанып сөйләп торды, сөт, каймак, катыкка кинәндерде әле быел колхозлар, ди. Шундый сүзне ишетүе дә рәхәт. Күңелдә нур арта. Безнең хезмәт шулай куандыра дигән сүз бит кала халкын. Кешеләрне сөендерә алырлык эшләү, вообще-то, уен түгел инде ул, кызым...

— Быел йөкләмәләр дип зурданрак та куптык, ахры...— Зөбәйдә үзенең икеләнүләрен этисенә әйтми булдыра алмады.— Дүрт мең килограмм дип язып кую гына ансат.

— Телеңнән тартып әйттермәгәннәрдер ич. Менә тагын иске авыздан яңа сүз. Былтыр шул чамага җитә яздың, быелга бик чын йөкләмә ул синең.

— Телдән тартып алмасалар да, кыстадылар инде, әткәй. Председатель дә, партком секретаре да: «Кыю бул, алын. Һәммәсе алдында батырып әйт сүзеңне!»— дип үгетләп-өндәп тордылар.

— Ышанганга әйткәннәр. Хәзер артка каранасы түгел инде, кызым. Сүзне җилгә ташлаучылар без түгел ул. Маннуровлар әүвәл-әүвәлдән әйткәннәренә хуҗа була белгәннәр. Күңелеңә васвәсә кертәсе түгел. Тешең-тырнагың белән тырыш, мәгәр иләк авыз, буш сүз булып каласы түгел...

Больница палатасын производство киңәшмәсенә әйләндерүе Илфатка бераздан гына барып җитте. Авырып егылган этисе янына дип сагынып, зарыгып килгән кызыңа сөт арттыру, ярышны көчәйтү хакында акыл сатып тор, имеш. Мәзәк димәсәң. Икенче төрле уйлап карасаң, гел мәзәге юк, сүзләре тормыш тоткасы хезмәт, шул хезмәт юлында бирелгән вәгъдә турында лабаса. Алай да Илфат әңгәмәне бүтән тарафка боруны кирәк тапты: күрше-күләннәрнең хәлен сорашты. Зөбәйдә аларның һәммәсеннән күп сәламнар алып килгән иде. Дивана Җәләлетдин дә сәлам әйткән. «Илфат абый тизрәк терелеп кайтсын!» ди икән (Җәләлетдин алтмышны тутырып килә инде югыйсә, Илфат

аңа һич абый түгел. Ни әйтәсең, яшьтәшләренә дә абый ди, үзеннән кечерәкләргә дә).

Сүз йомгагы сүтелә торгач, Рәмзия апасының ничек килеп чыгуы хакында да сөйләшеп алдылар. Илфат аңлатып бирде, ләкин кызының ул җавабтан бөтенләй үк канәгать булмавын да чамалады. Зөбәйдә хатын-кызларга хас нечкә бер тоем белән нидер сизенә, фараз итә иде. Әтисе исә андый күрәзәлек итүләргә юл калдырмаска тырышты. Балалар әниләренең истәлегенә җил кагылганны өнәмиләр, дигәнне Илфат яхшы белә иде.

Зөбәйдә әтисе янында утырганда, Илфатка кичке аш керттеләр. Әтисенең чәнечкене сул кулга тотып ашый башлавы Зөбәйдәнең күңелен янә чеметкәләп алды. Ул үзенең газиз кешесен канаты каерылган кошка тиңләде. Гомере буена шулай кала торган булса, нишләп кенә бетәр бичаракаем, дип ачыргаланды.

— Үзем ашатыйммы, әткәй?— дип карады Зөбәйдә.

— Кирәкмәс, кызым. Үз кулым белән туйдырыйм әле тамакны!— Илфат күрәләтә сер сынатмас өчен тырыша иде.— Сул кул болай да азрак эшләүчән. Уң кулга авырлык зерә дә күп төшә. Инде сулы да шәбрәк кыймылдасын.

— Бик җайсыздыр бит, әткәй.

— Авыру хәленең җайлы булганын кем күргәне бар? Борчылма, кызым, бер дә. Әткәң солдат булган кеше, әмәлен табар. Чыдамлык белән әрсезлекне әҗәткә аласы түгел безгә... Бар, кайт Рәмзия апаңнарга. Үпкәләр югыйсә. Кайт, сулу ал, ял ит...

— Иртән киләм дә төштән соң поездга төшәм инде мин...

— Шулай итәрсең, кызым...

Кызы каршында батырайса да, ул киткәч, Илфат сүрелеп-сәлперәеп ятты. Сүз дә күп булды бүген, уй да күп булды. Әлсерәтте. Кичке аштан кайтып кергән Хәбиб абзыйның «Күңелегез булдымы инде бүген? Кызыгыз да килде» диюенә каршы да кәефсез генә җавап бирде:

— Килделәр, рәхмәт. Балалар әйбәт минем, Хәбиб абзый...— Аннары зар сүзе ычкындырды.— Үземнең рәт юк бит әле...

Төпле фикере булган кешеләр картлыкта да җан яшьлеген саклыйлар. Хәбиб абзый көр тавыш белән рух күтәрерлек итеп әйтте:

— Артыгын ашыкмагыз, Илфат энем. Хәлегез әйбәтләнәсенә шигегез булмасын, тик ашыкмагыз. Бабайлар ни дигән? Ашыккан ашка пешә, диганнәр.

Әлеге әйтемне Илфат беренче тапкыр унөч яшендә чагында авыл диванасы Җәләлетдиннән ишеткән иде.

...Кырык өченче елның кышы. Зәмһәрир суык төн уртасы. Ызба бүрәнәләре, салкынга чыдаша алмыйча, шарт та шорт атышалар. Шакыраеп каткан тәрәзәләр аша төшкән алсу яктылык кояш чыгып килгән чакны хәтерләтә. Кемдер тәрәзә капкачларына таяк очы белән шакыйшакый кычкыра:

— Торыгыз! Шәйхуллалар яна! Пожар!

Әнисе, апасы, сеңелесе, Илфат елан чаккан төсле сикерешеп торалар. Ут алып торыш юк, болай да яп-якты. Киемнәрен таба алмыйлар. Ни эләкте шуны киеп, урамга йөгереп чыгалар.

Шәмәрдән Шәйхулласының өе яна. Карт тракторчы йорты Илфатларның каршы күршесе. Халык җыелган. Авылның олысы-кечесе шунда. Детдом малайлары да чабышып килгән. Янгынны сүндерергә азапланалар. Ләкин кызыл әтәчнең гайрәтләнүенә чик-чама юк. Үч иткәндәй, янгынчыларның пар ат җиккән чанадагы насослары төчкерәнәпошкырына, рәтләп эшләми. Бер читтәрәк торган сәлперәймеш картлар:

— Пожарда я көрәк, я йөрәк кирәк!— дип кычкырынган булалар.

Йорт хуҗасы Шәйхулла абзый, акылын талап киткәннәр диярсең, гел бер сүзне тәкрарлый.

— Түр караватт астында, түр караватт астында...

Авыл Советы председателе Гайшә апа аңардан кат-кат сораштыра торгач, бу сүзләрнең мәгънәсен аңлады тәки: түр караватт астындагы фанер чемоданда яңа өй буралыгына дигән акчалары икән!

Илфатның шуны ишетүе булды, насос эчәгесенең сиптергече астына басып суга манчылуы булды, яныш торган өйгә атылып кереп китүе булды. Халык «Ах!» итте. «Башсыздыр бу Маһибәдәр малае!», «Бетә ләбаса акылсыз!» диештеләр. Илфат артыннан өй эченә ташланган Женя Логиновка да: «Нилҗә! Агунь бит, яныш умришь!» дип кычкырдылар. «Галавасыз икән бу урыс малае да сәпсим!» дип бот чаптылар. Таякка таянып та чак басып торган Сабирҗан карт кына:

— Башлылар тел чарлаганда, башсыз дигәннәре эш майтара инде аның,— дип үзенчә сөйләнеп куйды.

Каршы күршеләргә еш кереп йөргән Илфат түр караватның кай төштә икәнен белә иде. Тончыкса тончыкты, күзләрен төтен киссә кисте, Шәйхулла абзасының чемоданын тәрәзәдән урамга ыргытты. Кире чыгарга борылып, ике генә адым атлаган иде, абынып идәнгә барып төште. Женя күтәреп торгызмаса, җан куәтенә ишеккә сөйрәмәсә, Илфатның әҗәле үкчәсенә баскан иде.

Малайлар ут эченнән чыккач минут үттеме икән, өйнең матчасы ишелеп төште. «Гомерләре бар икән балакайларның!»— дип халык иркен сулап куйды.

Бүреге өйдә төшеп калган иде Илфатның. Кызулык белән һични абайламый аяусыз суыкта басып торды ул. Иртәгесен ике колагы кабартма сыман шешеп кабарды. Ай буе бәйләп йөрергә мәҗбүр булды. Шул вакытта әйтте инде Җәләлетдин: «Ашыккан ашка пешкән!»— диде. Аның уенча, яныш торган ызбада сабыр гына йөрергә кирәк булып чыга иде.

Дөнья көткәндә, тормыш пожарларында ашыгырга ярамаганын, бүрек яндыруның егетлек түгеллеген Илфат соңрак аңлады. Анда да акылы белән генә. Йөрәк дигәнең һәрвакыт акылга буйсынырга теләмәде...

*
* *

Зөбәйдә ике нәни үстереп, механизатор ир карап, колхозның товарлыклы-сөтчелек фермасында сыер савучы булып эшләсә дә, өен зиннәтле сарай кебек чиста-пөхтә тота. Һәр нәрсә үз урынында, юган-җыйган, артык һични юк. Шулай да Рәмзия апасының квартирына килеп кергәч, андагы тәртипкә, зәвык белән җиһазлауга сокланмый булдыра алмады ул. Стенадагы келәмнәр, идәнгә җәйгән паласлар, тәрәзә пәрдәләре — һәммәсе төсе-бизәге белән бүлмәнә бер бөтен итеп тора. Мондый бүлмәләрдә сулышка иркен, күңелгә рәхәт, җан ял итә. Тәрәзә төпләрендәге гөлләрнең февральдә үк чәчәк атып утырулары да рухны бәйрәм иттерә. Серванттагы затлы савыт-саба, махсус шкафтагы китаплар нәкъ кирәгенчә тезелгән. Люстрасы белән торшерына кадәр кабатланмый торган ямь биреп тора.

— Менә шунда яшәп ятам инде мин, Зөбәйдә сеңелем,— диде Рәмзия, кунак чишенеп зал якка үткәч. Хуҗабикә Зөбәйдәгә йомшак киез башмаклар бирде:

— Идән салкын түгел түгелен дә, киеп куегыз әле. Җылы сөяк сындырмый...

Зөбәйдә түрдәге өстәл буена барып утырды.

— Үзегез генә торасызмы, Рәмзия апа?— Аның беренче соравы шул булды.

— Үзем генә, сеңелем. Улым институтны бетергәч, өйләнеп Төмәнгә китеп барды. Кооперативка кергәндә, квартир алырга йөргәндә диюем, Булат та Казанда калса диебрәк исәп йөрткән идем дә... Яшьләрнең дөнья күрәсе килә, китталәр. Күнегелде инде, гел япа-ялгызым яшәгәнмендер төсле... Хәзер, ике-өч минут, чәй өлгертәм.— Ул аш-су ягына кереп китте.

Зөбәйдәнең карыны ачкан иде, чәйләп алу кирәген эченнән хуплап торды.

Бер-берсенең күңеленә ошаштылар булса кирәк, чәйдән соң бик тәмләп, иркенләп сөйләшеп киттеләр. Кырык тармаклы итеп гапләштеләр. Эштәге хәлләр дә калмады, кибет-базар бәяләрен дә телгә алдылар, мода-фасон хакында да сүз булды, балалар үстерү четреклекләренә дә кагылдылар, яшьлектәге истәлекле хәлләр дә телгә алынды. Сүз иярә сүз ялганып, Рәмзия үзенең гаилә тормышы барып чыкмаганын да сөйләде. Тора-бара оныкка килеп җиттеләр. Рәмзия оныгы дигәндә җанын фида кылып торганга охшый, йокы бүлмәсендәге шифоньерның өске бер киштәсеннән альбомнар алып килде, шуннан оныгының фотосурәтен алып күрсәтте.

— Менә ул минем бәләкәч оныгым. Өч яшен тутырды инде. Айдар...

Фоторәсемнән сөйкемле генә бала елмаеп тора иде.

Рәмзия улының, килененең фотокарточкаларын күрсәтте. Альбомнар кузгатудан файдаланып, форсатны ычкындырмыйча, Зөбәйдә сорап куйды:

— Яшь чагыгыздагы фотоларыгызны күрсәтегез әле, Рәмзия апа,— диде ул.

— Рәхим итегез, сеңелем. Алары менә альбомның монысында булыр...

Зөбәйдә Рәмзиянең кыз чагындагы фотоларын озаклап карады. Чыннан да, чибәр булган икән шул Рәмзия апасы! Хәер, ире дә карап кына торырлык матур кеше булган. Берга-бергә гомер генә итә алмаганнар. «Семьядан күңеле купты...» ди бит Рәмзия апасы. Аның бу сүзләре Зөбәйдәне дә борчуга салып алган төсле итте. Ир-атның күңеле йортка каккан казык булса икән дә бит...

Сөйләшә-серләшә торгач, Зөбәйдә, үзенең эчкерсезлегенә бирелеп, Рәмзиянең Гөл-Төркемдә эшләгән елындагы хәлләр белән дә кызыксынды.

— Авылның яшь яшәгән апаларыннан ишеткәнем бар, сез, Рәмзия апа, әткәй белән дус булгансыз бугай. Дөресме шул?— диде.

Мондый сорауны Рәмзия көтмәгән иде, әлбәттә. Ничегрәк җавап бирергә дигән кебек, бермәл иңнәрен җыерып, уйланып торды. Шуннан соң:

— Дуслар идек без аның белән, Зөбәйдә сеңелем,— дип, урау сүз башлады.— Яшүсмер чак дуслары. Мин аның гармун уйнавын, җырлавын бик ярата идем. Бергәләшеп спектакль уйнаганыбыз да булды. Бик кешелекле егет иде әтиегез. Ярдәмчел дигәндә ярдәмчел иде инде. Сезнең авылга беренче тапкыр килгәндә, мине көлтә арбасына утыртып ул алып кайтты. Беренче кичне мин сезнең өйдә кундым. Әбиегез, Маһибәдәр апа, исән чак иде әле...

— Ачуланмасагыз тагын бер нәрсә сорыйм әле, Рәмзия апа.

— Ниткән ачулану ди ул?! Булмаганны!

— Әткәй сезне бик яратып йөргән, диләр. Сез аңа карамагансыз бугай...

— Әй, сеңелем, сеңелем! Алар барсы да яшьлек хыялыйлыклары, барсы да... Тирәндә берничә егет бөтерелүгә алданып, иң кирәге күзгә күренмәүчән була икән ул... Безнең яшь чакларны кем шулай искә ала, сеңелем?

— Әнкәй сөйли иде. Мин тугач, исемемне дә Рәмзия кушарга җыенган булганнар да, аннары никтер Такташ шигырендәге исемне куясы иткәннәр.— Зөбәйдә боларны һичбер төрле сергә санамыйча сөйләде.— Әнкәй белән бик тату, бик килешеп яшәделәр болай. Әткәйнең әнкәйгә ялгыш кына да кыек сүз әйткәнен белмим мин. Әнкәй үлгәч, әткәй үзе дә дөньядан үткәндәй йөрде. Сүзсез калды, йокысы качты, тамактан язды. Бар юанычы эш булды. Хезмәтеннән кайткач, әнинең стенадагы рәсеменә карап әллә ни гомер тып-тын утырыр иде. Харис энемнең, әллә акылына зыян киләме инде әткәйнең, дип куркынган көннәре булды. Мин тормышта бит инде ул чакта, Варис монда, икенче курста укыган вакыты...

Рәмзия дә көрсенеп куйды.

— Күзгә-күз карашып гомер иткән кешеңне югалтып, тол калудан да карарак кайгы сирәктер, сеңелем. Картаймас борын бигрәк тә. Андый чакта йөрәк ярасы тиз генә элпә гартмый, чыйрап китми шул. Андый җәрәхәтнең гомер соңына тикле уңалмавы да бар...

Зөбәйдә этисенең килер көннәренә үз карашын әйтте.

— Нишләмәк кирәк?— диде, Рәмзия аңардан шундыйрак сүз ишетермен дип уйга да китермәгән иде.— Үлгән артыннан үлеп булмый. Калган кеше яшәргә дә, эшләргә дә тиеш. Әткәйгә сүз катканым булды. Бер ел тордың, мәйтәм, ялгызың, ел ярым узды, ике ел була. Болай яшәп бетмәссең, өйләнергә кирәктер, димен... Эндәшмәде. Ул хакта сүз катуны килештереп бетерми. Бездән, балаларыннан җайсызлана торгандыр инде. Тора-торып күнәр иде күнүен, үзе дә шул турыда уйланмый булдыра алмыйдыр. Бәла аяк астында йөри шул, күңелсезлекнең нинди енә дучар булдык. Хәзер инде аңа кияүгә чыгам дип торучы бик табылмас...

Рәмзия Зөбәйдә сөйләгәннәрне илтифатлы тыңлый, үзенең фикер иләгеннән үткәрә һәм: «Бу хатын этисен чын ярату белән ярата, аңа бәхет тели. Шуңа күрә әнисенең истәлегеннән көнләшеп газаплanудан өстен тора, күрәсең. Беркатлы күренсә дә, тирәннән алдыра»,— дигән уен җыйнап утыра иде.

— Табылыр, сеңелем, табылыр.— Хуҗа хатын, кунагының сүзен сүрелдермәс өчен, үз фикерен өстәде.— Илфат тереләчәк тә, эшләячәк тә. Менә күрерсең. Табылган кешесе кадерен генә белә торган булсын.

Рәмзия шулай диде, ә үзе бик күптән сүндегә чутлаган күңел учагында әле дә булса утлы бер күмер көйрәгәнен абайлады.

## Яңа җыр һәм вәхшәт

Даруларның гайрәт-шифасы барлыгына чыннан да ышандырып, больницага алып килүләренә ун көн дигәндә, Илфатның кәефе ярыйсы ук әйбәтләнде. Әлбәттә, әйбәтләнү дигәнне бик үк киңәйтеп җибәрмичә аңлаганда. Сөйләшү кыенлыгы бетте диярлек, кан басымы гадәти хәлгә кайтты. Баш сызлавы кимеде. Уң аяк та ихтыярга буйсына башлар шикелле. Кул исә арулану галәмәтен сиздерергә һич ашыкмый. Бөтенләй тыңлаусыз иде әле. Чит кеше әгъзасыдай. Шул кадәресе менә Илфатны куркуга сала. Савыгу өчен атналар, айлар кирәген акылы белән бик белеп, аңлап торган хәлендә, шиккә кала, килер көннәре нинди рәк булырын хафаланып уйлый.

Бәхетенә, палатадагы күршесе менә дигән. Оптимист Хәбиб абзый, боега белми. Илфатка да шомланыр җай калдырмаска тырыша. Көн аралаш килеп йөрүче Рәмзия дә тормышка бик өметле карауч зат булып чыкты. Илфатка аның килүләре бик тансык. Ул моны үз-үзенә дә ачыктан-ачык әйтергә җайсызлана, мәгәр якташының мөнәсәбәте

аңа дәва икәнлеген тоя. Варисны әйткән дә юк. Студент егет этисен гел рухландырып кына тора. Әле менә кече улы да килеп китәргә җыенуын язган. Сагынгандыр, күрәсең. Өченче көн авылдан колхоз председателе Кәрим Вәлиев шалтыраткан, баш врач белән сөйләшеп, хәл белешкән. Монысын бүлек мөдире Геннадий Иванович әйтте.

Кичә Хәбиб абзый бик теләп, бик юмарт сөйләшеп утырды. Сүз Мәскәүдә барган партиянең чираттагы съездыннан башланды да, үткәннәргә барып ялганды. Илфат үз колхозларының оешу тарихына сәяхәт ясап кайткан шикелле булды.

...Гөл-Төркем — өч йөзгә якын хуҗалыклы авыл. Зөя буена сыенып утырган. Җир шәп бу төбәктә. Туфрак — гөл туфрагы. Гөл-Төркемнеләр, тирә-як авыллар белән чагыштырганда, элек-электән икмәклерәк саналып килгәннәр. Шуңа микән, күмәкләшү дигәндә, дәррәү кубып төшмәделәр. Мең тугыз йөз егерме тугызынчы елның көзендә нибары егерме хуҗалык, атын-арбасын, сабан-сукасын, корама юргандай яткан җирләрен берләштереп, колхоз төзеделәр. Михнәт шулпасын бүтәннәрдән күбрәк эчкән кешеләр иде болар. Артык озак баш ватмадылар. Колхозның тамакны — тук, өсне бөтен итәсен сизенделәр. Дөресрәге, шуны өмет иттеләр. Егерме гаилә башлыгы арасында: «Беткән баш беткән, моннан да начар булмас әле!»— дип, томан ашарак караучылар да булгандыр.

Шул көзне уртак арыш чәчеп калдырдылар...

Утызынчы елны аларга тагын унҗиде хуҗалык кушылды. Алар арасында да: «Агай бара — мин дә барам»,— диебрәк керүчеләр бар иде. Колхозга берләшүнең тулысынча ихтыяри икәнен җентекләп төшендергән документлар игълан ителгәч, күмәк хуҗалыктан чыгып китүчеләр дә табылды.

Утызынчы елның язы онтылырлык кына булмады.

Март башы иде. Башта — үзәк газеталарда, аннары милли матбугатта Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» дигән мәкаләсе чыкты. Анда ярлы һәм урта хәлле крестьяннарның авыл хуҗалыгы артеленә ирекле рәвештә берләшүләренә тагын бер кат басым ясалган иде.

Партиянең Ташбуа канткомы җитәкчесе Хәбиб Гайсин, алдан сөйләшеп, тимерле чанага җигелгән атын колхоз кәнсәләре урнашкан йорт капкасының алкасына бәйләп, өйгә кергәндә, идарәдә беренче председатель Әхмәтҗан Вәлиев белән авыл Советы башлыгы Ярулла Кәлимуллин икәү генә утыралар иде. Ә халык, карга бураны гайрәтләнүгә исе дә китмичә, урам тутырып клубка агыла. Кулакларның җан фәрманга тырышуы бушка китмәгән иде. Авыл җитәкчеләренең йөзендә аптырау. Ярулла бөтенләй аптырап калган. Әхмәтҗан яшькә дә олы, дөньяны да күбрәк күргән, авылдашлары белән сөйләшеренә ышана, шулай да сүзнең авыр буласын белеп тора, борчыла.

Кантком җитәкчесе килеп кергәч, авыл башлыклары күңелендә ышаныч беркадәр ныгыды ныгуын. Шулай да Әхмәтҗан булып Әхмәтҗан да исәнләшкәч әйтә куйды:

— Итәк астыннан ут уйнаталар, иптәш Гайсин,— диде.— Бу мәкалә чыккач, кулаклар прәме канатланды, арыслан булып айга сикермәкчеләр. Тәкать калмады, чыдар чама юк. Тагын ниләр булып бетәр?

Яксаң да җылы тормый, ызба каралмаган иде, кәнсәләр бик суык. Алай да Хәбиб бүреген салып өстәлгә куйды, күпереп торган куе чәчләрен тараштырды, тышлы тунының төймәләрен чиште, аннары урындык алып утырды. Кантком секретарен каршылап аягүрә баскан авыл җитәкчеләре дә утырышты.

— Сине каушап калырсың дип уйламаган идем, Әхмәтҗан абый,— диде Гайсин, гаҗәпсенү катыш канәгатьсезлек белән.— Лена вакыйгаларында катнашкан кеше син, комбедны җитәкләгәнсең. Сыйнфый уяулыгың, политик сизгерлегең бар. Моңарчы ныклык сорап та әҗәткә

керми идең. Әйдәгез, сөйләшик халык белән. Ачыктан-ачык. Аңлашыйк. Мәлҗерәп калу безнең эш түгел...

Җыелышка алар өчәү бергә килделәр. Клуб дигәннәренд эн тер-тер урын да юк иде. Колхозга кергәннәр дә, керергә бөтенләй уйламаганнар да җыелган.

Җыелышны ачып, Сталин мәкаләсен укырга керешкәч, залның бер чатыннан:

— Ишетелми! Үзегезне күрмибез!— дип бәйләнә башладылар.

Хәбиб Гайсин әүвәле урындыкка, аннары өстәлгә менеп басарга мәҗбүр булды. Бүтән чарасы юк иде. Колхозлашуга ничек кенә булса да карышуны максат иткән кешеләргә бу җитә калды:

— Өстәлгә менеп басып, ник безне хурлыйсыз?!— дип бәйләнделәр. Батыраеп акыра башладылар.

— Колхоз төзү турындагы протоколны ертыгыз!— дип бугаз киерделәр. Бу инде ультиматум иде.

Тартыша торгач, ике сәгатьтән артык вакыт узды. Гайсин бер карыш та чигенмәде. Әхмәтҗан Вәлиев тә нык торды. Мәкаләне укып чыктылар, бәйнә-бәйнә аңлаттылар. Моның мәгълүм бер дәрәҗәдә уңай тәэсире булмый калмады, шулай да ярсыган халык тиз генә тынычланмады.

Бер заман, сабан туйларында чабыш атларын каршылагандагы кебек, халык төркеме ике якка аерылып, кемнәргәдер юл бирде. Сәхнә дип йөрткән күперчектәгеләр ни күзләре белән күрсеннәр: егермеләп хатын-кыз аларга таба ажгырып киләләр. Араларында йөкләләре дә бар. Соңрак беленде, аларны котырткannap: «Ни генә эшләсәгез дә сезгә тия алмыйлар»,— дигәннәр. Хатыннарның телендә бер генә сүз: «Ертыгыз пртакулыгызны!», «Безгә колхоз кирәкми!»

Кычкырынып кына калырга да исәпләмиләр, сәхнәгә үреләләр. Әхмәтҗанны тартып төшерергә, кыйнап ташларга ниятләнәләр. Шул чак Хәбиб Гайсин колхоз председателен үз янына бастырды да гөж килгән халыкка кистереп әйтте.

— Һичнинди башбаштаклыкка юл куелмаячак, шуны бик яхшы белеп торыгыз! Сыйнфый дошман коткысына бирелеп, колхоз башлыгына кул ягучы була калса, каты җавапка тартылачак. Шушыннан ук алып китәчәкбез!— дип катгый кисәтте. Аңлы рәвештәме, әллә ярсуы житкәнгәме, кабурасын да капшап куйды.

Сүз озак барды. Җитәкчеләр алты сәгать буена әсирлектә калган кебек тордылар. Ахырга таба колхозга беренчеләрдән булып язылган Фәйзерахман чыдамады, авылдашларын сабырлыкка өнди башлады.

— Җәмәгать!— диде ул, картларча итеп.— Монда күмәкләшү юлыннан баруның хаклыгына ышанмаучылар бар. Мин менә Советлар эшенә бар булдыгым белән ышанам. Большевик булмасам да, партия эшенә иман китерәм. Ялгышмагыз, уйлагыз, хәл кылыгыз, авылдашлар! Безнең өчен бердәнбер дөрес юл — колхоз...

Бүлдермиләрме соң, Фәйзерахманны да бүлдереп бугаз ертучылар табылды:

— Бүген болай җырлыйсың да син, Күке, атыңны колхозга илткәч, ник мендәр тешләп җыладың соң?— диде, тискәрелеге белән атаклы Карун Сәйфулла.

— Шатлыктан җылау иде ул, Сәйфулла абзый!

Юк, мондый җавап белән дә каршы якның авызын томалый алмады Фәйзерахман, шау-шу тагын көчәеп алды.

Ә былтыр көзен җылавы хак иде бит Фәйзерахманның. Һәм шатлыктан түгел, юртакны колхозга бәгырьләреннән өзеп тапшырудан иде. Председатель Әхмәтҗан абзыйсына ялваруы да хак. «Кантком сатып алырга ат эзли икән. Сат, Әхмәтҗан абзыкай гынам, безнең кашканы!

Анда аны җиңелгә генә җигәрләр, фуражлары да күптер аларның...» Бик теләп, гариза биреп колхозлашкан Фәйзерахманның да тез буыны йомшап алган чагы булды шул, булды. Шуны күзенә төртеп әйтте Карун.

Кашканы колхозга биргәч, өзгәләнү хәлләрен Фәйзерахманның үз этисе — Габдрахман карт авылга фаш итте. Ул май капкан булса, бүген Сәйфуллалар кулында «уен тузы» булмас иде. Нишлисең, Габдрахман абзыйның да биеп торган юртагын үз абзарыннан колхоз конюшниенә чыгарып җибәрәсе бер дә килмәгән иде дә бит, улы үзсүзләнде. Җыласа җылады, атны колхозга бирде...

Утка керосин сипкән тагын бер хәл булып алды. Чыпта Шәйхи, кемнәндер яздырган гаризасын сәхнәдәгеләргә бирде дә, сүз алып такмакларга керешге. Сүзе көмеш булса, теленә салынмавы алтын буласы икән дә бит, сөйләми чыдамады. Заман үзгәрде, күп кеше сөйләргә һәвәсләнеп китте ләбаса!

— Агай-энеләр, җәмәгать, мин дә уйландым, җиде кат исәпләдем. Аркылыга да, буйга да, ие. И карар кылдым: калхузга язылырга! Безнең өчен уйлап тапканнар аны, калхузны. Мин сезне дә язылырга димлим, агай-энеләр! Соңгармагыз, үкенерсез...

Аңа да беренче сорауны бирүче Карун Сәйфулла булды. Шуннан бүтәннәр дә дөрләп кабынды.

— Гаризасыннан башка колхозга ни бирәсең соң син? Анысын ник әйтмисең?— дип бугазладылар.

— Үземне дә, ике күземне бирәм. Карчыгым да эшләр...

Шунда ярсып карадылар инде.

— Бетен бирсенмени?!

— Ватык шешәләрен төяп илтсенме?!

— Нигә кирәге бар аның колхозга, айнымас адәмнең? Авылга бер адәм мәсхәрәсе бит!

— Кеше эшләгәнгә хак алып, аракы чөмермәкчедер... Табылган балимәр кош!

— Шалишь, Чыпта! Якын китермибез сине колхозга!

— Мир кимереп ятмак була. Тотсын капчыгын!..

Чыннан да, Шәйхинең авылдашлары алдында абруе чамалы иде. Чыпта суга, базарга илтеп сата да, акчасы беткәнче сәрхүшлектән арынмый йөри ул. Аты юк, сыеры юк, тавык та асрамый.

Гауганы бастыру нияте белән председатель Әхмәтҗан:

— Колхозга кабул итәбез икән, чыптаны колхозга сугачак,— дип тә карады, тынычланмадылар. Былтыр көздән үк колхозга кергән Хөснетдин житәкчеләрне аптырашта калдырырлык сүз ычкындырды.

— Чыптаның керүе була калхузга, минем чыгып китүем була. Аның ишеләрне тыгындырып, бөкере чыгарасым юк!— диде...

Шәйхинең гаризасын соңрак карарга булдылар. Бу җыелыш күмәк хуҗалыкка бер генә кеше дә өстәмәде. Шеш тишелде, мәгәр шеш урыннары тиз генә ямалыр төсле күренми иде.

Җыелыштан соң җитәкчеләр Фәйзерахманны чакырып алып калдылар һәм аны Ташбуага тракторчылар курсына җибәрергә уйлауларын әйттеләр. Бу тәкъдимгә Фәйзерахман бик риза иде, ләкин этисе белән килешмичә җавап бирә алмады.

Тимерне кызуында сугучы Хәбиб Гайсин һәм председатель Әхмәтҗан Вәлиев, Габдрахман абзый белән сөйләшергә дип, Маннуровлар йортына юнәлделәр.

Йорт башы сискәнә калды, алай да көтелмәгән кунакларны ак өйгә чакырды. Күкрәк баласы Илфатны кочагына алган Маһибәдәр килен бик тиз кече якка чыгып китте. Өч яшен тутырып килүче Илһамиясе аның итәгенә ябышкан иде.

Гайсинның сүзе ышандырырлык булдымы, авторитет үзенеке ит-

теме, Габдрахман агай мәсьәләнең асылына тиз төшенде, улын тракторчылыкка укытырга ризалык бирде.

— Аллага тапшырдык,— диде тонык кына тавыш белән. Малаен зур эшкә димләүләренә эчтән генә шатлана да, сагая да иде ул.— Кулыннан килсә, укып баксын... Трактор сәгать сүтеп җыю гына булмас түльке...

Хәбиб Гайсин шул көзне Гөл-Төркемгә беренче трактор кайту тантанасында да булды. Булды дип, яңарак кына оешкан машина-трактор станциясеннән колхозга кайтучы беренче могҗиза-машинага бөтен авылның игътибарын юнәлтү кирәклеген үзе әйтте.

Район яңа оешкан көннәр. Август азагы. Колхозлар арыш урагын тәмамлап, сабан ашлыгын уралар. Туңга сөрер чак. Трактор берничә булса да артык буласы түгел дә, кайдан аласың?! Монысына да шатланып туя алмыйлар. «Ызаннарны сөрергә бик шәп булды әле!»— диләр.

Каз үләне баскан олы урамга ике яклап халык сибелгән. Картыяше, хатын-кызы, бала-чагасы. Карчыклар ир-ат күзенә артык чалынмаска тырышалар, туздырып бәйләгән яулык читләре белән авызларын каплап, чышын-пышын гына сөйләшәләр, ә «шайтан арбасы»н барыбер күрәселәре килә. Балаларның күзләрендә очкыннар уйный. Малайларның бер ишесе, авылны чыгып, корыч айгырны Агачбашы юлындагы сыза буенда ук каршылаганнар, хәзер трактор артыннан юырталар.

Тракторчы Фәйзерахман ниләр кичерә? Горурлык-бәхет хисеме, әллә үзен шулай каршылаудан каушап та калганмы? Ни генә димә, шушы яшенә җитеп, аның бу хәтле халык алдына җәяүле килеш тә чыгып басканы юк иде әле. Ә бүген тирә-юньгә гөрелте таратып, сул көпчәк канатына җайлап кадалган кызыл әләмне җилфердәтеп, авыл тарихында беренче тракторны иярләп кайта. «Фордзон»ның тешле-тешле көпчәге артыннан киртләч эзләр кала.

Төрлесен уйлагандыр Фәйзерахман, авыл тарихына, күмәкләшү тарихына эз салам, дип кенә уена китермәгәндер, тракторның ул елларда мәшәкатьле һәм четрекле крестьян хезмәтендә революция символы икәнен генә уйлап җиткермәгәндер.

Хәер, клуб янында башланып киткән җыенда боларны райком секретаре Хәбиб Гайсин үзе әйтте.

— Бу куәтле машинаның кайтуы авылның индустрияләшү юлына, социалистик үзгәртеп кору юлына басуын исбатлый. Хәерле сәгатьтә, иптәшләр!— диде. Хәбиб өздереп сөйләде, күңеле дә, тавышы да көр иде. Килеш-килбәте үк зур эшнең шаһиты икәнлеген раслап торды.— Тракторны йөртүче авылдашыгыз — Габдрахман абзый Маннуров улы — Фәйзерахман иптәш тә буразналар сызып, ызаннарны сөреп кенә калмас, сездә, күмәк хезмәтнең ямен-тәмен тоя башлаган игенчеләрдә, белемгә, фәнгә, техникага мәхәббәт уятыр! Фәйзерахманнар һәр елны арта барачак, ишәя барачак. Монысына шик юк. Авылның киләчәге техникада. Уңыш телик аларга! Барыгызның да эше уң булсын, иптәшләр!

Бу көнне трактор бер тутәрәм дә җир сөрмәде. Бәйрәм икән — бәйрәм, диделәр. Колхозның ун арбасын бер-берсенә тагып, тракторга элэктерделәр дә, арбаларга төялеп урам әйләнделәр. Карт-коры моны килештереп тә бетермәде, аның караvы яшь-җилкәнчәкнең, бала-чаганың күңеле булды. Көпә-көндез, кояш көлеп торганда, Гөл-Төркем урамында җыр яңгырады. Заманның үз җырын җырладылар.

Авыллардан авылларга
Телефон баганасы,
Хәзер иске заман түгел,
Техника заманасы!

Фәйзерахман тракторын колхоз йортына куеп, каравылчыларга тапшырып кайтканда, әнисе чәй өлгерткән, әтисе кешелеккә кия торган киемнәрен киеп алган иде. Өйгә үзенә бер төрле бәйрәм рухы иңгән иде. Мактау сүзенә бик саран һәм килештереп сөйли белми торган Габдрахман абзый чәй янында улына җылы сүз әйтми калмады.

— Булдырдың, улым!— диде.— Булдырдың! Күке нәселенең кулы тракторга да ятканын күрсәттең. Имгәнмә, кысылма гына инде машинаңа. Аждаһа куәте бар үзендә...

Гаилә шатлыгына, колхозга берләшкәннәр сөенеченә киләсе язга кайгы кара канатын салыр, дигән уй бу көнне берәүнең дә башына кереп чыкмады. Ә бәла килде. Язгы матур кичнең бар ямен хәсрәт басты.

...Ул көнне Фәйзерахман күз бәйләнер чакка хәтле сөрде. Инде кайтырга ниятләделәр. Каравылчы белән юлда очраша иделәр. Аркылы елга, икенче төрле атаганда, Коры елга буендагы басу авылдан булырбулмас бер чакрымда. Плугарь егетне дә кайтарып җибәрде Фәйзерахман. «Атлый тор, куып та җитәрмен әле. Каравылчы Хәйрулла абзый да килә төшсен»,— диде. Аучылык даны чыккан Озын Хәйрулла тракторны саклый иде.

Плугарь ярты юлга да җитмәгәндер, эңгер-меңгер эченнән трактор янына ике күләгә килеп чыкты. Аларның берсе мәче житезлеге белән Фәйзерахманга ташланды һәм егетнең аркасына хәнҗәр кадады. Тракторчы әрнүле-газаплы итеп кычкырды да, күпереп торган буразнага ауды. Адәмнәрнең икенчесе аркасына аскан капчыктан чүбек, сүс калдыклары, чүпрәк-чапрак бушатты, алар өстенә калай бидоннан керосин түкте.

— Тизрәк, атаңның арт сөяге сынгыры!— Башлык боермый, елан булып ысылдый иде.

— Шырпы юешләнгән.

— Ах, селәгәй! Үзеңне дә, мине дә харап итәсең бит!— Әмер бирүче гарьлегенә чыдаша алмый акырып җибәрде.— Бир шырпыны тизрәк!

Алар кара ниятләре белән шулкадәр мавыкканнар иде, яннарына якынлашкан Хәйрулланы да абайламый калдылар.

— Әй, кемнәр анда?

Иңендә бүре ядрәсе белән корган мылтыгы була торып шүрли калды сунарчы. Аркасыннан тараканнар йөгереште, тавышы тотрыксызланды. Җанвардан курыкмаган — адәмнән шүрләгән, диләр бит.

Явызларны яшен суккандай итте, ләкин алар хәлне бик тиз чамалап алдылар һәм, ат куәтенә йөгереп, яр астына тәгәрәделәр.

Хәйрулла мылтыгын кулына алды.

— Туктагыз! Атам!— дип кычкырды. Аңа җавап булып яр балчыгының шыбырдап коелуы гына ишетелде. Сунарчы яр астына таба атып җибәрде.

Мылтык тавышы яңгырап тынгач, тирә-якны шомлы тынлык басты. Шунда гына Хәйрулла колагына үзәк өзгеч ыңгырашу ишетелде.

Фәйзерахман сөйләшер хәлдә түгел иде. Кан эчендә. Хәйрулланың да акылы томаланып калган кебек булды. Мылтыгын корды да атты, корды да атты. Патроннары беткәнче. Әгәр явызлар аңа яңә һөҗүм итә калсалар, ул берни дә кыла алмас иде.

Мәгәр мылтык бушка шартламаган булып чыкты. Плугарь егет, тынына кабынып, кире әйләнеп килде.

— Хәйрулла абзый, ник атасың?

— Ут бул. Авылга чап! Ат җигеп килегез! Фәйзерахман үлә. Каданнар!

Көткәндә вакытның минуты сәгатькә әйләнә. Хәйрулла тракторчының исән калырына өмет өзде дигәндә, плугарь егет белән колхоз атларын караучы килеп җиттеләр.

Авыл башында аларны председатель Әхмәтҗан, Габдрахман абзый, тагын берничә кеше каршылады...

Ташбуа врачына мең дә бер рәхмәт! Операциядән соң өч тәүлек буена Фәйзерахман яныннан китмәде. Кеше гомере кыл өстендә иде, әти-әнисе, сабыйлары, хатыны бәхетенә, ул гомер өзелмәде.

Хәбиб Гайсин үзе больницада еш була иде. Җинаятьчеләрне бик тырышып эзләделәр, тик — ни гаҗәп — эзләренә төшә алмадылар. Монысы колхозларда бармак белән генә санарлык тракторчыларны хәвефкә төшерде...

— Үзәк Комитетның утыз дүртенче елгы ноябрь Пленумыннан соң, яңа районнар оештырылгач, мине Буденный районына секретарь итеп җибәрделәр. Әтиегезне шуннан соң күргәнем булмады. Кырык бернең октябрендә үзем теләп фронтка киттем. Фәйзерахман кырык икенең башында китте, дисезме? Алай... Шәп ир иде...

Кичәге әңгәмәсен, сестра кереп төшке ашка чакыргач, Хәбиб абзый шулай түгәрәкләп куйган иде.

Үзе дөньяга килгән өермәле еллар хакында бу гомердә бик күп ишеткәне, байтак укыганы бар Илфатның. Гомере өзелә язып калганны әтисенең дә сөйләгәне булды, әнисе дә еш кына искә төшерә иде. Хәбиб абзый ул вакыйгаларны дәвер агышына, чор сулышына, игенченең эчке дөньясы үзгәрүгә бәйләп сөйли. Шуңа микән, электән мәгълүм нәрсәләр дә бүтән төскә керә, башкача яңгыраш ала, саллырак, мәгънәлерәк күренә башлый.

Җинаятьчеләрнең тотылмавын Илфатның кат-кат фикер бизмәненә салып караганы бар. Эзләрен бик оста яшерерлек кемнәр булды икән ул явыз бәндәләр? Һәрхәлдә, читтән килмәгәннәр бит инде! Авылныкылардыр. Ихтимал, хәзер дә исәннәрдер әле. Шуларның балалары, оныклары белән аралашып, кул бирешеп яшибездер бәлки?!

## Казан туфрагыннан — Прага җиренә

Фәйзерахман Маннуровның мең тугыз йөз кырык икенче елны, март урталарында, МТС аша бирелгән бронен калдырып, армиягә китүенә авылдашлары төрлечә карады.

— Күкенекеләр шулай җилҗаклана бит инде! Бер бүген генә түгел. Батыр булып телгә кермәкчедер,— диештеләр берәүләр.

— Сугышның очы күренми әле, барыбер алмый калмасларын сизеп китә ул. Хәзер китеп барса, ни генә әйтмә — доброволец!— Фәйзерахманның ил-көн алдындагы абруеннан көнләүче кайбер кешеләр шулай сөйләшүдән дә тартынмадылар.

— Ир-егет йөрәге чыдамый, шуңа китә!— дип, кырт кисүчеләр дә булды.

Илфат ул чагында әлеге сүзләрне колагына да элмәде. Ишетсә дә, мәгънәсенә тирән төшенеп, төпченеп тормас иде. Аңа бер нәрсә ачык иде: әтисе фронтка китә. Ут эченә. Китмәсә дә була иде, тылда да тракторчылар бик кирәк, бронь дигәнне бер дә юкка гына бирмиләрдер. Шулай да әтисе китә. Аның әтисе белми эшләмәс...

Кем ни генә сөйләмәсен, Фәйзерахманның сугышка кузгалуын ничек кенә юрамасын, колхозның беренче тракторчысын озатырга ярты авыл диярлек килгән иде. Председатель Кәлимулла абзый артлы чанага нәсел айгырын җигәргә кушкан иде.

Олаучы малайның дилбегә кагуы булды, биеп торган айгыр дәррәү кузгалып китте. Фәйзерахман, яшүсмер чагыннан кулында уйнаткан гармунын сызып җибәрде дә, җыр башлады.

Һаваларда очкан кошлар кебек,
Ярсый-ярсый канат кагынып,
Башлар исән булса, яу басылгач,
Без кайтырбыз сезне сагынып...

Фәйзерахман янәшәсенә хатыны Маһибәдәр дә утырып китте. Әмма аның ирен военкоматка озата баруы түгел иде. Трактор ремонтларга МТСка баруы, уңга каерылган юлга җиткәч, ул төшеп калачак.

Маһибәдәр юл аермасына кадәр араның озын, бик-бик ерак булуын теләп барды, гүя бу аның теләвеннән генә тора иде. «Олы юл Ташбуага илтә, уңга китә торганы — МТСка... Юллар аерылган сыман, безнең язмышларның да мәңгегә аерылуы шулдыр инде...»

Төште Маһибәдәр чанадан, ире белән елап саубуллашты-бәхилләште дә каккан казык кебек юл чатында басып калды. Үкси-үкси Фәйзерахман утырып киткән олау күздән югалганчы карап торды. Үзәгенә суык үткәч кенә, уянып киткән кеше сыман, МТСка таба тәпиләде.

Йорт башы китеп ике-өч көн узуга, ганләсендә зарыгып хат көтә башладылар. Тик Фәйзерахманның беренче хаты апрельнең икенче атнасында гына килде. Гап-гади хат. Өчпочмаклы конвертка «Просмотрено военной цензурой» дигән пичәт басылган. Әмма шушы гап-гади хатның кыйммәтенә чик-чама юк иде кебек.

«Сагынычлы хат башы, сез дә язарсыз каршы.

Сезки җанымнан артык семьяма — хатыным Маһибәдәргә, улым Илфатка, кызларым Илһамия белән Илшадиягә күптин-күп сагынычлы сәламнәремне иртән искән язгы таң җилләре аша җибәрәм.

Сәлам соңында шуны язып узам, билгеләнгән җиргә килеп җитеп урнаштык. Сугыш һөнәренә өйрәнә башладык. Шулай итеп, мин көпчәкле машинадан чылбырлы табанлысына күчеп утырдым булып чыга. Монда бик озакламабыздыр, ахры, алай да хатыгызны менә шушы адрес белән языгыз:...

...Авылда ни хәлләр бар? Ничекләр генә итеп яшәп ятасызлар?

Маһибәдәр! Үз хәлләрең ничек? Ремонтта бик тә биртелмисеңме? Суык гаражда машина астында ятып салкын тидерә күрмә берүк. Матрац сымак итеп сырма сыр трактор астына кергәндә җәяргә дип.

Балакайларым! Сез инде дәү үстегез, акыллы булыгыз. Әнигезнең сүзе — закон, шуны белегез. Мин әйләнеп кайткач, үпкәләшерлек булмасын. Әйбәт укып килә идегез, алда да тырышыгыз.

Шуның белән хатымны тәмам итәм. Сезгә изге теләктә калам. Янә дә кайнар сәлам белән: Маннуров Фәйзерахман булыр.

9 апрель, 1942 ел».

Күңелдән ятларга теләгән төсле, әлеге хатны барсы да кат-кат укыдылар. Чылбыр табанлы гайрәтле машинаның танк булуын да бик тиз төшенделәр. Әтиләренең Казаннан егерме чакрымдагы лагерьда оешып килә торган 91 нче аерым танк бригадасы сугышчысы икәнлеге генә аларга мәгълүм түгел иде.

Казан тирәсеннән Гөл-Төркемгә тагын бер хат җибәрде Фәйзерахман. Ул Беренче Май бәйрәме көнне килеп җитте. Анысында да чук-чук сәламнәр язган, авыл хәлләрен сорашкан иде. Шуның белән бергә, бик тә кызыклы бер хәбәр дә бар иде ул хатта.

«...Без өйрәнеп ята торган җиргә, командирларыбыз янына, бик дәү кеше килеп китте. Мин штаб сагында идем. Шулай булмаса, күрә дә алмас идем. Беренче күргә аптырап калдым. Неужели шул булыр, мәйтәм. Комбриг аңа званиесен әйтеп эндәшкәч, ул икәнлегенә шигем калмады. Вәт, Маннуров, димен үз-үземә, кемне күрер сәгатьләрең дә бар икән. Илфат, син армиягә китәргә җыенып йөрүче егетләр җырлый торган бер җырны һаман көйләп йөргән була идең.

...Армиягә баруымны
Зур бәхет дип саныймын,

— дип. Шул җырның башын искә төшерсәң, эткәң кемне күргәнен чамаларсың...»

Илфат этисе язган җырны тапкырлау таблицасы кебек белә иде. Башы болай аның:

Ворошилов портретын
Күргән саен карыймын...

Илфатның этисе сугыш һөнәренә өйрәнә торган төшкә Советлар Союзы Маршалы Климент Ефремович Ворошилов килеп киткән дигән сүз. Менә кемне күргән аның танкист эткәсе!

Шуннан соңгы хатларында Фәйзерахман яңа җиргә күчүләрен хәбәр итте. Аннан инде Көнбатыш фронтка киткәнлекләре мәгълүм булды. Ут эченнән бер-ике генә җөмләле хат кисәге килеп иреште. Кырык икенче елның сентябрендә танк йөртүче Фәйзерахман: «Мин хәзер Идел капкасын саклашам. Иң хәтәр җирдә сугышабыз. Дөнья хәлен белеп булмый, солдат башына ниләр генә килмәс. Әмма дә ләкин бер әйберне туп-точно беләбез, без җиңәчәкбез»,— дип язган иде.

«Идел капкасы», «Иң хәтәр җир»... Сталинград булмый кай төш булсын?! Маннуровлар гаиләсендә монысын да шундук абайлап алдылар.

Аннары Фәйзерахманнан хатлар килмәс булды. Өйдә борчу, шик, шом хөкем сөрә башлады. Баштарак мәлдә бер-берсеннән: «Хат юкмы?», «Бүген дә юкмы?»— дип сорашалар иде. Ай ярым узгач, ике ай тулып киткәч, Мәһибәдәр балаларына сорау бирмәс булды. «Ни язганын күрербез инде, балакайларның бәгырен телгәләмим»,— ди иде ул. Көндез йөзеннән — елмаю, төннәрен күзеннән йокы качты. Күзгә күренеп ябыкты, сулды Мәһибәдәр. Хезмәте авырлыктан, тамак ягы такытокы булудан гына түгел иде аның кара янып, коргаксып баруы, ире язмышының билгесезлеге аны әчтән кимерә иде.

Балалар да әниләренә «Әтидән хат юкмы?» дип, эндәшмәс булдылар. Җае килгән саен алар Мәһибәдәрнең күңелен күрмәк булып тырыштылар. Үзара шаярышып үртәшүләрен дә оныттылар, тынып калдылар.

Хәбәрсезлеге дүрт айдан ашты дигәндә, Фәйзерахманның исәнлек хәбәре килде. Өйдәгеләрнең сөенешүен күз алдына китерү кыен түгел иде. Куллар чәбәкләнде, чырайларга нур сирпелде, телгә җор сүз керде һәм... шатлыктан күз яше түгелде.

«...Соңгы айларда хат-хәбәр язарга бер дә ара булмады, газизләрем,— дигән иде сержант дәрәҗәсен алган Фәйзерахман.— Мондагы хәлләрне сөйләп тә, язып та аңлатырлык түгел. Җәһәннәм диясе дә, бүтәнне әйтәсе юк. Аждаһа белән бер ул фашист тилчәсе. Тиз генә, җиңел кулдан дөмектерермен, димә. Әмма дә ләкин безнең көчкә чыдый алмый. Арт сабагын укытабыз. Киләсе көннәрдә ниләр күрергә насыйптыр, күрәзәлек итәр хәл юк, шулай да фашист бандитларын кырып-себереп бетерәсебезгә иманыбыз камил.

Бу хатымда үзем өчен бик тә шатлыклы хәл турында бер кәлимә сүз язып узыйм әле. Газеталарда яздылар, хәзер бу сер түгел: шушы елның 28 январенда безнең бригада Красный Октябрь поселогын алды. Без Сталинград читенә килеп җиттек. 2 февраль көнне инде бер карыш та чикмичә шәһәрне саклаган армия сугышчылары белән кушылдык. Шул сугышлар өчен мине «Батырлык өчен» медале белән бүләкләделәр. Белегез, Мәһибәдәр син дә, Илһамия, Илфат, Илшадия сез дә, Фәйзерахман Маннуров медальле танкист хәзергесе көндә. Медаль

үземнең дә, авылдашларымның да, бөтен халкыбызның да батырлыгы билгеседер кебек...

Уйлап очына чыгалмаслык батырлыклар күрсәтәләр монда егетләр. Наумов дигән лейтенант командиры булган танк бер көн эчендә генә дә фашистның 15 пулемет оясын тар-мар итте, кораллар тутырылган 5 землянканы юк итте, ил баскыннарының 120-ләп солдатын-офицерын кырып салды. Шунысы бик жәл, фашист үләтләре аларның танкын жимерделәр. Әлбиттә, танклары шып туктап калгач та, алар соңгы патроннарына кадәр сугыштылар. Гитлерчылар танкны чолгап алганнар да, экипажны плен төшәргә үгетләгәннәр. Танк эченнән: «Без — руслар, исән чакта фашистларга плен төшмибез!»— дип җавап биргәннәр. Шуннан соң фашист вәхшиләре танкны бензин сибеп яндырганнар. Егетләр актык сулуларында «Интернационал» җырлаганнар... Исләрең, акылларың китәрлек батырлык бит бу! Шундый гайрәт, чыдамлык, көч кирәк безнең барыбызга да...

6 февраль, 1943 ел.»

Алдагы көннәрдә дә Фәйзерахманнан хәбәр өзелеп торулар байтак булды. Тора-бара Маһибәдәр дә, балалар да моңа күнектеләр. Сирәк кенә килгән өчпочмаклы сәлам-хатлар Курск дугасындагы мәхшәр хакында, Днепрны кичү өермәләре турында саран гына сөйлиләр иде. Курск янындагы бинниһая зур сугышта катнашып, Фәйзерахман Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде.

Маһибәдәр иренең Польшаны гитлерчылардан арындыру сугышларында катнашуын, Берлинны штурмлашуын, Праганы азат итешүен белә алмыйча вафат булды. Улы белән кызлары исә түр як стенасына эленгән иске картага билгеләр төшерә-төшерә, әткәләре узган юлны тамгалап бардылар, йорт башының, бердәнбер таянычы булып калган әткәләренең җиңеп кайтуын зарыгып көттеләр. Шул көн киләсенә ышандылар.

Ләкин... Прага урамнарының берсендәге сугыш Фәйзерахман Маннуров өчен соңгы бәрелеш булды. Мең тугыз йөз кырык бишенче елның тугызынчы маенда — Җиңү көнендә!— дошманның үзйөрешле авыр орудиесе снаряды аларның Т-34 машинасының башнясын җимереп ыргытты. Шуңа да бирешмәстән, үз артыннан куе төтен койрыгын сузып танк алга барды. Аның пушкасыннан әледән-әле ялкын телләре шартлап чыга торды. Экипаж соңгы көчен, азакны ихтыярын туплап сугыша иде әле. Берничә мизгелдән танктагылар, өсләренә ут капкан хәлдә, җиргә сикерделәр, тик яннарына ук төшеп ярылган снаряд кыйпылчыклары аларны аяктан екты. Батырлар шулай һәлак булдылар...

Әтисенең каберен барып күрү Илфатка тиз генә насыйп булмады. Җиңүнең чирек гасырлык юбилеен билгеләп узган елда гына барды ул Чехословакиягә. Турист путевкасы белән икәүләп бардылар. Моңа кадәр Илфатның да, Хатирәнең дә чит илгә сәяхәт кылганнары юк иде.

Влтава елгасының ике ярына да урнашкан борынгы Прага каласы беренче мәртәбә килүчеләрне таң калдыра. Илфат белән Хатирә дә әлеге агымсу аша салынган күперләргә, мең еллык Градка — Прага Кремленә, Мала Страна кварталындагы паркларга, сарайларга, храмнарга сокланып йөрделәр. Старое Местодагы иске ратуша курантларының чыңы әле дә колакта яңгырый сыман. Башкаланың үзәге — Вацлав мәйданы да бик ошады. Әмма бу илгә, бу шәһәргә килеп төшкән көнне Илфат күңелен иң тетрәткән урын Ольшан зираты булды.

Зират тып-тын иде. Туганнар каберлегенә яңа Чехословакия өчен көрәшеп һәлак булган совет сугышчылары күмелгән. Гөл-Төркем туфрагында туып үскән Фәйзерахман Маннуров та шунда ята.

Илфат та, хатыны да, тын калып башларын игән килеш, кабер алдында бик озак басып тордылар. Ара-тирә үтеп йөрүчеләр аларга ихтирам белән карап узалар иде. Беләләр бит: үзләренең якыннары зиратын эзләп килгән совет кешеләре болар.

Хатирә башына китермәгән иде, Илфат ак ефәк янчыкка салып Гөл-Төркем туфрагын алып килгән булып чыкты. Фәйзерахман дөньяга килгән төп нигездән, утызынчы ел язында аның каны тамган басудан һәм Маһибәдәр кабереннән алган туфрак бу.

Илфат Татарстан туфрагын каберне каймалап үскән чәчәкләр төбенә бушатты, аннары, туган нигезгә сибәргә дип, янчыгына туганнар кабереннән бер уч туфрак алып салды. Аның күңеле тулды, тамак төбендә кайнар төерчек кыбырсыды. Ул күз кырые белән генә Хатирәгә карады. Хатынының яңаклары буйлап яшь бөртекләре тәгәри иде.

— Менә без килдек, әткәй, янына...— Илфатның иреннәре сизелер-сизелмәс кенә кыймылдаша иде.— Сезнең яныгызга килдек, илдәшләр...

Ольшан зиратыннан чыкканда, Илфат катлы-катлы тойгы кичерде. Әткәсе кабере яныннан кузгалып китүе авыр иде. Гомерендә тагын зиярәт кыла аламы ул бу урыннарны, юкмы, ничек әйтәсең?! Шул ук вакытта күңелендә нинди дер ак, саф бер хис тә канат җилпи иде: килделәр бит газиз кешесе күмелгән җиргә, халыкның: үлгәннәрнең кабере бел, дигән васыятен үтәделәр.

Гөл-Төркемгә кайткач, көзен, Хатирә белән Илфат, әтиләре истәлеге итеп, үз бакчаларына әлегә авылда бердәнбер булган эрбет агачы утырттылар. Аның төбенә Praганың Ольшан каберлеге туфрагын салдылар. Урман хуҗалыгыннан алып кайткан эрбет агачы, ел үсәсен ай үсә дигәндәй, Гөл-Төркем җирен үз итте, шәбәеп бара. Гасырлар кичә икән ул. Дөнья иминлеге өчен гомерләрен корбан иткән каһарманнар хатирәсенә үстерергә дип яралган диярсең...

*

* *

Илфат йокысыннан сәер бер халәттә уянды. Җаны бер үк вакытта сөенечле дә, эч пошыргыч та хисләр белән кайный иде. Әтисен күрде ул төшендә. Шуңа сөенгән иде. Төш кенә икәнен чамалап алуга, бик күңелсез булып китте. Кәефкә сөремле юшкын утыргандай булды. Ә әтисе нәкъ сугышка чыгып киткәндәге кыяфәттә иде. Кайры тун, колакчын бүрек, озын балтырлы киез итек кигән. Муенына Маһибәдәр үз куллары белән бәйләгән ак йон шарф ураган. Шул шарф аның кара туткыл йөзен ачып тора. Фәйзерахман янәшәсенә, зур өстәл буена, больница халаты, ямьшәйгән чүәкләр кигән Хәбиб абзый Гайсин барып утырган икән. Аларга каршы якта Илфат үзе һәм кече улы Харис утыралар, имеш. Харис бабасына бер-бер артлы сораулар бирә, Фәйзерахман җайлап, тыныч кына җавап кайтара тора. Илфат, алар сөйләшүеннән кызык табып, бик бирелеп тыңлый. Хәбиб абзый исә, Фәйзерахман сөйләгәннәргә кул куйган төсле, ара-тирә баш кагып тора. Картның йөзендә вәкарь бар. Ул гүя: «Безнең тәрбияне алган буын менә шундый! Тыңла, улым, тыңла!» — ди.

Илфат төшен Хәбиб абзыйга сөйләмәкче булган иде дә, исәплэп карагач, андый ниятеннән кире кайтты. «Төшкә-фәләнгә ышанучылардан булмаса да, күптән үлгән кеше белән янәшә утырганыңны күрдем дигәч, агайның кәефе кырылуы бар»,— дип уйлады.

Харис белән бабасының сөйләшүе кызык кына иде. Ап-ачык истә калганы болайрак:

— Мин, бабай,— ди, имеш, Харис,— тормыш максаты, тормыш

мәгънәсе, бәхет нәрсә икәнен тәгәл аңлатып бирә алмыйм. Күпшы сүзләр сөйләп булыр иде булуын... Ә сезнең бит максатыгыз ачык булган — җиңәргә һәм исән калырга! Әллә сез дә икеләнә идегезме?

Фәйзерахман каймактай ак, тигез тезелешкән тешләрен күрсәтеп елмаеп куя, уң кулы белән ияген учлап, беравык тын тора. Аннары башын бер якка кыңгыр салыбрак сөйләп китә.

— Сугышка кадәр, улым, икеләнгән чаклар булды инде ул. Өлгесез, күчергесез килеш яңа тормыш төзи башлады бит халык. Ә фронтта бернинди икеләнү дә булмады. Ил каршындагы бурыч ачык иде. Шуны үтисең икән, вөҗдан газапламый, син — кеше! Максат бер иде — озаграк яшәргә. Җиңәр өчен, җиңү хакына. Сугышта ярым-йорты уйлар булмый. Әнә — дошман, менә — үзебезнекеләр. Илгә тугрылык бар, батырлык бар. Сатлык булу бар, куркаклык бар. Икенең берсе. Моннан да ачыграк нәрсә булмый.

— Безне кайчак баласыталар... «Сезнең яшьтә бабаларыгыз, этиләрегез инде...» диләр. Сез ничек тиз җитлектегез соң?

Бабасы тагын берхәтле тынып тора. Җавабы әзер булмаганнан түгел, аңлаешлырак итеп әйтер җай эзли.

— Мин үзем сугышка яшьләй китмәдем,— ди ул.— Утыз бишне тугыра идем инде. Бик яшь китүчеләр күп булды. Аларның яшьлеген сугыш умырып алды. Яшь чак — самай хыялланыр чак, фашист хыялларны ярты юлда тураклады. Егет булып кына бара торган үсмерләр үлем, кан, ачлык эчендә калды. Якыннарны, белешләрне югалту авыр иде. Үзең дә һәр көн үлем белән прәме йөзгә-йөз. Шул хәлләр адәм баласын бик тиз олыгайтты.

— Шулай да, бабай, сезнең буын көчлерәк тә, яхшырак та булган...

— Беләсеңме, улым,— дип, кырт кисте бу юлы Фәйзерахман,— алай дип өзеп сөйләве читен. Сезнең буын да, кирәк икән, утка да, суга да керәчәк, җиңәчәк. Сезнең буын йөрәгенә дә, төптән уйласаң, Туган ил дигәнең тирән тамырланган. Кешеләрне, менәтерә, ике төрлегә бүлеп карарга мөмкин. Яныш торган тәвәккәлләр бар, житезләр, өлгерләр; бар тыныч, сүлпән, сак кешеләр. Дөнья бит. Бераүләр, ирекледәр булып, кулына корал алды, добровольцлар диюем. Андыйлар атакага да беренче булып күтәрелде. Икенчеләре дә сугышмый кала алмый иде, знамо. Әмма дә ләкин аларга һөҗүмгә бару газап белән бирелде... Сезнең заман башка, улым. Әгәр бүген кемдер тайгада чуен юл салмый, космоска очмый икән, аны без икенче сорт кеше дия алмыйбыз бит. Шул мыштым гына зат, кем белсен, бәлки безнең акыл җитмәгән ачышлар ясар...

Төшнең Илфат хәтерендә ап-ачык булып калган өлеше шундый. «Эткәй турында истәлекләр тыңлау галәмәте инде бу. Эткәйләр бүген нинди киңәш-унаш бирерләр, кайсы шөгылебезне хупларлар, ни өчен рәнҗерләр иде, дип уйлану галәмәте... Караватт үлчәп озаграк ята калсаң, җиденче буын бабаңа да сораулар бирә башларсың,— дип, сөземтә ясап куйды Илфат. Шулай да үткәнгә караш ташлауга һич тә каршы түгел иде ул.— Бер уйласаң, үзеңдәге җан байлыгына ревизия дә кирәктер ул. Кичерешләреңдә казыну түгел, юк! Мин бүген, бу атнада, быел нишләдем, ниләр майтардым дигән ревизия кирәк. Үзем башкарган эшем, кылган гамәлем мине тормыш баскычының яңа бер басмасына күтәрдеме? Югыйсә бит, яшьлегеңдә бик ашкын булып та, тора-бара абына-сөрлегә бушап калучылар да буа буарлык. Ник болай килеп чыгамы? Яшьлектәге уңышлары башларын әйләндерә андый иптәшкәйләрнең, гомер буе шулай юыртып барырлар төсле тоела аларга. Әмма дә ләкин, руслар әйтмешли, ан нет! Кырык ел буе сыңар аякта титаклап булмый икән шул. Болай сикерү бала-чагага гына килешә...»

Февральнең соңгы якшәмбесендә, көненә генә, Илфатның төпчеге Харис та килеп китте. Улы палата бусагасын атлауга, әтисенең уйлаганы шул булды: «Суырылып-ябыгып киткән малай. Эләгә моңар! Хатынкыз өчен дә, ир-ат өчен дә җигелеп йорт тартырга калды бит әле бу бала».

Буйга-сынга абыйсыннан да шәбрәк егет исә бер дә бирешкәнгә охшамый иде болай. Күңеле аяз, кәефе әйбәт күренә, сүзен өзеп сөйли, чәчрәп-яшьнәп тора. Яшьлек дигәнең кайгы карасын үзенә бик йоктыручан түгел бугай ла ул. Дөрес, әтисен сагынганлыгын сүзләре генә түгел, күз карашы да сөйли иде. Авылдагылардан күп сәлам алып килгән, колхоз хәбәрләрен иренми ирештерде, әтисенең хәлләрен берәмтекләп сорашты. Аннары, вазифам үтәлде минем дигәндәй, китәргә дә җыенды. Кайсыдыр урамдагы бер йортка сугылып, кемдер калдырып киткән хоккей кәшәкәләрен алып кайтасы бар икән. Мәктәптә хоккей командасының терәкләреннән берсе бит...

Илфат аңа: «Төнге поезд белән генә китсәң, нишләр? Рәмзия апаңнарга кереп ял итәрсең»,— дип караган иде, мондый киңәш улының касыгына төрткән сымаграк булып чыкты.

— Юк!— диде Харис, башын чайкап.— Беркемгә дә кермим дә, ял да итеп тормыйм... Апа сөйләде миңа аның турында...

Шушы бер-ике авыз сүз, ярты минутлык кына тискәреләнү, киресен әйтеп кую җитә калды, улы киткәч, Илфат бу хакта кат-кат уйланып ятты. Кәефе кырылды хәтта: «Карале син төпчекне! Рәмзия исемен телемнән чыгаруым булды, сырт йоннарын кабартты. Зөбәйдә, авылга кайткач, Рәмзия турысынданиләр сөйләде икән соң?»

Бимазалы уйларын читкә тибәрергә тырышып, Илфат, Харис сүзләрен әллә ни чутка сугарга кирәкмәстер лә, дип тә карады. Яшь-җилкенчәк нәрсә әйтеп куймас?! Үз-үзләрен бик яраткан чаклары лабаса! Мөстәкыйльлек күрсәтмәк булып әрсезләнә торган еллары. Бала түгеллекләренә ышандырырга теләп җан аталар... Тик авыру кеше күңелен кимерә башлаган шик-шөбһә тынмады һәм ул Илфат хыялында кабыныр-кабынмас кына елтыраган өмет-юаныч утына үрмәлидер иде кебек. Ярый ла ул шик юкка чыкса. Үсә барып, азынып, олы бер вәсвәсәгә әйләнмәсә.

Менә сиңа Харис! Тапты казык тешен күрсәтеп алыр чакны! «Юк, арымадым мин, әткәй»,— дип кенә калса, житмәс идеме? «Апа сөйләде миңа аның турында»,— дип әллә нинди мәгънә-төсмерләр салып әйтә бит. Зөбәйдә тәмсез телләнмәгәндер, алай дип шигәергә урын юк. Ул үзе — бала анасы. Варисның да Рәмзия дигәндә бозык чырай күрсәткәне, тавышын үзгәрткәне булмады әлегә. Төпчегенең генә канында кайсы әби-бабасыннандыр калган үзсүзлеләнү өянәге уйнап алды булса кирәк. Әллә соң бу Харисның әнисе исләгеләгән сабыйларча көнләве, бүтән исемнәрне Хатирә исеме янәшәсенә якын куймаска тырышуымы?

Әбәд ашап, ял сәгатьләрен уздырганчы Илфат шундый уйларның очына чыга алмый аптырады. Өйләдән соң сестра кереп, аның хәлен сорашты, янына бер полковник килгәнен әйтте, керсенме соң дигәнрәк рәвештә рөхсәтен сорады.

— Ниткән сүз, милая!— диде Илфат.— Керсен, бик керсен. Гамилдыр ул, яшьлек дустым. Үзем чыгып йөри алмыйм ич әле!..

Полковник булсын да, Маннуровны сорап больницага да килсен, Гамил булмый кем була, ди ул?!

Нәкъ үзе! Палата ишеген сак кына ачып, китель өстеннән иңнәренә ак халат салган Гамил Нургасимов палатага керде. Хәбиб абзыйга да, Илфатка да уртак сәлам биргәч, районлашының койкасы янына килде

һәм күрешергә кулын сузды. Шунда гына бу хәрәкәтнең саксызлык күрсәтү икәнлеген төшенде, мәгәр соң иде инде. Илфат, мендәреннән калкына төшеп, аңа сул кулын бирде. Шунда шаяртып та алды:

— Правая — каждому, левая — важному,— диләрме әле, иптәш полковник?

Гамил да елмайды.

— Анысы да хактыр... Беренче эш итеп, котлыйм әле үзеңне! Котлыйм, дускай! Мәктәпнең беренче «Алтын Йолдыз»лысы син.

— Рәхмәт, Гамил. Ил зурлады. Бурычлы калмыйсы иде дә соң...

— Тагын бер теләк, давай тизрәк савык!..

Аларның елдан артык күрешкәннәре юк иде инде. Частьтан демобилизацияләнеп военкоматка кайткач, Нургасимовны Кама буе районнарының берсенә хәрби комиссар итеп билгеләделәр. Анда ярты ел гына эшләттеләр дә Казандагы иң зур районнарның берсенә комиссар итеп билгеләделәр. Подполковник иде, полковник булды. Теге елны туган авылы Тоныксуга кайткач, Гөл-Төркемгә дә килде, бер-ике көн кунак булды. Шуннан бирле очрашмаганнар иде. Ә бер-берсенең исәнсаулык хәбәрен хатсыз-телеграммасыз гына белешкәләп тордылар. Арадашчылары бик төгәл иде: Илфатның улы Варис белән Гамилнең кызы, медицина институтының инде соңгы курсында укучы Миләүшә, бик дуслар. Якташлар булып танышып киткәннәр иде. Танышлык — дуслыкка, дуслык мәхәббәткә әверелде. Аларның үзара мөнәсәбәтләре курсташ студентларга да, әти-әниләренә дә мәгълүм иде инде. Илфат та, Гамил белән хатыны Зәйтүнә дә яшьләрнең якынаюына бик риза лар да. Варис белән Миләүшәдән генә калмаган, сөешерләр дә, өйләнешерләр дә, гаилә корып, балалар да үстерерләр. Сау-сәламәт булсыннар, укуларын уңышлы очлап чыксыннар да кеше арасында кеше булып дөнья көтсеннәр, бәхетле-тәүфыйклы булсыннар. Кыскасы, һәр ата-анага хас теләкләр белән яши иде өлкәннәр. Ләкин..., Монда бик үзенчәлекле бер «ләкин» бар. Менә шул «ләкин» аркасында, Гамил да, Илфат та, яшьләр үз язмышларын бер төенгә төенләми генә аерылсалар, иркен сулап куячаклар. Ике кордаш, ике классташ, үсмерчак дуслары бу мәсьәләне кузгатып авыз ачканнары юк. Илле бишенче елгы ул вакыйгага Варисны һәм Миләүшәне катнаштырып сүз кузгалганы булмады. Ихтимал, алдагы көннәрдә дә булмас. Әмма Гамил Нургасимов белән Илфат Маннуров йөрәгендә, хәер, тагын бер зат бәгырендә төзәлми торган сызлавык яши...

Палатага Гамил кергәч, Хәбиб агай, гадәтенчә, шөгыльме, йомышмы табып, коридорда әңгәмә коручылар янына чыгып китте. Канына сеңгән итагать-әдәп галәмәтедер инде, танышлар, дуслар, туган-тумача сөйләшкәндә сүзгә богау төсле утыруны өнәми ул.

— Я, хәлләрең кай тирәдә, Илфат?— Гамил, урындык алып тормастан, кордашының ятагындагы ак җәймәне бераз күтәреп, аяк очына, караватка утырды. Аңлашылса кирәк, болай итүе өлкән офицерның рәт белмәвеннән түгел, үз итүе, тарсынмавыннан һәм Илфатның да гаепкә алмасына ышануыннан иде.

— Хәлләр күреп торганынча, иптәш полковник,— дип көлемсерәде Илфат.— Берүк шушы сәгатьтә оркестрлар сбор уйный күрмәсен, гвардия өлкән сержанты Маннуров сафка басарга йөгереп чыга алмаячак. Хандра, в общем-то, Гамил... Алай да комиссовать итеп, ак билет тоттырырга уйлама. Сабыр ит, яме. Илләне узу — илгә яраксыз булу түгел әле ул...

Гамил ярым шаян, ярым моңсу тондагы сүз башын шундук кабул итте.

— Ә мин сине, гариза тотып килсәң дә, учеттан төшермәс идем, агай-эне.— Ул халатын иңнәренә җайлабрак салды да кордашының

йөзенә якынрак иелде.— Ә мөнә кырынмаганың өчен старшина аркылы берәр җәза чәпәтер идем мин сиңа.

Илфат Хариска кушарга онытты бит, билләһи! Малай актыгы димәсәң, әллә ниткән чебен тешләде дә үзен, китәргә каударланды. Уенда шул иде, теленә бүтән сүз килде.

— Гаеплемен, иптәш полковник. Яшьлек хатасы, төзәлермен,— дип куйды.

— Кырынгычың бармы соң?

— Бар. Безопаска. Пәкеләре дә «Ленинградский».

— Бездә дә лезвие ясарга өйрәнеп баралар. Кая, кырыйм үзеңне...— Гамил караваттан торды, кырыну әсбаплары эзләп, тумбочканы ачты. Анда азык-төлек келәте хасил булган иде.— Ә кайнар су? Әһә, бүлмәдә үк икән бит!

— Мәшәкатьләнмә сәнә, Гамил!— Илфат чын-чынлап карышмакчы иде.— Варис килгәч, яшәртер әле. Бүген генә кызлар янына барасым юк. Кызлар да мине күзләми...

— Кырынасың һәм вәссәлам!— диде полковник, аннары станокка яңа пәке куйды, помозокка «Флорена» кысып чыгарды.— Кырынасың, агай-эне. Кызлар хакына түгел, солдатлык хакына. Кызлар дигәне дә, яшьлекне сагынып, тирәңдә тулганалар дип ишетәм.

Илфат сәламәт кулын селтәде.

— Варис дигән сертотмас үрдәк информацияседер...

— Әйе, Варис сөйләп торды. Ник, гаебе бармыни? Рәмзия апа баргалап йөри әти янына, ди. Мин сөендем, беләсең килсә. Малай чакларны искә төшердем. Рәмзия дип саташкан вакытларыңны.

Илфат сул кулын селтәде.

— Булган, үткән...

— Алай гына димә, агай-эне...— Бу хактагы сүзгә шул төштә нокта куелды. Кеше җанына озынборын булып кадалырга ярамаганы ачык лабаса!— Яле, сөлгеңне ияк астына куйыйк. Сабынга чумырыйм әле кара чутыр йөзеңне. Бераз агармассыңмы?..

Гамил кордашының битен сабынлый башлады. Илфат дәшми-тынмый гына ятарга тиеш булды. «Олыгая Гамил да,— дип уйлый иде ул шушы минутта.— Тормыш үзенекен ала. Яшьлек ямен суыра. Аның бәрабәренә әнә җыерчыклар өсти, күзләргә уйчанлык, тамак астына сыр сала. Кызгылт-сары чәче дә әүвәлгечә түгел Гамилнең. Аңа да гомер кыравы кагылган. Борын өстенә мул сибелгән сипкелләре генә бер дә кимемәгән төсле...»

Военком иптәш, хәрбиләргә хас җитезлек белән, ялт-йолт китереп, Илфатның сакал-мыегын тиз кырды. Аннары сөлге очын кайнар суга чылатып, массаж ясагандай итте.

— Мә көзге,— диде ул, тумбочка өстеннән тәрәүле кечкенә көзге алып, дустына сузды.— Кара бер чәһрәңә! Я, әйт, ничә яшькә яшәрдең?

— Кырынып кына яшәреп булса, Гамил, гарип кулым белән дә тәүлегенә өч кырынмый калмас идем,— диде Илфат һәм яшьтәшеннән мыскал да тартынмыйча офтанып, ямансу көрсенеп куйды.— Эх, белмисең эчемдә нинди утлар янганын!..

Гамил бер-ике адым артка чикте һәм ләм-мим эндәшми классташына текәлеп торды, авызына су капкандыр, я булмаса иреннәрен тегеп куйганнардыр диярсең. Илфат:

— Я, нәрсә чекерәйдең? Авыру кеше күргәнең юк идеме әллә?— дими торып теленнән бер аваз да чыгармады. Сырхау үзе сорагач кына җавап кайтарды:

— Бар иде күргәнем. Була тора,— диде Гамил, таләпчән итеп.— Минә хәзер дә күреп торам. Хәлең шәптән түгел, ләкин әле өметсез дә түгел. Авыру килми торамы кешегә? Яныңа кергәнче бүлек башлыгы белән сөйләштем. Ачыктан-ачык. Ирләрчә. Ул — тәҗрибәле врач. Мине

якыннан белә, военкоматта еш була. Сафка басуына тулы гарантия бирә. Үзең генә мәлҗерәмә!

Илфат карашы белән, ымы белән Гамилны янына утырырга чакырды, сәламәт кулының бармак очлары белән яңакларын капшаштыргалап алгач, яшьтәшенә күңеленең тәрәз пәрдәләрен ачты.

— Мәлҗерәмәскә тырышам инде, Гамил. Синнән гайре берәүгә дә сер биргәнем юк болай. Һәммәсе мине юата, мин аларның күңелен күтәрмәк булам. Үлемнән курыкмыйм мин...

Гамил аның сәламәт кулына кагылып куйды.

— Бу сүзне лексиконнан чыгарып торыйк әле, яме,— диде ул.

— Алай димә...— Илфат фикерен өзәргә теләми иде.— Картлар әйткәндәй, үлем — бер хак. Вакытсыз килгән әҗәл инде менә бәгырьләрне айкап гарьләндерәчәк. Ә курыкканым шул: ни аллага, ни муллага дигән кебек, бернинди эшкә яраксыз тере мәет булып яту. Кеше күзенә карап. Тилмереп, кеше тилмертеп... Менә нәрсә коточкыч, Гамил!..

Хәрби комиссар янә кырысланды.

— Менә шундый елак уйлар өрлектәй ирләрне дә балавыз итә инде ул, Илфат. Ташла чыгарып башыңнан шул тузга язмаганнарны! Уйлар нәрсә беткәнмени?! Әти, мәрхүм, әйтә иде, бәланы кайчак кеше үзе дәшеп китерә. Йомшаклыгын сиздерә. Ә бәла буыны сыекланганнарны гына көтеп йөри, ди торган иде.

Мирзанур абзыйны күз алдына китерү Илфатка ләззәт бирде. Агай аның исендә тирән акыллы, сабыр, тәмле телле, ярдәмчел кеше булып калды, шулай булып яши. Мирзанур абзый сугышка бармады, яше чыккан иде. Нурҗамал түти белән икәүләп тугыз бала үстергәннәр алар. Өлкән уллары Галим сугышта Кызыл Йолдыз орденының беренчесен алган елны, кырык дүртнең көзендә, аларның төпчек уллары Ризван туды. Абзыйның кызык бер хәтерсезлеге бар иде. Балаларының кайсын да булса берсен чакырып аласы булса, тугызының да атын әйтеп чыгар иде: Галим, Сылу, Зөләйха, Гамил, Шамил, Сәвия, Хамис, Гыйльман, Ризван...

Тугызынчыда укыганда, ял көненә дип, Илфатның Гамилларга, Тоныксу авылына кайтканы еш булды. Ятим дип кызганудандыр инде,— тик моны ул сиздермәскә тырыша иде,— Мирзанур абзый улының классташына бик мәрхәмәтле иде. Үз өендә тугыз баланың җидесе мыжгып ятканда, өйдә артык кием-салым булырмы икән. Еллары нинди иде бит житмәсә! Менә шул өзелгән-биртелгән елны офицер улыннан килгән гимнастерканы Илфатка яраклы итеп бозып тектерде бит. Тектерде дә, өстенә кигезде дә. «Галим абыеңның ут эченнән сау-сәламәт кайтуын телә, балам!»— диде. Бүтән бер сүз дә әйтмәде. Нурҗамал апаның: «Менә икегезгә ике әпәй!»— дип, дүшәмбе көнне мәктәпкә озатып калуларына да Мирзанур абзый бер сүз әйтми иде. Ятим бала күңеле болай да китек, бераз булса да юансын диюе булгандыр. Бөтен иппи түгел, бер телеме дә гаҗәеп куаныч иде шул ул елларда! Илфат бу хәлләрне хәзер бик нечкәләп төшенә. Дәрт тә бар, дәрманлы да яшибез, тамак тук, өс бөтен. Их, бер генә сөйләшеп утырасы иде ризыкнигъмәт тулы өстәл янында дөнья бәясе Мирзанур карт белән! Юк шул инде, киләчәккә атлап була, үткәннәргә кайтыр хәл юк...

— Җир кешесе иде мәрхүм,— дип, «җир» сүзенә басым ясады Илфат.— Җирне ярата иде, туфрак кадерен белә иде. Улларым, кызларым да иген игәрләр дип хыялланганлыр, вообще-то...

— Язмыш үзгәчәрәк хәл кылды шул мәсьәләне...— Гамил әллә Илфатның төрткеле сүзен кабул күрмәде, әллә үз туганнарының туган туфрактан кубып китүләрен бик табигый күренешкә хисаплый иде.— Өчебез — профессиональный хәрбиләр. Өчебез — эшче. Ризван фән кешесе булды, кандидат, доцент. Сәвия — күрше авылда укытучы. Бер-

дәнбер Зөләйха апа үз авылыбызда. Кияүгә авыл кешесенә чыкты да Тоныксуда төпләнде.

— Мирзанур абзый күбрәкне өметләнгән булгандыр, әйеме?

— Бәлки...

Шулай Мирзанур абзый хакында сөйләшеп торганда исенә палатадагы күршесе Хәбиб абзый Гайсин килеп төште һәм Илфат Гамилгә аның турында сөйләп алды.

— Әти белгәндер аны алайса,— диде Гамил.

— Мөгаен!— дип, кордашының фикерен куәтләде Илфат.— Мирзанур абзый да карт коммунист иде.

— Егерме дүртенче елдан.

— Хәбиб абзыйның партстажы да илле елдан артык.

Аннан сүз янәдән Илфатның сәламәтлегенә әйләнеп кайтты.

— Бер айны гына ятам да ятам инде мин монда.— Илфат котылгысыз җәзага дучар кеше сыман әйтеп салды. Дусты исә моны бик табигый хәлгә санады.

— Аякка басу, сәламәтләнү өчен күпме кирәксә — шул кадәр ятачаксың,— диде.— Верховный командующийлар — врачлар. Бездән фәкать хәер-фатиха, изге теләкләр...

Палата ишеген шакыдылар. Илфаттан да алда көр тавыш белән Гамил рөхсәт бирде.

— Да, да...— һәм, үз күзләренә ышанасы килмичә, тотлыгып калды. Бусагада Илшадия басып тора иде. Ул да аптырады. Әмма керми дә хәле юк иде.

— Исәнмесез!— Илшадия мизгел эчендә үзен кулга алды, кыю атлап абыйсы янына килде, сак кына аның иңнәреннән алды.— Исәнме, абый! Куанычы белән көенече бергә килде үзеңә. Хәлләрең ничек?

— Арулана, сеңел, арулана...

— Шулай була күрсен.— Аннары Илшадия Гамил белән күреште.— Хәерле көн!

— Исәнмесез!

Алар бер-берсенең күзләренә карамаска тырышалар иде. Сөйләшү дә, магнитофон тасмасына язып алган төсле, әзер юлдан барды. Күрешмәскә тырыша-тырыша чирек гасырны уздырсалар да, очрашу насыйп икән. Тау белән тау гына очрашмый дигәннәре хак шул.

Палатада һава электрланып калгандай тоелды. Энә очыдай очкыннан да шартлау чыгар төсле. Сүзнең тәме китте, уйлар чуалды. Хәлне җиңеләйтергә кирәклеген иң беренче булып Гамил чамалады.

— Ярый, Илфат, мин китәм. Күрештек, сөйләштек. Тик савык.— Бая гына әйткәннәренә капма-каршы җөмлә дә өстәде.— Озак ятарга рөхсәт юк,— диде һәм, командага буйсынгандай, тиз генә саубуллашып чыгып китте.

Палатадагылар тын калдылар. Агалы-сеңелле Маннуровларның уйлары гомер томаны белән өртелгән елларга чигенгән иде бугай. Педагог кеше, Илшадия, сүзсезлектән котылу чарасын тапты. Ул:

— Врачларның прогнозы нинди соң, абый?— диде. Сорау саксыз иде, гадәттә сырхау кешегә болай кырт кисеп эндәшмиләр. Акылы белән Илшадия дә моны әйбәт аңлый, тик менә сәеррәк хәлдә калгач, аның теленә шундый сүзләр килде.

— Алар ни дисен? Тереләсең, диләр. Шунсыз ярамый да инде. Терелмичә, савыкмыйча дигәнем. Үзең ниләр майтарасың?

Илшадия:

— Беләсең инде безнең хәлләрне абый!— дип, бик җәеләсе итмәде сеңелесе.— Хатын-кыз директорга ансатмы? Укыту-тәрбия эшләре генә булса икән... Ягулыгы, төзелеше, ремонты, тәҗрибә участогы... Уптым илаһи җыеп әйтсәң инде, чыдарлык.

— Илһамия ападан сиңа хат юкмы?— Илфат агроном кияве белән чирәм җирләрдә көн күрүче апасы хакында сорашты.

— Килгән иде, ике атна гына бардыр инде. Сау-сәламәтләр. Апа һаман үз эшендә, бухгалтериядә. Пенсия тәрәз кага, дигән. Ялга чыккач, озаклап кунак булырга Гөл-Төркемгә кайтам, дигән. Татарстанны сагына... Җизни бер көй эшли икән. Балалар үсеп беткәч, икәүләшеп чүкердәшәләрдер инде...

— Булат нишләп йөри?

— Өйдә. Укый, рәсем ясый. Күп сәлам әйтте.

— Сәламәт булсын! Миннән дә сәлам.

Булатка кагылышлы сүзне дә озакка сузмадылар. Сүз озайтмый да аңлашыла торган нәрсәләр бар тормышта. Ул егет хакында төпченеп сораштыру сеңелесе өчен күңелсез, боектыргыч икәнен Илфат яхшы төшенә. Язмыш Илшадиянең карап торганына йонлач кулын сузды шул. Өметсез шайтан диләр дә соң...

Илшадия абыйсы кырында сәгатьтән артык утырып китте. Салмак-сабыр гына атлап, кулына күчтәнәчләр тоткан Хәбиб абзый палатага кайтып кергәч, әйтә куйды:

— Бүген приемный көн булды сезнең, Илфат энем. Бик ялыктырмадылармы?

— Зыян юк, Хәбиб абзый. Хәл белик дип киләләр, үземнекеләр. Рәнҗемәссең бит...

— Шулай, энем, шулай. Талчыга күрмәгез дигәнем генә. Минем дә карчык килгән иде әле, вестибюльдә сөйләшеп утырдык.

Талчыгу кадәресен бик дөрес әйтә булмадаше. Үзеннән белеп сөйли. Башыннан кичкәне байтак.

Килеп китүләре анысы йончытмый, менә уйлар тынгы бирми. Бал кортлары ил аергандагы кебек. Бер күч уй килеп ябырыла да, кусаң да китми. Куам дип селтәнмә дә, үчегә генә баралар. «Уйла, үлчә, безмәнгә сал, акны карадан аер, кибәкне бөртектән җилгәр» дип, теңкәгә тияләр. Инде һични үзгәртү мөмкин түгеллеген белсә дә, һәммәсе үткән-беткән икәнен аңласа да, Илфат сеңелесе белән яшьлек дусты кичергәннәрне йөз дә беренче кат анализлап ята. Бу җәһәттән үзенә дә еллар ераклыгыннан караш ташлый. Йөрәк саңгыраулыгы белән чирләп калмадымы икән ул теге елны? Абый буларак, кулыннан килердәйне эшләдеме?

## Күңелдәге сызлавык

...Илшадия Гамилны беренче мәртәбә абыйсы белән Гөл-Төркемгә кайткач, кырык биешенче елның апрель башында күргән иде. Үзләренең алты почмаклы, шатрун түбәле йортларында. Кичке ашны житкереп ашагач, алар — Илһамия, Илшадия, Илфат һәм Гамил — түр өстәлне түгәрәкләп алып, «Йөзек кашы» повестен укыганнар иде. Әйе, башлаганнар иде дә укып бетермичә туктый алмаганнар иде. Сукыр лампаның күмерләнгән филтәсен ике-өч тапкыр кырырга туры килгән иде. Үз акылы белән үз йөрәген бергә куша алмыйча бунтарьланып йөргән Айдар һәм сылу-чибәр Василә язмышы барчасын исәрткән иде. Хәер, һәммәсен дә гаҗәеп исәрткән иде дию дөресрәк булыр. Ник дигәндә, китаптагы мәхәббәт тарихының уңсыгез яшен тутырып килүче Илһамияга тәэсире бер төсле булса, унөчтәге Илшадияне икенче төрлерәк кыбырсыткандыр. Илфат үзен Айдар урынына куеп, ләкин үлемнән котылган, бүген дә тере иттереп күз алдына китерде. Василә итеп, әлбәттә, ул укытучы кыз Рәмзияне күз алдына китерде. Инде Гамилга килсәк, аның хыялындагы Василә классташының бертуган сеңелесе

Илшадия төсле иде. Койган да куйган Илшадия. Сөйләшүләре, көлүләре, бит уртасындагы чокыры, авыз-борыны, гәүдә тотышы, йөреше... Тик Гамил үз уенда Илшадияне бераз үстерә төшә, җитеп килгән кыз итә иде. Күкрәк-түш тиреләрен дә калкурак итеп күрә. Хыялда кызның кием-салымы да затлы. Ефәккә уралган Вәсилә-Илшадия. Аягында затлы туфлилар. Колакларында ялык-йолык килеп торган алкалар...

Илфат Ташбуага йөреп тугыз классны тәгәлләү белән канәгатьләнергә мәҗбүр булды. Йортны алып барырга, Илшадияне укытырга кирәк иде. Шулай итеп, абый кеше җигелеп колхозда эшли башлады. Тракторчылар курсында укып кайтты, механизатор булды. Тракторчыларга ул елларда ук гарантияле түләү бар иде. Унынчыны Илфат Армиядән кайткач, үз авылларында ачылган кичке мәктәптә тәмамлады. Булачак хатыны Хатирә белән дә шунда якынлашып киттеләр.

Гамил исә укуын өзмәде, тоташтан укып, өлгергәнлек аттестатына ия булды. Юристлыкка ниятләп, институтка имтиханнар тапшырды, студент билеты да алды, тик югары уку йортына җаны ятмадымы, тартып җиткерүе кыенгарак килдеме, ВУЗны ташлап кайтты. Аттестатка өстәмә итеп бер кыш «гыйлем өстәде» дә, алдагы көздә хәрби училищега китеп барды. Еллар үтү белән, яшь офицер Германиядәге Совет гаскәрләре группасында хезмәт итә башлады. Шуннан Союзга ялга кайткан лейтенант, сирәк булса да, хат алышкалап торган студентка Илшадия янына, Казан педагогия институтының тулай торагына килде. Бик күңелле очраштылар. Илшадия Гамилны әле дә булса абыйсының мәктәп дусты итеп кабул итә, ихластан якын күрә иде. Һәрхәлдә, офицер егетнең үзенә бүтән күзлектән карау ихтималын уйламый иде ул. Ишетә белә иде: Гамил медицина институтында укучы райондаш бер кызны ярата, тик араларыннан суык җил узган, бозылышканнар. Күпкәме, озаккамы, әллә бөтенләйгәме? Мәхәббәт үпкәсез, бәхәссез генә, ялыну-ялындырусыз гына буламыни?! Килешерләр әле!

Соңгы курста укучы, җәй җитүгә урта мәктәпнең рус теле һәм әдәбияты укытучысы дипломын алачак кыз кайчандыр яшүсмер Гамил хыялында гәүдәләнгән чибәр генә түгел иде инде. Фантазиягә бирелеп торасы да юк, табигатьнең сирәк бүләге — җир җиләгедәй гүзәл кыз аның каршында басып тора һәм колакны назлый торган матур, ягымлы тавыш белән аны студент кызлар бүлмәсенең түренә чакыра иде.

— Узыгыз, Гамил абый, узыгыз! Өстегезне салыгыз. Бирегез, монда элим,— ди.

— Үзем, үзем,— ди Гамил, Илшадиянең бүлмәдәшләрен дә сәламләгәч. Ул шинелен, бүреген чөйгә элә. Китель чабуларын тарткалап куя, чәчләрен сыпыргалап ала, чалбар кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып битен сөртә һәм түрдәрәк тәкъдим ителгән урындыкка утыра.

Мәзәген-чынын бергә кушып беркадәр гәпләшкәч, бүлмәдәш кызлар чыгып киттеләр («Читалкага төшәбез!»). Яшьләр аулакта калды. Гамил Илшадиягә соклануын яшерә алмаудан хәтта уңайсызлану сизә башлады. Кыз, чыннан да, әкият гүзәледәй бит: нәфис буй-сын, төз гәүдә, дөньяга тутырып, томырылып карый торган көләч күзләр, очлары бөгелгән куе керфекләр, чәчәк таҗыдай иреннәр. Дулкын-дулкын куе коңгырт чәч. Илшадия ул чәч дулкыннарының әрсезлеген толымнарга үреп кенә тыеп яшидер кебек. Йомры күкрәк өстенә яткан ике калын толым кыз гәүдәсенең сылулыгын арттыра гына төшә.

Киенә белеп киенә иде студентка. Юк кына нәрсә дә аның өстенә кеше көнләштерерлек булып ятышып тора. Төс, фасон сайларга дигәндә, иптәш кызлары аның белән киңәшәләр иде.

Үз бәясен яхшы белә иде Илшадия. Сугыштан соңгы еллардагы кайбер кызлар түгел. Моны Гамил тиз абайлады. Тойгылары нечкә туташның нәзакәтле, әмма шул нечкәлек янәшәсендәге тәкәбберлеге дә

күзгә ташланмый калмый. Күрергә күркәм, килергә куркам диюең бар. Кай ягыдыр сагайта.

Курстан-курска институт егетләре, юк сылтауларны бар итеп, Илшадия тирәсендә бөтерелделәр, тик кыз аларның әйләнү-тулгануларын күрә торып күрмәмешкә салышты. Дөрес, физматтан бер егетне хөрмәт итә иде ул, мәгәр тегесенең чамасыз тыйнаклыгы кызны уйга калдырды.

Шундый-шундый эшләр, тора-бар нишләр, дип яшәгән бер вакытта, мең тугыз йөз илле бишенче елның февраль башында, лейтенант Гамил Нургасимов Татарстан җиренә кайтып төште. Эчендә мәчеләр тырнаша иде аның. Медицина институтын тәмамлаучы Фәйтүнә исемле бер туташ гафу итүен сорап аңа хат язган, үзенең кияүгә чыгуын хәбәр иткән иде. Мәгәр башын түбән иярга, күңелен төшерергә исәбе юк иде егетнең: «Миннән башканы тиз генә таба алмады дип кукраерга җай бирү булмас! Аңардан да күркәмрәк кызга өйләнергә кирәк миңа!» — дип күңеленә беркетте.

Тулай торак бүлмәсендә аулак калса да, Гамил Илшадияне шәһәргә чыгарга өндәде. Кыз карышмады, тиз генә җыенды да, кузгалдылар.

Яшь офицер «Казан» кунакханәсенә тукталган иде, Илшадияне шундагы ресторанга чакырды. Кыз, гәрчә рестораннарга йөреп күнекмәгән булса да, абыйсының яшьлек дусты кыстагач, ялындырмый-назланмый гына ризалашты.

Көзгеле залда кеше аз иде әле. Гамил белән Илшадия иң түрдәге сулъяк өстәлне сайладылар. Бик тыныч урын иде бу. Җитез йөрүче официант — Касим татары — шундук заказ алды, елмаеп-көлеп шәраб, салкын ризыклар китерде һәм яшьләрне беравыкка тынычта калдырды. Гамил гадәтенчә юмарт булды. Кыз каршында чая да, хәлле дә күреним дип тырышудан түгел, күңеле бәйрәм сорый иде аның. Һәм ул бәйрәм үзе дигәнчә башланып та килә иде. Хәмер-шәраб белән әллә ни дус булмагангамы, бермәлдән Гамил җиңелчә генә исерү сизде, рәхәтлек тойды, кәефе күтәрелде. Шулчак ул Илшадияне үзе байтактан әзерләнеп килгән аңгәмәгә тартасы итте.

— Әгәр дә мин Америка ачарга ниятләсәм, сез, Илшадия, үтә дә гаҗәпләнерсез микән?

Гамил кызның коңгырт күзләренә текәлде, тик анда үзен түгел, люстрадагы электр лампочкалары тәлгәшен генә күрде. Илшадия шаярып елмайды һәм лейтенант күңелендә дә җылы уятты.

— Гамил абый, дөньяның ул кисәген унбишенче гасыр азагында ук ачканнар бит. Диңгезченең исеме дә Гамил булмаган.

Гамил сүз дилбегәсен ычкындырырга ярамаганын абайлый иде. Күзләрен каршында утырган туташтан алмыйча һәм ала алмыйча ялгап китте.

— Мин, Илшадия, сезгә һәм үземә генә кагыла торган материк турында сүз алып барам.

Илшадия кинәт җитдиләнеп һәм хәтта кәефсезләнеп калгандай булды. Тик сүзсез торыр хәл юк иде, күптәнге белешең, туганың сыман үз итеп йөргән кешең нидер аңлашырга тели икән, аны тыңламыйча булмый ич инде.

— Шаяртмасагыз тыңлыйм, Гамил абый,— диде ул, кырыс кына караш ташлап. Әлеге караш лейтенантны да айнытып җибәргәндәй итте. Ул, аклану эзләп, гафу сораган төсле:

— Мин җитди сөйләшергә телим, Илшадия,— диде.

— Тыңлыйм.

— Энәсеннән җебенә кадәр белмәсәгез дә, Фәйтүнә белән минем арадагы мөнәсәбәтләр колагыгызга кергән иде бит инде. Соңгы хатларыгызның берсендә юату җөмләсе дә язган идегез...

— Шуннан?

— Шуннан, Илшадия, мин ниләр уйлаганны, ниләр кичергәнне бөртекләп сөйләмәсәм дә чамалыйсыз. Миңа зур удар булды аның фокусы.

— Тиктомалдан гына ике кеше арасындагы хәлләрне хөкем итәргә алынып булмый. Аннан соң бу — минем эшем дә түгел...— Менә шунда Илшадиядәге тәкәбберлек тышка бәреп чыкты, әллә нинди генә эрелек ишетелеп калды. Гамил исә тимерне кызуында сугарга ашыкты.

— Кыскасы, Фәйтүнә белән минем ара өзек. Бөтенләйгә! Ул — ир хатыны хәзер...— Гамил киң-тирән чокыр авызына якынлашкан кеше сыман калды: я бөтен көч-куәтеңне туплап сикереп чыгасың, я чокыр төбенә мәтәләсең. Мәтәлергә ярамый! Егерме биш яшен тутырып килүче офицер, саулык-сәламәтлек бөркеп торган егет, перспективасы-киләчәге бар кеше югалып калырга тиеш түгел дә түгел! Чигенмәстәй шундый фикергә килгәч, Гамил өзеп әйтте:

— Мин сезнең кулыгызны сорар идем, Илшадия. Китапча сөйләнә башладым бугай, гафу итегез. Мәгънәсе аңлашылса кирәк. Үзегезне дә, туганнарыгызны да күптән беләм. Безнекеләргә сезнең як таныш... Бик тә көтелмәгән тәкъдимме, Илшадия?

— Көтелмәгәннән дә битәр, уйланылмаган тәкъдим түгелме дим мин. Сез, ни өчендер, мине дәррәү риза булырга тиеш кешегә исәплисез, Гамил абый. Бәлки Илшадиянең үз планнары бардыр, аннан соң күздә торкан кешесе булу ихтималы да уегызга килми түгелме? Үз-үзегезгә артыгын ышанганга охшыйсыз.

Гамил сүзен килештереп сөйли белмәве өчен үзен күңеленнән аяусыз битәрли иде инде. Гомергә шулай булды, азак әйтәсен алдан тукып куйды, кереш сүзе ахырга калды. Бер фикернең ялы, икенчесенең койрыгы бергә үрелеп чәбәләнде. Дипломатлык аңардан ерак йөрде. Менә хәзер дә һич югы «Вәгъдәләшкән, ышандырган кешегез булмаса» дию кирәк иде ләбаса.

Авыз ачкач, сүзне очлый да белү зарур. Гамил хатасын төзәтергә тырышты.

— Мин, Илшадия, бу тәкъдимне озак уйланганнан соң гына әйттем,— диде ул, югалып калмаска һәм бәясен төшермәскә карар кылып.— Билгеле инде, күңелегезгә якын кешегез булмаса, дигән шартны күздә тоткан идем.

— Мондый мәсьәлә бер утырып сөйләшүдә хәл кылынмый дип беләм, Гамил абый. Мин кайтыйм әле булмаса. Иртәгә ял көне түгел.

Гамил аның аз гына сабыр итүен үтенде, вакытның әле бик иртә икәнен исенә төшереп куйды һәм әңгәмәне ярты юлда өзеп калдырмаска теләде.

— Мондый мәсьәлә турындагы сүз дә бер башланырга тиеш бит инде, Илшадия,— дип, дәвам итте лейтенант.— Вакыты да шундый. Мин отпускыга кайттым. Иң мөһиме — сез быел эшкә направление аласы кеше. Мәсьәләне бер яклы итү кирәк диюем.

— Һәрхәлдә миннән җавапны бүген көтмисездер дип уйлыйм, Гамил абый. Күрше коесына суга кереп чыгу турында сөйләшмибез ич... Бүгенгә шуннан артыгын әйтү кыен миңа.

Әңгәмә шунда тәмамланды дияргә мөмкин иде. Гамил Илшадияне тулай торакка озата килде. Саубуллашып, иртәгә тагын очрашырга килешеп китеп барганда, егет үз тәкъдимен студентка хәтеренә янә бер кат төшерәсе итте.

— Тыныч йокы, тәмле төшләр телим, Илшадия. Минем уңай җавап көтүемне оныта күрмәгез,— диде.

Мәгәр яшьләрнең икесен дә йокы алмады бу төндә.

«Мине ничектер үз итүен тоя идем мин аның,— дип уй йөртте Илшадия.— Бәлки ул дустының сеңелесенә җылы караш кына да булгандыр. Фәйтүнә апа кияүгә чыгып киткәч, тормышында шундый бер

адым ясарга карар иттеме икәнни? Ә бит Фәйтүнә апа белән урта мәктәптән үк таныш булганнар алар. Яшь врач кыз ни өчен Гамил абыйдан йөз чөерде икән?

Гамил абыйның чамасыз кызуланып ташлавы гына түгелме? Фәйтүнәсе гомер буена күңеленнән китмәсә? Йөрәк ачып серләшер кеше дә юк бит ичмасам! Әнкәй исән булса, беренче итеп аңа сүз кушар идең. Илһамия апа да дөнья читендә шул. Женләнделәр бит чирәм җирләр дип... Әлеге мәсьәләдә Илфат абый белән дә җәелеп сөйләшүе кыен. Ир туган — тормышта төп терәк, сердәшкә кыз туганы бик кирәк дигәндәй килеп чыга...

Быел гына кияүгә чыгармын дип тәгаенләгәнем дә юк иде. Районга укытырга китәм, ә читтән торып аспирантурада укымаммы, дигән ният белән һавада асылынып калырмы? Гамил абый белән бергә булган очракта чит илгә китәргә туры киләчәк. Анда нишләрмен? Диплом кочаклап утырырмынмы? Аны Союзга кайчан кайтаралар әле? Хәрбиләр үз белдекләре, үз теләкләре белән эш итә алмыйлар. Гомерләрен офицерлар белән бәйләгән хатын-кызлар үкенмиләрме? Сүз дә юк, аларның ирләре авыр, кирәк хезмәттә. Кырыс хезмәтләрен азмы-күпме җиңеләйтешү өчен хәрби эштәгеләргә бермә-бер игътибар, илтифат, гаилә җылысы кирәк. Әмма гомер итү елга кичү генә түгел. Кемнеңдер тормышын тулы, түгәрәк, җылы, якты итү бәрабәренә үз өметләреңне җилгә очыру хак эшме?..»

Гамил да каршылыклы фикерләр камалышында калган иде.

«Илшадия — миңа кулай зат. Бер мохит кешесе. Чыгышы белән, тумышы, үсмеше белән. Бер үк газапларны татып үскән кеше.— Лейтенант кайта-кайта шулай уйлады, шул фикернең тамырлануына ирешергә тырышты. Шулай уйлау аңа Илшадиягә ясаган тәкъдимен нигезләү, аклау, шул нигезгә таянып, алга таба хәрәкәт итү өчен кирәк иде.— Ул — чибәр, уйлап, үлчәп сөйләүчән. Җилбәзәклек — аңа ят сыйфат. Тормыш итә белүче хатын булырына шикләнмәскә мөмкин. Икмәк телеменең, акчаның, кигән киемнең нәрсә икәнен белә. Ятим үстеләр. Ятимнең ипие эремле була. Шуның тәме гомер буена бара һәм азынып-масаеп сикеренүләргә юл куймый. Чынбарлыкның әле минем хыялдан күркәмрәк тә булуы мөмкин. Илшадия белемле, тәрбияле, нәзакәтле булуы сизелеп тора. Тик...

Тик артык нык характерлы (чакматаш холык диләрме әле?), горур да Илшадия. Тора-бара әлеге характер ныклыгы үзсүзлелеккә әйләнмәсме? Белемле булуы миңа югарыдан карарга җай өстәмәсме? Нәзакәтлелеге гел генә наз сорап торуга, нәзберреклеккә кайтып калмасмы?— Шулай күңелендә казына-актарына торгач, Гамил үз-үзеннән мыскыллы көлде.— Кырт кисеп, миңа кияүгә чык дип тәкъдим ясa да, төне буена уйланып, күзеңне шар ачып ят инде!

Фәйтүнәнең әкәмәте авызны пешергәндәй иттемени соң? Моңа тикле андый-мондый икеләнүләр җиде ятып бер төшемә дә керми иде.»

Илшадия белән Гамил иртәгесен дә, өченче көнне дә очраштылар. Ниһаять, уртак фикергә килделәр. Язылышу кадәресен Тоныксу авыл Советында башкарырга булдылар. Авылдаш офицер егеткә бу мәсьәләдә тоткарлык тумасы мәгълүм иде. Беренче мөмкинлек чыгу белән, Гамил туган илгә кайтырга рөхсәт сорап рапорт язарга вәгъдә итте. Илшадиягә июльдән дә кичекмичә чакыру кәгазе җибәреләчәге хакында сүз беркеттеләр. Туй хәстәрлеге турында да сөйләшми калмадылар.

Әмма боларның барсыннан да элек, Гамил авылга кайтып, әти-әнисе һәм туганнары белән киңәшергә, бер уңайдан Гөл-Төркемгә барып, мәсьәләне Илфат белән уртага салып сөйләшергә тиеш иде. Килешенгәнчә эшләделәр. Гамил дүрт көн дигәндә Казанга әйләнеп килде. Һәр ике якның да ризалыгын алып килгән иде ул. Ике-өч көн яшьләр Казан

кибетләрен айкадылар, иртәдән башлап төнге караңгы капканчы аяк өстендә булдылар. Тоныксуга алып кайтасы әйберләре, ризык-күчтәнәчләре, туган-тумачага бүләк-мазар, Ишадия әйткәндәй, «ат йөге» җыелды. Анысын алып кайтуда Илфат булышты, районнан машина белән килеп алды.

Яшь кияү белән кәләш, җиңел чемодан һәм сумка гына тотып купелы вагонда кайтып киттеләр. Тоныксу разъездында колхоз ветераны Мирзанур абзый улы белән булачак киленен артлы тимер чаналарга пар атлар җигеп каршылады. Дугаларга чигүле сөлгеләр уралган, кыңгыраулар тагылган, «җиз тараканнар»ы ялт та йолт килеп торган йөгәннәргә әллә ни төсле тасмалар, кулъяулыклар бәйләнгән иде. Яшьләрне ап-ак мамык мендәргә терәп утырттылар. Кияү юлдашлары — Тоныксу егетләре — гармун күрекләрен кызганмый суздылар, җырга-такмакка да юмарт иделәр. Тояк асларыннан очкын чәчкән юртаклар зур авыл урамының бер башыннан икенчесенә коштай очты. Капка төпләренә чыгып баскан карт-корының куллары каш өстенә менде, тәрәзәләргә ябырылган кыз-кыркын да тел шартлатып калды.

Алдан планлаштырылганча, җигүле атлар кәрваны туп-туры авыл Советы бинасына кайтты. Загс кәгазьләре шунда язылды, рәсми тәбрикләр шунда әйтелде. Аннары тантана Мирзанур абзый йортына, кияү гуып-үскән йортка күчте.

Яшь киленне Тоныксуда әүвәл-әүвәлдән килгән гадәт буенча сынапчамалап торырга ара зур булмады. Туйның иртәгәсен, якшәмбе кичендә, кияү белән килен Казанга китәргә тиешләр иде. Хәер, Илшадия, кайтып беренче чәйне эчте дә, кичкә билгеләнгән туй мәҗлесен хәзерләшергә керешге. Сынап караганнарга сынар җай бар иде. Бик бәйләнчек кодачалар да аның эшеннән гаеп-кыек таба алмаслар иде, мөгаен. Эшләп үскән кызның аш-суга да кулы ятулы, җиһаз-җәйманең дә рәтен-җаен нечкәләп белә иде.

Кыскасы — туй бик матур узды. Килгән кунаклар да канәгать таралышты. Хуҗалар да һәммәсеннән риза-бәхил иделәр. «Сыңар кашык та төшмәде өстәлдән, сыңар чынаяк та ватылмады. Шөкер! Ахыры хәерле булсын!» — диештеләр.

Әмма туйның ахыры хәерсез бетте. Мәгәр бу шомны беренче мәлгә берәү дә белмәде, берәү дә башына китермәде. Туйдан соң тимер юл станциясенә озата барганда да, кияү белән киленнән кала, халык берни сизмәде. Һәркем: «Яшьләр кавышты. Егете теләп алды, кызы теләп барды. Туй менә дигән үтте. Киләчәк гомерләре дә татулыкта, бәхеттә, бер-береннән туйгысыз мәхәббәттә узсын!» — дип кенә торды.

Туган-тумачаның да кайберсенә туй азагы күңелсезлеге ике-өч атнадан, бүтән берәүләренә айлар узгач гына килеп ирешге. Белгән бере «Аһ!» итте. Сәбәбен төпченүчеләр дә булды, үзләренчә генә юрап, үзләренчә генә гөман итүчеләр дә табылды. Шулай да боларына карап та, тегеләренә карап та эшнең асылы үзгәрмәде. Кавышкан сәгатьләрендә мәңгегә аерылышкан кияү белән кәләш язмыш дигән тирән, киң елганың икесе ике ярында торып калды.

Мондый очракларның күпчелегендә кыз хакында имеш-мимеш таралучан. Янәсе, кыз абруе чүк өстендә, аннан төшсә — чүп өстендә. Имеш, яшь киленнең куначасы кыска булган. Кәләшнең башы пеләш булган, ди. Һәм башкалар, һәм башкалар...

Илшадиянең намусы саф, вөҗданы пакь иде. Гыйффәтле булганга күрә дә, Гамилнең ахырын уйламыйчамы әйткән сүзләрен күтәрә дә, кичерә дә алмады.

Ул хәерсез сүзләрне туй мәҗлесенең иртәгесен, кияү мунчасында әйтте Гамил. «Хатын-кыз күрмәдем түгел, әмма синдәен күргәнем юк иде әле, Илшадия»,— диде.

Яшь киленне яшен сукты мыни! Илшадия беравыкка телсез-өнсез калды, аннары үзенә дә ят, кыргый тоелган ямьсез тавыш белән кычкырып сорады. Төгәлрәге, акылын җуйган кыяфәттә үкереп куйды:

— Синең белән булган беренче сәгатемдә шулай хурлыйсыңмы? Аннары көн саен кайтып отчет бирермен, дисеңме? Мактанырмын дисеңме?

Илшадияне калтырау алды. Теше тешкә тимәс дәрәҗәгә житте. Дерелдәшеп торган иреннәре арасыннан: «Әшәке җан! Җирәнәм мин синнән!» дигән сүзләр сытылып чыкты. Ул, өстенә су да коеп тормастан, ак мунчаның җиләс ягына атылды һәм киемнәренә ябышты. Дивана хәленә калган Гамил аның артыннан чыкты, хатынын юатып, назлап бакты, шаярттым гына бит дип, гафулар үтенде, бүтән һичкайчан кәефеңне китәрердәй сүз әйтмәм дип ант итте. Шуларның берсен дә искә алмастан, Илшадия тыңлаусыз һәм буйсынмас халәттә калды. Ахыр чиктә ул Гамилнең: «Һич югы бүгенгә, кешеләр таралышканчы, үзебез поездга утырганчы чыда», дигән соңгы шартына күнде. «Әтиәниең хакына гына!» — диде Илшадия һәм, чыдап-чыдап та булдыра алмагач, ярсып елый башлады. Күз яше түгүдән туктарга кирәген акылы белән аңлый иде, җанына әмер итә алмады...

Депрессиянең, рухи изалану-ачыргалануның теләсә кемдә булып алуы мөмкин. Әмма, Илшадия чигенмәде дә, гафу да итмәде.

Илфатның: «Бу ниткән эш, сеңелем? Нәсел-ыругда булмаганны!» диюенә каршы кыз туганы сабыр гына җавап биргән иде: «Ниткән эш икәнен Гамилдән сорый аласың, абый. Ирләр үзегез аңлашырсыз дип уйлыйм».

Илфат Гамил үз частена китеп өлгергәнче үк сорашты. Лейтенант яшьлек дустына чын дөресен сөйләде. Шуннан соң Илфат сеңелесе белән ныгытып гәпләшергә, кече туганын үгетләп багарга да исәпләгән иде, булдыра алмады. Илшадиягә басым ясау аның намусына тукыну, ихтыярын кысу, шәхес буларак кимсетү тоелыр дип уйлады. Ә менә чирек гасырдан соң үз алдына сорау куя: «Йөрәк саңгыраулыгы белән чирләп калмадыммы икән теге елны?»

Мең тугыз йөз илле бишенче елның августында Илшадия Алабуга районына укытырга китте.

Гамил аның карашы үзгәрмәсме дип бер ел көтте, өметләнде, аннары инде түземе төкәнеп, бүтәнгә өйләнде.

Илшадия белән Гамил хәлләре, күңелләргә сызлавык чыгарса да, үсмерчак дусларын аермады. Анысы начар түгел иде. Инде менә якынлашу көтелә. Хәерлегәме?

Палатадан Гамил ашыгып чыгып китәргә мәҗбүр булгач, Илшадиянең тораташтай катып утыруына сәбәп бер генә иде: аның күңел түрендә бу кешегә карата күптәнге тойгы соңгы тапкыр талпынып җан бирде.

## Авыр сөйләшү

Больницага хәл белергә, күчтәнәч авыз иттерергә дип килүчеләр, телиләрме-теләмиләрме, бер вакыттарак киләләр, чөнки сырхаулар янына иртән дә, кичке якта да мәгълүм сәгатьләрдә генә кертәләр. Шул сәбәпле еш кына болай була: берәү янына бер сәгать дәвамында ике-өч кеше килә. Якшәмбеләрдә бигрәк тә шулай. Хәл белергә дип килүчеләрнең төп хезмәтләреннән буш булуларына бәйләнгәндер инде, күрәсең. Мартның өчендә, якшәмбе булмаса да, Илфат янына да берьюлы өч кеше килделәр. Рәмзия белән Варис подъездда ук очрашканнар. Алар керәп җитеп сәлам бирергә дә өлгермәделәр, Илфатның

кияве Даниял Имамов Гөл-Төркемнән килеп төште. Иртәнге поезд белән кузгалган булган.

Даниял бераз кәефлерәк иде шикелле (хатын яныннан юлга чыгып киткәч, иркенләп алгандыр инде). Ләкин бик ачык чырай белән, бабасын чыннан да сагынып килеп керүе бәхәссез иде. Гөлдерәп торган тавыш белән, гадәтенчә, җыр сүзләре әйтеп сәлам бирде:

— Минуты ай, сәгате ел, шулкадәрле сагындым, дигәннәре хактыр, бабай. Ычкынып-арынып чыгар хәл юк колхоздан. Ике атна буе ашлама ташыдык. Юл өзелгәнче дип ашыктырдылар... Сау гынамы? Хәлләрең аруландымы?

— Хәзер ярый, тернәкләнәм бугай. Үзеңдә ни хәлләр?

— Ашыйбыз да яшибез, яшибез дә ашыйбыз. Зөбәйдә сау-сәламәт калды. Рафис белән Хафиз ике өйне бер итеп уйныйлар. Вагоны белән сәлам алып килдем үзләреннән.

— Сәламәт булсыннар, бик рәхмәт!

Даниял Варис янәшәсендә утырган хатынны танымый иде. Рәмзия Гөл-Төркемдә укыткан елны бишегендә мышкылдап яткандыр әле. Танышмыйча утыру читен иде, сорашасы итте. Илфат аңа бик гади генә итеп аңлатты. «Бу апаң заманасында безнең авылда укытып киткән кеше. Минем чирләп китү колагына кергән дә, килеп йөри минә, рәхмәт төшкере!»— диде. Рәмзия исә бу сүзләрне кияүдән сагаебрак әйтелгәнгә чутлады. Яшьлек дуслыгын сиздерергә теләмәүдән дип уйлады. Аулакта гына килеп чыгарга җай килмәүгә үкенә иде ул. Җан тоемы дип әйтикме, әллә заман шартына китереп телепатия дип җибәрикме, Илфат үзе дә нәкъ шул турыда уйлап куйган иде. Икәүдән икәү генә бик сөйләшәсе килә Илфатның да. Бер уйласаң, ни генә сөйләшерләрдер инде. Икенче уйлап баксаң, һич кенә дә кырт кисәсе түгел. Ни генә димә, аларның күңел эчкәресендә кечкенә генә өмет чаткысы да юк түгел бит. Бәлки алар аңлаша алырлар? Бәлки алар тормышның бик зур мәсьәләсе хакында гәпләшерләр? Бәлки алар, берәүнең дә бәхет өлешенә кермәстән, киләчәктә бер-берсен бәхетле дә итә алырлар? Бу сораулар ханымның да, агайның да күңеленә бик яшерелгән иде, әлбәттә. Хәзергә. Тик кайчанга кадәр?

Илфат Рәмзия күңелендәге сизелер-сизелмәс кенә җылылыкны тойгандай була. Хатын-кыз, татар хатыны, ир-ат тел тибрәтми торып, сине яккан мич кызуы белән җылытмас бит инде. Бу буын хатын-кызларының әдәплесеннән андый сүзне тиз генә ишетә алмассың. Шәһәр паркларында егетләр муенына үзләре ташланырга торган хәзерге кызчыклар түгел алар. Илфатның ерактан урап кына сүз кушарга, мәсәл теле белән генә ул мәсьәләгә кагылып карарга дәрт тә, дәрманы да җитәр иде, кыю-чая булып дан казанмаса да, мокыт түгел ич! Аның шикләнгәне, хәтта шүрләгәне бүтән: авырып егылгач тәкъдим ясавыңмы дип уйласа? Хәлләр мөшкелләнгәч кирәгем чыктымыни, дип туптуры әйтә калса? Телисеңме, теләмисеңме — шулай килеп чыкканга охшап тора лабаса! Бик өзгәләнгән булсаң, Хатирә вафатыннан соң ук эзләп табар идең дисә? Хаклы булачак. Күңелендәген туп-туры әйтүчән ул Рәмзия. Казан хәзер Гөл-Төркемнән килү өчен ындыр арты кебек кенә ул, ә мин эскерт астында югалган энә түгелне беләсең дип тә куйса? Каланың иң зурысында да исемен, әтисенең исемен, туган елын белгән хәлдә адәм баласын тапмый калмыйлар, син, ир-егет, шуны чамаламадыңмы дип әйтсә?

Күңеленнән шундый әңгәмәне кичергәч (булырмы әле ул, юкмы), Илфат әле батыраеп та алды. Үз-үзенә вәгазь укып куйды: «Дилбегә буе сорауларны чакырым буена тезеп ятканчы, ирлегеңне итеп, кырт кисеп сүз кушсаң, уңмассыңмы? Балан бәлеше булып яту, чыннан да, бер тамчы да егетлек түгел инде!»

Кияү белән бабайның сүзләр берегеп китә алмаганын бик анык чамалаган Рәмзия хатын-кыз хәйләкәрлегенә бирелеп алды.

— Без, Илфат, Варис белән кибеткә генә барып килик әле. Бик шәп тавыклар кайтарганнар дигәннәр иде. Сез Даниял белән сөйләшә торыгыз, яме?— диде. Варис та әлеге уенны кабул итте, китәргә чамалап утыра иде инде.

— Кабат кертерләрме соң үзегезне?— Бу — Илфатның ризалашуы иде.— Швейцарлар бик усал дисез ич...

— Һәр усаллыкка дару бар, Илфат, кайгырма,— дип, җавап бирде Рәмзия. Ишек катындагы шәрран ярып, килгән бер кеше белән талашып йөргән хатынга бер кап һинд чәе төрткән иде ул. Шуннан соң кертә генә түгел, бөтен авыруларыңны күтәреп чыксаң да сүз катмаячак.

Рәмзиядәге тоемны кара әле! Даниял тик аны-моны сөйләнеп утырган икән. Кайнише белән Рәмзия чыгып киткәч, алыштырып куйгандай булды кияү. Җорланып китте, тик чаманы югалтып, артыгын кыюланган булып чыкты, бабасы чак кына сүгеп ташламады үзен. Нәрсә ди бит? «Минем тельняшка астына гына, корсакка кыстырган бер акбаш бар, бабай. Аллага тапшырабызмы әллә шуны? Кеше-кара күргәнче ялт иттерик!»

— Вообщем-то дурак син, кияү!— Илфат моны тавышын күтәрми генә, мәгәр төптән кистереп әйтте.— Дурак! Больницага килдеңме син, сәрхушханәгәме? Мине теге дөньяга олактырмакчы буласыңмы? Шалишь, иптәш кияү-Имамов! Үзең зәм-зәм суын йотарга өлгергәнсең бит инде!

— Минем нормадан куркасы юк ла, бабай!

— Мин шуннан куркам шул, Даниял. Үзең өчен генә куркуым да түгел. Кызым өчен дә куркам, багалмадай үсеп килүче оныкларым өчен дә бик-бик куркам. Яхшыга илтмәгәнен беләм мин котырган сыер сөтенең. Үткән ел партия членлыгына кандидат булып керергә рекомендация сорагач, нәрсә дип яздым, неужели оныттың? Яхшы механизатор, молодец, дидем. Башы эшли, илгә-көнгә начарлык кылмасына үземә ышанган кебек ышанам, дидем. Җәмәгать эше дигәннәреннән дә шүрләми, дидем. Но бер минусы бар, яка астына төшергәләргә ярата, аннары кыз-кыркынга күз аларта, дидем. Шуларны холкыннан куып чыгарырга батырлыгы җитмәсә, членлыкка кергәндә миннән хәер-фатиха өметләнмәсен генә түгел, каршы кул күтәрәсемне дә алдан ук әйтеп куям, дидем.

— Әй, арттырып язган идең былтыр да. Кызларга исем дә киткәне юк. Минем хатын хур кызларына алыштыргысыз. Шулай итеп миңа гел сухой закон ясыйсыңмы инде? Зур-зур кешеләр дә тост әйтәләр, бокал чәкешәләр.

— Бәйрәмнәрдә ник тотып куймаска?! Чама белеп. Урынын белеп. Син бит, кияү, чатта-чотта эчәсең. Кыз-кыркын белән тотканым юк, ну колакка кергәләде. Шуны бел, бер өшәнсәң, тансыкка да батырая алмассың... Палатага ярты күтәреп кергәнеңне минем күрше сизенмәсен. Хәбиб абзый Гайсинны әйтәм. Карт коммунист, әдәпсезләрне җене сөйми. Мине дә больницадан кудыртырсың, рисвай итәрләр.

— Син, бабай, тагын күпертә башладың. Мине я утларга, я суларга салмак буласың. Сине, Герой кешене, әдәп иясен кем куа ала?

— Арттырасың, кияү, арттырасың. Геройлык та, коммунистлык та бер дә юкка күкрәк сугарга, бугаз киерергә права бирми. Нәрсә әле дөньяны аңламаганга салышып утырасың? Геройга таләп зуррак, беләсең килсә.— Илфат борчылды, дулкынланды, ахры. Артыгын сайрашып утыруны киракcезгә санап, кырт кисте.— Я, бетте аракы турында ләчтит. Авылда ниләр бар, шуны сөйлә!

— Тракторлар квартал саен график белән ремонтлана. Бер ишесе

көндәлек эшкә кирәк. Әйтәм ич әле ике атна ашлама ташыдык дип. Быел күп тә бирделәр үзен. Комбайннар ремонты өченче көн бетте. Сабаны, чәчкече, культиваторы син Казанга киткәнче үк әзер иде. Язны көтәбез — шул!.. Сине кайчанрак кайтаралар соң әле? Өзеп әйткәннәре юкмы?

— Ул кадәресен әйткәннәре юк әле. Киләсе атнада аякка басып карарсың, диләр. Кул тиз генә төзәлмәс шикелле, вот нәрсә! Вообщем-то, өметсезләнгән юк. Тагын бер-ике атнадан чыгарырлар инде. Әйе, ни, әйтергә онытып торам, съезд материаллары басылган гәзитләрне аерым куеп җыйсын әле, Харисның хәтеренә төшер. Монда радиога колак салгалыйм да соң. Кичә съезд делегатларына дип оештырган концертны тыңладым. Зыкина әйттерде мин сиңа әйтим, кияү. Нәрсә ди? Мәктәп баласы шикелле ятлап калдым.

Чем угодно можно поступиться, ди,
Золотом червонным пренебречь, ди,
Только хлеба каждую крупицу, ди,
Сердце повелело нам беречь, ди.

Вәт! Тыңламадыңмы?

— Әйтәм ич, ашламада. Ташбуага кыш үзәгендә икешәр рейс ясап кайткач, кая ул! Түнү ягын гына карыйсың. Хатынны да тыңлыйсы килми.

— Язгы чәчү алды партҗыелышы булдымы инде?

— Юк әле. Ел да апрельдә була ич. Механизаторлар җыелышы булды. Ике сәгать буран дулаттык.

Илфат белә: тракторчылар, комбайнчыларны, аларга хезмәт күрсәтәчәк кешеләрне еш кына җыйгалыйлар. Андый чакларда тиенгә-тиен өзеп сөйләшенә. Кем кайда нишли? Норма нинди? Арттырып үтәлгән чакта өстәмә күпме түләнә? Энәсеннән җебенә кадәр. Буран дуламый ләкин. Илфат шуңа гаҗәпләнә калды.

— Нәрсә булды ул чаклы?

— Нәрсә булсын! Синең «дус» бар ич инде, Әхмәт Хәйретдине. Гармунын лыгырдата, үзе лыгырдый, кызын мактый. Яңа трактор биргәннәр иде бит аңа. Шуны бәрдергән. Син әйтмешли, яка астына җибәргән килеш күрше авылга — Казнага киткән. Авыл башына барып керүгә, сыерлар фермасының яңа кирпеч абзарына таран ясаган. Бер бәрелгәч, артка чигенгән. Аннары тагын нинди җеннәре купкандыр, янә барып сөзгән. Алгы як кабартма инде тракторның! Үз хисабына төзәттерергә, диделәр. Тракторга да, комбайнга да ике ел якын җибәрмәскә дип карар чыгардылар. Трактор РТСта әле. Түләткән өчен артык шүрләми ул. Акча ул карунда! Эшләтмибез дигәнгә ертылды инде. Теленә салыша башлагач, ишү катырак бәрделәр тегене... Ә кая бара?! Кәрим абый, председатель, әйтә: «Ник соң син мотоциклың белән генә барып сөзмәдең ферманы?» — ди. Аның бит әйтсә әйтә торган гадәте бар.

— Мотосын ялап кына тора ул! Инструкциясен күңелдән белә, шигырь сөйләгән кебек. Тракторы шәп иде. Түгелгән тулы булмас инде. Хөсетле бәндә зыян күрми калмый ул, әй! Казнага нәрсәгә баруы булган соң?

— Яхшы папирос бар дип әйткәннәр иде, ди...

— Ахмак! Бездә тракторларны карап кына торсаң да чакка килә әле. Нагрузка күп потому што аларга...

Тагын беравык утыргач, бераз гәпләшкәч, Даниял китәсе итте. Саубуллашканда сорады:

— Кайчан килеп алыйм?— диде.

Бу сорау Илфат күңелендәге әллә кайсы гына кылны өзде дә куйды, бабасы йомшап калды.

— Синнән алда кайтып китәр идем. Җәяүләп. Кар каплаган кыр

һавасын сулар өчен әллә ниләр бирердәй булдым инде,— диде, чынчынлап нәүмизләнеп.— Патша сарае кебек булса да, больницаларына борылып та бакмас идем. Кайтып булсын иде бүген, басуга чыгарып өйгән тирес өеме өстенә менеп, басудан авылга сөрән салыр идем, бәлләһи. Авылны шулкадәр сагындым!.. Шәһәрне яманлар хәл юк, кияү. Ну авылны да онытыр хәл юк. Ата-баба каны шулай итәдер инде. Эчеп үскән суы, яланаяк чапкан туфрагы...

Рәмзия шактый йөреп килде. Даниял киткәч тә байтак торып. Илфат уйларында баягы бәхәс тагын бер кузгалып алды. Ниһаять, урапурап кына авыз ачарга тиеш булды.

— Менә кияү дигән җан иясе килеп, авылны искә төшереп китте, әле, Рәмзия. Алгысытып. Җирсетеп... Кайтасы килә. Бик!

— Шулай, шулай. Кояшның да үз оясы була.

— Яшьрәк чакта оя корсаң, шәһәр тормышы да начар түгелдер дә. Олыгайгач, үз нигезең тарта икән. Белмәгән идем болай ук булыр дип.

— Шәт, озаклатмаслар инде.— «Чегән чибәре»нең карашында җан җылысы, теләктәшлек чагыла иде. Миһербанлылык кешене чибәрәйтә төшә бит, күркәмлек өсти. Рәмзия дә бу минутларда әллә нинди актрисаларыңнан, примадонналарыңнан да матуррак булып күренә иде. Илаһилык белән өретелгән матурлык иде ул. Шул хәл Илфатка көчкуәт, кыюлык-чаялык өстәде. Әле генә Рәмзия әйткән сүзгә ялгап:

— Тик үз оямда мин, байгыш, япа-ялгыз булам бит инде, Рәмзия. Бер ялгызым.

— Байгыш та үз баласына лачын дип исем кушкан, диләр. Ник алай дисең? Илдә чыпчык үлми.

— Алар да парлашып яшәгәнгә үлмиләр.

Рәмзия йоклап торучылардан түгел шул. Кыюлык җыеп сорамасынмы:

— Авылны сагынып тилмерүең шул тикләме? Солдат булган, читтә җир-су күргән кеше бит син, Илфат. Әллә югыйсә миңа әйтер сүзең булып, әйләнеп боргаланасыңмы?

Илфат моны ук көтмәгән иде.

— Рәхмәт яусын әйтмичә аңлавыңа, Рәмзия,— диде һәм ятагында калкынып куйды.— Яшьлектә үлеп-үлеп яратуым хакына олыгаеп беткәч ачыктан-ачык сөйләшик әле...

Рәмзия тавышында исә ягымлылык, күңел күрергә тырышудан битәр үтә җитдилек ишетелде. Кырыс җитдилек хәтта.

— Монысы бит инде, иптәшкәем, кибеткә күмәч алырга чыгу гына түгел. Монысы — авызы пешкән, дөнья җилендә йөзе какланган кешеләрнең икенче, өченче катка алданмаска теләп зур мәсьәлә чишәргә маташулары. Минем дә үз оям бар. Анда мин үземне хуҗа итеп тоям. Минем дә балам бар. Аның белән киңәшми генә җилбәзәкләнә алмаячакмын. Инде дә килеп, минем нык нязләшкән эш урыным, хезмәттәшләрем, Рәмзия апа гына дип торган шәкертләрем бар.

— Үзең риза булсаң, калганнары хәл кылынасы киртәләр, Рәмзия. Миңа үз ризалыгың кыйммәт. Минем нигезгә кайтып гомер итәргә ризалыгың. Минем малайларның киләчәге хәл кылынган дип сана. Варис тиздән инженер-механик буласы егет. Армиягә барып кайта да үз көнен үзе күрә башлый. Харисы башта солдат хезмәтемне тутырып кайтам, аннары укыйм, ди. Безнең якта торасы егет түгел диюем. Кайткан чакларында — баш өсте. Безнең өй алты почмаклы, хет туп тип, футбол уйна!.. Зөбәйдә күптән аерым дөнья көтә. Казандагы фатирыңны фәкать үзеңә киләкчә хәл кыласың, мин ул мәсьәләдә сыңар сүз дә әйтмим...

— Фатирга хуҗа табылыр. Мин, синең белән җитди сөйләшү бул-

ды дигән шарт белән, Хәйдәргә хат язам. Менә шул. Аннан җавап килми торып, әлеге бу хакта кузгатмыйбыз, яме?

— Килештек. Мин арып киттем сымак. Сөлге очын салкын суга гына манып бирче. Битне, маңгайны сөртеп алыйм. Һәм курыкма, минем бу халәт озакка бармас. Синең ризалыгың мине тиз аякландырыр. Өметсез шайтан, диләр.

— Куркырдай булсам, бүгенге сөйләшү булмас иде.

Йөзен-битен салкынча су белән сөрткәч, Илфатның кәефе ярыйсыланды. Бүген, ихтимал, беренче тапкырдыр әле, ул кинәнеп елмайды. Ниләр генә юк иде бу елмаюда! Барыннан да элек, яшьлек дустының үзен аңлавына чиксез куану. Киләчәккә күңел тулы өмет. Тагын әллә ниләр...

Хәбиб абзый кайтып керде. Соңгы араларда ул кордашлары, больницада дәваланучы фронтовиклар белән гәпләшә, кызыл почмакта газеталар, журналлар актара, карчыгы килсә (көн аралаш ул килми калмый), аеруча рухланып китә. Бүген кәефе күтәренке, берсекөнгә аны больницадан чыгаралар.

— Аш вакыты җитте, Илфат энем. Әйтимме, кертсеннәрме?

— Рәхмәт, Хәбиб абзый. Сестралар бүтән чакта кертер. Менә Рәмзия алып керер бүген. Монда гына ич,— диде Илфат. Бу сүзләрне әйтүдә горурлык та, таянычы барлыгына гаҗәеп сөенү дә, үзе хакында кайгыртып йөрүче агайга меӊ-меӊ рәхмәт хисе дә бар иде. Күп кирәкмени адәм баласына?! Кайчак без шулай дибез. Ә төптәнрәк фикер йөртсәң, күп, бик күп кирәк. Сине аңлаган, аңларга тырышкан, сиңа булышудан җанына җим таба алган кешең булу — бик-бик күп нәрсә ул. Биниһая зур нәрсә. Кайберәүләр шул бәхетне бөтенләй татымыйча, татый алмыйча якты дөньядан китәләр. Икенче берәүләр бу бәхетне татырга сәләтсез булалар. Андыйлары үз җаннарының караклары гына түгел, башка җаннарны талаучы караклар булалар. Иң кызганыч бәндәләр шулар. Тик алар үзләренең җәлләүгә дучарлыкларын аңламыйлар. Шуңа күрә башны салават күперенә терәп йөриләр, зурдан кубып сөйләшәләр, үчегәләр, хөсетләнәләр, кара эшләрдән тартынмыйлар, кара сукмаклардан йөриләр.

Рәмзия ханым белән Илфатны, килер көннәре ничегрәк булып калыпланса да, андый кара көннәр көтми. Андый кара көннәр аларның күңел яктысыннан шүрләп ерак читенәчәкләр. Тагын бер күрәзәлек әйтергә мөмкин, шушы яшьләренә җиткәнче күргәннәре, кичергәннәре аларга бәләкәй генә сөенечне дә олы итеп тоярга булышачак. Кояшлы иртә, хуш исле чәчәкләр, күршеләренең ихтирамлап эндәшүләре, гади генә хәләл ризык, кешегә биреп торган әҗәтләре — һәммәсе аларга бәхет мизгелләре, сәгадәт минутлары булып тоелачак. Гади, эчкерсез, гадел, ярдәмчел, эшчән булып кала алган кешеләр алдында баш иярга кирәк...

*Ахыры киләсе санда*

## Рәшит Гәрәй

# ЙӨРӘКТӘГЕ УЧАКЛАР

## Шул инеш хакына

*Советлар Союзы Герое*
*Фәхрази Галиевкә*

Таң яңа сызылып килгәндә
Нурлары уйнаклый үрләрдә.
Таң белән уянган солдатның
Теләмим уйларын бүләргә.

Нигә соң әле бу дулкыннар
Чупылдап бәреләрларга.
Алар да тиеш бит ләбаса
Ветеран йөрәген аңларга.

Күзләре текәлгән инешкә,
Таллары иңенә сарылган.
Днепр суларын кичкәндә
Ул шушы инешне сагынган.

Шул инеш хакына ыргылган
Бөтерелеп кайнаган упкынга.
Я үлем, я җиңү!.. Эзләмә,
Өченче бүтән юл юк монда.

Ыргылган, куплэрнең язмышын
Салган да үзенең иңенә:
— Яңадан кайтарып алынсын
Бер окоп казырлык җир генә.

Аннары күз күрер... Калганын
Кыюлык, җитезлек хәл итәр.
Әнә ич, артымнан ярдәмгә
Ашыга Апанас, Хәмитләр.

Исенә төшерә ветеран...
Таллары иңенә сарыла.
Ул бүген шул кояз талларны
Кочканда Днепрны сагына.

Ил-анам, күр, ничек кинәнеп
Тыңлый ул йөрәгең тибешен.
Барысы да кадерле шул аңа:
Иделең, Днепрың, инешең.

## Арышларым исән-сау булсын

Бытбылдыклар әле исән икән,
Арышлардан килә тавышы.
Ник алар да шулай минем кебек
Якын итә икән арышны?!

Ишетмичә таныш авазларын
Кыш буена ничек түзгәнмен...
Юл кырына чыкмас микән алар,
Күреп китәр идем үзләрен.

Юк, чыкмыйлар... Ә бит сизеп торам,
Бик якында алар, якында:
Басу уртасында җәелеп үскән
Әнә теге нарат артында.

Килә, ахры, мине әүвәлгечә
Артларыннан дәшеп кертәсе.
...Алар кагылып үткән арышларның
Чәчләремә куна серкәсе.

Иңнәремә куна... Кулым бармый
Кагып төшерергә берсен дә.
Бытбылдыклар сине оныткан, дип
Син көрсенмә, күңел, көрсенмә.

Тавышларын тыңлап кинәнәм ич,
Нәрсә кирәк сиңа тагын соң?
Безне әле кат-кат очраштырыр,
Арышларым исән-сау булсын!

## Шәһәр читенә чыксам

Кырлар исе тулды автобуска,
Чыкканбыздыр шәһәр читенә.
Башым тыгып карыйм тәрәзәдән
Зәңгәр чәчәк аткан җитенгә.

Тып-тын басуга да җан керә шул
Иркә җилләр йөзен сыйпаса.
Дулкыннарын кагып, әнә ул да
Офыкларга барып тоташа.

Офыклар да шундый зәңгәр-зәңгәр,
Зәңгәрлекне күктән аламы...
Әйтерсең лә алар чәчәк аткан
Җитен кырларының дәвамы.

Чиге дисәң, мондый зәңгәрлекнең
Чиге булу мөмкин түгелдер.
Уйсу җирдә торсаң, бу зәңгәрлек
Өсләреңә синең түгелер.

Ә бер якта бодай дулкынлана,
Юлчыларга биреп сәламен.
Кешеләр йөзендәге елмаюның
Ул күптәннән белә сәбәбен.

Башаклары тулырак булган саен
Яме арта җирнең, елларның.
Иминлектә үткән бу гомернең
Һәр мизгеле матур җыр аның.

Ә ул гомер туган җирдә узса,
Нәрсә кирәк тагын кешегә?!
Шәһәр читенә чыксам, шул җитеннәр
Авылымны искә төшерә.

Башыма сыймый: ташлап киткәннәргә,
Туган илем, ничек яттыр син?
КамАЗларың, аның янындагы
Авылларың белән якын син!

## Ромашкалар үскән урында

Юкка куанганбыз, туктадык, дип,
Бераз привал ясап алырга:
Ашыкмагыз әле, дигән кебек,
Боерык булды окоп казырга.

Буйсынып без кырыс командага,
Сибелештек урман кырына.
Яткан җирем минем туры килде
Ромашкалар үскән урынга.

Бер-бер бәйрәмнәре микән әллә,
Бөтенесе актан киенгән.
Буйга җиткәннәре сеңелләрен
Кочып алыр өчен иелгән.

Гаебемне йолып бетә алмам,
Серләрен, дим, әгәр бүлдерсәм.
Алар мине мәңге гафу итмәс
Сапер көрәгенә үрелсәм.

Чәчәкләрен түгел, тамырларын
Ничек кулың барсын өзәргә?!
Җиргә күмелеп калыр өченмени,
Үскән алар җирне бизәргә.

Командирга багам:— Бер гөнаһсыз
Чәчәкләрне кирәк аярга:
Рөхсәт итче окоп казыр өчен
Башка урын миңа сайларга!

## Дозорда

Күк йөзендә болыт күренер көнне
Көткән идек күпме вакытлар.
Китереп койды... Яңгыр суы белән
Яртылашка тулды окоплар.

Чылансак та, безгә бөтен буйга
Торып басу катгый тыелган.
Авангардтан дозор икәнеңне
Чыгарма син монда уеңнан.

Маневрлар гына бит бу, димә,
Сабырлыгың җуйма, түземеңне.
Тыныч окобыңда итеп түгел,
Сугышта дип хис ит үзеңне.

Бераз дөнья күргән ирләр өчен
Җебеп-коелып төшү чит нәрсә.
Тик нишләмәк кирәк — окобыңда
Хисләреңә урын җитмәсә:

Дозорда да күнегә алмам, ахры,
Камышларга поскан тынлыкка.

Кычкырасым килә күккә карап
Безнең якка аккан болытка:

— Төяп килгән шифаларың белән
Бөтен җирне тигез куандыр.
Җитен чәчәк аткан кырларымны
Иңләп үтсен берүк бу яңгыр.

## Сабан төрәннәре тутыкмаса...

Гомер буе, дисең, җир сукалыйм,
Кырдан башка нәрсә күрелгән...
Ничек булыр икән бу һөнәрне
Алыштырып куйсам бүгеннән.

Тракторны кем дә йөртә аны,
Йөртмәгәннәр укып өйрәнә.
Йөз ат көченә ия моторы бар,
Сабаны бар тагып сөйрәргә.

Мен дә утыр... Иплэп кенә кабыз...
Бер карап ал тирә-ягыңа.
Киңәшләрен тыңла агрономның
Буразнаңны сызган чагында.

Ә син менә Айга очып кара,
Очып кара чиксез Галәмгә.
Андый эшне бик үк тапшырмыйлар
Безнең ише гади адәмгә.

Ул чаклысын өмет итмим дә мин,
Уйлыйм менә нәрсә турында:
Без эшләрдәй бер-бер эш юк микән,
Космонавтлар очкан урында.

Тукта, дустым, әйтер сүзләремә
Кабармасын берүк ачуың.
Космонавтлар очып киткән урын —
Син сөргән җир, синең басуың.

Галәм киңлекләрен буйсындырган
Батырлар да күктән төшмиләр.
Алар да бит җирдә син үстергән
Арышларның исен иснилэр.

Иген игүчеләр! Батырлыкта
Үзегезне нигә чиклисез?
Министр да, шагыйрь, космонавт та
Яши алмый җирдә иписез.

Дөньядагы барлык җырларның да
Матурлыгы, көче икмәктә.
Кем дә булса үлмәс дан казанса,
Сез лаеклы аңа икеләтә.

Аңлыйм да мин сезне: ни әйтсәң дә
Күңел инде һаман күңел ул.
«Сабан төрәннәре тутыкмаса,
Айга очу берни түгел ул!»

## Дөрли аның учаклары

Кемнәр сине гөләп белән
Каймалап алган, урман?
Баскан җиремнән ни гомер
Кузгала алмый торам.

Сокландыра матурлыгың,
Серлелегең аннан соң.
Тезләнеп сиңа табынсам,
Мине сүзсез аңларсың.

Аңларсың җирсәүләремне —
Йөргәндә еракларда.
Хисләнер йөрәк юк, димә,
Ил гизгән ир-атларда.

Ялгышма берүк, алар, дип,
Сагына-яна бәлми.
Һәркайсының күңелендә
Туган як уты дөрли.

Дөрли аның учаклары
Күпме үр-аланнарда!
Тик синдә янган берсеннән
Якынын табалмам ла.

Яна ул мең-мең очкынын
Ерак-еракка чәчеп.
Ымсындырып, мине һаман
Тора үзенә дәшеп.

Кайтам иркен аланыңа,
Ул чакырган урынга.
Телим мин шул учагыңның
Бер очкыны булырга.

## Сыймассың йөрәгемә

Кыр казлары да уздылар
Моң түгеп, каңгылдашып.
Бер миннән генә калмаган
Китүләр саубуллашып.

Туган авылым белән тагын
Хушлашам... озаккамы?
Аз булмады аның мине
Кадерләп озатканы.

Озатты, тайпылма диеп
Сукмагың-юлларыңнан.
Тормыш эченә озатты
Җитәкләп кулларымнан.

Күпме генә тырышсам да
Сагынмый торалмамын.
Тагын бер әйләним әле
Урамын, урманнарын.

Кочыйм әле усакларын
Яшьтәш дусларым итеп.
Миләшләрен авыз итми
Китим соң ничек үтеп?!

Үр менгәч каерылып карау
Кергәндер гадәтемә.
Бер үк сүзләрне кабатлыйм
Аерылу сәгатендә:

— Сагышым кала эленеп
Талыңа, тирәгеңә.
Алып китәр идем салып,
Сыймассың йөрәгемә.

Ялан тәпиләп башлаган
Гомерем юлы бит син.
Кечкенә улың өчен бик
Зур бит син, олы бит син.

Тукайның 100 еллыгына

# КАЗАНДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ

И Казан! Дәртле Казан!
Моңлы Казан! Нурлы Казан!

Г. Тукай. «Пар ат». 1907.



Казанда элекке «Болгар» номерлары. (Хәзерге Татарстан белән Киров урамнары чатындагы йорт.)

Тукай 1907—1912 елларда «Болгар»ның 40 нчы бүлмәсендә яшәгән.

Татьяна Зуева рәсеме.

## Зәкия Рәсулева

# ТУКАЙ ЭЗЛӘРЕННӘН

### Сүз башы

Моннан бик күп еллар элек, без пионер чакта, әле пионер отрядлары Казанда яңа гына төзелеп килгән елларда, без Кырлай авылына әбиемнең бертуган апасына кунакка кайттык.

Әбиемнең апасын без олылап «Кырлай дәү апа» дип, аның ирен «Кырлай җизни» дип атый идек.

Кырлай җизни белән Кырлай дәү апа үзләренең олы уллары Хәлилрахман абыйның зур гаиләсе белән бергә яшиләр иде. (Хәлилрахман Гобәйдуллинның «Тукай турында замандашлары» һәм «Тукай турында хатирәләр» китабында истәлекләре бар.) Шул Хәлилрахман абый 18 бала атасы булып, ул балаларның байтагы үлгән булса да, без барганда өй кыр чирүе кебек эреле-ваклы балалар белән тулы иде. Ләкин шундый зур бу гаиләдә һәркем итагатьле, чиста-пөхтә һәм гаҗәеп бер тәртипкә буйсынып яши. Һәр олы үзеннән кечене кадерли, һәр кече үзеннән олыны хөрмәтли.

Хәлилрахман абый уңган балта остасы булып, тирә-күршеләргә тәрәзә рамнары һәм башка кирәк-яраклар эшли. Аның хатыны — туганым җиңги — җөй остасы. Ә көн саен өйдәге идән-сәкене юып чыгару, кечкенә балаларны чиста тоту, ишегалдын себерү, терлек-туарны тәрбияләү — үсмер балалар эше. Алар бу эшләрне һичкем әйткәнне көтмичә үз чиратларында житез һәм пөхтә итеп башкаралар.

Өйдәге иң карт кешеләр — Кырлай җизни белән Кырлай дәү апа — балаларны бик яраталар. Эш-көшләр беткәч, алар: «Ягез әле, балалар, урын хәзерләгез!» дип әйтүгә, «кечкенә өй» бер мәлгә гөж килеп ала. Бу ике тәрәзәле кечкенә өйдә почмакка бик пөхтә итеп өеп куелган урын-җирдән гайре һичнинди мебель заты юк. Ялт итеп юып чыгарылган идәнгә өйдә сугылган палас, аның уртасына шулай ук кулдан сугылган кызыл шакмаклы ашъяулык җәелә. Ашъяулык әйләнәсенә стена буйлап утыру өчен аллы-гөлле корамадан сырылган озын тар көрпәләр сузыла, таянып утыру өчен нәни мендәрләр ыргытыла. Баш лап Кырлай җизни белән Кырлай дәү апа түргә менеп тез чәнчеп утыралар. Аннан соң, без, кунаклар, кем ничек булдыра ала, шулай урнашабыз. Аннан инде дистәгә якын бала-чага бик әйбәтләп аяк бөкләп тезелешеп утыралар. Шулай итеп бу күңелле табынны алар түгәрәклиләр.

Кырлай җизни табын уртасына зур агач табак куя. Ул арада һәркемгә тиз генә агач кашыклар өләшенә. Җизни зур катык тәпәнен каплаган кызыл читле тастымалны ача. Ә анда тәпән тулы мөлдерәп пешкән кып-кызыл җиләк! Җизни «Бисмилла»сын әйтеп, вакарь белән генә җиләкне табакка аудара, ә дәү апа янындагы савыттан җиләкле табакны сөт белән тутыра. Бүген пешкән хуш исле ипине җизни күкрәгенә терәп кисеп, авырлыгын сиземләрлек телемнәрне һәркемгә өләшеп чыга. Аннан инде үзе дә бик кәефләнеп: «Ягез әле, балалар, җиләктән житешегез: Кырлай җиләге бу! Кышын сагынып сөйләрсез әле,

әйдә, житешегез!» дип, фәрманын биругә, ашау башлана. Һичкем сөйләшми. Мондый тәмле җиләк ашаганда, сөйләшеп торасыңмыни соң?!

Бер табак җиләкне ялт иттеругә, берәуләр тиз генә табынны җыеп ала, икенчеләр савыт-саба юа, өченчеләр урнаштыра, кайберсе йөгереп кенә ашъяулыкны селкеп кереп, төреп киштәгә элә, палас та җыелып куела.

Шуннан Кырлай дәү апа безгә карап: «Дәү әниегез хат язганда гел сезнең турыда яза. Ягез, безгә дә һөнәрләрегезне күрсәтегез!» — ди.

Безнең өйдә элек-электән музыка, җыр, бию, шигырь сөйләү бик яратылганга, аларны башкарырга кушканда кыстатыш дигән нәрсә булмаганга, монда да без, абый белән икәү бүлмә уртасына чыгып басып, бик ихлас күңелдән:

— И туган тел, и матур тел, әткәм, әнкәмнең теле! — дип, кычкырып җырлап җибәрәбез. Аннан соң абый «Сабыйга» шигырен сөйли. Аны мин алыштырам. «Бичара куян» бетүгә абый «Кызыклы шәкерт»не башлый. Аннан икәүләшеп «Эш беткәч уйнарга ярый»ны сөйлибез. Аннан соң мин, башыма чачаклы-чуклы каттажи киеп, әнинең очып торган киң юка шарфын иңбашларыма салып, кулларым белән җилпеп, оча торган күбәләккә охшатып:

Әйт әле, күбәләк,
Сөйләшик бергәләп...

— дип җырлый-җырлый биеп әйләнәм һәм шигырь беткәндә җизни белән дәү апа алдына килеп тезләнеп баш иям.

Кырлай җизни белән Кырлай дәү апа: «Бәрәкалла! Машалла!» — дип, бик яратып карап утыралар, тел шартлатып, бер-беренә күз төшереп алалар. Аннан җизни дәү апага:

— Менә боларның барсын да Габдулла язган бит!— ди.

— Әйтмә дә инде, атасы. Каян шулай остарган диген, ничек барсын да уйлап чыгарган бит!

— Бик зирәк бала иде шул! — дип, алар үзара сөйләшә башлыйлар. Без бу форсаттан файдаланып, моңарчы күзләрен ахыр чиккә кадәр ачып таңга калган балаларның олысы: «Әйдәгез инешкә!» — дип аваз салуга, оясыннан купкан умарта иледәй дәррәү кубып, өйдән чыгабыз да, үзләре белән су куыш уйнарга көткән көмештәй вак балыклар янына инешкә йөгерәбез.

Ә икенче көнне таң белән һәрберебез каен тузыннан эшләнгән тырыслар асып, ашарларыбызга алып, Кырлай урманына җиләккә китәбез.

Дәү апаларның әнием белән яшьтәш Зәйнәп исемле кызларын без «туганым апа» дип йөрибез. Ул икенче авылда кияүдә булып, без авылга кайткач, ул да Кырлайга килде.

Туганым апа сабыр табигатьле, һәрбер сүзен матур итеп үзенә бер күңеллелек белән сөйләүчеләрдән иде. Ул килгәч, без аннан Габдулла Тукай турында белгәннәрен сөйләвен үтендек.

Туганым апа истәлекләр сөйли. Күптән, бик күптән үткән хәлләр күз алдына килә, мин аларны үзем күргәндәй булам.

Әнә Кырлай авылының ямь-яшел чирәмле урамы. Фәтхерахман җизниләр капкасыннан чыгып Казан якка китсәң, күршедә Хәлиуллалар нигезе, әнә Мөхәммәтшалар, аннан Гатауллалар йорты, алардан соң Сәгъди абзыйлар. Әйе, нәни Габдулланы тәрбиягә алган Сәгъди абзыйлар йорты. Ул читән коймалы, җил капкалы өй, башка өйләрдән әчкәрәк кертеп салынган. Өйалдында матур булып ак каен үскән. Урам якка да, ишегалды ягына да икешәр тәрәзә караган салам түбәле кечерәк кенә йорт.

Туганым апа нәни чакта төрле йомыш белән дә, сабан туе чорларында күкәй җыя йөргәндә дә Сәгъди абзыйларга кerә торган була.

Сәгъди абзый ат-сыерлы — таза тормышлы кеше. Агара башлаган сакаллы кечерәк кенә буйлы абзый. Ул үзе дә Кырлай җизни янына кергәли торган була.

Әнә Сәгъди абзыйның хатыны — нәни Габдулланың тәрбиягә алган әнисе Зөһрә апа, ябык кына озын буйлы, зәңгәр күзле хатын, уң кашы өстендә зур гына миңе бар. Кызыл француз итәкле, зәңгәргә манган киндер күлмәк кигән, башында француз яулык. Ул ак тула оек белән чабатадан йөри. Калын гына тавыш белән сөйләшә торган була.

Бер елның көзендә, Зөһрә апа үзенең тәрбиягә алган улы Габдулланы Мәһруй абыстайга — Кырлай дәү апага укырга китерә.

Кырлай дәү апа уртача буйлы, сабыр табигатьле, җайлап кына сөйләшә торган олы яшьләрдәге апа. Ул нәни Габдулланы дога укып кабул итә.

Шул көннән башлап һәркөн иртән тәрәзә алдыннан куян бүрекле, кыска бишмәтле, иңе аша бау белән кызыл чүпрәктән теккән букчасын аскан Габдулла үтә. Аны көн саен Сәгъди абзыйның кызы Сажидә озата килә. Әнә алар зур урам белән киләләр, багана башларына ак шарлар утырткан, бастырыклы, биек татар капкасы янына җиткәләр. Сажидә апасы авыр капканы ачып, Габдулланы ишегалдына кертә. Ишегалдына кергәч, уң якта келәт, кое, каралтылар. Ә сул якта, капка янында, җимеш бакчасы, аңа башы белән салынган зур йорт. Ул йортның алгы өч тәрәзәсе «ак өй», ике болдырлысы «кечкенә өй», өйнең инешкә караган ягы «аш өе». Габдулла белән Сажидә апасы ишегалды буйлап үтеп аш өенә җиткәләр.

Сажидә апасы калын ишекне ачып Габдулланы укырга кертә, шулай энесен озатып кайтып китә. Ә уку беткәч, тагын килеп ала. Ул чакта бик кадерле була Габдулла.

Кырлай дәү апада Габдулла, башка балалар белән бергәләп «Иман шарты»н укырга өйрәнә. «Иман шарты» әлифба һәм төрле догалардан торган беренче дәреслек була.

«Иман шарты»н өйрәнгәч, укучылар Фәтхерахман җизнигә мәдрәсәгә күчереләләр.

Фәтхерахман җизни чак кына билдән бөгелеп йөри, кечерәк кенә буйлы, очланып төшкән сирәк ак сакал-мыеклы, күзен кысыбрак кына көлемсерәп сөйләшә торган карт. Ул Габдулла Тукайның атасы Гариф абзый белән үз заманында данлыклы булган Кышкар мәдрәсәсендә укыган.

Кырлай җизни балаларны укыта торган мәдрәсә ишегалды түрендә, инешкә төшә торган бакчада шомырт агачлары янындагы кечкенә генә бер йорт. Ян-якларда икешәр тәрәзә. Өй эче түрендә сәке. Сәкедән ишеккәчә озын утыргыч сузылган. Шул кечкенә генә өйдә утызлап бала укый. Уку иртәнге җидедән тугызга, аннан сәгать унбердән көндезге бергә кадәр дәвам итә. Бу мәдрәсәдә балалар гарәп телендә язылган дини китаплар укырга өйрәнәләр.

Мин туганым апаның сүзен бүлеп сорап куям: «Нигә кирәк инде ул дини китапны өйрәнергә?» — дим. «Ай, юкны сөйләп утырма,— ди туганым апа, гаҗәпләнү һәм шелтә белән миңа карап.— Ул заманда дини китап укытмыйча ни укытсыннар тагын,— дип сүзен дәвам итә ул.— Минем Хәлилрахман абыем белән Габдулла бергә укыйлар, дәрестән соң урамда бергә уйныйлар иде. Ләкин ул озак тормады. Габдулла Кырлайдан китте»,— дип сүзен бетерде туганым апа.

Өйдә тынлык урнашты. Бераздан: «Туганым апа, ә сез Тукайны тагын күрдегезме?» — дип сорадым мин.

— Байтак еллар үтте,— дип тагын сөйләп китте туганым апа.— Хәлилрахман абыйга 21 яшь тулды һәм көннәрнең берендә аңа солдатка алу өчен чакыру килде. Ат җиктеләр дә, әти абыйны утыртып, комиссия торырга Арчага илтә китте. Әни ак өйдә намазлык өстендә намаз укып, теләк теләп калды. Мин керләр удым да шуларны эләргә ишегалдына чыктым. Кинәт олы капка ачылып китте. Мин ялт итеп әйләнеп карадым. Ишегалдына кун аяк киемле, өстенә зәңгәрсу-кара пальто кигән бер егет килеп керде. Салкынча күзге көн булгангадыр инде, аның битләре кызарган, түгәрәк кенә матур йөзле, килеш-килбәте сылу гына бу егетне мин бик аз вакыт күреп калдым. Һәм шунда ук танылым, ул — Габдулла иде. Мин оялып тиз генә бакчага кердем. Чөнки ул заманда без — кызларга ир-атка күренергә ярамый иде, без кача идек.

Габдулла акрын гына килеп өй ишеген шакыды. Һәм әни янына кереп китте. Әнигә ул күчтәнәчкә бөртекле яхшы чәй, бүләккә бик матур башъяулыгы китергән иде. Шунда ул: «Мин хәзер китаплар язам. Сезгә дә китапларымны җибәрермен әле»,— дигән. Бераздан алар сөйләшә-сөйләшә өйдән чыктылар. Габдулла: «Мин үзебезнең авылга кайткан идем, ә Кырлайга сезнең белән саубуллашырга дип килдем. Мине дә солдатка алырга комиссиягә чакырдылар, хәзер каралырга барам»,— диде. Габдулла саубуллашып чыгып китте. Әни дә, мин дә аның артыннан изге теләкләр теләп, озатып калдык,— дип сүзен бетерде туганым апа.

Бу сөйләгәннәрдән соң, Кырлайда барлык нәрсә минем өчен бөтенләй үзгәреп китте. Мин иртән торып көндәгечә ишегалдына чыгам. Ләкин әйләнә-тирәм миңа инде бөтенләй башкача — җанга бик якын булып күренә.

Әнә чирәмле киң ишегалды. Бу чирәмле сукмаклардан нәни Тукай үткән. Әнә ишегалдының бер ягында бакча һәм зур йорт. Бакчадагы җимеш агачлары Габдулланы көн саен каршы алганнар һәм озатып калганнар. Ә менә бу йортта Габдулланың нәни куллары беренче булып китап ачкан, бу йорт стеналары нәни Габдулланың тырыша-тырыша әлифба өйрәнгәнен тыңлап торганнар. Мин таң белән ишегалдына чыгам, анда Тукай эзләренә басып йөримен сыман. Инеш янындагы бакчада ярымкараңгы кечкенә өй дә хәзер миңа бик кадерле — Габдулла шунда укырга йөргән. Ә бик карт биек шомырт агачлары Тукайның башыннан үткәннәрне күреп, аның кичерешләрен аңлап торганнардыр һәм хәзер һәрбер яфрак селкенүе белән алар миңа шул хәлләрне сөйлиләрдер кебек тоела иде. Якындагы инешкә төшәм. Анда да ташлар арасыннан челтерәп аккан су тавышына кушылып:

> «Зурмы?» — дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә;
> Халкының эчкән суы бик кечкенә — инеш кенә,—

дип Тукай җырлый сыман. Ә инде Кырлай урманына кереп, кызарып пешкән җиләкләргә үрелү белән, шул тирәдә генә чыршы, наратлар арасында хәл җыеп, күккә карап яткан Тукайның:

> Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
> Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк,—

дип, көйләп җырлаганы ишетелгәндәй була.

Инде ял вакыты беткәннән соң, ат юырттырып кайтыр юлда да безне Тукай моңы озата килде:

> Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап...

Кырлайның зур урманы, нәни инеше, кызарып пешкән җиләкләре, хәтта Казанга илтә торган такыр юлы да, күңелләргә үтәрлек моң көйләүче талгын җиле дә Тукайны хәтерләтә. Шуңа күрә Кырлай бик кадерле булып һәрчак күңелдә саклана.

Мәктәптә укыган чаклардан ук әнә шундый истәлекләрне язып куя торган гадәтем бар иде. Үз истәлекләремә әтиемнең Габдулла Тукай белән танышуы турында сөйләгәннәре... әниемнең хатирәләре, туганнарымнан ишеткәннәр дә кушылды. Мин шулай ук байтак кешеләрдә, нәкъ безнең гаиләдәгедәй, Тукай турындагы истәлекләрнең легендалар кебек буыннан-буынга сөйләнеп килингәнлеген һәм кадерләп сакланганлыгын белдем. Алар рөхсәте белән ул истәлекләрне дә язып алдым. Бу язмада әнә шулар бергә тупланды.

Истәлекләр Тукай биографиясенә карата хронологик тәртиптә урнаштырылды һәм дүрт бүлем итеп тупланды: «Туган якларда», «Уральскида», «Казанга кайткач» һәм «Тукайның туганнарын эзләгәндә».

Берничә кешенең Тукай тормышының төрле елларын эченә алган озын истәлекләре, мөмкин булганча бүлгәләнеп, фәлән кешенең беренче истәлеге, икенче истәлеге һ. б. рәвешендә елларына карап төрле бүлекләргә урнаштырылды.

Кайбер истәлекләрне ачыклау өчен, Тукай турында моңарчы матбугатта басылып чыккан истәлекләрдән өзекләр китерелде.

Истәлекләрнең күбесе бик кыска, Тукай турындагы олы хатирәнең бер мизгелен генә яки Тукайны чолгап алган мохитны гына тасвирлыйлар. Ләкин ул кечкенә генә штрихлар да шагыйрь турында безнең белгәннәребезне тагын да тулыландырырга ярдәм итәрләр, дип уйлыйм.

Бу язмага кергән истәлекләр һичнинди фәнни-документаль булуга дәгъва итми. Алар Тукайның халкыбыз күңел түрендә булуын, Тукайга әз генә кагылышлы булган кечкенә генә истәлекләрне дә югалтасы килмичә, бер кадерле тарихи хикәя итеп саклавын, халыкның олуг шагыйрьгә булган кадер-хөрмәтен күрсәтәләр.



# ТУГАН ЯКЛАРДА

## Соңгы күрешү — бәхилләшү

*Корбангалиева Әминә Шакировна (1902 елда туган) сөйләгәннәрдән беренче истәлек*

Бу очрашу 1950 еллар тирәсендә булды. Казанда Николай Столбов урамында яшәүче Якублар мине кунакка чакырдылар. Без аларга барып кереп урнашкач, хуҗалар: «Менә безнең авыл кунагыбыз да бар әле,— дип, минем янга бер авыл абыстаен утырттылар. Минем күзләрем инде ул вакытта ук яхшы күрми иде. Гадәтебез буенча куллар биреп күрешеп, хәл-әхвәл сорашкач, мин бу абыстайны якынрак беләсем килеп: «Сез кайсы авылдан килдегез?» — дип сорадым.

— Мин Соснадан — Сосна Пучинкәсеннән,— диде.

— И, алай булгач, сез Габдулла Тукай энисе Мәмдүдә абыстай турында да ишеткәнегез бардыр. Белсәгез миңа сөйләгез әле, зин-

һар. Минем Мәмдүдә абыстайга хөрмәтем бик зур, аның язмышын бик беләсем килә иде,— дидем.

— Мин аның турында әнием сөйләгәннәрдән генә беләм шул,— диде күршем, сүзен башлап.— Безнең авылда әле мин белгәндә дә, бик кырыс табигатьле Шакир мулла бар иде. Ул Өчиле авылыннан баласы белән тол калган Мәмдүдә абыстайга өйләнә. Башта Мәмдүдәнең үзен генә алып кайта. Соңрак Мәмдүдәнең улы Габдулланы да үзебезнең авылга — Соснага алдырта. Ул вакытта минем бала чагым иде. Ә Габдулла бер нәни малай гына иде.

Беркөнне авылда һич көтмәгәндә Мәмдүдә абыстайның хәле бик начар икән, дигән хәбәр чыкты. Шунда әниләр, күрше карчыклар бергә җыелып, Мәмдүдә абыстайның хәлен белә бардылар. «Барып керсәк,— дип сөйләде кайткач, әни,— Мәмдүдә абыстай урын өстендә бик авыр хәлдә ята. Без керү белән, аның янына утырып, тәһлил әйттек. Шул чак Мәмдүдә абыстай күзен ачты. «Улымны китерегез»,— диде. Габдулла кече якта әбисе янында икән. Әбисе аны җитәкләп әнисе янына китерде. Мәмдүдә абыстай хәлсез куллары белән Габдулланы кочаклагандай итте, үзе елый. «Әй, балам, мин сине үстерә алмадым, бәхил бул инде»,— ди, Габдулланы әкрен генә сөйде. Мескен үзе шуннан озак та тормады, җан бирде»,— дип, әни кайтып безгә елый-елый сөйләде.

## Газизә

*Габдулла Тукайның, ана башка булып, бер атадан туган апасы Газизә Зәбированың улы, ягъни Тукайның туганнан туганы Хөсәен Зәбиров истәлеге.*

«Мин, дип сөйли иде әни, 1877 елда Кушлавычта тудым. Әнием Гафифә үлгәч, әтием Мөхәммәтгариф Мәмдүдә дигән кызга өйләнде. 1886 елда энем Габдулла (булачак шагыйрь Габдулла Тукай) туды. Яңа әни — Мәмдүдә әни мине яхшы тәрбияләде. Мин уйнарга чыккач, башка кызлар үзләренең энеләрен, сеңелләрен, я күтәреп, я нәни арбада тартып урамга алып чыгалар, шул бәбиләр белән мәж киләләр иде. Мин аларга бик кызыга идем. Кулда тотарлык булгач, әни миңа Габдулланы биләп төреп бирә башлады. Мин бик шатланып бәби күтәреп әлеге бала багучылар янына барам. Авылның яшел чирәмле урамына җыелып утырып, без бәби карый идек. Мин Габдулланы бик ярата идем.

Ләкин энем Габдуллага биш ай да тулып җитмәде, безнең әтиебез Мөхәммәтгариф үлеп китте. Шуннан соң әтинең энесе, аннан әнинең Казанда тора торган сеңлесе мине үзләренә асрамага алдылар. Ә энем Габдулланы, әнисе үлгәч, Өчиле авылындагы Зиннәтулла бабасына кайтарганнар.

Шулай итеп мин энем Габдулладан озакка аерылдым, дип сөйли иде әни».

## Кырлайга килү

*Кырлайда туып-үскән бертуган Һаҗирә белән Гарәфетдин Фәйзерахмановларның сөйләгәннәреннән (1910, 1906 елларда туганнар). Беренче истәлек.*

Әниебез — Әхмәтшина Нәфисә Габидулла кызы. Габдулла Тукайның Кырлайдагы тормышы турындагы кайбер истәлекләрдә ул «Нәфисә карчык» дип искә алына.

Үзенең сөйләве буенча, әниебез Нәфисә Өчиле авылында туып үскән. Өйләре Зиннәтулла хәзрәтләр белән күрше булган. Нәфисә Зиннәтулла хәзрәтнең беренче кызы Мәмдүдә белән яшьтәш булып, кечкенәдән бергә уйнап үскәннәр. Туганнар шикелле ике өйне бер итеп бер-берсенә керешеп яшәгәннәр. Тик Мәмдүдәнең әнисе Камилә абыстай үлеп, аның урынына үги әни булып Латифа килгәч кенә, аларга бик кергәләп йөрергә туры килмәгән. Озакламый икесен дә кияүгә биргәннәр.

Мәмдүдәне, елатып, Кушлавыч авылының тол калган мулласы Мөхәммәтгарифка биргәннәр. Ләкин Мөхәммәтгариф кыска гомерле була. Мәмдүдә Габдулла исемле улы белән тол кала. Аны үзенә хатынлыкка Сосна авылыннан Шакир мулла ала. Габдулланы бер карчыкка бер кибән арыш биреп асрамага калдыралар, тик соңыннан гына Соснага алып кайталар. Шакир мулла каты куллы, авыр холыклы кеше була. Мәмдүдә монда озак яши алмый, кәтелмәгәндә үлеп китә. Аның ятим калган улы Габдулланы Өчилегә Зиннәтулла бабасына кайтаралар.

Бу вакытта инде әниебез Нәфисә Кырлай авылына килен булып төшкән була. Кырлайдан туган авылы Өчилегә килгәләгәндә, Зиннәтулла хәзрәтләргә кереп, дусты Мәмдүдәнең ятим калган улы Габдулланың бик авыр хәлдә яшәгәнен күрә, аны бик кызгана. Кырлайга кайткач, әле яңа гына бердәнбер уллары үлгән, таза тормышлы Сәгъди абзыйларга уллыкка бала кирәк булса, Өчиледә бер ятим ир бала барлыгын хәбәр итә. Алар Сәгъди абзый белән бергәләп, Өчилегә Зиннәтулла хәзрәтләргә Габдулланы алырга киләләр. Ләкин Зиннәтулланың икенче кызы — Тукай әнисенең сеңлесе Сажидә истәлегендә: «Габдулланы асрамага алачак кеше аны алырга килгәч, әтием бирен жибәрмәде, берәр атна үзебездә торсын әле, дип әйтте, диелә. Әлеге кеше ике көннән соң килеп Габдулланы алып китә. Зиннәтулла: «Бер дә бирмәс идем, дөньясы шул»,— дип, елап кала». «Совет әдәбияты», 1946, № 4. З. Р.)

Сәгъди абзый белән Габдулланы юл Ия башы авылы аша Кырлайга китергән. Алар уңында да, сулында да ике тегермән торган басу капкасыннан кергәннәр. Басу капкасыннан керүгә, уңнан дүртенче йорт әниңнең килен булып төшкән, нык тормышлы кайнатасы Әхмәтша йорты була. Шул уңайдан тагын ике йорт, бер тыкрык үткәч, Сәгъди абзый өе. Шуннан ерак түгел тәгәрмәчле кое булган. Зур хуҗалыкка килен булып төшкән әни таңнан кичкәчә эштә йөргән. Башка эшләр белән бергә коедан күп итеп су да ташыган. Суга гел шул зур тәгәрмәчле коега чыга икән.

— Чиләкләремне чыңгылдатып суга чыгуымны шул тирәдә уйнапчуалып йөргән Габдулла шунда ук күреп ала иде,— дип сөйли иде әни.— Габдулланың башында матур кәләпүш, өстендә яшел хәтфә белән кырлап теккән җиңсез камзул була иде. Ул шатланып көләкөлә, әле бер аягы белән, әле икенчесе белән тыраклый-тыраклый, минем янымa килә. Аның тыраклап сикерүеннән яшел, кызыл хәтфә корамадан тегелгән кәләпүшенең озын кара чугы баш түбәсендә бик кызык сикерә иде. Габдулла килү белән миңа елыша. Без икебез дә бу күрешүгә бик куана идек.

Сирәк кенә булса да, эштән арынып, әниләр янына кайтырга мөмкинлек булганда, мин Габдулланы да үземнән калдырмыйча Өчилегә алып кайта идем.

Габдулланы Өчиледән Кырлайга китергән беренче көнне дә Сәгъди абзыйларда булдым. Сәгъди абзыйның хатыны Зөһрә апа килү белән Габдуллага ипинең кибән башын кисеп бирде, катык ашатты, сөт эчертте.

Сәгъди абзыйларга Габдулла башта бик кадерле булды. Ләкин шул

елларда аларга кайгы арты кайгы килде: башта кызлары Сабира җен зәхмәтеннән үлде. Аннан аксак кызлары Сажидә үлде. Аннан Сәгъди абзыйны зәхмәт сугып, аягы аксак булып калды. Шул хәлләрдән соң Зөһрә апаның: «Бу малай безгә бәхетсезлек алып килде. Бу бәхетсез малай булды»,— дип, карчыкларга зарланганын сөйли башладылар. Озакламый Габдулланы Кырлайдан алып та киттеләр. Без ул көнне кырда эшли идек, шунлыктан мин Габдулланы озата да алмый калдым.

Тукай турында бу истәлекләр сөйләнеп беткәч, Һаҗирә апа әнисе Нәфисәнең, 85 яшенә кадәр корьән арасына куеп саклаган, аннан Һаҗирә апа үзе 35 ел буена кадерләп саклап, бик еракка җыеп куйган бер газетаны эзләп тапты. Бу — 1914 нче елның апрелендә Казан шәһәрендә басылган «Кояш» газетасы иде. Газетаның бер битендәге игълан Габдулла Тукай үлеменнән соң, аның истәлегенә «Габдулла Тукаев» исемле бик яхшы исле сабын чыгарылуын хәбәр итә. Шунда ук сабынның рәсеме ясалган, өстендә Габдулла Тукайның фоторәсеме төшерелгән.

Тетелеп беткән, саргайган бу газета үзендә Тукай рәсеме булганы өчен гасыр буе шулай кадерләп сакланган. (З. Р.)

## Кырлайда

*Габдулланың Кырлайдагы кордашы Хәлилрахман Гобәйдуллин истәлеге.*

Без малай чакта Сәгъди абзый Өчиле авылыннан Кырлайга асрамага дип бер малай алып кайтты. Малай Габдулла исемле иде. (Ул вакытта аны инде Казаннан Өчилегә китергән булганнар икән.)

Габдулла ябык ак йөзле, йомылыбрак йөри торган бер малай иде. Безнең әтиләр яшь чакта заманында данлыклы булган Кышкар мәдрәсәсендә бергә укыганнар — шәрик булганнар. Без дә Габдулла белән бик тиз дуслашып киттек. Әти дә аны якын итә иде. Ятим бала дип, һәр базар көн алдыннан, күчтәнәч алырсың дип, аңа биш тиен акча бирә иде. Без бөтен көнне бергә үткәрәбез. Уйнап арыгач, безгә янсә безнең каршыда гына торган әтиемнең энесе Хәбибрахман абыйларга кереп, чәй эчеп чыккалыйбыз. Кышларын икәүләп башта әнидә, аннан әтидә Габдулла белән бергә сабак укыдык.

Габдулла башта бик тын малай күренсә дә, ара-тирә шаярып та ала, хәтта кайчакларда һич уйламаганнарны да эшләп ташлый иде.

Беркөнне шулай әти миңа Арча базарыннан уенчык скрипка алып кайтып бирде. Минем шатлыгым әчемә сыймый, скрипкамны күтәреп урамга чаптым, Габдулла алдына барып бастым да, аллы-гөлле тавышлар чыгартып, скрипкамны бөтен көчкә сызарга тотындым. Габдулла шаккатты! Иреннәрен кысып, күзләрен зур итеп ачып озак карап торды. Аннан, ни арада өлгерде бу, кискен хәрәкәт белән скрипканы минем кулдан йолкып алды да җан-фәрманга чабып качты да китте. Бу көтелмәгән хәлдән инде мин катып калдым. Аңыма килгәч, көчкә куып җиттем үзен. Скрипканы чытырдатып кочаклап тоткан да бирми генә бит. Һич аерыласы килмәде шул скрипкадан.

(Хәлилрахман Гобәйдуллин абзыйның Тукай турындагы башка истәлекләре «Тукай турында замандашлары», «Тукай турында хатирәләр» дигән китапларда басылды.)

## Туй

*Тукай энисенең сеңелесе Бибисаҗидә кызы Хәбибуллина Әкълимә Сафовна истәлеге.*

Минем әни Бибисажидә Габдулла абыйны сабый чактан ук бик ярата. Ачлык елны зур гаиләдә үзенә тигән икмәк сыныгын да нәни Габдулла белән бүлешә торган була.

Габдулла абый да әнине — үзенең Сажидә апасын яратып, аның турында китапларында язып калдыра, аны «Йомшак күңелле ак фәрештә» дип атый.

Әни Габдулла абый турында безгә дә сөйли иде. Әнигә унжиде яшь тулгач, аны Көтернәс авылыннан Әхмәтсафа дигән егеткә (әтигә) кияүгә бирәләр. Туй Өчиледә була. Туйга Кырлайдан нәни Габдулланы да алып киләләр.

Безнең якларда туй көнне кәләш янына керәсе кияүгә яшь-җилкенчәк, бала-чагалар ишек төбендә җырлап туктаталар. Гадәт буенча, кияү ишек бавын тотучыларга акча өләшергә тиеш була.

Әнинең туенда да җырлый-җырлый ишек бавы тоталар. Шунда Габдулла абыйга да бауны тоттыралар. Ул зур шагыйрь булгач, «Ишек бавы» дигән шигырендә шуларны яза.

Туй үткәннең икенче көнендә Габдулла абый, бездәге гадәт буенча, апасы һәм кияү җизнәсе янына күрешергә кертелә. Кияү (безнең әти) аның бик нык ябык нәни малай икәнен күреп: «Габдулла, өй ишегең ачу бик авыр бит. Аны бөтен малай җыйналып, күбәүләп ачкансыздыр инде, ә?!» — дип, көлеп сорый. Габдулла оялып дәшми утыра. Аннан: «Юк ла, җизни-абый, без бер малай белән икәү генә ачтык»,— дип җавап бирә. Апасы белән җизнәсе аны иркәләп, үзләре белән чәй эчәргә утырталар.

Габдулла абый Уральск каласына китеп укыганда Өчилегә әниемә 1903 ел 30 июньдә язган хатында: «Бервакыт Кырлайдан Өчилегә җыенга килгән вакытымда, бабайларда җизнәмнең яңа кияү вакыты иде. Исегездәме, мин икегезнең хәлвәт бүлмәсенә (кияү белән кыз ялгыз кала торган бүлмәгә. З. Р.) кереп чәй эчтем... Мөшфика (шәфкатьле. З. Р.) апаем! Синең сабый вакытымда һәм хәзер дә иткән изгелекләреңне кабердә ятсам да онытмам»,— дип яза.

## Язарга яратучы малай

*Кырлай авылы һаҗирә һәм Гарәфетдин Файзерахмановларның икенче истәлеге.*

Әниебезнең каен энесе Әхмәтшин Таиб абзый сөйли иде: «Без Габдулла белән кордашлар. Кырлайда Фәтхерахман хәзрәттә бергә сабак укыдык, урамда да бергә уйный идек. Уйнап арыгач, безнең өйгә кайтабыз. Беркөнне шулай кайтып керсәк, безнең Нәфисә җиңги зур җилпуч тотырып он иләп куйган. Габдулла моны күргәч, шуның янына ашыгып барды да, җилпучның ап-ак булып тигез он сибелгән кырыйларына бармагы белән күп итеп язу язып чыкты, онлы җилпучны матур итеп язу белән сырлады».

## Бәет чыгару

*Мәҗитова Разия Зиннәтовнаның беренче истәлеге.*

Әнием ягыннан туганыбыз Өмбе Сәлимҗан (Хөснетдин улы) абзыйның сөйләгәннәреннән:

«Безнең як авылларда берәр зуррак вакыйга яки ятрак хәл була калса, яшьләр шунда ук бәет чыгаралар. Ул бәетнең кайберләре моңлы, кызганыч булса, күбесе көлке була иде. Берәрсенең ярамаган эшеннән көлеп, бик зәһәр тел белән әйтелгәннәре дә була иде.

Кырлайда бер олы гына кеше ярамаган эш эшләгән. Моны сизеп алып, олы яшьтәге малайлар теге кешегә карата бәет чыгармакчы булалар. Ләкин бу эш берсенең дә кулыннан килми. Шуннан алар, әйдә, Габдуллага әйтәбез, ул җыруга бик оста; дип аңа кушалар. Габдулла шунда ук бәет чыгара. Малайлар — егет кисәкләре кич кырын урам буйлап бу бәетне әйтеп тә йөриләр.

Икенче көнне, теге кеше таң белән Сәгъди абзыйларга килгән: «Сәгъдиулла, улыңны тый! Минем турыда такмак чыгарып йөрмәсен! Кара аны, әгәр тагын бер ишетсәм, Габдулланы бәреп үтерәчәкмен!» дигән».

# УРАЛЬСКИДА

## Килү

*Тукайның туганнан туганы Сатыйга Нуриева истәлекләре. Улы Җәүдәт Нуриев тарафыннан язып алынган.*

Минем әнием Сатыйга Нуриева — Габдулла (Тукай) абыйның туганнан туган абыйсының кызы. Мин бу истәлекләрне әнием сөйләгәннәрдән язып алдым.

Әниемнең әбисе Фаизә — Габдулла Тукай әтисенең бертуган апасы.

Фаизә әби ире Җәләлетдин мулла белән элеккеге Казан губернасы, Казан өязе, Кармыш волосте, Югары Масра авылында яши. Бу авыл кечкенә һәм бик ярлы булып, халкы, көз көне барлы-юклы игеннәрен җыйгач, кыш уздырырга читкә, башкорт, Пермь якларына чыгып китә торган булган: кайсы итек баскан, кайсы тегү теккән, кайберләре кырык тартмачы булып сату иткән.

Җәләл мулла шул ярлы халыктан килгән сәдака белән генә яшәгән. Үзләре ике бала белән дүрт җан булып, алар янына тол калган ике сеңелләре икешәр бала белән кайтып, Фаизә әбинең гаиләсе ун кешегә җиткән. Ачлык еллар аларның тормышын тагын да авырайткан. Шул чорны бөтенләй ятим калган Габдулла (Тукай) абыйны Фаизә әби үзләренә ала алмагач, Уральскида бай сәүдәгәргә кияүгә чыккан туган сеңелесе Газизә Госмановага хат яза. Габдулла абыйның ятим калуын, чит кешеләр кулында булуын әйтеп, аны балалыкка алуларын үтенә. Газизә Госманова апаларның шул чорда уллары үлгән була. Үлгән улыбыз урынына ул булыр, үлгәч, үзебезгә догачыбыз булыр, дип, Галиәсгар җизни белән Газизә апа Габдулла абыйны Кырлайдан Уральскига алдыралар.

Фаизә әби белән Җәләл мулла уллары Габдрахманны алып (Габдрахман — минем әнинең әтисе), 1901 елда Уральск шәһәренә Газизә Госманова апаларга кунакка баралар. Бу вакытта инде унбиш яше тулган Габдулла абый Газизә Госманова апаларда яшәгән һәм мәдрәсәдә укый торган булган.

Казаннан килгән кунаклар хөрмәтенә Галиәсгар җизни зур мәҗлес җыя.

Аларның икешәр катлы ике өйләре була. Мәҗлестә утырганда, Габдулла (Тукай) абый күздән югала. Эзлиләр — таба алмыйлар.

Кычкырып чакырганга да җавап булмый. Шуннан соң эзләргә мин чыгып киттем, ди Фаизә әби. Ишегалдына, урамга чыктым — күренмәде, ди. Керешли аскы өйне карадым. Мич арасына күзем төшсә, анда Габдулла идәнгә тезләнеп утырган, алдына тәрәксез урындык куйган да, зур корсаклы байлардан көлеп, ниндидер шигырь яза иде, ди.



## Мәдрәсә шәкерте

*Тукайның апасы Газизә Зәбированың килене Зәбирова Сания Гиззәтовна истәлеге.*

Минем кайнанам Газизә Зәбирова энесе Габдулла Тукай белән Уральск шәһәрендә үзләренең туталарында (Газизә Госманова белән Галиәсгар Госмановларда) кабат очрашалар. Апа-җизниләре аларны тәрбиягә алалар. Габдулла укырга бик яраткан, шуңа күрә аны укыган кеше итәргә уйлыйлар, «Мотыйгия» мәдрәсәсенә бирәләр. Минем кайнанам буласы Газизәне Габдрахман дигән кешегә кияүгә бирәләр.

Галиәсгар җизнәләре үлгәч, Габдулла да мәдрәсәгә торып укырга күчә. Шул ук вакытта Әхмәтша учитель мәктәбендә русча да укый. Ә ял, бәйрәм көннәрендә, җизнәсе өйдә юк чакларда көнен кайнанамнарда — Газизә апасында үткәрә.

Кайнанам әле олыгаеп беткәч тә, безгә Габдулла Тукай турында, аның гадәтләре турында бик күңелле итеп сагынып сөйли иде.

«Бервакыт Габдулла безгә килгән көн иде. Мин нидер эшләргә җыенып йөри идем. Кашык-аяк юарга булса кирәк, ахрысы. Габдулла ашъякка кереп китте. Ә мин яңа гына бик кадерләп төреп куйган намазлыгымны югалттым. Эзлим-эзлим — табалмыйм. Карасам, ашъяктан чыгып килүче Габдулланы күреп шаккаттым. Ул минем әлеге кадерле намазлыгымны бау белән бик әйбәтләп биленә бәйләп куйган да, җиң сызганып, савыт-саба юып йөри. «Габдулла, нишләп намазлык бәйләдең?» — дип соравыма: «Һи, апай, без мәдрәсәдә аш-су пешерсәк тә, кашык-аяк юсак та, корымлы чуен тотасы булсак та намазлык бәйлибез, намазлык тотабыз. Намазлыкны без гел алъяпкыч итеп йөртәбез. Әй, апай, алъяпкыч итәргә иң җайлы нәрсә шул намазлык инде ул!» — дип, безне көлдерде.

Кайчакта бергәләп нинди дә булса бер эшне тын гына эшләп утырганда, Габдулла кинәт сикереп тора да, өтәләнеп, өстәл янына китә. «Габдулла, ни булды сиңа?» — диюгә, «Илһамым килде! Илһамым!» — дип, ашыгып язарга тотына иде»,— дип сөйли иде кайнанам.

## Җаен тапты

*Уральскида туып-үскән Ибәтуллина Гарифә Сәйфетдиновна истәлеге.*

Минем әни ягыннан бабайлар үзләре Чистайдан. Алар электән үк Уральскига күчеп килгәннәр. Әти кешеләргә ат сбруйлары ясаган, әни өйдә биш бала үстергән. Мине укыту өчен әни Мотыйгулла хәзрәтләргә өй эшен караучы булып кергән.

Безнең торган йортыбыз Мотыйгулла хәзрәт мәчетенә каршы якта, почмакта, трактир күршесендә иде. Мәдрәсәләр дә безнең янда. Агач мәдрәсә мәчет күршесендә, ә таш мәдрәсә безгә каршы урамда.

Әниемнең туган энесе, хәзер Мәскәүдә яшәүче Зәки Вәлиев абый һәм бертуган абыем Шәрифҗан Акъегетев тә Габдулла белән әнә шул таш мәдрәсәдә дә, Әхмәтша учительдә дә бергә укыдылар. Алар

гел бергә йөриләр. Габдулла безгә килә, кайчак бездә кунып та кала иде.

Бер көнне иртән торып ишегалдына чыккан идем, өйдән Габдулла килеп чыкты. Ул алай зур гәүдәле түгел, өстендә җилән, аягында читек иде булса кирәк. Кулына китаплар тоткан, үзе бик ашыгып капкага юнәлде. Сабагыма соңга калмагаем диде, ахры, ашыгып капканы ачмакчы булды. Ә ул заманнарда төнгә капканы бикләп ята идек бит, капка ачылмады. Габдулла капканы тарткалап карады да, ул ачылмагач, капка астына иелде. Безнең капка җирдән шактый биек итеп ясалган, аста ачык урыны бар иде. Габдулла шуны карады да, шуышып капка астыннан чыгып та китте.

Бездән ерак түгел Габдулланың туганнары — Зәбировлар яши иде. Ирен — тирече Габдрахман дип, хатынын — Газизә, дип йөртәләр иде. Шуларның Вәли исемле малайлары бар иде. Ул җырларга ярата, тавышы да матур иде. Аның бер җыры әле дә истә калган:

Байлар-байлар бал эчә,
Урта байлар сыра эчә;
Безнең кебек ярлы мескен,
Ярга ятып су эчә.

Абыйлар үзара «Яшьләр түгәрәге», «Яшьләр түгәрәге» дип бик сөйлиләр иде. Ләкин мин әле ул вакытта нәни кыз гына булганга, аның нәрсә икәнен белмәдем.

Озак та тормадык, без Уральскидан күчеп киттек. Льбищиннән ерак түгел Мерген дигән җирдә яшәдек. Габдулла Тукай белән бергә укыган Шәрифҗан абыем шул Мергендә мөгаллим булып балалар укытты.

## Уральскиның Бозаулык урамында

*Джамбул шәһәреннән бертуганнар Даутова Тамилла һәм Еникеева Сания Вахриевналар истәлеге.*

Тукай турында без бала чактан ук үзебезнең бабабыз Мусин Йосыфҗан сөйләгәннәрдән, әбиебез һәм әниебез истәлекләреннән беләбез.

Габдулла ябык кына кечерәк гәүдәле, фәкыйрь киенгән, үзе телгә оста, кешегә ихтирамлы булган. Гаделсезлекне дошман күргән.

Уральски шәһәрендә бик авыр яшәгән чорында аны Йосыфҗан бабайга алып килгәннәр. Бабай аны үз канаты астына алган. Бабай үзе тегүче булып, тирә-юньдәге кешеләргә кием-салым теккән.

Габдулла безгә еш килгән. Килгәч тә башкалар шикелле өй янына килеп, өй эчен карап тәрәзә какмаган. Алай эшләүне тәрбиясезлек дип санаган. Ул үзе ишегалдындагы өйалды тәрәзәсенә килә торган булган. Аның килүен күрү белән бабай әбигә: «Син Габдуллага тизрәк ашарга хәзерлә, ашат»,— дип, әйтә торган булган. Һәм киткәндә, Габдулланы шатландырып, биш тиен акча да бирә икән. Бабай аңа күлмәк-чалбар теккән, әби өс-башын юган.

Йортсыз бер ятим булганга, урам малайлары аны какканнар, аңа төрле мыскыллы кушаматлар такканнар. Бабайның квартирасы тыгыз булса да, Габдуллага да төн кунар урын тапканнар.

Бабай Габдулланы пекарняга эшкә урнаштырырга уйлый.

— Шунда эшкә кер, улым, ичмасам, тук булырсың, ди.

— Абзый, мин бернәрсә дә эшли белмим бит,— ди икән Габдулла.

— Белмәсәң, өйрәтерләр,— дигән бабай.

Пекарня хуҗасы аны эшкә алырга теләмәгән:

— Бигрәк сыек инде, үзе ышанычсыз, урлашыр,— ди икән.

Бабай аның бик гадел, намуслы икәнен сөйләгән. Икмәк пешерүче Габдулланы эшкә алган.

Эштән соң Габдулла бабайларда икмәкне бик тәмләп ашый икән. Аннан: «Син пекарняда туеп чыкмыйсыңмыни?» — дип сорагач: «Без икмәк пешерәсе камырны, чалбар балакларын сызганып, аякларыбыз белән изеп басабыз. Ул камырдан пешергән ипине ашарга мин җирәнәм. Ә менә сездә ипи бик тәмле»,— дип ашый икән.

Бабайда өйрәнчек булып эшләүче малайлар Габдулладан төрлечә көлә торган булганнар. Сиңа кием тегү өчен үлчәү алабыз, дип аны йөзтүбән яткырып, аркасыннан тимер аршын белән авырттырып сыза торган булганнар. Ул чорда ук Габдулланың шигырь дәфтәре булган. Ул аны һичкемгә бирмәгән. Ләкин яшьләр аның дәфтәрен яшереп кенә алып, аннан шигырьләр күчереп, шуны ятлап, күңелдән сөйләп йөргәннәр.

Ул чакта малайларны мәчеткә кертмәгәннәр. Ә Габдулланың мәчеткә кереп манарадан шәһәрне карыйсы килә икән. Көннәрдән бер көнне бабай аны үзе белән мәчеткә алып кереп манарага мендергән. Манарада Габдулланы күргән урам малайлары: «Карагыз, Габдулла манарага менгән!» — дип кычкыра башлагач, Габдулланың шатлыгы эченә сыймаган.

Габдулла: «Казаннан ниндидер журнал яздырам»,— дип акча җыярга тырышкан. Ләкин һич мөмкинлеге булмаган. Шуннан: «Ул журнал бик күңелле, анда төрле әкиятләр, төрле хәбәрләр басыла»,— дип бабай белән әбине шул журналга язылырга димләгән. Бабай язылган. Ул журналның һәрбер санын Габдулла түземсезлек белән көтеп алып, төннәр буе укыган. Ул журнал, әллә инде рөхсәт ителмәгән журнал булган, шуны алдыра башлау белән бабайны мәчеткә кертми башлаганнар.

Безнең әниебез ул чакта, Тукайның үзе кебек, бер яшь кыз булып, Тукайга ул бик ошый торган булган. Ләкин ул заманнардагы каты законнар егет-кызларга күрешү-сөйләшү гадәтләрен тыйган.

Пекарняда эшләгәндә Йосыфҗан бабай Габдуллага утырырга бер урындык рәтләгән. Габдулла шунда утырып эшләгән дә, шигырьләрен дә шунда утырып яза торган булган.

Инде Уральскидан киткәндә, ул урындыкны Габдулла бабайга бүләк итеп биргән. Ул урындык Тукай истәлеге буларак, кадерле реликвия булып гаиләбездә шушы көнгәчә саклангды.

Уральск музеенда Тукайга багышланган почмак ачылгач, без ул урындыкны үзебездә булган Тукай фоторәсемнәре белән шул музейга тапшырдык.

Габдулла эшләп йөргән пекарня инде күптән янган. Ә Йосыфҗан бабай йорты — Габдулла безнең гаиләгә килеп йөргән йорт әле дә исән. Ул элек Бозаулык урамы дип, хәзер исә Хамид Чурин урамы дип йөртелә. Шул урамдагы 60 нчы йорт безнең йорт була.

*Дәвамы бар*

**Гариф Галиев**

# КАРЛЫГАЧЛАР ОЯ КОРА

хикәя

Дөнья куласа — әйләнә дә бер баса, дигәндәй, Сабира апаның тигез һәм тыныч тормышы бер ел эчендә кинәт бөтенләй үзгәрде. Иң элек чыпчыклар егылып төшәрлек бик каты салкын бер кышны көтмәгәндә суык тиеп ире дөнья куйды. Шул ук кышны билгесез бер йөк машинасы сугымга дип асрала торган үгез бозауларын таптап узды. Бу кайгы-хәсрәтләр, бу казалар Сабира апаны да һәм аның бердәнбер улы Шәрифне дә аптыраашта калдырды. Ләкин бер кирегә китсә китә икән, алдагы көннәрдә аларны тагын бер борчулы вакыйга көтә иде.

Сарайлы авылының кырыеннан үтә торган Ык елгасы шул язны башка елларда булмаганча, аеруча көчле ашкыну белән кешеләргә үзен танытып үтәргә булды. Үзенең нинди көчкә ия икәнлеген күрсәтергә тели иде кебек ул. Һәм менә бер язгы төндә Ык елгасында боз кузгалды. Бу калын-калын бозлар берсе өстенә берсе менеп, актарыла-актарыла ага башладылар. Ә инде икенче төнне исә Сарайлылар йоклаган вакытта Ык җәелгәннән җәелеп, Сарайлы авылының читенә үк килеп житте һәм тора-бара авылның урамнарын су басты.

Сарайлылар иртән торуга бу хәлне күреп гаҗәпләнеп калдылар. Моңа кадәр алар ташкын вакытында балык тотып калу өчен Ык елгасына көймәләр белән кереп, чайкала-чайкала йөргән булсалар, бүген Ык елгасы чабак, осетр, табан балыклары белән Сарайлыга үзе килгән иде. Һәм ул сарайлыларга гүяки: «Сез ел саен җәй буе һәр төрле шартлаткычлар шартлатып, әллә нинди агулы матдәләр җибәреп минем балыкларымны һушларыннан яздырасыз, хәлсезләндерәсез, минем көмеш кебек суларымны болгатасыз, мине мәсхәрә итәсез. Менә мин сезгә балыкларым белән үзем килдем. Туйганчы алып калыгыз минем балыкларымны. Мин монда, сезнең урамнарыгызда, озак тормам, сезнең белән исәнләшеп, үз юлыма кабат төшәрмен һәм үзем теләгәнчә агармын, дигән кебек, дулкыннарын кага-кага сөйләгәндәй булды.

Сарайлылар Ык елгасының уйламаганда, кинәт авылга килеп керүенә баштарак гаҗәпләнеп карасалар да, урамнарда йөзеп йөргән балыкларны күргәч, бу форсаттан файдаланып калырга булдылар. Кызыл канатлы чабак, шома гәүдәле осетр, озын борынлы чуртан балыклары белән ятьмәләр һәм чиләкләр тулды. Өйләрдә, мич алларында хатын-кызлар кулында көмеш тәңкәле балыклар ялтырады, чуен табалар шалтырады, урамнар кулларына тере балыклар тоткан ялан аяклы бала-чагалар белән тулды.

Ык шулай авыл башына килеп житеп, көчле дулкыннары белән чайкала-чайкала ике тәүлек чамасы торды да, күзгә төртсәң күренмәслек бер караңгы төндә Сарайлыны калдырырга, ягъни үз юлына төшәргә булды. Мәгәр Сарайлы кешеләренең кайчакларда балык тоту нияте белән уйламыйча-нитмичә шартлаткычлар белән агым суны болгатканнары яисә башка шундый җансызлыклар, тупаслыклар эшләве өчен гүяки үч алырга, аларга үзенең көчен күрсәтергә карар бирде, һәм чигенгән чагында, юл уңаендагы ихаталарның капкаларын-коймаларын аударып, мунчаларын сүтеп, аларның бүрәнәләрен үзе белән агызып алып китте.

Сарайлылар иртән йокыдан торып чыгу белән гаҗәпләнеп калдылар: авыл урамнарын баскан су кире үз юлына киткән, анда-санда такталар, бүрәнәләр һәм чүп-чарлар өелеп калган. Кыскасы, бернәрсә дә диярлек үз урынында түгел, бөтенесе көчле афәт үткәнлекне күрсәтеп торалар иде.

Сабира апаларның күршесе — бик сабыр холыклы, ап-ак сакаллы, озын гына гәүдәле Гыйниятулла карт иртүк торып урамга чыгу белән аның янына тирә-яктан кешеләр килеп басты. Барысы да Ыкның болай бәла-каза белән килүеннән зарландылар. Берәүләр бу күренешләрне безгә язмыш күрсәткәндер, дип юандылар һәм бу хәлнең кабатланмавын теләделәр. Икенчеләр, афәтнең булуын ел килешенә бәйләделәр, соңгы елларда табигатьнең үзгәрүеннән бик сәер хәлләр булуны сәбәп итеп аңлаттылар.

Гыйниятулла карт исә бөтенләй башка фикердә иде. Ул янында басып торган авылдашларына карап, озын һәм бик ябык бармаклары белән ап-ак сакалын ике якка аера-аера болай диде:

— Ык елгасының ярларын ишелүдән саклап торган зифа буйлы талларны кисеп бетердегез. Юан ботаклы, куе яфраклы шаулап утырган тирәкләрне, тамырларын тирәнгә җибәргән карамаларны аудардыгыз. Һәрберсе бер чиләк җимеш бирә торган шомырт агачларын бутап, кәүсәләрен шәрә калдырдыгыз. Монда юл салабыз дигән сылтау белән кып-кызыл балан агачларын, гөлҗимеш, карлыган куакларын тамырлары белән кубарып ыргыттыгыз. Ык елгасы үзенең менә шушы байлыкларын, шушы матурлыкларын вәхшиләрчә бетергән өчен, сездән, бездән, бөтенебездән үч алып, бөтенебезгә каһәр укып, үз юлына китте. Белмәссез, ул яңадан безнең Сарайлыга килмәс тә бәлки, җир астыннан үзенә юл алыр, ягъни җирнең өстеннән түгел, астыннан агар.

Картның барлык кешеләрне уйга калдырган бу сүзләренә берәү дә каршы килмәде. Бөтенесе дә картның фикерен куәтләделәр.

Сабира апаларның моннан берничә генә ел элек салган яңа мунчаларын да шушы ташкын бөтенләй җимереп, бүрәнәләрен берничек тә җыеп алмаслык итеп, кайсын кая таратып, түбәнгә таба агызып алып китте. Бу артык зур каза булмаса да, хәсрәт өстенә килгән хәсрәт иде.

Инде күп еллар колхозда эшләп, моннан ун еллар элек пенсиягә чыккан Сабира апаның гадәттәге тереклек итү дәрте бу вакыйгалардан соң ничектер сүрелә башлады. Һәм ул еш кына ялгыз калып уйланып утыра торган булды. Әлбәттә, тормышны алып бару өчен йортта армиядән кайткач колхоз фермасында нәселле бозаулар карарга керешкән Шәрәфи бар иде һәм Шәрәфи колхозда иң җигелеп эшләүче яшьләрнең берсе иде. Ул бу эшне ташлап беркая да китмәячәк, гомер буе шушында авылда калачак, Сабира апа аның шулай булачагына көн кебек ышана иде. Аны аптыраткан мәсьәлә — Шәрәфине кыш кергәнче башлы-күзле итү, ягъни өйләндерү иде. Мәгәр бу мәсьәлә ике яклы иде. Ярый ла, йортка килен булып төшәчәк кыз эшчән һәм яхшы холыклы булса, ә бит юк-бар сүзгә дә дөрләп кабынып китә торган, кайнананы пәри урынына күрә торган мәкерле киленнәр дә очрый. Андыйлар гадәттә эшне дә яратмыйлар, йортка күңел дә салмыйлар.

һәм алар ир белән тора да алмыйлар. Мондыйлар безнең үзебезнең тирә-күршеләребездә дә бар. Андыйлар бер-ике ай да тормыйлар, иреннән аерылып китәләр. Мондый кыска тәртәле кешеләр егетләр арасында да юк түгел. Ләкин безнең Шәрәфи холык-фигыле белән әнисенә тарткан. Ул бер өйләнсә, шаять, хатын аеру белән шөгыльләнмәс, шул хатын белән тора бирер. Тик менә егерме бишкә житеп бара, ә өйләнү турында сүз кузгатканы юк. Кызлар белән дә бигүк аралашмый шикелле. Бәлки аның яратканы башка авылдадыр. Алай да булуы мөмкин. Кайчакларда бер уңай вакыт табып, юк йомышны бар итеп, Наратлы авылына барып кайткалый үзе. Әле шушы арада гына ферма малларына ашарга салу өчен өч япьле агач сәнәкләр кирәк иде, үзебездә юк, бәлки Наратлыда бардыр, алар урман эчендә утыралар бит, дигән сылтау белән тиз генә Наратлыга барып кайтты бит. Бәлки яраткан кызы шундадыр...

Менә шушы «бәлки» сүзе тәки дөрес булып чыкты лабаса. Беркөнне Шәрәфи әнисе белән иртәнге чәйне эчеп утырганда сүз арасында гына:

— Әни, мин бүген кичкырын Наратлыга барып киләм, соңга калсам, борчылма,— дип куйды.

Сабира апа бик саклык белән генә:

— Наратлыда Армиядә бергә хезмәт иткән дустым бар дип сөйли идең, шуны күреп кайтырга барасыңдыр инде? — диде.

— Әйе, дустым да бар...

Ул ничектер тотлыгып калгандай булды. Әнисе аны бу кыен хәлдән чыгарды:

— Я, әйтеп бетер инде, әйтеп бетермәдең исә,— диде.

— Әни, әйтсәм әйтим инде, минем яраткан кызым бар Наратлыда,— дип җавап бирде Шәрәфи.

— Бик әйбәт! — диде әнисе.— Һаман өйләнмичә тормассың инде. Әгәр син аны яратсаң, ул сине яратса һәм тормыш итәрлек ышанычлы булса, кушылыгыз да куегыз. Мин дә көннән-көн артка таба барам. Төкле аягы белән килсен.

Ишегалдында Шәрәфинең эшкә йөри торган җигүле аты тора иде. Ул аты янына чыкты. Арбага утырыр алдыннан, әнисенең ризалыгын алгач, тагы берничә авыз сүз әйтте:

— Әни, алай син дә минем фикердә булгач, мин Хәмдия белән нык-лап сөйләшеп кайтам. Шушы көннәрдә председатель Сафиулла абзый яучы булып барыр,— диде.

Бу сүзләрне ишеткәч, Сабира апайның йөзе тагын да яктырып китте:

— Бәрәкалла, бәрәкалла, председатель Сафиулла үзе барамыни?— дип, гаҗәпләнеп Шәрәфигә карады.

— Әйе, үзе әйтте, яучы булып мин үзем барам, диде.

Менә Шәрәфи, капканы ачып, җигүле атны урам якка чыгарды, аннары капканы япты да арбага утырып дилбегәне какты:

— Әйдә, Канаткаем, Наратлыга!

Канаткай, шул сүзне генә көткән кебек, авыл уртасыннан үткән асфальт юлга төште дә, дага тавышларын чыгара-чыгара, юыртып китте.

Ә инде авылны чыгып, ике-өч километр узгач, Шәрәфинең әмерен дә көтмәде, асфальт юлдан Наратлыга кереп киткән арба юлына ат үзе борылды. Ул Шәрәфинең Наратлыга баруын гүяки аңлый һәм гүяки аның белән бергә үзе дә ашыга кебек иде.

Күп булса бер сәгать чамасы вакыт үтүгә алар Наратлыда иде инде.

Хәмдия белән Шәрәфи арасында моннан ике-өч ел элек Наратлы сабан туенда башланган мәхәббәт көчәйгәннән-көчәеп, аларны инде

бер-берсен күрмичә яши алмаслык дәрәҗәгә житкергән иде. Шунлыктан булса кирәк, Шәрәфи атын тугарып та тормады, туп-туры колхоз ашханәсенә юнәлде. Чөнки Хәмдия шушы ашханәдә повар булып эшли иде. Алар бер-берсе белән бик тиз аңлаштылар. Шәрәфи гореф-гадәт буенча шушы көннәрдә яучы жибәрәчәген һәм Хәмдиянең әти-әниләрен шуңа хәзерләвен үтенде.

Хәмдия, әлбәттә, риза булды. Ләкин ул яучыга кемне жибәрәчәге белән кызыксынмыйча кала алмады. Чөнки ул әтисенең беркадәр җинелрәк холыклы икәнен белә иде:

— Яучы булып кем килә? — диде.

— Кем булсын, Сафиулла абзый,— диде Шәрәфи.

— Кайсы Сафиулла? Сездә бит берничә Сафиулла бар.

— Колхоз председателе Сафиулла! — дип җавап бирде Шәрәфи үзенә бер төрле горурлык белән.— Безнең председателебез ул башлык булып кына утырмый, яучы булып та йөри, ул инде армиядән кайткан өч-дүрт егетне үзе яучылап өйләндерде. Алай гына да түгел, яңа өйләнешкән гаиләләрне яңа өйләргә дә урнаштырды. Сыер-сарыклар белән дә тәэмин итте. Хәтта яңа гаиләләрнең һәрберсенә икешәр умарта да бирде.

Бу җавапны ишеткәннән соң Хәмдия үзен җиргә бик нык баскан кебек хис итте:

— Алай булса, бик әйбәт, безнең әти андый кешеләр белән бик тиз килешер,— дип куйды.

Шәрәфинең сүзе бетмәгән иде әле:

— Сафиулла абзый синең үзең белән дә кызыксына ул.

— Ничек?

— Безнең колхоз повары пенсиягә чыкты бит. Безгә повар кирәк. Сафиулла абзый миңа, син фермада маллар карарсың, кәләшең ашханәдә повар булып эшләр. Кулинарлык курсларын бетергән кыз бит синең Хәмдияң, дип әйтте,— диде.

Шәрәфи Наратлыда озак тормады, Хәмдия белән сөйләшкәннән соң Сарайлыга кайтып китте. Бердән, ферма малларына төннәлеккә азык таратасы бар, икенчедән, Сафиулла абзыйсы аңар озакламаска, Наратлыдан кайту белән үзенә килергә кушкан иде. Шунлыктан Шәрәфи Сарайлыга кайтып фермадагы эшләрен тәмам итү белән Сафиулла абзыйсына китте һәм аңа кызның ризалык биргәнлеген белдерде.

— Болай булгач, бик яхшы. Ярый, сөйләшкәнчә, берсекөнгә мин яучы булып барырмын. Мәгәр әниең белән дә миңа киңәш-табыш итү кирәк. Юкса, аның малайны миннән башка өйләндерделәр, дип, кимсенүе мөмкин. Ул бит сиңа ана. Ә анага хөрмәт белән карарга кирәк,— диде Сафиулла.

Аннары инде Шәрәфигә фермадагы терлек азыкларын саклап тоту, аларны мөмкин кадәр эшкәртеп ашату турында күрсәтмәләр бирде. Артык шау-шулы мәҗлесләр белән мавыкмаска кушты һәм иң соңыннан болай диде:

— Йорт-җирегез бик әйбәт, шушы төп йортта тора бирегез. Абзар-кураларыгыз да төзек. Ә инде ташу агызып алып киткән мунча урынына сезгә яңа мунча салып бирербез. Идарәнең карары шулай. Наратлы урманында безнең колхозның кисә башлаган диләнкәсе бар бит. Анда сезнең өчен мунча буратып куйдык. Туйга чаклы шул бураны алып кайтып мунча салырсыз.

Председательнең бу сүзләре Шәрәфине канатландырып җибәрде. Юаш кына табигатле бу егет, эчке бер дулкынлану белән:

— Сафиулла абзый, син безнең әти урынына калган кеше икәнсең... Күңелем белән күкрәгемә ипи куеп ант итәм, мин колхозыбызның бу ярдәмен онытмам, аны кайтарырмын. Күп тә үтмәс, фермада

мин үстергән бозауларны күреп шаккатарсыз. Рәхмәт сиңа, Сафиулла абзый! — диде һәм чыгып китте.

Бу шатлыклы хәбәрне әнисенә әйтү өчен ашыга иде ул. Аның аягы җиргә әллә тиде, әллә тимәде, ул үзен гүяки очкан кебек хис итә иде.

Икенче көнне кичкырын гына аларга председатель Сафиулла килде. Бөек Ватан сугышыннан берничә яра белән кайткан, шуңа карамастан, бик тере хәрәкәтле, тәмле телле, бик абруйлы бу житәкче кешене бөтен авыл халкы үз итә, аңа ышаныч белән карый иде. Шуңа күрәдер инде ул колхозның беркайчан да алышынмый торган председателе иде. Ул бусаганы атлау белән үк, газ плитәсе янында савыт-саба белән кайнашучы Сабираны күрсә дә, гадәтенчә бик йомшак һәм шаян тавыш белән:

— Өйдә кеше бармы? — дип дәшкән булды.

— Бар, бар, Сафиулла туган, син икәнсең, әйдә, түргә уз, түргә, исән-сау гына йөрисеңме? — дип, плитә яныннан кузгалды Сабира апа.

Сафиулла һәркем белән әйбәтләп сөйләшә һәм һәркемне сүзгә тарта белә иде. Ул:

— Аллага шөкер, Сабира, әле хәзергә бер дә зарланырлык, аһвалһ итәрлек түгел. Үзеңнең хәлләрең ничек соң? — диде, йомшак кына тавыш белән.

— Шулай бер килеш инде, Сафиулла.

— Әкренләп картая да барасыңдыр инде, Сабира. Олыгайган саен аяк-куллар да тыңламый башлый. Әле мин урамнан сезнең турыдан үтеп барганда синең плитә янында нәрсәдер эшләп маташканыңны күреп кердем. Син гел эшлисең дә эшлисең, арый торгансыңдыр?

— Армыйммы соң, Сафиулла. Әле генә үзең әйттең ич, олыгая башлагач, аяк-куллар тыңламый, дип. Мин дә шулай инде, мәгәр өй эшен мин эшләмәсәм, кем эшләсен, шулай бит?

— Шулаен шулай инде, элек-электән үк: «Өй эше тавык чүпләсә дә бетми ул»,— дигәннәр бит.

— Бик дөрес әйтәсең, Сафиулла, бер эш бетүгә, икенчесе туып тора. Картайгач, авырга килә икән ул.

— Аны җиңеләйтергә кирәк иде,— диде Сафиулла.

— Минем эшне кем эшләсен, без бит икәү генә, малаем да, мин.

— Шәрәфине өйләндерергә кирәк, өчәү булырсыз.

— Бүген иртәдән бирле үзем дә шул турыда уйлана идем әле. Шәрәфи кичә Наратлыга барып кайткан иде. Шунда аның яраткан кызы бар икән, Хәмдия исемле, ди. Колхоз ашханәсендә эшли, ди. Менә шуңа өйләнмәкче була. Мин ул кызның үзен дә, нәсел-нәсәбен дә белмим,— диде Сабира апа.

Сафиулла кинәт:

— Мин бик яхшы беләм аларны. Тормыш итә торган эшчән кешеләр,— дип куйды.

— Син белгәч, безгә шул җитте алайса, мин синең сүзеңә һич икеләнмичә ышанам,— диде Сабира.

— Алай, син ышангач, мин үзем яучы булып барам,— дип әйтә куйды Сафиулла.

Сабира апа кайчаннан бирле үзен борчыган бу мәсьәләнең, ниһаять, хәл ителү алдында торганлыгын аңлап, әллә шатланып, әллә каушап калдымы, бик мәзәк бер әчке кичереш белән:

— Хәерлегә булсын, Сафиулла туган, яучы булып син барырга булгач, җиңеләеп киттем әле. Игелекле кеше ишектән керсә, җиңел була, дип тиккә генә әйтмәгәннәрдер шул,— диде.

Сөйләшү шулай бик әйбәт узды. Иртәгесен Сафиулла Наратлыга

барып, Хәмдиянең ата-аналары белән сөйләшеп, алардан ризалык алып кайтты. Кайда, кайчан туй вакытлары билгеләнде.

Сафиулла Наратлыдан кайтышлый туп-туры Сабира апаларга кереп, аларны кодалар белән сөйләшүнең нәтиҗәләре белән таныштырды.

Туйга чаклы әле ун көн вакыт бар иде. Шунлыктан, Сафиулланың киңәше буенча яңа мунча салуны туйга кадәр үк тәмамларга булдылар. Сафиулла иртәгә иртүк Шәрәфигә ярдәмгә колхоздан ике балта остасы бирергә вәгъдә итте.

Икенче көнне К-700 тракторы белән Наратлы урманына барып бураны алып кайттылар. Шул көнне үк аны күтәрделәр һәм шифер белән түбәсен яптылар. Аннары инде ишек, тәрәзә яңаклары куйдылар, мич чыгарып, аның өстенә таш өйделәр. Кыскасы, яңа мунча салу дүрт-биш тәүлектә тәмам булды.

Бу кадәр җиңел кул белән эшләнгән эш Сабира апаны да нечкәләп дәртләндереп җибәрде, аның күңелен күтәрде. Ул үзен бөтенләй яшьләр кебек тоя башлады. Хәтта беркөнне иртәнге якта мунчаны ягып та карады. Нәтиҗә бик шәп булып чыкты, берниндн төтен кайтару да булмады, ташлар да тиз кыздылар һәм бер чүмеч су салу белән «чажж» итеп тавыш бирделәр.

Көзге көннәрнең берендә Хәмдия Наратлы авылыннан Сарайлыга килен булып төште. Әлбәттә, киленне бик зур тантана һәм бик бай табыннар әзерләп каршы алдылар. Хәтта борынгы гадәт буенча, гомере рәхәтлектә үтсен, дигән теләк белән аны машинадан төшкәч тә мамык мендәргә бастырдылар. Әле яңа гына тормыш башлаучы бу ике яшь җанга бәхет-сәгадәт, исәнлек-саулык һәм иминлек-тынычлык теләделәр. Үз гомерендә башыннан күп кенә вакыйгалар кичергән, һәртөрле гаугаларны үз җилкәсендә күтәргән күршеләре Гыйниятулла карт мәҗлестән чыкканда:

— Тату яшәгез, борынгылардан калган «Тавышлы йорттан бәхет китәр», дигән бер бик мәгънәле сүз бар, шуны онытмагыз! — диде.

Күп төрле мәшәкатьләре белән көндәлек тормыш башланды. Билгеле, Хәмдия өчен бу гаиләдәге кайбер гадәтләргә ияләнү яки аларга иярү бигүк җиңел булмады булуын. Ләкин ул үз әнисе биргән киңәшләрне хәтерендә нык тотты, бу киңәшләрне беркайчан да онытмады. Әйтик, кайнанасы Сабира карчыкның аш-су хәзерләүдәге кайбер житешсезлекләрен күрсә дә күрмәмешкә салышты. Ә бит Хәмдия кулинария мәктәбен тәмам итеп, туып үскән авылында повар булып эшләгән яшь аш остасы булганлыктан, бу мәсьәләдә кайнанасыннан шактый белемлерәк иде. Шулай булса да, вак-төяк, юк-бар житешсезлекләрне күрмәмешкә салышты һәм, ул житешсезлекләр белән килешә алмаса да, кайнана белән телгә килүдән бик нык сакланды. Арада салкынлык булудан шулай ук бик сагайды. Хәтта кайнанасының кайбер катырак әйткән сүзләрен дә ишетмәмешкә салышты. Кыскасы, аңа каршы сүз әйтергә ашыкмады. Бу хәл Сабира апаны да сабырлыкка өндәде. Ул да әкренләп Хәмдиягә ияләнә башлады, хәтта Шәрәфи белән Хәмдия Наратлыга кунакка киткән очракларда ул аларны бик тиз юксына да торган иде. Өйдә Хәмдия булмагач, нәрсәдер житмәгән кебек тоела башлады. Шулай берчакны Хәмдия белән Шәрәфи көнен әйләнеп кайту уе белән Наратлыга киткәннәр иде. Ләкин шул көнне кинәт салкын яңгырлар ява башлады һәм алар кунып калдылар. Сабира апа өйдә ялгызы гына кунды. Ләкин ул төнне рәтләп йоклый алмады. Сәгать саен, минут саен диярлек аларның кайтып капка ачып керүләрен көтеп ятты. Һаман кайтмадылар. Ниһаять, икенче көнне иртүк, кояш агач буе күтәрелгәч кенә кайтып төштеләр.

Кайту белән өчәүләп иртәнге чәйгә утырдылар.

Көзнең соңгы атналары кергәнлектән, Сабира апа кар базы өстенә өеп куелган башлы суганнарны Сарайлыдагы гадәт буенча бауга тезеп, чормага менгереп эләргә булган иде. Чәйдән кузгалу белән ул коргаксыган кулларын бер-берсенә ышкыштырып, беркадәр кыенсыну белән Хәмдиягә дәште:

— Син, киленкәем, башлы суганны бау итеп үрә беләсеңме? Көннәр явымга әйләнгәнче баз өстендәге суганнарны үреп чормага элсәк, бик әйбәт булыр иде,— диде.

Суган үстерүдә гомер-гомергә дан казанган Сарайлы авылында бу эшнең бөтен нечкәлекләрен барлык кешеләр беләләр, ә менә Наратлы авылында суган үстерү белән бер генә хуҗалык та диярлек шөгыльләнми, чөнки аларның җирләре суган игү өчен яраксыз. Хәмдия исә шул авылда туып үскән кыз булганлыктан, бу эш белән бөтенләй таныш түгел иде. Шулай булса да, Сабира карчык биргән бу сорауга ул «белмим» дип җавап бирмәде. Чөнки Хәмдиянең эш турында «белмим» дип әйтергә теле беркайчан да бармый иде. Шунлыктан булса кирәк, ул кайнанасының бу соравына:

— Белеп җиткермәсәм, өйрәтерсез, әни,— диде.

Алар кар базы өстендәге өем-өем башлы суганнарны элек өй эченә ташыдылар, ә кичен ут яктысында, кыякларын юкә белән аралаштырып, бәйләм-бәйләм итеп үрделәр. Иртәгесен инде чормага менгереп киртәләргә элделәр. Хәмдиянең җитезлегенә, эшкә осталыгына Сабира апа хәйран калды. Хәтта ул киленнең суганны болай үрүе беренче тапкыр икәнлеген сизеп тә бетермәде бугай.

Беркадәр вакыт алар чормага элгән баулы суганнарга сокланып карап тордылар. Сап-сары һәм бик юка кабыклы бу баулы суганнар аз гына кагылу белән дә, үзара чаш-чош килеп, ниндидер бер йомшак тавыш чыгарып куялар һәм алардан аз гына әчкелтем ис аңкый. Чорма такталары арасыннан төшкән кояш нурлары аларга карап туймаслык матур бер төс бирә. Хәмдия исә:

— Әнием, суганнан башка тәмле аш хәзерләп булмый, ул үзе аз кирәк булса да, бик кирәк,— дип кабатлый-кабатлый, киртәгә эленгән баулы суганнарны һава йөрерлек итеп бер-берсеннән аралап чыкты, аннары чорманы чүп-чарлардан, иске-москыдан арындырып, төшәргә җыенды һәм бик мөлаем гына тавыш белән:

— Әни, мин төшим инде, көтү кайтыр вакыт җитте, сыерны каршы аласым бар,— диде.

— Төш, кызым, төш,— диде Сабира апа, Хәмдиягә карап, һәм шушы минутта үзенә-үзе аптырап калды. Ул Хәмдиягә гел «килен», дип кенә эндәшә иде. Ә менә әле үзе дә сизмәстән, «кызым», дип дәште. Бу ничек булды соң әле. Ничек булса да булды, ләкин алай дәшәргә Сабира апаны берәү дә мәҗбүр итмәде, бу сүзне ул үз теләге белән әйтте.

Хәмдия төшеп киткәч, Сабира апа эченнән генә: Хәмдия дөрес әйтә, бик дөрес, суганның да, тозның да, җиләк- җимешнең дә — барысының да үз урыны бар. Барысы да берсен-берсе тәмләндерәләр, барысы да — азык-төлек. Димәк, йортыбызга азык-төлекнең кадерен белә торган килен килде, дип, шактый вакыт чормадагы суганнарны тикшереп йөрде.

Хәмдия чормадан төшү белән капка алдына җигүле ат белән Шәрәфи кайтып туктады. Хәмдия аны күрү белән, ак өстенә кызыл бөрчекләр сибелгән ситса күлмәгенә сыеша алмаган гәүдәсен уйната-уйната, капкага таба юнәлде һәм сызганган кечле беләкләре белән аны ике якка ачып җибәрде. Шәрәфигә аның бу хәрәкәтләрен күрү белән тыелгысыз дулкын китереп бәрде. Хәмдиянең такта капканы киереп ачып җибәрүе Шәрәфи өчен кайчандыр өлкәннәр авызыннан

ишеткән «күк капусы ачылу» белән бер иде. Хәмдия белән Шәрәфи арасындагы һәркайчан берсен-берсенә тартып торган бик нечкә ефәк җеп аларны гүяки яңадан кат-кат урап, чорнап алды, гүяки алар бер-берсенә тагын да якынрак килделәр, тагын да бер-берсенә ныграк сырыштылар. Әле кайчан гына бер-берсенә күз салып кына, бер-берсенә якын килергә оялып кына йөргән бу яшь җаннар арасында менә шушы минутлардагы кебек тартылу юк иде бугай. Ә хәзер алар бер-берсеннән күзләрен дә ала алмыйлар. Күрәсең, Хәмдиянең капканы киереп ачып җибәрүе һәм, Шәрәфигә ишегалды түренә таба юл биреп, үзенең дә арбага сикереп менеп иренә терәлеп утыруы — бу бик озак елларга сузылачак һәм озын юлга чыгуның башы иде. Лапаска кадәрге берничә метр араны да бергә утырып үтү, бу — алар арасындагы мәхәббәтнең беркайчан да сүрелмәячәклегенең билгесе иде.

Дөрес, Сарайлыга килен булып төшкән көнне дә аларны шушы капканы ачып каршы алганнар иде. Ул көнне бу капка шаулап-гөрләп торган тантана эчендә ачылган иде. Ул көнне алар башкалар ачкан капкадан кергән булсалар, бүген бу капканы Шәрәфи өчен дә, үзе өчен дә Хәмдия ачты. Бүген туй көннәрендәге кебек ыгы-зыгылар да юк, һәр төрле шау-шулар да, җыр, гармун тавышлары да ишетелми. Шуңа да карамастан, икесенең бер арбага утырып лапаска таба үтүләре бу яшь җаннарның бер нәрсә белән дә алыштырмаслык шатлыклары иде. Бу — аларның гади бер эш көннәре, тормыш итә башлау көннәре иде. Бу көннең әнә шулай һәртөрле төчеләнүләрсез, кылanуларсыз башлануы, аларның үзләре өчен үзләре капка ачулары иде.

Алар лапас янына килеп туктау белән арбадан төштеләр һәм икәүләп атны тугардылар, аннан ашарына салдылар. Аннары Хәмдия озын керфекләре сирпелеп торган күзләре белән Шәрәфигә карады:

— Әйдә, чормага менеп, әни белән үргән баулы суганнары күреп төш,— диде.

Алар, озынча баскычның араталарына баса-баса, чормага күтәрелделәр.

Бу чорма һәртөрле ризык белән тулган үзе бер дөнья иде. Монда аз гына кагылу белән чаш-чош тавыш биреп торган сап-сары баулы суганнар тезелгән, эчләренә киптерелгән шомыртлар тутырылган кечкенә-кечкенә киндер капчыклар эленгән, учма-учма итеп бәйләнгән керән тамырлары, көлтә-көлтә кérән чәчкәле мәтрүшкәләр асылган. Монда ризык, монда муллык, монда дару үләннәре, монда барысы да бар, монда юклык кына юк!

Шәрәфи боларны күреп, шатлыгыннан нишләргә белмәде. Аның бу чормага күптән инде менгәне юк иде һәм ул аңа һәр төрле иске-москы әйберләр ята торган бер урын итеп кенә карый иде. Һәм ул дөрестән дә шулай иде. Ә хәзер бу чорма үзе бер матур урынга, үзе байлык белән тулган бер склад сыман бер урынга әйләнгән иде.

Менә урамда мал-туар тавышы ишетелә башлады.

— Шәрәфи, көтү кайта, капканы ачарга кирәк,— диде Хәмдия һәм тиз генә чормадан төшеп тә китте. Аның артыннан Шәрәфи төште.

Хәмдия капканы ачу белән җиленнәре сөт белән тулган бура кебек ала сыер кайтып керде. Хәмдия аны лапаска таба үткәрде дә, үзе өйгә кереп, аннан сыер саву өчен чиләк, тастымал кебек кирәк-яракларны алып чыкты. Ала сыер аны күрү белән беркадәр вакыт ятсыныбрак карап тарды. Ул соңгы вакытларда йомшак тавышлы бу яшь хатынны иртә-кич күрсә дә, аңа ничектер ияләнеп җитмәгән иде әле. Ләкин Хәмдия аның алдына зур ялгаш белән йомшак үлән китереп куйгач, ала сыер ятсыныбрак тормады, башын туп-туры үләнгә төртте. Ул үләнне бик теләп ашарга кереште. Хәмдия исә юеш тастымал белән аның җиленнәрен сөртте, аннары тулган җилемнәр астына калай чиләген куеп, имчәкләрне йомшак бармаклары белән җиңел генә

тарткалый башлады. Баштарак калай чиләкне яңгыратып беренче сөт тамчылары тавыш бирде. Аннары инде, бу тамчы тавышлары көчәйгәннән-көчәя барып, тоташтан сөт ага башлады һәм туктаусыз гөжләп торган сөт тавышы өстенләп алды.

Нәкъ менә шушы вакытта Сабира апа, өйдән чыгып, баскыч төбенә басып торган хәлдә лапас ягына күз салды, Хәмдиянең сыер савуын күзәтте. Исәбе, әгәр ала сыер, Хәмдияне ятсынып, сөт бирергә теләмичә аяклары белән тибенә башласа, Хәмдиягә ярдәмгә килү иде. Ләкин аның борчылуы урынсыз булып чыкты. Ала сыерның һич кенә дә холыксызланмыйча, Хәмдиягә тәмам буйсынганлыгын күреп һәм гадәттәгечә әллә нинди бер рәхәтлек бирә торган гөжләп аккан сөт тавышын ишетеп, куанычыннан нишләргә дә белмичә, күңелендә үзенә бер төрле канәгатьләнү һәм тынычлану сизде. Әйе, чыннан да, бөтен абзар-кураларны, алай гына да түгел, бөтен ишегалдын шаулатып торган бу сыер саву тавышы, туктаусыз гөжләгән бу сөт агымы бөтен йортка ямь бирә һәм, бу тавыш яңгырамаса, бу йорт, бу ишегалды бик җансыз, бик күңелсез, бик коры һәм бөтенләй буш булыр иде.

Сабира апа кайбер күршеләрнең үзләре сыер асрамыйча, көн саен диярлек иртән иртүк, кулларына ярты литрлы пыяла банка тотып, бер тапкыр чәй эчәрлек сөт сорарга керүләрен күз алдына китерде һәм, үзе белән үзе сөйләшеп, борынгыларның: «сыеры барның — сые бар», дигән сүзләрен исенә төшерде. Аллага шөкер, киләчәктә дә катыксөттән, майдан өзелмәбез. Болай булгач, бу Хәмдия тормыш итәргә килгән икән. Картайган көнемдә сыер да сава алмам, дип бик борчыла идем. Ишегалдыбызда бер тояк та булмаса, ул тормыш буламыни, дип бик пошынып йөри идем. Бу баланың кулыннан килә икән, бу эш кешесе икән,— диде.

Икенче көнне иртүк Хәмдия йокысыннан уянды һәм, ирен юрган астында калдырып, сыер саварга чыкканда, баскычта кайнанасын очратып һәм аның кулында сөт сава торган чиләкне күреп, аптырап калды. Ул аңа бик ягымлы тавыш белән:

— Әни, нишләп бик иртә торып чыктың, мин үзем савар идем,— диде.

Кайнана аны күрү белән әллә нинди бер шатлык кичерде һәм йөрәгенең түреннән чыккан йомшак тавыш белән:

— Кызым, Хәмдия,— диде, тамагына нәрсәдер тыгылган сыман булды.— Сезнең икегезнең дә яшь чагыгыз. Син ир куеныннан чыгарга ашыкма әле. Бүгеннән башлап иртәнге якта сыерны мин савармын. Бу синең савуыңны яратмаудан яки сине кагудан түгел. Мин сине үземнең кызым кебек якын күрәм һәм сине таң белән ирең куеныннан чыгарасым килми, син болай да көн буе эшлисең. Менә шулай иртәнге якта сыерны көтүгә мин куармын, ә кичен көтүне син каршы алырсың һәм сыерны син саварсың. Килештекме, кызым?

Хәмдия бу сорауга башта ничек җавап бирергә белмичә аптырап торды да, кинәт бер эчке дулкынлану белән:

— Әни, син таң белән йокыңнан уянып сыер саварга чыкканда, мин нинди йөз, нинди түземлек белән түшәктә ятыйм! Бу хәл минем башыма сыймый. Син җитмешнең теге ягында, ә миңа әле егерме тулып кына бара.

Бианасы аның каршына ук килеп басты:

— Менә шуңа күрә дә, сиңа егерме дә тулмаганга күрә мин сине дә һәм иреңне дә — икегезне дә якларга телим. Гомер дигәнең үтә дә китә ул, егерме дә тулыр, утыз да, кырык та... Шуның өчен яшь чакта яшәп, яшь чакта рәхәт күреп калыгыз. Картаерга өлгерерсез әле,— диде һәм лапаска таба атлады.

Хәмдия кайнанасының бу сүзләрен бөтен тирәнлеге белән аңлады. Күңеленнән аңа кат-кат рәхмәт әйтте. Аннары инде, кайнанасының

көннән-көн хәлсезләнә баруын һәм озакламыйча бу изге эшне башкара алмаячагын уйлап, эченнән генә риза булды.

Һәм шулай уйлавы дөрес булып чыкты. Бер ай да үтмәде, Сабира апа иртә белән сыер саварга чыга алмый башлады. Ул берничә ел инде вакыт-вакыт биле кузгалып җәфалана иде. Элекке елларда, врачлар биргән киңәшләр буенча даруланып, бу авырудан котыла иде. Ә радикулит дигән әлеге авыру бу юлы аны башлану белән үк урынга яткырды. Шунлыктан иртәнге якта ул сыер саварга чыга алмый башлады.

Инде кыш айлары үтеп, җәй айлары житте. Торган саен бу ишегалды үзгәргәннән-үзгәрде. Шушы җәй көннәренең берендә Гыйниятулла карт, бер уңай вакыт табып, аларның ишегалларына күз салды. Ишегалдындагы бауларга эленгән ап-ак җәймәләр, юрган сүрүләре, мендәр тышлары, озын-озын сөлгеләр әле төньяктан, әле көньяктан искән жилләрдә урала-урала жилфердиләр. Диңгез өстендәге жилкәнле көймәләр кебек үзләренә гүяки юнәлеш эзләп, әле бер якка, әле икенче якка чайкалалар. Ишегалдының түрендә, зәңгәр күк читендә кабара-кабара, кайный-кайный ак болытлар агыла. Хәмдиянең кибәргә элгән керләре ул. Шул болытлар бер караганда күккә күтәрелергә теләгән шикелле кабаралар, икенче караганда чайкалып кына калалар. Бу ап-ак ишегалды ерак жирләрдән килүче аккошларның канат тирбәтә-тирбәтә һавада йөзүләрен искә төшерә. Ак керләр арасында коеп куйган матур сынлы, түгелергә торган су шикелле зәңгәр күзле, терсәгеннән үк беләкләрен сызганган Хәмдия йөри. Әгәр монда Хәмдия йөрмәсә, жил дә болай исмәс, керләр дә болай чайкалмаслар һәм ишегалды да болай ямьле булмас иде. Монда жил дә Хәмдия өчен исә, керләр дә Хәмдия өчен чайкалалар, аяз күк читендә әзлексез агылган ак болытлар да гүяки шушы ак ишегалдындагы Хәмдия янына йомшак түшәк булып төшәргә ашыгалар иде. Бу берничек тә аңлатып булмый торган әллә нинди илаһи бер матурлык, әллә нинди сихри бер көч иде. Юк, бу бер дә әллә нинди сихри көч түгел, ә гади бер яшь хатынның башкаларны гел үзенә тартып, үзенә җәлеп итеп торган көч иде. Бу көч Хәмдиянең үзен-үзе тота белүе, үзенең матурлыгын һәркайчан саклый алуы белән барлыкка килгән көч иде. Тышкы ясалмалыкларны да, юк-бар нәрсәләргә табынуларны да — шушы көч кире кага иде.

Ишегалдында Хәмдиягә тәмам баш иеп карап торучы Гыйниятулла карт менә шулай уйлады.

Чынлап та, Хәмдиянең йөзенә иннекләр ягасы юк, чөнки аның якты чырае, мәкерсез күңеле тышкы буяуларны күтәрә алмый, аның гел хәрәкәттә, гел хезмәттә булуы аркасында барлыкка килгән алсулыгы бөтен төр буяуларга караганда әллә ничә тапкыр өстенрәк, әллә ничә тапкыр гүзәлрәк иде.

Әйе, ул һәртөрле ялтыравыкларга кызыга торган, тышкы зиннәтләргә баш ия торган, шуларга тез чүгә, сәҗдә кыла торган җан түгел, ул фәкать хезмәткә, яхшылыкка, тугрылыкка, үзенең көченә инана торган Хәмдия иде. Шуңа күрә дә аны һәркайда барысы да көтеп алалар; урак өсте көннәрендә аксыл сары камыллары белән бөгелә-сыгыла шаулап утырган арыш һәм бодай басуларындагы комбайнчылар да, туңга сөрү участокларындагы тракторчылар да, билдән булып үскән озын сабаклы люцерна чабучылар да, җәйләүдәге көтүчеләр дә — барысы да кайнар аш белән салкын компот китерүче Хәмдияне көтәләр. Хәмдия үзе алып килгән, кайнар шулпалары, кабарып торган бодай күмәчләре, куе чәйләре белән аларны сыйлап, аларга көч кертә. Хәмдияне көтеп алучылар басуларда гына түгел, үз йортындагы барлык җан ияләре дә аның тизрәк өйгә кайтуын түземсезлек белән көтәләр. Әйе, тавык-чебешләр, каз-үрдәк бәбкәләре дә, горур гәүдәле

күркәләр дә Хәмдиядән башка яши алмыйлар. Хәмдия алар өчен дә ана, алар өчен дә азык хәзерләүче.

Карлыгач дигән кыйгач канатлы кош үзенең оясын, гадәттә, кызыл балчык белән катнашкан измәдән ясый. Ул корган оя бик нык була. Ул бу измәне ничек әзерли торгандыр, анысын белмим, әмма шушы балчык измәсеннән корылган карлыгач оясының бернинди җил-давылларда да һәм бик көчле явым-төшемнәрдә дә җебемәслек, җимерелмәслек нык булуы билгеле. Хәмдия белән Шәрәфинең өйләнешеп, үзләренең гаилә тормышын башлаулары да нәкъ менә карлыгачларның, кыйгач канатларын кага-кага, үзләренә оя корулары кебек иде һәм бу карлыгачлар гел авыл өстендә очачаклар, алар беркайчан да авылдан китмәячәкләр.

1983 ел.

## Бер сорауга — бер җавап

**Сорау:**

**— Соңгы елларда очраган иң кызыклы археологик табылдыклар турында сөйләсәгез иде?**

**Равил Фәхретдинов, археолог:**

**— Соңгы елларда очраган иң кызыклы табылдыкларның берсе — бронзадан эшләнгән борынгы көзге. Ул безнең эрага кадәр VI йөздә ясалган һәм кулланылган. Димәк, аңа хәзер 2500 «яшь».**

**Көзге түгәрәк формада коеп эшләнгән, диаметры 18,5 см. Аңа 14 см озынлыкта сап куелган. Сап башында тәкә башы сурәте, ул шул заманнарга хас «җәнлек стиле»ндә эшләнгән. Белгечләрнең фикеренчә, мондый көзгеләр антик дөньяның Кара диңгез буендагы Ольвия шәһәрендә ясалып, скифлар арасында киң таралыш алган булган.**

**Әлбәттә, скифлар безнең якларда яшәмәгәннәр. Әмма Идел-Кама буйларында аларның замандашларыннан тиссагет исемле кабиләләр көн иткәннәр.**



**Без бу көзгене әнә шул кабиләләр белән бәйләргә мөмкин дип уйлыйбыз. Алар Иске Казан янында ук урнашкан бер борынгы нигытмада яшәгәннәр.**

**Бу фикер белән без Ижевскида булып узган VII Урал археологик киңәшмәсендә уртаклаштык. Көзге белгечләр һәм, гомумән, археологлар арасында зур кызыксыну уятты. Икенче төрлерәк тә фикер әйтелде, әлеге көзгенең борынгы грек тарихчысы Геродот тасвирлаган төньяк сәүдә юлында (Ольвиядән алып Урал тауларына чаклы булган юл) берәр скиф кешесе тарафыннан күмеп калдырылган хәзинәдән булуы мөмкин диелде.**

**Ничек кенә булмасын, Татарстанда гына түгел, бөтен бер Идел-Кама регионында беренче тапкыр очраган «Иске Казан» көзгесе безнең бу якларның көньяк скиф-грек дөньясы белән экономик-культура бәйләнеше хакында сөйли. Ә археологик истәлек булу ягыннан ул бердәнбер (уникаль) табылдык дигән исемне ала.**

*КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы карарларын — тормышка!*

**Мидхәт Фарукшин,**
философия фәннәре докторы

# ҖИҢҮЧӘН ЧЫНБАРЛЫК ҺӘМ ДОШМАНИ УЙДЫРМАЛАР

Иҗтимагый үсешнең бүгенге чорга хас үзенчәлекләреннән берсе — социализм белән капитализм арасындагы идеологик көрәшнең аеруча кискенләшүе. КПСС Үзәк Комитетының 1983 елгы июнь Пленумы карарында мондый юллар бар: «империалистик реакция, барыннан да бигрәк АКШның идарәчел даирәләре, бөтен дөньяда хакимлек итү өчен хыялый планнар корып, үзләренең агрессив политикасы белән кешелек җәмгыятен атом-төш һәлакәте чигенә этәрәләр. Советлар Союзына, социализм илләренә каршы масштаблары һәм оятсызлыгы буенча тиңдәше булмаган психологик сугыш алып барыла. Ялганлау һәм яла ягудан һич чирканмыйча, буржуаз пропаганда социалистик җәмгыятькә кара ягарга, безнең тормышның социаль-политик һәм идея бердәмлеген какшатырга омтыла. Шунлыктан бүген хезмәт ияләренең сыйнфый чыныгуы, буржуаз идеологиягә каршы компромиссыз көрәш аеруча әһәмият ала».

Коммунизмның идея-политик дошманнары империализм башлап җибәргән бу психологик сугышта милли мөнәсәбәтләрдән киң файдаланырга тырышалар. Мәсәлән, АКШ президентының элекке ярдәмчесе, киселеп чыккан антикоммунист З. Бжезинский, Нью-Йоркта басылган «Советлардагы милли мәсьәләләр» исемле җыентыкта: «Совет җәмгыятендәге үзгәрешләр хакында фикер йөрткәндә, миңа калса, хәзер элеккегә караганда үткеррәк күзләр белән милли мөнәсәбәтләр тоткан урынга текәлергә кирәк!» — дип, ачыктан-ачык әйтә.

Аңлашыла ки, бу очракта буржуаз советологлар милли мөнәсәбәтләргә бары тик социалистик җәмгыять үсешендә нинди дә булса четерекле хәлләр китереп чыгаруга өметләнеп кенә карыйлар. Бу җәһәттән Америка советологлары симпозиумының «СССРдагы милләтләр һәм милләтчелек: совет дилеммасы» дигән исем белән Вашингтонда басылган материалларына игътибар итик. Монда иң элек шул нәрсә күзгә ташлана: буржуаз идеологларны бары тик, милләтләрнең үзара мөнәсәбәте социализм чорында ниндирәк аңлашылмаучылык китереп чыгара алыр иде икән, дигән сорау кызыксындыра. «Советлар илендә күп санлы милләтләр арасындагы үскәннән-үсә баручы киеренкелек,— диелә ул материалларда,— совет җитәкчелеге каршына килеп баскан эчке, иң җитди мәсьәләләрнең берсе булып тора. Советологларның «тикшеренүләре» милли мәсьәләне СССРның хезмәт ресурслары, оборона сәләте, политик стабильлеге белән бәйле юнәлештә алып барыла, шунлыктан милли мәсьәләне анализлау тенденциясе совет иленең эчке политикасын тикшерүдә үзәк урыннарның берсен тотып тора.

Төрле илләрдә, төрле юнәлештә «тикшеренсәләр» дә, коммунизм дошманнарының фикере гел бер тирәдә әйләнә. Алар, нигездә милләтләрнең ассимиляциясе,

аларны руслаштыру һәм милләтчелекнең яңадан баш калкытуы турында сүз куерталар. Шушы темалар тирәсендә казынучы буржуаз әдәбиятта төрле милләт халыклары тормышындагы, милли телләрдәге һәм, аеруча, милли мөнәсәбәтләр арасындагы үзгәрешләр хакында гаугa бара. Бу темаларга багышланып чыккан һәр китапта советологлар милли төркемнәрнең ассимиляциясенә аерым басым ясыйлар. Буржуаз авторларның «хезмәтләрендә» әлеге мәсьәләләр бары тик я ассимиляциянең нинди дәрәҗәдә икәнлеге, я аның темпы турындагы мәгълүматларда гына аерма сизелә. Берәүләре, СССРдагы бөтен халыклар ассимиляцияләшә, руслаша бара, рус булмаган этник төркемнәр шул язмышка дучар ителгәннәр инде, дип, лаф оралар.

Советологларның икенче өлеше, антикоммунистлык ягыннан беренчеләреннән һич калышмасалар да, башкачарак фикер йөрткәндәй кылана. Болары ассимиляция күренешенә СССРның барлык халыклары да тартылмый, андый язмыш, башлыча, союздаш республика дәрәҗәсендәге мөстәкыйльлек ала алмаган милләтләргә генә хас, дип аңлаталар. Рейган администрациясендә Советлар Союзы буенча зур «белгечтән» саналучы профессор Р. Пайпс турыдан-туры Украина, Балтик буе, Кавказ һәм Урта Азия халыкларының ассимиляцияләшүенә һичнинди дә өмет юк, дип «өметләндерә». Пайпс фикеренчә, ассимиляция руслар күп яшәгән өлкәләргә генә кагыла. «СССРдагы милләтләр һәм милләтчелек: совет дилеммасы» дигән китапта ул: «Мин немецлар, башкортлар һәм татарлар өчен якты киләчәк күрмим,— дип яза.— Алар йотылып бетәчәк». Тик автор үзенең мондый «кыю» күрәзәчелеген һичнинди дәлил белән дә расларга кирәк санамый.

«Ассимиляция» төшенчәсе белән мавыгучы буржуаз әдәбиятта аны төрледән-төрле яссылыкларда күрсәтергә тырышалар. Мәсәлән, милли мөнәсәбәтләрнең социологик якларын тикшерүче америкаи советолог Б. Силвер СССР халыкларының «руслашуы» турында берничә гипотезаны алга сөрә. Бу күренешнең таралу дәрәҗәсе, дип аңлатырга тырыша ул, шәһәрләрдә, авыл җирендәгегә караганда, югарырак, ягъни әлеге процесс рус булмаганнарның руслар белән аралашу дәрәҗәсенә пропорциональ рәвештә арта. Руслашу ирләрдә, хатыннардагыга караганда, тизрәк формалаша, ә «мөселманнар» бу нәрсәгә акрынрак бирeләләр. Әйтик, татарлар һәм башкортлар арасында руслашу 2,9—4,4 процент, ә алар белән күршедәш «мөселман булмаган» халыкларда бу 15,5 тән 22,7 процентка җитә.

Бу очракта «мөселман» сүзенә аңлатма биреп үтәргә кирәк. Буржуаз әдәбиятта Советлар Союзының Октябрь революциясенә кадәр ислам диненә табынган халыкларын, алар хәзер материалистик, марксистик-ленинчыл караште торсалар да, барыбер — «мөселманнар», калганнарын «христианнар» һ. б. дип атыйлар.

Буржуаз советологларның югарыда китерелгән «ачышлары» һичнинди фәнни теориягә дә нигезләнмәгән һәм нигезләнә дә алмый. Бу — «тикшеренүләр»дә социалистик милләтләр тормышындагы мәгълүм хәлләр, социализм идеяләренә дошмани политик пропаганда төсендә, бозылып, терминологиягә үк әйләндерелә. Моның шулай икәнлеген бер «руслаштыру» термины мисалында гына да аңлатырга мөмкин. Безнең ил халыкларының бердәм гаиләсендәге дуслык, якынлашу, туганлашу күренеше белән әлеге төшенчә арасында нинди уртаклык булырга мөмкин?! «Руслаштыру» терминын, иҗтимагый фикерләүдә, бары тик рус патшалыгы хөкем сөргән чорда, властьларның халыкларны көчләп ассимиляцияләве, бөек рус державасы шовинизмы, «башка халык» дип кенә йөртелгән кечкенә милләт кешеләренең хокукын чикләү, аларның үсеш юлында киртә төсендә файдаланылган политика буларак кына аңларга мөмкин. Табигый ки, моңарчы күренгәннәр арасында иң гадел җәмгыятьтән саналган социализм, һәртөрле социаль һәм милли кимсетүләргә чик куйган кебек үк, андый кабәхәт политиканы юкка чыгарды.

Коммунизмның идея-политик дошманнары, «руслаштыру»ның социализмга бөтенләй ят мәгънәдә яңгыравын белсәләр дә, дошмани максатлардан чыгып, үз язмаларында бу терминны болгата бирәләр. Аңа социалистик чынбарлыкта булып торган, әмма халыкка һич тә көчләп тагылмаган объектив үзгәрешләр мәгънәсе дә, советологлар уйлап чыгарган ялалар авырлыгы да йөкләтелә. Шунлыктан буржуаз фальсификаторларны фаш итүдә идея дошманнарыбыз телендә «руслаштыру» дип йөртелә торган төшенчәнең асылын ачыклау бик мөһим. Тагын бер советолог язмаларына тукталыйк. Аның исеме — Р. Льюис. Ул «Совет милли мәсьәләләре» дигән җыентыкта,

безнең ил халыкларының объектив сәбәпләр аркасында, үзара бик дусларча аралашуын, бер милли республикада башка милләт вәкилләренең дә күбәеп китүен «руслаштыру» белән бутый. Махсус «ялгыша», әлбәттә. Ул, шул күренешне сурәтләү йөзеннән: «Аралашу нәтиҗәләрен тикшерү эшләребезне җиңеләйтү максатыннан, сүз агышында кулланганда, «руслаштыру»ны без төрле милләтләрнең рус культурасын яки аның кайбер якларын үзенә алу, күчерә башлау процессы итеп билгелик!» — дип яза.

Шуңа охшаш фикер йөртүләрдән күренгәнчә, безнең идея дошманнарыбыз, аңлы рәвештә дә, аңламамышка салышып та, фәнни төшенчәләрне, үз кирәкләренә карап, иркенләп буташтыралар. Моннан исә ялган нәтиҗәләр чыгарырга зур мөмкинлекләр туа. Социалистик милләтләрдә, иҗтимагый тормышның интернациональләшүе кагыйдәсе буларак, объектив төстә үзара якынаю процессы бара икән; әйтик, берсендәге күркәм элементларны икенче милләт кабул итә, тәҗрибә уртаклаша икән, бу да буржуаз идеологлар тарафыннан халыкларга көчләп тагылган ассимиляция политикасы белән таңгаләштерелә. Руслардан читләшеп яшәү, мәсәлән, Советлар Союзындагы бер генә милләт өчен дә отышлы түгел. Ник әле русларда тупланган уңай тәҗрибәдән, аның бай культурасыннан һәм рус теленең гаҗәеп мөмкинлекләреннән рәхәтләнеп файдаланмаска?! Бу сорауга туп-туры бер генә җавап бар: милли аерымлыкларга ябышып яту, милләтләрнең бер-берсенә якынаю юлын бикләү аларның үсешенә, алга китүенә зыян ясау, киртә салу булыр иде.

Тагын шуны да әйтергә кирәк: күп санлы буржуаз «экспертлар» һәм «белгечләр», коммунизм мәсьәләләренә кагылганда, «миллилек» төшенчәсен дә «әйбәт» кенә бозып кулланалар. «Миллилек», алар өчен — бары тик бер милләткә генә хас, аны башкалардан аерып торучы, ят бер үзенчәлек ул. Әгәр шул ялгыш фикердән чыгып тикшерә башласаң, миллилек белән интернациональлек төшенчәләре бер-берсенә капма-каршы басалар да... челпәрәмә киләләр. Рус культурасы элементларының башка милләтләр үсешенә уңай йогынтысын, әлеге дошмани караштан чыгып бәяләсәң, әлбәттә, нәкъ әнә шул буржуаз «фән эшлеклеләре ирешкән» уйдырмага тап буласың. Бу очракта милләтләрнең берсе ирешкән уңышны икенчесе белән уртаклашуы һәм гомуми алга китеш, үсү процессы халыкларга көчләп тагылган «ассимиляция һәм руслаштыру» кебек аңлашыла башлый.

Совет чынбарлыгы исә милләтләрнең рухланып, канатланып алга баруын алардагы аерым үзенчәлекләрдә бер-берсеннән ерагайтучан сыйфатларга ябышып ятуда күрми. «СССРдагы милләтләрнең бер-берсенә якынаюы һәм чәчәк атуы» исемле хезмәтендә совет галиме М. И. Куличенко ап-ачык аңлата: «Милләтләрнең үзләренә генә хас кыйммәтле сыйфатларын кадерләп саклаган хәлдә, без аларның үзара якыннан аралашуын, тәҗрибә алышуларын һәм уртак рухи байлыклар булдырырга тырышуларын күрергә телибез».

Буржуаз советологлар, яла ягу йөзеннән кузгалган бәхәсләрдә Советлар Союзында рус теленең киң таралуына, бу тел СССР халыкларының төп аралашу чарасына әверелүенә каршы көчле һөҗүм алып баралар. Р. Солчаник фамилияле берәү «Рус теле һәм совет политикасы» исемле язмасында, СССРда рус теленең өстенлегенә ирешү өчен махсус политика алып барыла, дигән уйдырмага ышандырмакчы була. Б. Майснер әфәнде дә, шул ук ялган фикерне куәтләп, СССРда рус теленә өйрәнүчеләр саны арту күренешен башка милләт кешеләрен руслаштыру, дип аңлатырга азаплана.

Үзләрен фән эшлеклеләре итеп күрсәтергә тырышучы шушы антикоммунистлар, әлеге яланы дәлилләү өчен, Советлар Союзыннан алынган статистик белешмәләрне китерәләр һәм рус теленең чын-чыннан милләтләрнең иң ышанычлы аралашу чарасы булуына таяналар. 1979 елда СССРда уздырылган халык санын исәпкә алу мәгълүматларына караганда, совет кешеләренең биштән дүрт өлеше, ягъни 214,8 миллионы рус телен мөкәммәл белә.

Шул дәрәҗәдә киң таралуы — һич тә аны кешеләргә көчләп тагу нәтиҗәсе түгел. «...Без, әлбәттә,— дип язды В. И. Ленин,— Россиянең һәрбер кешесенә бөек рус телен өйрәнү мөмкинлеге булдыру ягында торабыз. Без бер генә нәрсәне: ирексезләү элементын гына теләмибез. Без оҗмахка күсәк белән куып кертергә теләмибез... Безнең уебызча, бөек һәм куәтле рус теле кемнең дә булса аны таяктан кур-

кып өйрәнергә тиешлегенә мохтаж түгел». Рус теленең популярлыгын, милләтләр аралашуында аның төп таянычка әйләнүен объектив бәяләргә теләсәң, аның уникаль дәрәҗәдәге социаль әһәмияттен исәә алырга кирәк. КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ю. В. Андропов, безнең теләсә кайсы милләттәге миллионлаган кешеләребез көнкүрешенә табигый рәвештә килеп кергән рус теле илдәге экономик, политик һәм культура тормышында хәлиткеч роль уйный, барлык милләтләребезнең һәм халыкларыбызның якынаюына китерә, дөньядагы рухи байлыклардан ләззәт алырга мөмкинлек тудыра, дип аңлатты. Рус телен мөкәммәл белүнең файдасын шушылай төшендереп бирү белән, буржуаз советологларның дошмани фикерләвенчә, рус теленең киң таралуын көчләп руслаштыруга кайтарып калдыру арасында — җир белән күк аермасы.

Хәзерге чорда безнең илдәге күпчелек совет милләтләренә үз туган теле белән беррәттән рус телен дә әйбәт үзләштерү бик кулай. Милли тел һәм рус телен белү бер-берсенә һич тә каршылык тудырмыйлар. Социализмда милли телләрнең үсүен тоткарларга, гаиләдә, шәхси тормышта аның функциясен чикләргә һичнинди ихтыяҗ да юк. Һәр милли телнең язмышы туган теле саналган шул милләткә, аның конкрет вәкилләренә генә бәйле.

Милли телләрнең үсеше үзмаксат була алмый: тел иҗтимагый зарурлыкларне үтәгәндә, милләттә аңардан файдаланучылар булганда гына алга китә, яшәүчәнлеген, камилләшүен арттыра бара. Хәзерге дәвердә безнең илдәге күпсанлы милли телләр, һич сүз юк, бик мөһим иҗтимагый кирәкле роль үтиләр. Алар безнең кешеләрдә милли горурлык тәрбиялиләр, туган телдә белем алырга мөмкинлек тудыралар, милли культура һәм сәнгать байлыклары белән таныштыралар, шул милләт вәкилләренең якыннан аралашу чарасы булып хезмәт итәләр. Шуннан чыгып та раслларга мөмкин: бары тик социализм гына тудыра алган уңай шартларда милли телләр ирекле рәвештә үсәләр һәм бу үсеш гомум иҗтимагый ихтыяҗларга да бик хуп килә.

СССРда милләтчелек һәм милләтләрнең үзара бәрелеше турында сафсата сату совет милләтләрен тикшерүче буржуаз галимнәрнең гомуми бер сыйфаты булып тора. Т. Раковска-Хармстоун фамилияле бәрәү: «Этник милләтчелек Советларның союздаш республикасы булган һәр унбиш милләте арасында, ягъни бөтен төп милли группалар арасында бара»,— дип яза. АКШтагы буржуаз советологларның коллектив бер чыгышында: «...милләтчелек хәрәкәтенең иң көчлесе союздаш республика статусына ия халыкларга хас»,— дип язылa. Идеология дошманнары, тузга язмаган «милләт көрәше»н, «руслаштыру политикасы»н расларга тырышып, бездә алып барыла торган иң изге эшләрне мисалга китерәләр. Мәсәлән, соңгы елларда, бөтен халык бер булып кара туфраксыз якларны үзләштерү эшенә тотынды. Буржуаз социологлар совет халкының бу фидакарьлеген дә «рус шовинизмы шаукымы» дип бәяләргә азапланалар.

Тарихи чынбарлык фальсификаторлары СССРда милләтчелекнең яңаруы турында сафсата сату белән генә дә чикләнмиләр, алар безнең илдәге күп санлы милләтләрнең үзара туганнарча дус яшәвен дә, бер-берсенә карусыз ярдәмләшүен дә инкарь итәргә тырышалар. Шундыйлардан Д. Ротшильд дигән бәрәү үзенең Нью-Йоркта чыккан «Этнополитика. Концептуаль нигезләр» дигән язмаларында: «Марксистик интернационализм, христианнар яки мөселманнар арасында алга сөрелгән туганлык кебек үк — дип аңлатмакчы була,— этнополитик стрессларга юлыга». Дин уртаклыгына гына нигезләнгән туганлык, чыннан да, ышанычлы була алмый, чөнки бу очракта бәрәү дә нык социаль сыйнфый бердәмлеккә ия түгел. Социалистик милләтләрнең интернациональ бердәм хезмәттәшлеге, халыкара эшчеләр сыйныфындагы милли отрядларның бердәмлеге исә — объектив һәм реаль күренеш. Чөнки бу дуслык һәм туганлык — һәртөрле милләттәге хезмәт ияләренең тормыш максатлары, яктылыкка омтылышлары нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм ныгыган чынбарлык ул. Социалистик милләтләрнең хәтта буржуаз авторларның үзләре дә танырга мәҗбүр булган алга китешен, гөрләп үсүен СССР халыкларының туганнары дуслыгыннан, бер-берсенә ярдәмләшүеннән башка күз алдына да китереп булмый.

Буржуаз советологларның бездәге «милләтчелек» күренешен теорияләр кысасына кертергә азаплануында тагын шул ук хәл — төшенчәләрне буташтыру ярылып ята.

Алар «миллилек»не «миллэтчелек» белэн тэңгэл куеп фикер йөртэлэр. Бу хата исэ аларга телэсэ нинди яла ягуда ярдэм итэ.

Без социалистик җэмгыятьнең иҗтимагый тормышында милли күренешлэрне инкарь итэргэ җыенмыйбыз. Төрле миллэтлэрнең алга баруы социализм чоры максатларына һэм принципларына тулысынча җавап бирэ. Төрле миллэтлэрдэге архаик гадэтлэр, вакыт үтү белэн, көчсезлэнэлэр һэм юкка чыга баралар икэн, монысы — тормышның объектив закончалыгы. Милли чынбарлыктагы тормышчан, матур, гомуми ихтыяҗларга кирэкле яклар үсеп китэ, көчэя икэн, буржуаз идеологлар моны миллэтчелекнең яңаруы дип кабул итэ башлыйлар. Бусы — бер.

Икенчедэн, буржуаз авторлар миллэтчелекне милли горурлык белэн тэңгэллэштереп ялган нэтиҗэлэр чыгаралар. Миллэтлэрнең социализм чорында яңа уңышларга ирешүе, элбэттэ, аларны горур итэ, абруйларын күтэрэ. Эмма моны миллэтчелек яңара дип аңлату тамырдан дөрес түгел. СССРның 60 еллыгына багышланган чыгышында КПСС Үзэк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ю. В. Андропов бу хакта бик ачык иттереп сөйлэде. Без һэр ирешелгэн уңышлары өчен һэр миллэт халкының горурланырга, шатланырга хаклы икэнен тирэннэн аңлыйбыз, эмма бу хэл бер генэ миллэтне зурлауга, аны башкалардан аерып куярга, башкаларга кимсетеп карарга хокук бирми. Уңышлар, ирешелгэннэргэ карап горурлану милли аңлылыкның миллэтчелек кебек социализмга ят күренешкэ эйлэнүенэ китереп чыгармаска тиеш. Буржуаз социологлар телэгэнчэ, милли һэм сыйнфый аңлылык алдына дилемма китереп кую — ялтырап яткан фальшь ул. Совет чынбарлыгында мондый дилемма була алмый, чөнки дөньяга интернациональ караш белэн сугарылган безнең кешелэр үз миллэтлэренең үсешен илдэге барлык хезмэт иялэре тормышындагы гомум алга китештэн аерып йөртергэ телэмилэр дэ.

Өченчедэн, буржуаз пропагандистларның антикоммунистик «өйрэтмэлэрендэ» СССР халыкларының «миллэтчелек рухы» белэн тирэн патриотик тойгыларны тэңгэллэштереп нэтиҗэлэр чыгару да кара уйдырма булып тора. Монысы инде — космополитизм белэн интернационализмны тэңгэл куеп сөйлэшү белэн бер.

Совет кешесенең патриотик хислэре һэм милли горурлыгы туган Ватанының азатлыкта гөрлэп үсүеннэн туа. Туган иленең социаль прогрессыннан, эчке һэм тышкы дошманнарга каршы бэрелешлэрдэ яулап алган казанышларыннан, бөтен дөньядагы гомум-демократик һэм революцион изге көрэшкэ катнашудан, бөтен дөнья фэне, техникасы, культурасы, эдэбияты үсешенэ зур өлеш кертүдэн башка бүгенге дэрэҗэгэ менеп җитэ алыр иде мени ул?!

Без, кызганычка каршы, миллэтчелек кебек яман күренешнең кайбер яклары күренгэлэп китүне дэ онытмыйбыз. Милли чиклэнгэнлек чире дэ, элеккеге архаик гореф-гадэтлэрнең баш калкыткалап куюы да, социалистик яшэү рэвешенэ хас булмаган карашларны сакларга тырышучы кешелэрнең очраштыргалавы да бик ихтимал. Эмма болар гына совет кешелэренең бөек патриотизмын миллэтчелек белэн бутап йөртергэ һичнинди нигез бирми.

Дүртенчедэн, буржуаз советологлар, СССРда миллэтчелек күренешен күпертеп күрсэтү өчен, бездэге гаилэлэрнең төрле миллэт вэкиллэреннэн никахлашуына да «бэйлэнэлэр». Югарыда телгэ алынган Р. Пайпс фамилияле профессор бу юнэлештэ аеруча «эзлекле тикшеренүлэр үткэрэ». Никахлар ире дэ, хатыны да бер үк миллэт кешесеннэн төзелсэ, бу регионда миллэтчелек хэрэкэте көчле, дип раслап куя ул.

Гаҗэп: профессор кадэр профессор, яшь кешелэр гаилэ корырга җыенганда, иң алга нинди шартларның килеп басуын белми микэнни?! Ул, совет җэмгыятен кара тослэргэ буяп күрсэтү өчен, бу очракта да политикага кереп китэ. Хэтта Р. Пайпсның үз коллегалары да аның бу карашын уртаклашудан читтэ торалар һэм гаилэ төзергэ җыенган кешелэрнең бөтенлэй башка төрле фикерлэрдэн чыгып фикер йөртүлэрен, шул ук вакытта, үз миллэтлэрендэге гадэтлэрне истэ тотарга телэүлэренең дэ ихтималлыгын яхшы аңлыйлар.

Буржуаз авторларның кайберлэре, совет җэмгыятендэ миллэтчелек хөкем сөрүен расларга тырышып, гадэттэн тыш дэлиллэр эзлэргэ мэҗбүрлэр. Шундыйларның берсе — милли коммунизм дигэн уйдырма. Соңгы елларда советологлар бу темага багышланган шактый язмалар бастырдылар. Мэсэлэн, А. Беннигсен, С. Уимбуш фа-

милияле авторларның «Советлар Союзындагы мөселманнарның милли коммунизмы» дигән язмасында бу күренеш социализм, милләтчелек һәм ислам динендә уртаклык табарга һәм шуннан «милли коммунизм» дигән нәтиҗә чыгарырга азаплану булып күз алдына килә. Авторлар милли коммунизмны «милли сурәттәге социализм», «кәләпүшле социализм» итеп аңлатырга омтылалар. Уйдырмачы «теоретиклар» үз «хезмәтләренә» күптән инде тарих тарафыннан кире кагылган, фәнгә чит тезисларны: Солтангалиевнең антимарксистик карашларын, яһүд милли коммунизмының искереп беткән идеяләрен — барын да яңадан сөйрәп алып керәләр. Болар тарихны өйрәнү йөзеннән искә төшерелсә, әле бер хәл булыр иде. Юк шул, алай түгел. Үткәннәргә мөрәҗәгать итү аларга бары тик, СССРда милләтчелекнең тамырлары тирән, ул яңадан баш калкыта, дигән, совет чынбарлыгында бөтенләй булмаган уйдырманы яклау өчен генә кирәк. «Советлар Союзында милли коммунизм» исемле китап авторы Б. Гуревиц: «Советлар Союзында милли коммунизм хәрәкәте яңа үсеш аламы?» — дигән сорауга, һич икеләнеп тә тормыйча, уңай җавап кайтара. А. Беннигсен белән С. Уимбуш исә, югарыда телгә алынган язмада: «Солтангалиев идеяләренең күп кенә фикерләре онытылган бер вакытта,— дип тәкърарлыйлар,— әле күптән түгел генә «солтангалиевчелеккә» һәм «пантюркизмга» каршы алып барылган кампанияләр советлар илендә пантюркистик, панисламистик күренеш төшенчәләренең бөтенләй юк онытылмаганлыгын, көн тәртибеннән төшмәгәнлеген күрсәтәләр. Бу бик мөһим...»

Совет чынбарлыгы белән яхшы таныш булган һәр укучы, әлбәттә, безнең илдә әлеге авторлар телгә алынган «кампания»нең уздырылмавын яхшы беләләр. Монда тагын гап-гади төшенчәләрне юри бутарга тырышу, шул болгатулардан зур нәтиҗәләр чыгарырга азаплану ярылып ята. «Кампания», дигән булып, авторлар 1975 елда «Татарстан коммунисты» (№ 1) һәм «Совет мәктәбе» (№ 11) журналларында чыккан «Солтангалиев һәм аның буржуаз яклаучылары», «Октябрь революциясе һәм аның фальсификаторлары» дигән мәкаләләрне күздә тоталар.

1979 елда бездә Бөтенсоюз исәпкә алуы үткәрелгәч, буржуаз советологлар СССРдагы демографик үзгәрешләр турында, аларны үзләренең уйдырмалары җаена боргаларга тырышып, яңадан бер талпынып карадылар. Кабат СССР милләтләренең үзара мөнәсәбәтләрендәге чынлыкта булмаган каршылыклар телгә алына. А. Беннигсен белән М. Броксапның 1983 елда Лондонда чыккан «Исламның Совет дәүләтенә янавы» исемле китапларында төрле халыклар санындагы үзгәрешләрнең киләчәк егерме ел эчендә үзәк мәсьәләгә әйләнәчәгенә һәм милләтләр мөнәсәбәтенә нык тәэсир итәчәгенә басым ясала. Алар, мондый фикерне алга сөргәндә, СССРдагы рус милләте кешеләренең саны кимиячәк, дигән төшенчәләрдән файдаланалар. Буржуаз әдәбиятта, әлеге дә баягы, шул ук көрәзәчелеккә таянып, төгәл саннар да китерәләр. Әйтик, алар фикеренчә, 1979 елда руслар совет иле халкының 52,4 процентын тәшкил иткән булса, 2000 нче елда алар 44,3 яки 46—47 процентка гына калачак, имеш. Ә «мөселманнар» исә 65 миллионга, ягъни СССРдагы барлык халыкның 21—21,3 процентын «яулап» алачак. Кайбер язмаларда бу сан 66—75 миллионга, 22—25 процентка кадәр дә күтәрелә.

Буржуаз фальсификаторлар СССРда халык санын исәпкә алу нәтиҗәләреннән, совет җәмгыятендә киенлыклар чыгачак, милләтләр үзара бәрелешләргә керәчәк дигән уйдырмаларга нигез итеп файдаланып калырга ашыгалар.

КПССның XXVI съездында билгеләп үтелгәнчә, безнең илдәге демографик ситуация, ягъни халык санын исәпкә алудан күренгән хәл, кайбер яңа чаралар уздыруны таләп итә. Бу җәһәттәге төп мәсьәләләрнең берсе — эшче көчләрне, хезмәт ресурсларын нәтиҗәле иттереп файдалану. Халкы күп булган Урта Азиядәге, Кавказның кайбер якларындагы кешеләрне яңа территорияләрне үзләштерүдә, ил хуҗалыгын ныгытуда активлаштырасы бар.

Совет Армиясе сафларына елдан-ел илнең күп регионнарыннан төрле милләт яшьләре килә тора. Хәрби дәресләрнең югары нәтиҗәлелегенә ирешеп, егетләрне Ватанның каһарман-патриотлары итеп тәрбияләү өчен, яшьләрнең рус телен мөкәммәл белүләре сорала. Димәк, рус булмаган милләт балаларына тел өйрәтү турыдантуры илнең иминлеген саклау проблемасына килеп тоташа. Матур чынбарлыгыбызда- гы үз вакытында чишелешен табып торучан шушыңа охшаш мәсьәләләр буржуаз фальсификаторларга, совет илендәге халыклар санындагы үзгәрешләрдән әллә нинди

тузга язмаган бәрелеш эзләргә җитә кала. Г. Симон дигән кеше Кельнда чыккан «СССРдагы руслар һәм рус булмаган кешеләр» исемле язмасында: «...Советлар Союзындагы милләтләр проблемасының кечәюе,— дип ышандырырга тырыша,— үзләрендәге демографик мәгълүматлар тизлеге юнәлешендә генә артса да, советларның Урта Азиясе якын киләчәктә төп проблеманың үзәк регионына әйләнәчәк».

Бу — уйлап чыгарылган, дошмани уйдырма. Җәмгыятьтәге идея-политик һәм социаль бердәмлек ныгыганнан-ныгый барган чорда социалистик милләтләрнең сан ягыннан артуындагы яки артмавындагы статистик тигезсезлек күренеше генә Советлар Союзы өчен һичнинди куркыныч хәл дә тудыра алмый. Безнең коммунистик омтылышларыбызның, якты өметләребезнең җиңүенә ирешү өчен алга куелган максатлар СССР гражданнарының кайсы милләт кешесе икәнлегенә түгел, ә халкыбызның сыйнфый позициясенә, аның марксистик-ленинчыл идеяләргә ышанганлыгына бәйле. Буржуаз идеологларның бер милләтне башкаларга каршы куярга азаплануы бу фикернең социализм дошманнары тарафыннан уйлап чыгарылганлыгын әллә кайдан күрсәтеп тора. СССРдагы «мөселман» халыкларының саны артуга безнең илдә эчке киңелсезлекләр чыгарырдай зур таяныч итеп карап, шул темага китап арты китап язулары буржуаз «галимнәренең» көчсезлеген, фәннән ерак торуларын гына раслый. Мондый төрдәге «хезмәтләр» арасында татар халкы да телгә бик еш килеп керә. Яңа Орлеан университеты профессоры Э. Лаззерини Америка советологлары чыгара торган «Славик ревью» журналының 1981 елгы бер санында «Советлар Союзында татар гыйлеме һәм «Яңа тарих теркәү». Татарлар белән руслар арасындагы мөнәсәбәтләрнең мәгънәсен ачыклау» исемле язмасында татар гыйлемен «Идел буе татарларының җәмгыятен, культурасын һәм тарихын тикшерү» дип бәяли.

Дөньяда ислам байрагы астында күтәрелеп чыккан политик көчләрнең шактый икәнен, шул ук вакытта СССР халыкларының милли һәм социаль тормышында, буржуаз советологлар «мөселман» дип санаучы кешеләрнең зур роль уйнавын искә алганда, безгә әле киләчәктә дә дошмани уйдырмаларны күп кичерергә туры килер. Шуңа күрә сизгерлекне югалтырга һич ярамый. Киресенчә, без тарихыбызны да, бүгенге чордагы үсешебезне дә һәрьяклап өйрәнергә, фәнни нәтиҗәләр ясарга тиешбез. Буржуаз тарихчылар «СССР мөселманнары» дип атаган халыклар арасында, 1979 елны исәпкә алу мәгълүматлары күрсәтүенчә, татарлар саны 6 миллион 317 меңгә җиткән. Бу мәсьәләләрне чишкәндә, без халкыбызның реаль үсешен анализларга, бары тик социализм гына тудыра алган шартларда ул ирешкән уңышларны ачарга тиешбез.

Алда аңлатылганча, совет җәмгыятендәге һәр яңалык, бигрәк тә милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләр проблемасы буржуаз советологларның игътибар үзәгендә яши. Алар юк кына бер детальне үзләренең яман уйдырмаларын раслауда файдаланудан һич чирканмыйлар. Уйдырмалар исә социалистик җәмгыятьнең кешеләргә китергән бәхетен, совет чынбарлыгын пычратуга юнәлтелгән. Тарихны бозып күрсәтергә азапланучы мондый фальсификаторны фаш итү социализмның капитализмга каршы алып бара торган идея көрәшендә дә, совет җәмгыяте үсешенең хәзерге этабындагы милли процессны марксистик-ленинчыл караштан торып өйрәнүдә дә бик мөһим бурычтан санала.

АЭС
казан утлары
әдәби пост

# Хәйдәр Гайнетдинов

# КЕШЕ КАДЕРЕ



*«Камгэсэнергострой» берләшмәсе йортлар салу комбинатының 12 нче төзү-монтаж идарәсе начальнигы Рәис СӘЛӘХОВ.*

Н. Седов фотосы.

Татарстан атом электр станциясе төзелешендә булып кайтканнан соң, бер танышым миңа шундый сорау бирде:

— Я, ничек анда, планны үтиләрме соң?

— Үтиләр,— дип җавап кайтардым кыска гына итеп. Башкача ничек әйтим соң, чынлап та, Рәис Сәләхов җитәкләгән төзү-монтаж участогы айлык планны үтәп бара. Атом электр станциясе төзүчеләре яшәячәк меңнәрчә кешеләр өчен салына торган шәһәр әкрен генә төзелә. Бер ел эчендә диярлек биш-алты йорт калкытып куйганнар, мунча салып яталар, 1982—83 нче уку елын Кама Аланы авылы балалары өч катлы яңа мәктәптә каршылаганнар. Төзелеш дәвам итә. Һәм әлеге төзелеш башкаларыннан әллә ни аерылмый да диярлек. Әмма аерманы табарга була икән. Бу аерма — башка төзелешләрдә җибәрелгән хаталарны кабатламауда. Юлга җыенганда ук мин нәкъ шул хакта, элекке хаталар кабатланмыймы икән, дип борчылган идем. Мәсәлән, беренчесе (һәм иң зурысы) — төзелешне зурлап игълан итү һәм анда күпләп эшчеләр җыю. Икенчесе — юллар мәсьәләсе...

Танышымнан мин шуңа күрә дә башка сорау көткән идем.

— Эшчеләрнең кәефләре ничегрәк? Торак, ашау-эчү хәл ителгәнме?

Әмма, кызганычка каршы, мондый сорауны сирәк бирәләр шул.

...«Камгэсэнергострой» берләшмәсенең йортлар салу комбинаты янынннан автобус төп-төгәл иртәнге сәгать сигездә кузгалып китә икән. Бу автобус комбинат эшчеләрен Кама Аланы авылына илтеп куя, алып кайта. Автобуста кешеләр юк диярлек. Ниндидер эш кәгазьләре тоткан бер ханым, эш киеменнән бер ир заты, өстен чүпрәк белән каплап куйган чиләкләрнең хуҗасы — бер әби. Бары шулар гына. Автобус Брежневтан Кама Аланына кадәр ике сәгать бара. Димәк, бу машинага утырган эшче сәгать уннарда гына эшкә керешә алыр иде. Димәк, автобус эшчеләрне йөртү өчен генә түгел, ә бәлки комбинат белән Кама Аланына урнашкан СМУны эш мәсьәләсендә тоташтыру өчен күбрәк кирәк...

Автобус, Брежнев каласын артта калдырып, Түбән Кама шәһәренә юл алды. Тәрәзәдән өлгергән иген, кыр чәчәкләре исе бөркелә. Ә кайчандыр, бу тирәдә КамАЗ төзелә башлагач, тирә-як авыл халкы куркып калган иде: җирнең асты өскә киләчәк. Юк, янадан гөлбакчага күмелде борынгы Чулман буйлары.

Түбән Каманы да узып киттек. Тиздән Кама Аланы күренәчәк. Минем күңелдә горурлык артканнан-арта бара. Брежнев каласын, Түбән Кама, Зәй, Әлмәт шәһәрләрен төзүдә минем авылдашлар да — Зәй районының Дүрт Мунча авылы кешеләре дә катнашты. Шуларның берсе — Рәис Сәләхов. Хезмәт юлын КамАЗда башлаган иде.

КамАЗ төзүчеләре арасында беренче кеше буларак СССР Верховный Советы депутаты булды. Совет илендәге зур үзгәрешләрне чагылдырган документлар кабул итүдә катнашты. Инде, ниһаять, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет билгесе» орденнары кавалеры Рәис Сәләхов Татарстан атом электр станциясе төзүчеләре яшәячәк шәһәр салу белән җитәкчелек итә, «Камгэсэнергострой» берләшмәсе йортлар салу комбинатының төзү-монтаж участогы начальнигы ул. Сугыштан соңгы җимереклекләрне күреп үскән егет. Игенче һәм терлекче хезмәте белән дә, эшче хезмәте белән дә бердәй дәрәҗәдә таныш ул, барысының да кыенлыгын үз җилкәсендә татып караган.

Кама Аланына килеп төшү белән, беренче эш итеп, Рәис Сәләховны эзләп табарга булдым. Ләкин ул поселок советы башкарма комитеты утырышында икән. Мин төзелешне тамаша кылырга үйладым. Күз алдымда биш йорт басып тора. Дүртесендә инде кешеләр яши дә башлаганнар, берсе әле тәмамланып бетмәгән. Кама Аланы урынында, димәк, шәһәр калкачак. Авылның тарихы өр-яңа шәһәргә барып тоташачак!

Кама Аланына беренче мәртәбә аяк баскан кеше, мөгаен, А. П. Чеховның «Чия бакчасы» әсәрен хәтеренә төшерер. «Чия бакчасы»нда, әлбәттә, иске дворян утарының бетүе, аның урынында туып килгән капиталистның төпләнүе турында сүз бара. Моны бүгенге авылның социалистик шәһәргә әверелүе белән чагыштырып булмый. Әмма ни өчендер «Чия бакчасы»н уйлап куясың. Мөгаен, Кама Аланында яшәүче халыкның күпләп чия үстерергә яратуы белән бәйледер ул. Әйе, бакчаларга күз салсаң, өлгергән кып-кызыл чияләр күзеңнең явын алырлык. Аннары биредә халык яшелчә үстерергә дә ярата икән. Биек яр астындагы үзәнлектә кәбестә, кыяр, помидор үсә...

Шулай авыл белән, төзелеш белән танышып йөргәндә, Рәис Сәләхов үзе үк каршыга килеп чыкты. Җылы гына күрештек.

— Махсус эзләп йөрсәм, таба да алмаган булыр идем әле,— дидем мин.

— Монда мине каян эзлисең инде?!— диде ул елмаеп.— Кабинетта утырырга вакыт юк. Объектларда эш муеннан: әле бетон измә китермәгәннәр, әле панельләр бетеп китә, ә эшне туктатырга ярамый!

— Өзеклекләр дә булгалыймы?

— Алай ук еш түгел-түгелен. Шулай да...

— Төзелеш материаллары белән сезне Брежнев тәэмин итә икән. Түбән Камага караганда, Брежнев шәһәре ике мәртәбәгә ераграк бит. Ә нигә материалларны Түбән Камадан китертүне җайламаска?..

— Кызык сорау бу. Түбән Кама үзенең материалларын Брежнев шәһәре аша Менделеевскига озата. Ә без Түбән Кама аша монда ташыйбыз. Чынлап та, рольләрне алмаштырга мөмкиндер кебек. Тик бу — материалларның төренә һәм сыйфатына бәйле мәсьәлә.

— Эшчеләрегез дә йөреп эшлиләр икән?

— Юк, хәзер безнең эшчеләр Брежнев шәһәренә туганнары янына кунакка гына кайтып йөри. Мондагы эшчеләрне без торак белән тәэмин итә барабыз.

— Эшчеләр күпме?

— Җитәрлек. Менә бүген тагын Брежневтагы 47 нче училищедан кызлар килергә тиеш. Аларны каршылыйсы бар әле...

Без ары киттек. Әнә, көймәле тәрәзәләр белән ниндидер бина төзеп яталар. Бу бина торак йортлардан бик нык аерыла.

— Монысы нәрсә тагын?

— Бу безнең мунча булачак.

— Фасады сәеррәк?

— Мунчаның проектын Рига шәһәреннән кайтарттык. Үзебезнең милли архитектурага яраклаштырып, проектына беразүзгәрешләр керттек.

Шунда гына мунчаның никадәр кирәкле әйбер булуы күз алдына килеп басты. Менә бу авылда яшәүче гаиләләрнең һәрберсендә диярлек мунча бар.

— Каян башыгызга килде мондый матур идея?

— Соң... кеше бит юынмыйча яши алмый.— Рәис Сәләхов бераз гына уйланып торды да дәвам итте:— Тукайның ничек әле? «Тәнгә — мунча, җангa юк...» Бездә киресенчә: җанга мунча бар. Әнә, теге бинаны без вакытлыча гына клуб итеп оеш-

тырдык. Телисең икән — кинофильмнар кара, кайбер көннәрдә биюләр оештыралар, төрле кызыклы кичәләр, сәнгатькәрләр белән очрашулар була. Инде җанга мунча бар икән, тәнгә дә булырга тиештер, шулай бит?..

Болар һәммәсе дә кеше тормышында аерылгысыз компонентлар: хезмәт һәм ял итү. Ахыр чиктә, бездә бит шәһәрләр салу да кешеләр өчен, кеше кадере артсын өчен эшләнелә. Барысы да кешегә хезмәт итәргә тиеш: урман-сулар да, иген кырлары да, үзебез төзегән завод-фабрикалар да, станокларны, поездларны хәрәкәткә китерә торган электр станцияләре дә. Гомере буе кешеләргә йортлар төзүче Рәис Сәләхов моны бөтен җаны-тәне белән аңлый.

— Авырып киткән идем әле. Врачлар ярты айга эшкә яраксыз дип таптылар. Түзеп буламы соң?! Икенче көнне үк төзелешкә килдем,— диде ул моңсу гына елмаеп.— Эшләгәндә авыру да җиңел уза сыман. Ярый әле эш бар!

Мөмкинлек килеп чыкканда, Рәис Сәләхов туган авылына кайтып килергә тырыша. Ял итәргәдер, дияр кайберәүләр. Әмма безнең авыл халкы Рәисне яратып, ихтирам итеп болай сөйли:

— Тик йөри торган кеше түгел ул. Бөтенләй эш табалмаса, Камил абыйсының койма баганалары төбен төяргә тотына. Кыйшаймасын диптер инде...

Эш ярату — бер хәл, әмма монда Рәис атом электр станциясе кешеләренә яңа шәһәр салу белән җитәкчелек итә. Бу очракта, үзең җиң сызганып эшләү белән бергә, башкаларны да эшләтә белү кирәк. Күп җитәкчеләрне күргәнем бар минем. Кайберләре куркытып җиңә, кайсылары исә кеше күңеленә юл салалар. Рәис Сәләховны соңгылары рәтенә кертер идем. Төзелештә булып кайтканнан соң, моңа тагын бер мәртәбә инандым.

Без аның кабинетында сөйләшеп утырганда, Рәис абыйга кереп әйттеләр:

— Рәис Сәләхович, Брежнев шәһәреннән кызлар килделәр. 47 нче һөнәр училищесыннан.

Без алар янына чыктык. Җитәкчеләре шул арада Рәис абыйның колагына пышылдап алды:

— Бер кызыбыз авырыбрак тора әле.

Кызлар әле автобустан төшмәгән иде. Рәис Сәләхов алар белән училищеда бер мәртәбә очрашкан булган икән инде, ул баскычтан күтәрелеп аларга сәлам бирде:

— Исәнмесез, кызлар! Сез ике ай эчендә тагын да чибәрләнеп киткәнсез. Күреп торам, сезнең эшләргә дәрт бар.— Шуннан иелеп җитәкчеләреннән сорап куйды:— Кайсысы авырый?

— Әнә,— дип күрсәтте җитәкче.

— Авырыйсыңмыни?— диде Рәис Сәләхов.— Бездә авыручылар юк бит.— һәм ул миңа карап елмайды.

Кызлар автобустан чыктылар. Рәис абый алар каршына басты да гади генә сөйләп китте:

— Яңа төзелешкә аяк басуыгыз белән котлыйм сезне! Инде бүгеннән үк эшкә керешик. Сез утыз кыз икәнсез. Әмма утызыгызны да бер бригадага туплау кыенрак булыр. Эшне җиңеләйтү өчен сезгә ике бригадага бүленергә туры килер. Беренче бригада — буяучылар, икенчесе — сылаучылар.

— Мин сылаучы булмыйм,— диде кызларның берсе.— Маляр итмәсәгез, кайтам да китәм.

— Буш кул беләнме?— диде Рәис абый көлеп.— Кич белән урманга чикләвек җыярга барабыз. Ичмасам, чикләвек алып кайтып китәрсең.

Кызлар дәррәү көлеп җибәрделәр. Бу сөйләшү аларның күңелләрен күтәрде. Алар атаклы төзүчене сораулар белән күмеп ташладылар.

— Автобус беләнме?

— Анда чишмә бармы?

— Чикләвек күпме?

Әгәр дә кызларның сорауларына игътибар итмәсәң, яки дорфа җавап бирсәң, юньле нәтиҗә көтмә дә. Рәис Сәләхов аларга иң уңайлы җавапны бирде — сүзсез елмайды гына. һәм шушы елмаю шактый четрекле мәсьәләне хәл итте дә куйды.

— Инде, кызлар,— диде ул,— үз теләгегез белән төгәл ике төркемгә бүленегез. Аннары шобага салабыз. Сезгә — биш минут вакыт.

Без кызлардан читкәрәк китеп тордык. Әйләнеп килүебезгә, кызлар ике бригада булып оешканнар иде инде. Шобага салдылар. Ризасызлык ишетелмәде.

— Үземә дә кызык тоелды әле бу,— диде Рәис абый.— Үз гомеремдә беренче мәртәбә шундый сынау үткәреп карадым.

Әлеге кызларның әти-әниләре яныннан чыгып китүләренә дә күпме генә вакыт узган әле! Арада авыл кызлары да бар. Барысының да үзе яраткан эшне сайлыйсы килә. Әгәр дә дорфа кылансаң, эштән бөтенләй гайрәтләре чигәргә мөмкин. Рәис абый моны белә, кайчандыр үзенең дә, КамАЗ төзелеше башлангач, бәхетле бригадага эләгүен сагынып искә ала. Үткәндәге тәҗрибәләргә таянып, кешеләр белән аңлашуның яңа ысулларын эзли. Һәр яктан да аларга уңайлылык тудырырга тырыша.

Шәһәрнең план-проекты белән танышу ниятеннән, без аның эш кабинетына керәбез.

— Менә, безнең шәһәр шундый булачак инде,— ди ул.— Ничек, сиңа ошыймы?

Дөресен әйтим, борынгы крепостьлары, тар урамнары булмаган шәһәрне бигүк өнәп бетермим мин. Моны Рәис Сәләховтан да яшермәдем.

— Анысын мин дә аңлыйм,— диде ул.— Тик урта гасырлар крепостеның хәзер кемгә кирәге бар?! Әлбәттә, киләчәктә кафе, ресторанннарны, төрле күңел ачу объектларын бергә берләштергән шуңа охшашлы архитектура ансамбльләре төзелер дип уйлыйм мин.

— Авылны сүтәсезме?

— Юк әле, ашыкмыйбыз. Шәһәр хәзергә югарыга таба үсәчәк.

— Ник алай?

— Әнә бит Кама Аланында күпме чия үсә. Чия быел бигрәк тә уңды. Әгәр дә без авылны сүтеп ташласак, эшчеләрне чия вареньесыннан, чия компотыннан мәхрүм итәбез дигән сүз. Әле мондагы бәрәңгене дә, мал-туарны да истә тотарга кирәк. Яшәсен авыл үз көенә генә. Анда күбесенчә өлкән кешеләр тора. Аларның җиләк-җимеш үстерергә вакытлары күп.

Шундый зур төзелеш башлап җибәрелгән икән, димәк, эшчеләр саны да күп булырга тиештер, дип уйлаган идем мин. Шәһәр төзелешендә, ГПТУдан килгән кызларны да кушып, барлыгы 270 ләп кенә кеше эшли икән. Шуңа да карамастан, бирегә эшчеләр җыярга ашыкмыйлар. Ни өчен?

— Беренчедән, торак мәсьәләсе кыенга киләчәк. Торак булмадымы, кешенең кадере югала. Ә безнең иң зур байлыгыбыз — кеше. Кадрларның эшкә сәләтен белмичә торып бригада өстенә бригада оештырсаң, идарә итә алмаслык хәл килеп туачак.

— Шәһәрнең үз урыны бик уңайлы булса да, әнә теге шәрә калкулык ямьсезләп тора,— дидем мин аның фикерен белергә теләп.

— Анда быел яз көне без агачлар утырттык инде. Көз көне тагын утыртачакбыз...

Кама Аланы авылына нигез салучылар ышык урын тапканнар. Камадан кистереп искән җилләр дә кешеләргә зыян китерә алмый. Нигез салучылар, бәхәссез, акыллы булганнар. Әмма, яши башлагач, урманнар артка чигенгән. Кайчандыр агачлар үсеп утырган әлеге калкулык та бер заман шәрәләнеп калган. Ни өчен? Нигә? Монда инде нигез салучылар гаепле түгел.

— Шәһәрне салганда без дә бу тирәдәге табигатьне саклап калырга телибез,— дип сөйли Рәис Сәләхов.— Иң мөһиме — рельефны бозмау, туфракның астын-өскә китермәү. Соңыннан төзәтү кыен ул. Әнә бит, теге тау башында да урман шаулап утырган. Еллар узу белән ул урман юкка чыккан. Хәзер инде бу шәһәрне төзүчеләр ул хатаны төзәтергә тиеш булалар...

Без сөйләшә-сөйләшә автобус тукталышына юнәлдек. Автобусны шактый кеше көтә икән. Ул килүен килде, әмма күпкәнен бөрәү дә белми.

— Рәис Сәләхович, автобус кайчан булыр икән?

Юк, Рәис абый да автобусның кайчан булачагын төгәен генә белми.

— Автобусны комбинаттан чыгарып җибәргәндә, путевкага киту-кайтуына кул куелган була,— диде ул канәгатьсез кыяфәт белән.— Аларның килеп киткәнен мин белми дә калам. Шуңа күрә эшчеләремне ничек озатырга икән дип аптырап йөрим. Бу хакта комбинат начальнигы Марат Шакировичка шалтыратып әйтергә кирәк әле...

Проблемалар, проблемалар... Берсе артыннан икенчесе чыгып кына тора. Ян-

гырдан соң күтәрелгән гөмбәләр кебек. Алар барысы да тиз хәл итүне сорый. Бирсен дә кичектерергә ярамый. Кайсы эшчегә фатирны алданрак бирергә? Кайсын кайчан ялга җибәрергә мөмкин? Эшкә алуларын үтенеп килгән кайсы егетне яки кызны төзелешкә кабул итәргә? Кама Аланы поселок советы башкарма комитеты члены буларак та, төзү-монтаж участогы начальнигы буларак та бу мәсьәләләрне Рәис Сәләхов кайгырта. Әлбәттә, Рәис Сәләховичның Ө. Гайнуллин, А. Сапин, Р. Гыйльметдинов, Х. Гәрәев, Г. Поляков кебек атаклы төзүчеләре — тәҗрибәле бригадирлары бар. Ул һәрвакыт аларга таяна, алар белән киңәшеп эшли.

Көн кичкә авышып килә иде инде. Автобус тукталышында әбиләр чиләк-чиләк чия сатып утыралар. Сәләхов алар янына барып хәлләрен сорашырга да вакыт таба.

— Нихәл, әби! Чиягез күпме әле? Сез аны шимбә көнне күбрәк алып килергә тырышыгыз. Безнең Брежневка кайтып китүче эшчеләр сатып ала аны.

Аннары ул ашханәгә сугыла, пешекчеләр белән әңгәмә корып җибәрә.

— Бүген канәгать булдылармы ашаудан? Иртәгә нәрсәләр әзерлисез? Нинди рәк заказлар бар, үти алырсызмы?

Вәгъдә — иман, кызларга бит ул чикләвеккә барырбыз дип вәгъдә иткән иде. Кызганычка каршы, комбинатка кайтып килергә кирәк: бүген кирпеч китермәделәр. Түбән Кама бетон измәсе китерүне дә тоткарлады... Анда шалтыратырга онытылмасын... Тагын нәрсәләр? Ул янәшәсендә мин барлыкны да искәрми башлады кебек...

— Син гафу ит инде,— диде ул, минем хәлемне аңлап.— Әнә тегендә йорт урының билгеләргә тиешләр иде. Озак чуалдылар. Рәтенә төшенә алмыйлар бугай.

Һәм ул зур-зур атлап үргә менеп китә. Ә аста — авыл үзенчә генә яши бирә: тау битендә бозаулар чемченеп йөри, бакчаларда чия пешә, бәрәңге үсә, помидор-кыяр өлгерә... Анда тиздән, ун-унбиш елдан, шәһәр балкып торачак. Бу шәһәрне минем авылдашым Рәис Сәләхов егет-кызлары сала. Кайчандыр Чаллы элеваторын салганда Германиядән немец инженерларын чакыртканнар икән. Хәзер исә борынгы Болгар бабаларыбыздан мирас булып күчкән төзүче һөнәре — яңадан безнең кулларда.

Рәис Сәләхов яңа шәһәр төзи. Аның һәр сүзе, һәр хәрәкәте шул шәһәрне үстерергә ярдәм итә.

Шәрәф Әхмәдуллин

# МАКСАТКА РЕАЛЬ НИГЕЗ

Бүгенге татар совет прозасы... Ул нинди хәлдә? Аңа бүген ни җитми? Ниһаять, аның үсеш перспективасы нинди?

Беренче сорауга җавап укучыга билгеле. Р. Мостафин сүзләре белән әйткәндә, ул шуннан гыйбарәт: «Татар әдәбиятында реализм үсә, байый, тематик диапазон киңәя, художество осталыгы күтәрелә, чынбарлыктан фәлсәфи мәгънә табу активлаша».

Менә филология фәннәре докторы Т. Галиуллин фикере. «Советская Татария» газетасының 1982 ел 25 июль санында басылган мәкаләсендә ул болай яза: «70—80 еллар башындагы татар совет әдәбияты социаль-этик проблемаларны яктыртуда киң колач алуы белән, психологизмның тирәнәюе белән, нык үскән социализм чоры кешеләре идеалын сурәтләүдә күпкырлылыгы белән аерылып тора. Аңарда эпик киңлеккә омтылыш көчәйде, реалистик стильне куллану артты. Моңа дәлил итеп А. Расихның «Сынау», Ә. Еникинең «Тынычлану», Г. Ахуновның «Идел кызы», А. Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән», М. Мәһдиевнең «Кеше китә, җыры кала» кебек соңгы елларда басылып чыккан уңышлы проза әсәрләрен күрсәтергә мөмкин. «Ниһаять, тагын бер фикер. Язучы А. Расих: «...безнең алга чыккан сәңгеләребез булмаса да, әдәбиятыбыз тере, зур һәм үсә».

Китерелгән фикерләргә таянып татар совет прозасының бүгенге хәле турында гомуми нәтиҗә ясарга мөмкин: проза — тере, проза — зур, проза — үсә.

Әлеге караш чынбарлыкны дөрес чагылдырамы соң? Шөбһәсез. Укучы буларак, без моны үзебез дә күрәбез, тоябыз.

Ләкин ирешелгәннәр белән тынычлану ярамый. Бу — безнең тормыш законы. Ул безнең канга сеңгән, дөньяга карашыбызда тамыр җәйгән. Шуңа күрә дә табигый ки, бүгенге проза турында фикер алышуны башлап җибәргән мәкалә үзенең эсеме белән үк инде талант ияләрен катгый рәвештә искәртә: тынычлану зарарлы!

Бүгенге татар совет прозасына ни җитми? Әхсән Баянов: «Гыйбрәт яки үрнәк булып халык телендә йөрерлек образлар күрәсем килә»,— ди. Дөрес, анда уңай геройлар аз түгел. Ләкин алар арасында халык теленә кереп китәрлек, хезмәт ияләренә үрнәк булырлык зурлары, эреләре күренми. Безгә, Европа биеклегенә күтәрелеп әйтсәк, чорга лаек үз Фаустларыбыз, үз Робин Гудларыбыз кирәк. Партия язучылардан менә шундый калку итеп сурәтләнгән уңай образлар көтә.

Уңай герой иҗат итү — ул комплекслы проблема. Биредә эш бер талантка гына кайтып калмый, бәлки язучының шәхесенә дә бәйле. Мәгълүм ки, Фауст образын иҗат иткән Гете — зур талант иясе булу белән бергә олы шәхес тә. Нәваи, Низами, Сәгъди, Шекспир, Вальтер, Ф. Шиллер, А. Мицкевич, А. Пушкин, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил — болар шулай ук тиңсез талант белән бергә бөек шәхес сыйфатларын да үзләрендә берләштерәләр.

Әйе, ил югарылыгында иҗат итү өчен талантны камилләштерү генә җитми, язу-

чыны шәхес буларак үстерү турында да кайгыртырга кирәк. Бу җәһәттән рус әдәбияты безгә күргәзмәле үрнәк булып тора. Аның күп санлы вәкилләре ил эчендә барган партия, дәүләт, хуҗалык эшләре башкаручылар белән көндәлек аралашып, тәҗрибә һәм фикер алышып кына калмыйлар, аларның элемтәсе төрле чит илләргә дә сузыла, шунда дәвам итә. Шөбһәсез, болай киң аралашу язучы шәхесен баета, үстерә.

Безнең әдәбият вәкилләре өчен ил гизү, төрле сфералардагы кешеләр һәм аларның эшләре белән танышу бигрәк тә зур әһәмияткә ия. Чөнки аларның, Ләбибә Ихсанова сүзләре белән әйтсәк, туксан процентка якыны авыл туфрагын таптап үскән егетләр. Аларга шәхесне баетучы элемтәләрне арттыру — һава кебек кирәк. Шуңа да карамастан язучыларыбызның элемтәләре Татарстан чикләреннән әллә ни ерак китми. Урта кул әсәрләрнең дөньяга килүенә сәбәпләрнең берсе шушы түгелме икән соң?

Тагын нәрсә әдәбиятыбызның үсешенә комачаулый соң?

Шик юк, әсәрләребезнең үзәктә басылып чыгуы, шунда телгә керүе күңелле. Ләкин бу фактны әдәбият камиллегенең төп күрсәткече дип санау, төп бәяләү үлчәвенә әйләндерү — хата. Беренчедән, үзәк матбугатта даими рәвештә басылып килүче барлык авторларны да зур талант иясе дип, бар әсәрләрне дә югары үсеш баскычында тора дип булмый. Ә телгә керү-кермәүгә килсәк, бу фактор әсәрнең сәнгатьчә камиллегенә генә бәйле түгел. Эш болай: күп милләтле совет әдәбиятының барлык күренешләрен сөйләшүдә түкми-чәчми телгә алу белгечтән, тәнкыйтьчедән бик зур өлгерлек, көч, үңганлык сорый. Мәсәлән, безнең тәнкыйтьчебез Ф. Мусин «Правда» газетасында берничә милләт вәкилләре әсәрләренә кагылган ике әйбәт мәкалә бастырды. Ләкин хәзергә әле андый мәкаләләр аз язылалар, чөнки алар бик күп материал үзләштерүне таләп итәләр.

Әдәбиятны алга әйдәү, камилләштерү, яңа биеклеккә күтәрү — олы эш. Бирелә максатка юл бик күп төрле мәсьәләләрне хәл итү аша бара. Һәм шуларның берсе: язучы — укучы, язучы — тормыш элемтәсен ныгыту.

Кызганычка каршы, татар язучылары китапны чыгару белән үз бурычларын үтәлгән дип саныйлар. Ә менә әсәр укучыга барып җитәме, укыламы? Аның кешедә рухи ихтыяҗларны формалаштыруга һәм күтәрүгә ярдәме тиямә? Ул укучының идея-политик, әхлак сыйфатларына йогынты ясыймы? Әлеге сорауларга язучыда ачык җавап булмаганда әдәбиятны яңа биеклеккә күтәрү турында барган сүз үзенең реаль нигезен югалта. Чөнки максатка юл нәкъ менә язучының укучы белән, коммунистик төзелеш белән элемтәсен ныгытудан башлана. Ләкин әдәбиятны яңа биеклеккә күтәрү, юлдагы киртәләрне алып ташлау бер язучылар җилкәсенә генә төшә торган эш түгел. Бу — комплекслы проблема һәм аны хәл итүдә комплекслы чаралар күрү кирәк.

Прозаны яңа биеклеккә күтәрү турында сүз алып барганда безгә иртәгәге көн турында да нык уйларга кирәк. Бүгенге иҗат эшен иртәгә дәвам итәрдәй резерв бармы? Татарстан Язучылар союзы бу өлкәдә зур эш башкарса да, әдәбиятның киләчәген тәэмин итү өчен бу гына җитми. Талант күренсен, ачылсын өчен генә аны иң элек формалаштырырга кирәк. Бу эш исә гаиләдән башланып, балалар бакчасында, аннары мәктәптә дәвам итә. Биредә уңай нәтиҗә бик күп нәрсәгә бәйле. Барыннан да элек, бала гаиләдә, бакчада, мәктәптә телне бик яхшы үзләштерергә тиеш. Чөнки тел — язучының төп коралы. Кызганычка каршы, кайбер ата-аналар баланың тел үзләштерүенә җитәрлек әһәмият бирми.

Дискуссиядә чыгыш ясаучылар «әдәбият эшенең көрәш һәм батырлык» икәнен яшьләргә аңлатырга чакыралар. Әйе, кирәк эш. Ләкин өлкәннәрнең бурычы аңлату гына түгел, алар беренче чиратта үзләре «чын көрәш һәм батырлык» үрнәген күрсәтергә тиеш. Чөнки тормышны аңлату гына аз, аны революцион рухта үзгәртергә дә кирәк, дип өйрәтә безне марксизм-ленинизм...

...Бүгенге татар совет прозасы яңа биеклекләр яулау өчен киңәш тота. Мәсьәләләр күп, мәсьәләләр катлаулы. Аларны дөрес хәл итү — максатка реаль нигез.

Фәния Хөсәенова

# ӘЛЕ ДӘ КҮЗ АЛДЫМДА...

Үзган ел минем кулга «Современник» нәшриятында чыккан «Мәскәү-80» дигән хикәяләр җыентыгы килеп эләккән иде. Кызыксынып, хикәяләрнең барысын да диярлек укып чыктым. Китаптагы 26 хикәядән икесе хәтергә сеңеп калган: берсе инде мәрхүм Федор Абрамовның «Бабилей» исемле, икенчесе Евгений Чернов дигән язучының «А завтра домой» хикәяләре. Беренчесенең кыскача эчтәлеге болай: фермада савучы булып эшләүче хатын үзәнең илле яшьлек юбилеен үткәрә. Гомер буе сыер абзарыннан чыкмаган хатын бүген үзенең бәйрәмендә бөтенләй икенче кешегә әйләнә: уйный, көлә, бии. Төскә-башка да чибәр икән ул, хәтта үзенең кызларыннан да яшьрәк күренә. Бәләкәй генә авыл кешеләре табында әңгәмә корып утыралар. Моң-зарлары да бар икән аларның: авыл көннән-көн кимүгә бара, аны бөтенләй бетерү турында да сүз чыга икән җитәкчеләр авызыннан. Шушы кайгыларын уртаклашырга, шул бәладән котылырга ярдәм итмәсме дип, өмет итеп, алар язучыны да кунакка чакырганнар икән... Ә икенче көнне кайтып китәр алдыннан саубуллашырга дип килсәләр, ни күрсеннәр, кичәге шат йөзле хуҗабикәне алмаштырганнармыни — картайган бер карчык, битен-күзен яулык белән каплап, ашсу хәстәрләп йөри. Ә өстәл артында биш-алты ир утыра (ире һәм уллары!), килеп кергән кешеләргә алар комсыз күзләре белән карыйлар: шешәләре юк микән! Кунакларга тизрәк чыгып китүдән башка чара калмый. Кичә бәйрәмдә кайда булган соң бу ир? Туйганчы эчертеп, исертеп, кунакларны сыйларга, күңел ачарга комачауламасын дип, лапас башына менгереп ташлаган булганнар икән аны. Ә кунаклардан калган эчемлекләрне, әтиләренә калдырмыйча, уллары, кияүләре эчеп бетергәннәр. Шуның үчен чыгарып, йорт хуҗасы хатынының күзен-башын күгәрткән...

«А завтра домой» дигән хикәянең герое моннан биш ел элек институт бетереп киткән шәһәренә килә. Максаты — аспирантурага керү шартлары белән танышу. Аспирантурага ул фән өлкәсендә берәр ачыш ясау, илгә файда итү теләге белән түгел, ә хатыны кушкан өчен керергә тели: балалар үсә, зуррак шәһәргә урнашырга кирәк. Балаларны урнаштыра башласаң, фәнни дәрәҗә дә кирәк булачак... Бу шәһәрдә үзе белән бергә укыган, әле һаман тормышка чыкмаган кыз да яши икән. Бөтен эшләрен бетереп, иртәгә китәргә билет та алып куйгач, бер генә теләк кала: шул кыз белән күңелне ачып булмасмы?!.

Шушы ике хикәя инде елдан артык күңелдән китми. Авторларына ачу килеп йөри: тапканнар язар нәрсә, эчкечеләрне, үзләре өчен генә яшәүче адәм актыкларын сурәтләмәсәләр, яхшы кешеләр беткәнмени, колхозларда намус белән эшләүчеләр юкмыни, җанын-тәнен фәнгә биргән, гомерен илебез куәтен үстерүгә багышлаган кешеләр азмыни бездә?! Авторлар белән менә шулай әрепләшеп йөрдем моңа кадәр. Хәтта «Литературная газета»га язып җибәрергә дә уйлаган идем. «Казан утлары» журналында башланып киткән бүгенге проза проблемаларына багышланган сөйләшү материалларын укый башлагач, шуны аңладым: бу әсәрләр күңелне иң авырттыра торган проблемаларга багышланган икән, өстәвенә, бик оста язылганнар икән, шуңа күрә минем җанны айкап чыгарган, онытылмаслык булып күңелгә кереп утырганнар икән. Балкар шагыйре Кайсын Кулиевның бер мәкаләсен укыгач, бу язучыларга ихтирамым артты. «И снег не бесполезно тает»... дигән мәкаләсендә ул менә нәрсә ди: «...искусство ставит вопросы, поднимает тревогу: «Смотрите, люди, может случиться беда, не опоздайте, примите вовремя меры». Көннән-көн ныграк тамыр җәйгән ямьсез күренеш — эчкечелеккә, үзе өчен генә яшәүчеләрнең көннән-көн күбәюенә йөрәкләре әрнеп, шуңа каршы протест белдергәннәр икән хикәя авторлары.

«Тынычлану зарарлы» дигән мәкаләсен укыгач, Аяз Гыйләҗевны да аңладым мин. Хәзерге тормыштагы битарафлыкка, хуш күңеллелеккә, үз-үзеннән канәгать масаючы-

лыкка каршы чыга ул, кемнәрнеңдер тыныч сазлыгына таш ата. Ә менә Р. Мостафинның позициясе аңлашылып җитми. Ул Аяз Гыйләҗев мәкаләсендәге «тырпаеп торган почмаклар»ны шомартырга тырыша.

«Шулай итеп, тагын кабатлыйм, минемчә, прозабыз ул кадәр үк аяныч хәлдә түгел. Ләкин бәла шунда: безнең әдәбияттагы хәтта иң биек «нәратларыбыз» да совет һәм дөнья әдәбиятының киңрәк фонында караганда еш кына уртачадан узмаган гади агач булып, кайчакта куак кына булып күренә». Гыйләҗев та шул ук фикерне куәтләмимени? Тагын берәр татар язучысы Муса Җәлил биеклегенә күтәрелсә, зыян итәр идемени?!

Бәхәстә тагын бер бик үк килешеп бетмәгән нәрсә күзгә ташлана. Кайберәүләргә ни өчендер Аяз Гыйләҗевның өч язучы әсәрләрен яратып, кат-кат укуы ошамаган. «Нигә сиңа алар гына ошый, нигә мин дә ошамыйм» дип, Аяз Гыйләҗевның авызына суккан кебек тоелды миңа кайберәүләр. Бүтән авторлар ошамый икән, бу бит әле аларны бетереп ташлау түгел. Сугыш чоры һәм аннан соңгы буынны тәрбияләп үстергән язучылар К. Нәҗми, Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, И. Гази, М. Әмир, Г. Гобәй, Ф. Хөсни, Г. Кутуй, Ш. Маннур h. б. (барысын да санап бетереп тә булмыйдыр) турында бармый бит бу мәкаләдә сүз. Бу язучыларны кимсетү, бу чор татар әдәбиятын бәяләмәү дә аңлашылмый мәкаләдән. Бу язучыларның геройлары үз миссияләрен башкарганнар. Галияләр, Нәфисәләр, Мөниръләр, Галимнәр, Артыкбикәләр, Гаязлар, Илсөярләр h. б. h. б. балачаклары һәм үсмер еллары сугыш һәм аннан соңгы чорга туры килгән буынның күңеленә кереп сеңгәннәр инде, аларны аннан йолкып алып булмаячак. Бу әсәрләр дәреслек-хрестоматия битләреннән хәзерге буынны тәрбияләүдә дә зур роль уйныйлар. Сүз бит хәзерге әдәбият, хәзерге проза, чагыштырмача яшь язучылар һәм әдәбиятның киләчәге турында бара.

Әхсән Баяновның поэзиясе бигрәк кызык. «Әдәбиятта җитди тикшерү эшләрен «пик»лар белән мавыгу ыгы-зыгысына кайтарып калдыру — матур шөгыль түгел. Артык мәшәкать...» Бик кызык фәлсәфә бу. «Мин сиңа тимим, син миңа тимә. Минем дөньяга яраклашуыма комачаулама» дип тә өстәргә кирәк иде. Фәнне борын-борыннан «тыныч һава көтүчеләр» түгел, ә бертөрлелеккә, торгынлыкка каршы көрәштә җаннарын да аямаган чаялар алга этәрә түгелме соң?!

Әхсән Баяновка тагын әсәрләрне «талантлы» һәм «урта кул»га бүлү ошамый. Ә ни өчен соң кайбер әсәрләрне укып булмый. Ә кайбер авторларның, тагын нинди әсәрләре бар икән, дип, эзләп алып укыйсың. Бу очракта кем гаепле: укучымы, автормы?

Бәхәстә тагын «укучылар ни өчен Г. Әпсәләмовның әсәрләрен яратып укый икән», дигән аптырау, гаҗәпләнү бар. Әпсәләмов чын тормышны сурәтли бит, җанлы кешеләр турында яза. Аның геройлары тулы канлы, алар шатлана да, кайгыра да, уйлана да, хисләнә дә, ярсый да беләләр (хас тормыштагыча). Ә ничек ирешә икән соң ул моңа? Җавапны мин Ф. Галимуллин мәкаләсеннән таптым. «Репортер өчен ике атна да җитә торгандыр, ә язучыга кешеләрне өйрәнер өчен еллар кирәк. Кеше бит деталь түгел, аның җаны уйнап тора, салават күпере төсләренә кереп, күзләрне дә чагылдыра, кайчак сукырайта да. Кыскасы, кешеләргә озак карарга, аларның күңел нечкәлекләрен анык белергә кирәк».

Әнә ничек күп кирәккән Әпсәләмовка әсәр язар өчен. Ә Әхсән Баяновка роман язар өчен «газеталардан артып калган тәҗрибә» дә җиткән (үз сүзләре).

Бәхәстә катнашкан барлык авторлар да конкрет мисаллар кирәклеге, предметлы сөйләшү турында фикерләр әйтәләр. Тик, гаҗәп, берсе дә уңышсыз әсәрләр турында гомуми төстә әйтеп китүдән узмый (уңышлы әсәрләр турында бераз фикерләр бар, билгеле). Солтан Шәмси үзенең мәкаләсендә: «Соңгы елларда эшче темасына язылган әсәрләрнең сәнгать ягыннан йомшак булуы — әдәбиятка журналистларча килү, аны иллюстрацияләү чарасы итеп кенә карауның бер нәтиҗәсе» дигән фикерне әйтә. Тик нинди әсәрләр кергә соң андыйларга — монысын әйтми.

«Казан утлары» журналында басылган яхшы әсәрләрне укып барырга тырышам. Шундыйлардан, Ә. Еники әсәрләре, М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар», «Ут чәчәге», «Без — кырык беренче ел балалары», Гариф Ахуновның «Хәзинә», «Хуҗалар» романнары, Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы», А. Расихның «Сынау» романы, В. Нуруллинның «Аккан су юлын табар», Г. Бәшировның «Җидегән чишмә»се, Хәниф Хәй-

руллинның «Канатлар талмасын» дигән әсәрләре күңелгә сеңеп, хәтердә калганнар.

Менә күптән түгел генә журналның быелгы дүрт санын кулга алдым. Беренче санда Әхсән Баяновның «Таш китап» романы басылган. Нинди роман икән бу дип, укый башладым. Беренче битләрен укыдым да... журналны читкә алып куярга мәҗбүр булдым. Мәдинә Маликованың «Ак давылда тал бөресе» романын аерыла алмыйча, бөтен дөньямны онытып укып чыктым.

Менә журналның быелгы саннарында ике авторның романы басылган. Берсен укыйсы килми, икенчесеннән аерыла алмыйсың. Ни өчен шулай ул? Тәнкыйтьчеләр аңлата аламы шуны?

Беренче әсәрдәге геройларның язмышы җылытмый да, өшетми дә, яндырмый да, көйдерми дә. Ә икенче әсәрнең геройлары белән бергә яшисең, аларның уйхисләре белән янасың, көясең. Нилектән шулай икән? Әсәрдә чын тормыш сурәтләнгән, һәрхәлдә, автор сине шуңа ышандыра. Ә беренче әсәрдә герой, образ дигән нәрсә бөтенләй ачылмаган, ул юк. Икенче әсәрдә Зәйтүнәнең кичерешләрен автор (М. Маликова) ничек оста сурәтли, ә Зәриянең ни уйлаганын да белмибез. Ул уйлый белми микәнни? Ул гади эшче, ә Зәйтүнә кебек врач түгел, диярләр, бәлки. Профессиясе буенча кем генә булса да, ул бит кеше. Кеше яна, көя, уйлана, хыяллана, ярсый... Зәрия бит профессиясе буенча бизәүче, ни эшли ул, канәгатьмә эшеннән? Бизәүче — үзенә күрә иҗат итүче кеше булырга тиеш бит. Бәлки, ул рухи яктан бик байдыр, Камадан өстенрәктер ул? Ә моны укучы күрми. Каманың Зәриягә биргән характеристикасы: «ПТУ бетергән кыз», хатынын яклаучы ирнең сүзе: «Ни сөйлисең, ул бит минем законлы хатыным». Акыл хезмәте белән физик хезмәтнең тигезләнүе чорында эшче кызга бирелгән характеристика шулай булырга тиешмә? Шул герой замана герое була аламы?

Фәез белән Кама арасындагы мәхәббәт тә ышандырмый. Имеш, бер төнне бергә уздырганнар да, гомергә бер-берсен яратканнар. Каманың хыялы — шул төнне тагын бер мәртәбә кабатлау. Бу — мәхәббәтмени, бу бит — җенси азгынлык. Азгын хатынның ирләрне аздыру процессын да кешене ышандырырлык, нәфрәтләнерлек итеп яза белгән бит Мәдинә Маликова.

Бу әсәр производство темасына багышланган, интеллигенция тормышына түгел, дип әйтер, бәлки, автор. Ә бит Г. Ахуновның «Хәзинә», «Хуҗалар» романнары нефтьчеләр тормышына багышланган, нефть промыселларындагы эш процессы да, шәһәр төзү дә, электростанция салу да сурәтләнә. Ул романнарда тулы канлы тормыш бар. Ә Арслан, Мөнәвәрә, Сәгыйдә арасындагы мөнәсәбәтләр! Алар шулкадәр тормышчан итеп бирелгән, ышанмыйча мөмкин түгел. Бу язмышларга битараф калып булмый, ул геройлар күңелгә кереп урнашалар.

Замана герое — рухи яктан бай, югары максатка омтылучы, кешелекле, гадел булырга тиештер ул, минемчә. Әдәбиятны җыен чуп-чар образ белән тутыру дөрес микән?

Соңгы вакытта әсәрләрдә интим мөнәсәбәтләрне тәмләп-тәмләп сурәтләү киң таралды. Роман булгач, шуннан башка ярамый, диләр микән? Әсәрнең тәрбияви әһәмияте турында уйлау да юк. Бу мәсьәләдә Ләбибә Ихсанованың фикерләрен хуплыйм. Сугыштан соңгы әдәбиятта йөрәкләрне тетрәтерлек мәхәббәтләр сурәтләнә иде бит, бозыклык юк иде, сурәтләнгән очракта да, шуңа карата нәфрәт тойгысы уятырлык итеп сурәтләнә иде. Безнең буынны: «Өйләнешкәнче егетләр белән яту — мәхәббәт түгел, бозыклык, әшәкелек»,— дип өйрәтәләр иде. Ә хәзерге кайбер әсәрләрдә бозыклык сурәтләнә. Моның белән язучылар яшьләрдә җенси азгынлык пропагандаламыйлар микән? Яшь буынны җенси тәрбияләү турында газета-журнал битләрендә күп сөйлибез, ә чынбарлыкта, укытучыларга, әдәбиятчыларга ярдәмгә килердәй әсәрләр бик сирәк бит. Шундый әсәрләр дә була, укучыларга тәкъдим итәргә чирканасың. «Укымасалар ярар иде» дип уйлыйсың.

Яшьләрдә сафлык тәрбияләүче, тормыштагы бозыклыкка каршы торырлык итеп тәрбияләүче әсәрләр күбрәк булсын иде. Аяз Гыйләҗевның «Кызлар хатлары» кебегрәк гыйбрәт, сабак бирүче әсәрләр (бу әсәрне мин 1972 елдан бирле ел саен 7—8 нче класс укучыларына биреп укытам, туздырып бетерделәр инде китабымны, малайлар да урлап алып укыйлар икән).

Мин, укытучы буларак, яшьләргә тәрбия бирүче әсәрләр ягында. Укытучыларның

тәрбиячеләрнең ярдәмчеләре булырлык әсәрләр күбрәк булсын иде. Нәфислеккә, матурлыкка, рухи байлыкка омтылдыручы әсәрләр басылсын иде!

Бер яза башлагач, күңелгә ошаган тагын бер язучының әсәрләре турында әйтми булдыра алмадым. Ул — Хәсән Сарьян әсәрләре, бигрәк тә «Бер ананың биш улы» әсәре турында.

Мин шуңа гаҗәпләндем: журналда басылган ун мәкаләнең авторларыннан бары тик Фәиз Зөлкарнәев кенә Сарьян исемен, аның «Бер ананың биш улы» әсәрен телгә ала. Сарьянның «Әткәм һөнәре» повесте һәм «Идел егете» җыентыгына кергән башка хикәя, повестьлары һәрберсе үзе бер тарих, һәрберсе йотлыгып укыла торган әсәрләр бит. Аның геройлары — заман геройлары түгелмени?

Ә ана образы! Улы Сиринның: «Әни, бу хәлләргә син ничек түзәсең?» дигән әрнүле сүзләренә каршы ул: «Мин дә түзмәсәм, бөгелеп төшсәм, бу балаларымның балаларын кем аякка бастырыр!» — дип җавап бирә.

Дәһшәтле сугыш елларының бөтен авырлыгын үз иңнәренә йөкләгән, сугыштан соңгы авыр елларда илне һәм балаларын аякка бастырган, киләчәктә матур тормыш туасына өметен өзмәгән, шуңа балаларын ышандырган Ана образы ул! Ул бөтен кайгы-хәсрәтләрен җиңәр, оныкларын да аякка бастырыр, туган илгә турылыклы кешеләр итеп тәрбияләр. Укучы моңа чын күңелдән ышана.

Бу әсәрне мин моннан өч-дүрт ел элек, журналда басылып чыккач укыган идем, ә геройлар, әле генә укыган кебек, күз алдымда торалар.

Менә шундый, татар укучыларының күңелен тетрәндерерлек әсәрләр, бөтенсоюз укучысының да күңеленә хуш килмәс иде микән? Бик күп авторлар әйткәнчә, бөтенсоюз укучысына лаеклы әсәрләрне генә тәкъдим итәргә кирәк. Вак-төяк әсәр белән нигә татар әдәбиятының данын сатарга!?

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

**Сорау:**

— Поэзия тәнкыйтенә сезнең нинди таләпләрегез бар?

**Зөлфәт:**

— Шигъриятнең техникасы үсте дип әйтергә яратабыз, хәтта шуның белән мактанабыз да. Әйе, ул чыннан да соклангыч дәрәҗәдә үсте. Ләкин, уйлап карыйк әле... Шома рифмалар табу, ритмны тиешенчә саклау гына шигъри фикер йөртү осталыгын чагылдыра ала микән соң?.. Әлбәттә, шигырьнең тышкы калыбына яраштырып төрле рәвешләрдә кәгазьгә төшерелгән бу язмаларның поэзия белән һич кенә дә уртаклыгы юк. Алайса каян килә соң дөньяга шундый көяз, ләкин рухи яктан буш язмалар?

Монда инде сорау туа: «Тәнкыйть ни карый соң?»

Үткәннән бер мисал китерик: Пушкин хакында Белинский язганнарны уку — Пушкинның үзен уку кебек үк кызык. Ул чорларда тәнкыйтьче фикереннән соң шагыйрьнең серен эзләргә керешкәннәр. Ә киресенчә түгел. Дөресен генә әйткәндә, бигайбә, бүгенге көндә шигърият турындагы чыгышларның иң кызыклары шагыйрьләр каләменнән чыга... Безнең поэзия тәнкыйтьчеләренә вакыйга булган шигъри әсәрләр турында вакыйга булырдай тәнкыйть әсәрләре язарга вакыт җитте.

библиография

# ҖИРГӘ БЕР СҮЗ

Поэзиягә 60 нчы елларда килеп кергән Рөстәм Мингалим исеме укучыларга күптән таныш. Аны хәзер «коеп куйган» шагыйрь дип кенә атау да дөрес булмас. Р. Мингалим исеме Мәскәү, Казан, Әлмәт театрларының афишаларында урын алды. Аның халык иҗаты мотивларына таянып язылган, яшәешнең, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең катлаулы, четрекле якларын үзенчә яңгырата алган пьесалары сәхнәгә менде. Р. Мингалим балалар дөньясына да юл тапты. Табигать күренешләрен, хайваннар тормышын мөлаем юмор, шаянлык, фикер һәм сүз уйнату аша тасвирлап шагыйрь яшь дусларын олы дөньяны танырга, аңларга өйрәтә, аларга коммунистик әхлак кагыйдәләрен сеңдерә... Кыскасы, язучы иҗатының бу канатлары да игътибарга һәм өйрәнүгә лаек. Әмма биредә сүз шагыйрь Р. Мингалим турында. Форсат та җайлы: ниһаять, аның иҗат юлын мәгълүм бер тулылыкта күз алдына бастырырлык, сүзне аны исәптән алып барырлык «Шигырьләр, поэмалар» җыентыгы дөнья күрде[1].

1965 елда иҗат ителгән «Җиргә бер сүз» шигырендә Р. Мингалим болай дип язган иде:

*Кадер-хөрмәт күрсәталам диеп,*
*Кызыктырма минем күңелне.*
*Каберлекләр күрсәталам диеп,*
*Бозып торма минем күңелне.*
*Каберлекләр белән кадер-хөрмәт*
*Арасында эшем бар әле.*
*Кадер өчен мин кечкенә булсам,*
*Кабер минем өчен тар әле.*

Үзен тудырган, үстергән җиргә, туган туфрагына дустанә эндәшеп, шагыйрь дөньяда яшәүнең мәгънәсе турында, җирдә үз эзеңне калдырырга кирәклек хакында уйлана.

*Алкын сулар күргәнем күп булды,*
*Уйларым да алкын бит шуңа.*
*Алкын уйларыма таба йөзеп,*
*Күпме еллар килер каршыма?—*

«Алкын су» шигыреннән алынган өзектән күренгәнчә, Р. Мингалим поэзиясенең төп герое — катлаулы кичерешләре, хыяллары, тормыш һәм яшәеш турында уйланулары белән бергә шагыйрь үзе. Күпчелек әсәрләрендә аның шәхси биографиясе мотивлары, холкы ачыла. «Чын яшемнән мин яшь күренәмдер — Җитди генә сәбәп бар моңа» («Сәбәп»), «Сәер генә еллар була, юллар була. Үзем дә мин әллә нинди сәер бәндә» («Нәрсә гаҗәп?»), («Рәхәтләнеп көлеп яшәгәндә Күкрәгемне авыр уй баса...» («Ул шулайдыр әле, уйласаң...»), «Бу дөньяда кайгырдым да, Шатландым да, елмайдым да. Дөресен әйтим, ни күрсәң дә Яшәү рәхәт, рәхәт монда» («Ни күрсәң дә»). Һәм табигый буларак, Р. Мингалим илһамланып туган ягы кырлары, Камышлы, бала чагы, авыр сугыш еллары, чордашлары, малаен сөяргә өлгерә алмыйча, «укылмыйча югалган кыйммәтле хат төсле», «хәбәрсез югалган әтисе», дөнья мәшәкатьләрен җилкәсенә алып вакытыннан элек картайган әнисе турында яза («Әткәйгә», «Сәбәп»).

Сугыш чорының бер елы, бер көне генә дә бик күп әсәрләр өчен материал бирә ала.

*Ире дә югалган аның,*
*Уллары да югалган.*
*Аларны эзләр өчен тик*
*Зур-зур күзләре калган.*

Яшьлеген, матурлыгын сугыш алып киткән карчыкның җанлы портретын тудырып кына чикләнми автор, шуннан фәлсәфи нәтиҗә килеп чыга. Чөнки шигырьнең эчке логикасы, драматик пружинасы шуны таләп итә:

*Бара ул, ялгыз көймәдәй,*
*Бара ефыкны куып.*
*Күзләреннән шаулап тула*
*Көймәгә вакыт суы.*

Табигать, турыдан-туры табигать тормышына багышланган шигырьләре күп түгел Р. Мингалимнең. Ләкин бер шигырендә дә

[1] Рөстәм Мингалим. Шигырьләр, поэмалар. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1983

диярлек ул аны читләтеп үтми. Кеше күңеленә, кеше йөрәгенә, үз кичерешләренә иң туры юлның табигать образлары аша икәнен шагыйрь яхшы аңлый:

*Ул каеннар күккә ишарәләп*
*Җир туганнан бирле тора бугай:*
*Шуның өчен генә бөтен дөнья —*
*Йортын өскә таба кора бугай.*

Кыш, кар турында шулай матур итеп, яратып язган шагыйрь татар поэзиясендә күп түгел. Кыш аңа ак төсе белән ошый. Ә ул төс шагыйрьнең күңел түрендә утыра, илһамына якын тора. Сурәтне кат-кат, төрле тезмәләрдә кабатлаудан тартынып тормавы да шул хакта сөйли:

*Илкәемнең ак кырында*
*Ак юллар салып уздым.*

Р. Мингалим шигъриятен берничә сүз белән генә аңлатуы кыен. Ул — риторикага, ясалма купшылыкка каршы, публицистик шигырьләр язуны да артык кулай күрми, аның ритмикасы җыр өчен дә бик килешеп тормый. Р. Мингалим шигырьне, тормышның үзе шикелле, табигый яшәтергә омтыла. Бизәкләрне сайлап, нечкә иләк аша уздырып, эчтәлек агышына буйсындыра белә.

*Мин гаҗәп төн булыр идем*
*бер генә тапкыр.*
*Кешелекне*
*үзем аша*
*уздырыр идем*
*бер генә тапкыр.*
*...Бер генә тапкыр...*
*Ләкин шушы гаҗәп төннән*
*Чыгармас идем*
*бозык уйлы кешеләрнең*
*берсен дә,—*
*Таңның ал капкасы аша*
*Яңа якты көнгә*
*Керерләр иде*
*Чиста уйлы кешеләр генә...*

Шагыйрь табигый нәфислек, табигать яме белән кеше акылы, кеше зиһене, кеше иҗаты тудырган төшенчәләр арасында якынлык эзли, яшәеш проблемаларын төрле образлы рәтләр, бер-берсенә охшамаган борылышлар, төсләр, нәкышләр белән сурәтләү юлын эзли. Бу сыйфат Р. Мингалимнең КамАЗ төзүчеләргә багышланган «Күз карасы» поэмасы, «Казан аэропортында», «Минем яшьлек», «Нәкъ унбиш ел үткәч», «Якташлар янынннан...», «Шпаллар», «Килә тезелеп машиналар» кебек шигырьләрендә ачык күренә.

Шулай да, Р. Мингалим язарына азыкны төзелешләр темпыннан һәм хәзерге чынбарлыктан чумырып алса да, төп игътибарын лиризм, моң ярдәмендә кеше кичерешләрен ачуга юнәлтә. Бу сыйфаты аның поэмаларына да хас. Поэмаларның саннары күп түгел. Нибары дүртәү: «Иртәгә», «Минем дәүләт», «Күз карасы», «Күк астында». Аларда шагыйрьнең лирикада алып барган эзләнүләренә нәтиҗә, йомгак ясала.

Коры хикәяләү, вакыйганы энәсеннән җебенә чаклы түкми-чәчми сөйләп бирү алымыннан баш тартып, шагыйрь динамика һәм сурәтлелек, метафора һәм аллегория аша рухи дөньяга юл ала. Замандашының фәлсәфи-әхлакый эзләнүләре, сагышлары, табышлары, киләчәккә омтылган хыяллары турында уйлана.

«Иртәгә» (беренче варианты «Юл өстендә тургай») поэмасының төп иҗат принцибы — конкрет тормыш, көнкүреш вакыйгалары аша гомумиләштерү юлына чыгу. Үзәктә шагыйрь образы. Башка хәлләр, детальләр аңа тартыла, аның туган җире, Татарстаны, шәхес һәм кешелек язмышы турында уйланулары ачыла. Заманны шагыйрь үзенчә күрә белә.

Табигать күрке, матурлык символы — тургай җыры, тургай моңы турындагы сөйләм чорыбызның шатлыклары һәм каршылыклары турында уйлануларга алып чыга.

*Кынысында кылычы бар*
*Ир тартыла тургайга,*
*Тартылмаска уйлап торган*
*Ил тартыла тургайга.*
*Уйламагыз тартылмый дип,—*
*Җир тартыла тургайга.*

Поэманың нигез фикере Вакыт агышы турында уйлану белән бәйле. Аның тизлегенә иярә алмаучылар да бар икән. Берәүләр «Канатсыз кош булып утырып кала, Ятып кала башсыз яу булып...», икенчеләр «Ак күбеккә баткан ат кебек...» төшеп кала. Шул күзәтүләр җитди нәтиҗәгә алып чыга:

*...Ниләр кала шулай, кемнәр кала?*
*Көйләр кала микән, илләрме?*
*Мөмкин түгел җиңел генә бару*
*Дөнья тизлегенә ияреп.*
*Бүген алган тизлек бүген ярый,—*
*Яңа тизлек кирәк иртәгә.*

Шагыйрь «Минем дәүләт», «Күз карасы» поэмаларында да туган иленең тарихи үткәнен, бүгенге олы адымнарын дәртләнеп җырлый, аның башкалар күрмәгән матурлыкларын табу һәм сурәтләү рухы белән яши.

Р. Мингалимнәр буыны фәлсәфи лириканы үстерүгә, тарих — заман — вакыт кебек төшенчәләрнең эчтәлегенә, фәлсәфи мәгънәсенә үтеп керүгә зур көч куя.

*Тиләләр*
*Йөри шаулашып*
*бер якында,*
*бер еракта.*
*Сүгәләр алар Вакытны,*
*Йодрык селкеп,*
*туктап-туктап.*
*Вакыт — мәшгуль,*
*Сүгенүләрне тыңлый алмый.*

Вакыт — объектив чынлык кына түгел, ул гаять гадел категория дә икән:

*Илтә Вакыт—*
*Түзәр булсаң,*
*йолдызларга*
*гомерең илтә.*

Ләкин вакыт, заман — мәңгелек һәм изге төшенчәләр. Алар белән шаярып булмый. Әмма кайчак шагыйрьнең игътибары кимеп китә. Менә шуңа бер мисал: «Әйтерсең вакыт — аучы» шигыре кискен драматик нотада башлана: «Вакытның бер күзе — Кояш, ә икенче күзе — Ай». Димәк, кеше галәмнең ике күзәтчесеннән, аучысыннан берничек тә качып котыла алмый. Вакытның кулында «өр-яңа мылтык», чакмага басты исә, кемдер егылыр. Дөрес, бу трагик нота шактый кискен ноктада өзелә, дөресрәге, шагыйрь аңа башка юнәлеш бирә: «Мин куркаклар нервысында юри бераз уйнадым».

Әлбәттә, кызык, оригиналь бетем. Ләкин шигырьнең гомуми төзелеше, олы төшенчәсе югала, җитди драматизм бутафория чүбенә урала. Бу сюжет җитдирәк нәтиҗәгә лаеклы диясе килә. «Иллә мәгәр» шигыренең дә дидактикасы, әхлакый сентенциясе ясалма тоела.

*Башың җитмәсә — уйлама,*
*Башың җитсә — уйла.*
*Көчең җитмәсә — уйлама,*
*Көчең җитсә — уйна.*

Дөньяда мәхәббәт хисләре турында язмый калган шагыйрь юктыр. Р. Мингалимнең интим лирикасы тормыш драматизмына сизгерлеге, киң күңеллеге белән аерылып тора. Лирик героеның тойгылары кешене күтәрә, сафландыра, тормыш мәшәкатьләрендә, дөнья ваклыкларында югалып калмаска, дөреслеккә таянырга, кеше кичерешләренең муллыгына ышанырга өйрәтә.

*Су сипсәм дә, якын үсте,*
*Үсте гел кызыл чәчәк.*
*Синең юллар минем янга*
*Киләчәк ул, киләчәк.*

Р. Мингалим мәхәббәт турында нпле һәм матур итеп, шигъри суратка натуралистик ваклыкларны кертмичә, үз януын синең януыңа күчереп яза белә.

*Сиңа авыр сүзләр сөйләмәдем —*
*Миннән күрмә күңелең тулуын.*
*Газаплыйдыр сине көннәреңнең*
*Бер-берсенә охшаш булуы.*

Р. Мингалим иҗатында 60 нчы елларда татар поэзиясенә килгән буынга хас үзенчәлекләр ачык чагылыш таба. Остазларга яңача мөнәсәбәт. Фикерләү киңлеге. Динамизм.

Рөстәм Мингалим метафорага, җегәрле, пластик детальгә өстенлек бирә. Иркен, ирекле форманы үстерә, вакыты-вакыты белән аның шигъре прозага барып тоташа, тезмә белән чәчмә арасындагы чик югала.

*Саклаплык, горурланырлык,*
*Кызыгырлык иде, диде.*
*Кирәк иде, безнең өчен*
*Бер горурлык иде, диде.*
*Югалды, югалды, диде...*
*«Нәрсә, нәрсә?» — дип сорыйлар.*

*Ни өчен соң бу кешеләр*
*«Кем?» — диярга ашыкмыйлар?*

Тулысынча китерелгән бу шигырьнең рифмасы да урынында, хыял уены, антитеза да композицияне бизи. Ләкин биредә шагыйрь өчен иң мөһиме — фикер, күңелен борчыган, әрнеткән уз уен әйтеп калу. Биредә аны бизәкләү чаралары борчымый диярлек. Ә бу инде табигыйлек дигән сүз.

Р. Мингалим хикмәтле сүз, мәкаль, әйтем, дидактик фикерләү традицияләренә киң таяна. Ачык төгәл тесләрне, катлаулы фикер борылышларын ярата.

*Торган җирең яхшы булу белән,*
*Туган җирне онытып буламы.*

*«Узган гомер*
*Искән җил» дип*
*Әйтәсе килми әле.*

Р. Мингалимнең шигъри дөньясы тормышның үзе кебек бай, шәхес кичерешләре кебек катлаулы. Ул үзенең хыял-уйларын, йөрәк серләрен, әхлакый нәтиҗәләрен тиз генә, гади генә ачып сала торган шагыйрь түгел, чөнки бу шигъри дөнья күп еллар буена аерым сүзләр, образлар, җөмләләр ярдәмендә төзелгән. Ә алар артында еллар чалымы һәм реаль шәхес тора. Бу шәхеснең рухи дөньясын аңлауга шактый кыйммәт бәя — чирек гасырга якын вакыт түләнгән. Иң шатлыклысы шул: Р. Мингалим поэзиясе бу олы хакка лаеклы. Еллар заяга үтмәгән. Алар халык күңеленә үтү юлларын эзләүгә багышланган.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН.**

*Риза Фәхретдиневнең туууына 125 ел*

**Миркасыйм Госманов,**
тарих фәннәре докторы

# КАТЛАУЛЫ ЧОРНЫҢ КАРШЫЛЫКЛЫ ВӘКИЛЕ

I

Унтугызынчы гасырның ахыры, егерменче йөзнең башы социаль-иҗтимагый каршылыкларның гаять кискенләшүе белән аерылып тора. Агония кичерә башлаган Россиядә төп ике каршылык хөкем сөрә иде: дәүләт белән изелгән халык арасында һәм хезмәт белән капитал арасында. В. И. Ленин бу чордагы ситуацияне аңлатып болай язган иде: «Хәзер Россиядә революциянең эчтәлеген ике көрәшүче көч түгел, бәлки ике төрле һәм бер-берсенә үзгә булган ике социаль сугыш тәшкил итә: берсе хәзерге самодержавие-крепостнойлык строе эчендәге сугыш, икенчесе күз алдыбызда инде туып килә торган, булачак буржуаз-демократик строй эчендәге сугыш. Берсе азатлык өчен (буржуаз җәмгыять азатлыгы өчен), демократия өчен, ягъни халык самодержавиесе өчен бөтенхалык көрәше, икенчесе — җәмгыятьне социалистик нигездә төзү өчен пролетариатның буржуазиягә каршы сыйнфый көрәше» [1].



1905 елгы революция — элгәрге «гаделлек өчен» барган легаль-юаш чыгышлардан, матбугат һәм китап битендәге бәхәсләшүләрдән, коралсыз демонстрацияләр оештырып, дәүләт җитәкчеләренә мөрәҗәгать итүләрдән, шул рәвешчә аерым ташламаларга ирешүләрдән, ягъни гомум формадагы абстракт-демократик көрәшләрдән үзгә буларак — аренага коралны пролетариатның сугышчы һәм оештыручы рәвешендә чыгуы белән аерылып тора. Ләкин, әле генә әйтелгәнчә, Бишенче елгы революция «ике сугышның» бер вакытта, бер мәйданда узуы, үрелеп үсүе, бер-берсен көчәйтүе, шул ук вакытта үзара бәрелешкә керүе белән дә характерлана иде.

Татарлар арасында бу каршылык аерата көчле чагылды. Чөнки әлеге гомум демократик һәм сыйнфый көрәшкә 1905 елдан соң яңа көч белән дөрләп кабынып киткән милли-азатлык хәрәкәте дә өстәлде, шул рәвешчә көрәш шартларында яңа мәсьәләләр туды, яңа фронтлар ачылды. Милли көрәш белән сыйнфый көрәш Россия кебек күпмилләтле дәүләттә актив хезмәт-

[1] Ленин В. И. Әсәрләр, 9 том, 304—305 бб. (татар телендә).

тәшлек тә итә, кискен конфликтка да керә иде: сыйнфый көрәш башында торган марксистик партия милләтләрнең азатлыкка булган хокукларын тулысынча таный, ә милли хәрәкәткә җитәкчелек итүчеләрнең зур бер төркеме хезмәт ияләренең социаль тигезлеккә булган дәгъваларын кире кага. Мондый хәл исә объектив сәбәпләр аркасында милли хәрәкәтнең башында эре буржуазиянең торуыннан килеп чыккан иде. Ул исә азатлык дип иң элек үзенә кирәкле булган базар азатлыгын гына таный, шул яссылыкта гына үзенең иҗтимагый позициясен, политик стратегиясен билгели.

Метрополиядән сөрелгән, провинциядә кысрыкланган татар буржуазиясе кыска гомер эчендә катлаулы эволюция кичерде. Бер яктан, ул татар тормышында, башка буржуаз милләтләргә караганда, ныграк сакланган феодаль мөнәсәбәтләргә, иҗтимагый тормыштагы туң догматизмга каршы актив көрәште; икенче яктан, базар өчен барган ярышта олуг дәүләтчелек сәясәтен йөрткән рус буржуазиясе белән кискен конфликтка кереп, халык массаларын үз юнәлешенә тартты; өченче яктан исә, әле генә тарткалашкан рус буржуазиясе белән берләшеп, хезмәт ияләренең сыйнфый хәрәкәтләрен бастырды. Шул ук вакытта буржуазия сыйныфы үзенең яшь энергиясе, мәгълүм дәрәҗәдә тарихи революционлыгы белән тормышка, экономикага, культурага һәм фән-техникага күп прогрессив үзгәрешләр, яңалыклар алып килде. Бу аның тарихи миссиясе иде. В. И. Ленин махсус күрсәткәнчә, хезмәт ияләренең азатлык перспективасы өчен капиталистик мөнәсәбәтләрнең тизрәк үсүе, киңрәк колач җәюе файдалы, хәтта зарур иде [1].

Бер яктан үзенең милли изүчеләре, икенче тарафтан колониаль җәбер астында йончылган татар хезмәт ияләре өчен капитализм үсеше тагы да зарурырак иде.

Татар буржуазиясенең иң актив чоры шушы гомум ил күләмендәге катлаулы дәвергә туры килгәнлектән, ул кайбер оештыру мәсьәләләрендә шактый уңышларга да иреште, чөнки политик спекуляция өчен мөмкинлекләр күп табылды. Чорның, андагы көрәш хәрәкәтләренең шаһиты булган, иҗтимагый көрәшкә үзе дә актив катнашкан Галимҗан Ибраһимов сүзләре белән әйткәндә, «татар буржуазиясе халыкның зур бер өлеше алдында үзен бер сыйныф булудан бигрәк, милләт кайгыртучы, милли, дини хәҗәтләр артыннан йөрүче, шуның өчен көрәшүче итеп күрсәтә алды» [2].

Г. Ибраһимовның бу кызыклы, тарихи дөрес күзәтүенә шуны гына өстәргә мөмкин: билгеле бер дәвердә халыкны үзенчә оештырып, кайбер мәсьәләләрдә лидерлык функциясен үтәгән татар буржуазиясе хезмәт ияләренең бер өлешенең сыйнфый аңына томан салуда да шактый казанышларга ирешә алган иде. Халык составында крестьяннарның тоткан урыны чагыштырмача күпкә зур булган татар чынбарлыгында буржуаз иллюзияләргә аерата бәрәкәтле җирлек туган иде. Бу хәлләр исә татар буржуазиясе прогрессивлыгының тарихи чикләнгәнлеген дә, аның объектив сәбәпләр аркасында бик тиз реакционлашуын да тәэмин итте. Образлы итеп әйткәндә, татар буржуазиясе әле кичә генә, искелектән нәфрәтләнеп, мескен бүреген йолкып аткан, кырган башына цилиндр кигән булса, бүген хезмәт ияләренең картуз кия-кия «баудан ычкынуыннан», ягъни шул рәвешчә милли йомыклыктан чыгып, башка милләт эшче-крестьяннары белән якынаюыннан куркып, яңадан мескен бүреген мактарга һәм аны пропагандаларга тотынган иде.

Бу гомум мәсьәләләргә киң тукталуның сәбәбе шунда ки, бары тик чор һәм мохитның катлаулылыгын истә тотканда гына без Риза Фәхретдинев кебек бай мираслы, гаҗәп каршылыклы каләм ияләренең тарихыбызда тоткан урынын фәнни гадел билгели алачакбыз. Чөнки Р. Фәхретдинев, кайберәүләр моңарчы уйлаганча, ишек-тәрәзәсе бикле кабинет галиме дә, дөньявилыктан кул селтәгән мәҗнүн рухани да түгел иде. Аның эшчәнлегендә XIX йөзнең икенче яртысы, XX гасырның башындагы каршылыклы татар дөньясының — интенсив буржуаз-капиталистик үсү стадиясенә күчсә дә, феодаль патриархальлектән арынып бетмәгән, тулаем алганда халыкның күпчелеген изелгән, караңгылыкта йончылган крестьяннар массасы тәшкил иткән шактый спецификалы татар чынбарлыгының тирән

[1] Ленин В. И. Демократик революциядә социал-демократиянең ике тактикасы. Казан, 1952, 36 б.

[2] Ибраһимов Г. «Урал» һәм «уралчылар». Казан, 1927, 15—16 бб.

каршылыгы чагыла. Безнең алда ихлас күңелле, изге ниятле гуманист әдип, зирәк акыллы галим, чын белем эстәүче; шул ук вакытта киң дөньяга карашы шактый тар, хәтта ялгыш, кичәгенең сыйфаты белән бүгенге һәм иртәгәге прогресска ышанган наив фикер иясе, идеалист-метафизик. Бер яктан һәр яңалыкка, мәдәни, рухи тормыштагы һәр казанышка сөенгән объектив тарихчы; икенче яктан иҗтимагый чынбарлыктагы чын яңалыкларны күрмәгән, күрә алмаган, күрергә теләмәгән «сәер кеше»... Кыскасы, бер шәхестә укмашып үрелгән каршылыклар — драманы да, трагедияне дә, комедия белән фарсны да бергә кушып каткан төеннәр...

## II

Ризаэтдин Фәхретдинев 1859 елның 4 январенда (яңа стиль белән 17) элекке Самар губернасының Бөгелмә өязенә караган Кичүчат авылында Фәхретдин Сәйфетдин угылы дигән рухани гаиләсендә дөньяга килә (бу авыл хәзер Татарстанның Әлмәт районына керә). Әнкәсе Мәһүбә шул ук Бөгелмә өязе Иске Иштирәк авылының (хәзер Сарман районында) имамы Рәмкол Максуд улының кызы була. Бәләкәй Ризага иң беренче сабак бирүче, аны хәрефкә өйрәтүче әнкәсе Мәһүбә абыстай була. Моннан соң ул дәресләрне үз әтисеннән ала: җиде-сигез яшьлек чакта ук атасы аны башка авыллардагы зуррак мәдрәсәләргә җибәрә башлый. Иң күп укыган җире Кичүчат ягындагы Түбән Чыршылы авылы мәдрәсәсе була — анда ул ун елга якын дәрес тыңлый.

Иске мәдрәсә «программалары» буенча дин һәм шаригать нигезләрен үзләштерү белән бергә ул тырышып гарәп, фарсы һәм төрек телләрен өйрәнә. Яшь Ризаның тел өйрәнүгә сәләте аерата көчле булган.

Мәдрәсәдә укыган чакта да, аннан соңрак та Ризаның иң яраткан шөгыльләренең берсе китап күчерү була. Кирәген дә күчерә, кирәкмәгәнен дә... Мәсәлән, хәзер Уфада саклана торган шундый кулъязмаларның берсендә (шаригать буенча кулланмада) мондый юлларны укыйбыз: «Нинди хыяллар берлә язып утырганмын? — мәгънә ма мәгънә...» [1].

Бу кырыс сүзләр, әлбәттә, соңрак, белем артып, дөньяга караш киңәя төшкәч язылган. Һәм алар безгә Р. Фәхретдиневнең үсә баруын, иске татар мәдрәсәсенә карата әкренләп тәнкыйди карашка күчә баруын күрсәтәләр.

Яшь чагыннан ук Ризаның Шиһаб Мәрҗани тәэсиренә эләгүен без аның үз сүзләреннән үк беләбез. Ул үзенең элек «Җарудә» исемле бер клерикаль китапны укуы, аны Мәрҗани язган «Назурә» әсәре белән чагыштыруы турында сөйләп, болай ди: «...һәрхәлдә, Мәрҗанине тануыма беренче сәбәп «Җарудә» булды. Шул көннән игътибарән Мәрҗанинең һәрбер матбуг әсәрләрене тәгъкыйб итеп тордым вә бик күп истифадә кылдым» [2].

Димәк, иске мәдрәсәдә язу таныган, нигездә шунда телләр, дин кануннарын өйрәнү белән бергә азлап-азлап иҗади эзләнүләргә бирелә башлаган яшь Фәхретдиневнең яңа юнәлеш алуына, чын иҗади фикер йөртә башлавына атаклы мәгърифәтче Шиһаб Мәрҗани хезмәтләре, аның фәлсәфәсе, прогрессив тәгълиматы сәбәп булган икән. Аның соңрак канат җәйгән педагоглык хезмәтендә дә, тарих өлкәсендәге эшчәнлегендә дә, ниһаять, фәлсәфи-теологик эзләнүләрендә дә, ахыр чиктә идеологик чикләнгәнлеге белән сыйнфый сукырлыгында да Мәрҗанинең тәэсире бәхәссез иде. Димәк, Р. Фәхретдиневнең дөньяга карашындагы үзенчәлекләрнең, тирән каршылыкларның **бер тамыры** шул татар мәгърифәтчелегенең хосусиятларына, аның тарихи чикләнгәнлегенә барып тоташа икән.

Әле генә китерелгән фактлардан Р. Фәхретдиневнең мәдрәсәдә укып йөргән чакта ук «Назурә» кебек саф гарәпчә язылган зур фәлсәфи әсәрләрне тирән анализлы алырлык дәрәҗәдә гарәпчә әдәби телне үзләштерүен күрәбез. Әлбәттә, мондый казанышка ул, иске мәдрәсә «программасыннан» тыш, үзлегеннән

---

[1] Уфа. Тарих, тел һәм әдәбият институты архивы, кулъязма № рб. 3764.
[2] Мәрҗани мәҗмугасе. Казан, 1915, 384—385 бб.
Сүзлек: тәгъкыйб итү — күзәтү; истифадә кылу — файдалану.

укып, ирешкән. Шул елларны ул, үзе соңрак үкенеп икърар иткәнчә, «бик соңгарып», рус телен дә өйрәнә башлый. Бу эшне ул олы яшькә җиткәндә дә дәвам итә һәм, русчаны начар беләм дип зарлануына карамастан, тарихи хезмәтләреннән күренгәнчә, Карамзин, Соловьев кебек мәшһүр галимнәрнең фундаменталь хезмәтләреннән актив файдаланырлык дәрәҗәдә үзләштерә (зарлану, күрәсең, күбрәк телне белүнең сыйфатына караган булса кирәк).

Мәдрәсәдә укуының соңгы елларында Р. Фәхретдинев үзе дә укыту эшләренә җәлеп ителә башлый: мөдәррисләр аңа яшьрәк шәкертләргә сабак бирүне тапшыралар. Аның шулай бик иртә педагоглык эшен башлап җибәрүенә, бәлкем, Әлмәт ярминкәсендә Каюм Насыйриның хисап дәреслеген сатып алуы, аны җентекләп өйрәнүе дә сәбәп булгандыр. Һәрхәлдә, Түбән Чыршылыда укып-укытып йөргән чакларда ук «Риза-пишкадәм» (ягъни аспирант) һәм «Риза хәлфә» үзе дә китаплар язу эшенә тотына. Аның беренче китабы «Әт-төхфәт әл-әнисия» исемле 1887 елда татарча язылган хезмәте булса кирәк. Шул ук 1887 елны гарәп теле грамматикасы буенча «Китабе әт-тәсрыйф» исемле дәреслеге Казанда басылып чыга. 1888 елны мирас бүлү мәсьәләләренә багышланган, бу өлкәдәге шәригать кануннарын популяр аңлатуны күздә тоткан «Китабе мөкаддимә. Әт-тәхрир-әл-мосфа...» исемле үз чоры өчен файдалы хезмәте дөнья күрә. Шул 1888 елны ук җәмәгатьчелектә зиң яңгыраш табып, авторга исем һәм авторитет китергән «Китабе игътибар» дип аталган мәгълүм хезмәте нәшер ителә. Аның белән танышкач, Шиһабетдин Мәрҗани болай ди: «Бу егет өметле. Мәсләгендә дәвам итсә, яхшы хезмәт итәр». Бәхәссез ки, Мәрҗани халыкка, мәгърифәткә хезмәт итүне күздә тоткан. Мәгърифәт оранчысы Мифтахетдин Акмулла да соңрак китапның шул сыйфатына ишарәләп, аңа мәдхия җырлый:

«Игътибар»да игътибарга алган икән
Хөрмәтле Ризаэтдин — бер камил зат!

Шул ук вакытта Р. Фәхретдиневнең галим буларак оешуы, җитлегүе үзенең зурлыгы ягы мәдрәсәсе белән дә әллә ни зурылып тормаган Түбән Чыршылы авылында узуын онытмыйк. Аның 1884 елга кадәр зур шәһәрләрне күрмәвен, бары шул елны гына беренче тапкыр Казанга сәяхәт ясавын, анда беренче мәртәбә «Тәрҗеман» газетасын күрүен, дөньяда төрки телдә дә мондый «хикмәтнең» барлыгын белеп шаккатуын игътибарга алырга кирәк. Димәк, галимнең дөньяга карашындагы каршылык һәм чикләнгәнлекләрнең и к е н ч е  т а м ы р ы н без ул яшәгән, үскән реаль шартлардан эзләргә тиешбез икән.

Әмма тарихи гаделлек хакына шуны да икърар итик: зур шәһәрләрдән ерак авылдагы урта кул мәдрәсәдә чоры һәм җирлеге өчен шактый югары белемгә ирешә алу егетнең генә сәләтен, омтылышын түгел, бәлки безнең иске мәдрәсәләребезнең дә кайбер хосусиятларын, китап репертуары буенча мөмкинлекләрен характерласа кирәк. Ягъни үзе белемгә омтылган кеше өчен иске татар мәдрәсәсендә дә азмы-күпме дәрәҗәдә шартлар булган икән (моны дөрес бәяләү татар шартларында Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, Г. Кандалый, Г. Мәхмүдев, Акмулла кебек фикер ияләренең тормыш юлларын аңларга булыша...). Аның каравы тиздән, мәдрәсәне бетергәч, Р. Фәхретдиневкә көтелмәгән мөмкинлекләр ачыла. 1887 елда имамлыкка имтихан биреп, янә бер-ике ел тулы хокуклы хәлфә булып мәдрәсәдә эшләгәч, 1889 елны аны хәзерге Азнакай районындагы Илбәк авылына икенче мәхәллә имамы итеп чакыралар. Тагын бер елдан укытуы һәм китаплары (бигрәк тә «Игътибар» китабы) белән тирән белемле, имамәтлек хезмәтендә исә ихлас гадел кеше сыйфатында танылып өлгергән Р. Фәхретдиневкә Диния назаратында казыйлык дәрәҗәсен тәкъдим итәләр. Чөнки, капиталистик мөнәсәбәтләр тормышны тәрләләндереп, мәгърифәтчелек хәрәкәте яңа баскычка менеп, инде искечә яшәүнең мөмкин түгеллеген руханиларның да бер төркеме аңлый башлаган вакытта, Диния назараты өчен дә кысалардан чыкмас дәрәҗәдәге тәрәккый пәрвар — прогресс тарафдары кирәк иде.

Ләкин 1891 елны Уфага күченеп килү, анда казыйлык — дини судьялык эшенә тотыну Р. Фәхретдиневкә өлкән дәрәҗә, матди мул тормыш кына түгел, бәлки авыл шартларында җитлеккән яшь галимгә бөтенләй көтелмәгән гыйльми мөмкин-

лекләр дә тудыра: хуҗалары үлгәч вакыф (васыять) итү юлы белән назаратка җыелган кулъязма һәм иске басма китаплардан тыш, әле генә чит илләрдән кил- гән яңа әсәрләргә, Якын Көнчыгыш илләрендә чыккан газета-журналларга ишек ачыла.

Риза казый, назараттагы китап хәзинәсеннән максималь рәвештә файдаланудан тыш, анда барлыкка килгән 100 еллык архивны җентекләп өйрәнү, аны тәртипкә салу, димәк, төрле характердагы документлар белән танышу, алардан копияләр алып үзенең шәхси архивын баету эше белән дә шөгыльләнә башлый. Менә шушы шартлар дини публицист, иске мәдрәсә педагогы буларак формалаша язган Фәхретдиневне кырыгынчы яшенә күчкән чакта яңа юнәлешкә — тарих фәненә таба борып җибәрә. Шуңа күрә, Риза Фәхретдиневнең казыйлык карьерасына карата үзебезнең гомум мөнәсәбәтебезне үзгәртмәгән хәлдә, безгә галим биографиясендәге шул этапның объектив әһәмиятен дә онытмаска кирәк. Чөнки нәкъ шушы чорда әлеге китапханә, әлеге документлар хәзинәсе ярдәмендә капитализм чоры татар мәдәниятының мөһим фактларын, хәтта төгәл бер күренешен тәшкил иткән мәгърифәтчелек рухындагы «Сәлимә» һәм «Әсма» повестьлары язылып, документаль нигезлелеге ягыннан фундаменталь хезмәте — «Асарь» исемле биобиблиографик җыелмасы төзелә башлый. «Асарь»нең бөтен тукымасын гел документлар, документаль материаллар тәшкил итә.

Шул ук вакытта Ризаның Дини назаратта рәсми дәрәҗә биләве аның әлек яшәгән мохиты, тәрбиясе буенча килгән идеологик каршылыкларын, чикләнгәнлекләрен көчәйтә дә төште. Менә бу хәлләр, минемчә, Р. Фәхретдиневнең чынбарлыкка мөнәсәбәтендәге каршылыкларның беренче нигез сәбәбен тәэмин иткән булса кирәк.

Эволюция һәм реформалар, меценатлар тырышлыгы ярдәмендә генә дә тормышны үзгәртеп була дип инанган, безнең шартлар өчен шул юл биргән кайбер эреле-вaклы казанышлар белән мавыккан, буржуазия сыйныфының, аның кайбер вәкилләренең «агартучылык» миссиясенә ихлас ышанган наив кеше иде ул. Боларның һәммәсе аны гыйлем белән байлык «бер кошның ике канаты яки бер кинәнең ике ишкәге... Гыйлемдән башка байлык, байлыктан башка гыйлем булмас. Ягъни гыйлемсез милләт баемас вә алга китмәс, баемаган милләт гыйлем тәхсил итә алмас»[1] дигән бер карауга дөрес кебек, әмма идеалистик тирән ялгыш ышанычка китерә. Икенчерәк итеп әйткәндә, шушы буржуаз реформизм иллюзиясе Р. Фәхретдинев иҗатына, ул калдырган катлаулы һәм бай мираска хас каршылыкларның, идеалистик чатаклыкларның дүртенче чыганагын тәшкил итә.

1905 елгы революциягә Р. Фәхретдинев менә шундый укмашып беткән каршылыклар белән килә. Ләкин революция нәтиҗәсендә кайбер ташламаларга ирешә алган татар буржуаз сыйныфы каршында, югарыда аталган әсәрләреннән тыш, «Тәрбияле бала», «Тәрбияле ана», «Тәрбияле ата», «Нәсихәт», «Шәкертлек әдәбе», «Әдәбе тәгълим», «Мәшһүр хатыннар», «Исмәгыйль сәяхәте», «Ибне Рөшд», «Мөталага», «Сәгыйдь (касәбәсе)», «Коръән вә тәбакать» исемле, кайберләре әллә ничә кат басылган китапларның авторы буларак, Риза казый зур авторитетларның берсенә әверелгән иде. Шуңа күрә татар буржуазиясенең иң күренекле һәм эшлекле вәкилләреннән булган бертуган Рәмиевләр, беренче мөмкинлекләр туугa ук, махсус журнал оештырып, аны тулысынча диярлек Ризаэтдин Фәхретдинев хәзрәтләренең карамагына тапшыралар. Милли тигезлеккә ирешүнең кайбер мөмкинлекләре тууга, буржуаз реформациягә юл ачылуга, шул рәвешчә милләт тәрәккый итүгә, ягъни милли баюга, баю аша милләтне гыйлемле итүгә ихлас инанган Риза казый, Рәмиевләрнең тәкъдимен алуга ук, югары руханилык дәрәҗәсеннән икеләнеп тормыйча, рәсми рәвештә баш тартып, охравилыктан (ахирәт өчен генә хезмәт итү юнәлешеннән) дөньявилыкка таба зур бер адым ясый.

Менә шул рәвешчә Россиядәге бөтен шәрык өлкәләрендә киң популярлык тапкан мәгълүм «Шура» журналы, журналистикада аксакаллыгы белән халыклар

---

[1] Фәхретдинев Р. Асарь, I том, I кисәк, мөкаддимә.

арасында дан казанган мәшһүр мәсьүл мөхәррир — җаваплы редактор Ризаэтдин бине Фәхретдин барлыкка килә.

Тагын дистәләгән китаплар, йөзләгән мәкаләләр, әдәби әсәрләр, тарихи тикшеренүләр, публицистика, фәнни публикацияләр; дини һәм фәлсәфи уйланулар, борчылулар; педагогик һәм дидактик китаплар; документлар эзләү, бәхәсләр оештыру, чын бәхәсләрдән качу... иллюзияләр... пошыну... көенү... өмет чаткысы кабыну...

Абстракт пацефистның җанын әрнеткән Беренче дөнья сугышы; сагаетып калдырган Февраль революциясе... бөтен дөньяны «җимергән» Октябрь...

Халык революциясен Риза Фәхретдинев авыр кабул итте. Үзенең аңы идеалистик диалектика һәм метафизик күзаллаулар белән характерлы булган алтмышка җитә язган карт өчен бу үзгәрүләр «теш үтмәслек» иде...

1917 елның маенда Мәскәүдә уздырылган Бөтенроссия мөселманнар съездында үзенең ризалыгыннан башка аны яңадан Диния назаратына казый итеп сайлыйлар (Р. Фәхретдинев ул съездда катнашмый), ни өчендер аның үз кандидатурасын үзе кире кагуы (самоотводы) кабул ителми. Съезд карарына, ягъни бер төркем җәмәгатьчелек ихтыярына мәҗбүри буйсынып, ун ел дәвамында «Шура» журналын чыгарган Оренбург шәһәрен калдырып, тагын Уфага килә ул. Бер кадәре вакыт казыйлык иткәч, акларга ияреп Себергә киткән, шунда үлгән иске мөфти урынына Риза казыйны мөфти итеп билгелиләр. Ул тагын бу эшне сыкранып кабул итә.

Мөфтилек эшенә куелуга, Фәхретдинев өстенә йөкләнгән оештыру эшләренә күмелде, СССРдагы мөселманнарга вәкаләтлек итеп, чит илләргә барып кайтты, империализмга каршы халыкара кампанияләргә дә катнашты һ. б.

Рәсми хезмәте ни булуга карамастан, карт галим соңгы көннәренә кадәр тарихи хезмәтләре өстендә эшләвен дәвам итте.

Бары бер мәртәбә аңа балаларча ихлас җилкенеп сөенергә туры килә, 1925 елның август-сентябрендә була бу хәл: СССР Фәннәр академиясенең 200 еллык юбилеена багышланган тантанага рәсми чакырган махсус язу килү, Ленинградка сәяхәт итү, күпләгән ориенталист галимнәр, җөмләдән, академик Крачковский белән очрашу, чит ил кунаклары белән әңгәмә, Һиндстан вәкиле... швед галиме... музейларга, гыйльми китапханәләргә экскурсия... Ун елга якын истәлек итеп сөйләрлек хәлләр...

Риза Фәхретдинев 1936 елның 12 апрелендә 77 яшендә Уфада вафат була һәм татар зиратына күмелә, чөнки аңарчы гел мөфтиләр күмелә килгән назарат каберлегенә җирләмәүләрен үзе кат-кат васыять итә...

Бу аның элгәрге мөфтиләргә дә, Россия шартларындагы мөфтилек дәрәҗәсенә карата да соңгы хөкеме иде.

## III

Югарыда китерелгән материаллардан, бигрәк тә Р. Фәхретдинев адресына, дөресрәге аның дөньяга карашына юнәлгән кырыс тәнкыйть фикереннән чыгып, кайбер укучыларда: «Бу хәтле каршылыклы шәхес турында шул кадәр сүз куертып, аны пропагандалап торуның кирәге бар микән?» — дигән берьяклы сорауның тууы ихтимал.

Беренчедән, Риза Фәхретдиневнең эшчәнлеге гел чикләнгәнлек, гел кире күренешләрдән генә тормый — аның иҗатында бәхәссез тарихи уңай сыйфатлар, хәтта чоры һәм җирлеге өчен мөһим казанышлар да шактый. Икенчедән, галим эшчәнлегендәге каршылыклар аның шәхси каршылыгы гына булмыйча, аны тудырган даирәнең дә, димәк, аны биргән халык чынбарлыгының да катлаулылыгы, каршылыклыгы иде. (В. И. Ленинның җәмгыятьтә яшәп тә, җәмгыятьтән азат була алмау хакындагы өйрәтүен хәтердән чыгармыйк).

Өченчедән, һәм, иң мөһиме, Р. Фәхретдинев эшчәнлегенә, аның гаҗәеп бай әдәби, гыйльми мирасына мөрәҗәгать итүдән максат — бу мирасның тарихи әһәмиятен дөрес аңлау һәм фәнни, тормышчан гадел аңлатырга омтылу. Әлеккe

кайбер чыгышлардагы кебек галимнең күпсанлы китапларыннан, чын фәнни хезмәтләреннән шыпырт кына файдаланып, җае килгән һәм килмәгән саен аны сүгеп узулар ише принципсызлыктан да өстен булырга кирәк. Шул ук вакытта Р. Фәхретдинов адресына юнәлгән кискен тәнкыйтьләрнең һәммәсеннән дә баш тартырга дигән сүз түгел бу: безгә арзанлы-җиңелле «тешләп узулардан», урынлы-урынсыз күкрәк сугып кизәнүләрдән арынып, чын методологик фәнни тәнкыйтьне үстерергә, көчәйтергә кирәк. Бу таләп исә галимнең мирасына тулаем абстракт кына түгел, бәлки тарихи конкрет якын килүне шарт итеп куя. Шушы конкретлылык принцибы белән гамәл кылганда, без Р. Фәхретдинев иҗатында ике юнәлештәге төп ике сыйфәтны күрербез: аның гомум идеологик позициясе, иҗтимагый һәм гыйльми теләге, ягъни субъектив омтылышы һәм практик әдәби-журналистик, гыйльми-тикшеренү эшчәнлеге, шуларның объектив нәтиҗәләре.

Беренче юнәлештә без өлешчә буржуаз-демократик, өлешчә буржуаз-либерал үзгәртүләр, реформалар тарафдары булган төзәлмәс идеалистны, консерватор эшлеклене күрәбез.

Икенче юнәлештә исә безнең алга конкрет әдәби әсәрләре, практик журналистлыгы, күпсанлы педагогик һәм тарихи хезмәтләре белән иске тормыштан йөз чөерү идеясен пропагандалаган, хәтта үзенә үзе каршы килеп, феодаль шартларның гына түгел, буржуаз тәртипләрнең дә искерүен аңсыз икърар иткән фикер иясе килеп баса. Әлбәттә, бу карашлар галимнең әсәрләрендә турыдан-туры әйтелми, бәлки алар аның чынбарлыкка тәнкыйди мөнәсәбәтендә, канәгатьсезлегендә чагылыш таба. Тик бу ризасызлык Р. Фәхретдиневта гаять үзенчәлекле гәүдәләнә: алга, киләчәккә омтылышта түгел, ә ерак узганны — «гаср-ел-сәгадәтне», ягъни ислам дине «бозылып» җитмәгән, әле «саф» булган Мөхәммәд пәйгамбәр чорын сагынуда, аны идеаллаштыруда күренә. Шулай итеп, без Риза казыйның тагын бер мөһим каршылыгына килеп төртеләбез: прогрессив кире кагу белән регрессив расләуга.

Бу гаять катлаулы, моңарчы әле тиешенчә тикшерелмәгән мәсьәләләр киләчәктә җентекләп өйрәнүне сорыйлар, әлбәттә. Бу юлда безгә, аерым детальләрне ачыклап, фактларның һәммәсен бергә туплау белән бергә, В. И. Ленинның мөһим күрсәтмәсеннән чыгып гамәл итәргә кирәк: хосусый мәсьәләләрне хәл кылуда, конкрет гыйльми тикшеренүләрдә кыйммәтле хезмәтләр бирә алган буржуаз галимнәрнең казанышларын таныган хәлдә, гомум теоретик һәм фәлсәфи мәсьәләләрдә аларга һич тә ышанырга, ягъни аларның концепцияләрен кабул итәргә ярамый [1]. Шуңа күрә без дә Р. Фәхретдинов кебек узган чор галимнәренең мирасындагы гомум теоретик һәм гносеологик мәсьәләләренә — сыйнфый һәм партияле позицияне аларның конкрет гыйльми казанышларыннан аерып карарга, һәрберсенең үзенә лаек өлешен бирергә, ягъни методологик ялгышларны кире кагарга, фәнгә биргән конкрет өлешләрен икърар итәргә тиешбез. Бу — фәнни объективлыкның зарури таләбе.

Бәс шулай икән, ул вакытта Риза Фәхретдиневнең Октябрь революциясенә кадәрге татар әдәбияты һәм журналистикасына, иҗтимагый фикере белән тарих фәненә керткән конкрет өлеше бармы, булса, нәрсәдән гыйбарәт?

## IV

Аның каләм көчен сынавы шактый иртә башланып, беренче мәкаләләре «Тәрҗеман», «Шәркый Рус» газеталарында, аннары Оренбургта чыга башлаган «Вакыт»та басылса да, журналистлык куәтенең чын-чынлап колач җәюе «Шура» журналының баш редакторы һәм төп язучысы булып эшләгән чорга туры килә.

Һәр номеры, тышлыкның эчке битләрендәге текстларны да исәпләгәндә, 34 биттән гыйбарәт бу журнал айга ике тапкыр чыгып, тәгәл ун ел дәвам итә һәм барлыгы 240 сан дөнья күрә. Журналның һәр санында диярлек Р. Фәхретдиневнең авторлыгы күрсәтелгән һәм күрсәтелмәгән ике-өч мәкаләсе басыла (кайбер

[1] Ленин В. И. Әсәрләренең тулы җыелмасы, 18 том, 363—364 бб. (рус телендә).

мәкаләләр дәвамлы рәвештә 4-5, хәтта 10-15 санда нәшер ителә, ягъни зур күләмле публикацияләр кыяфәтен ала). Моның өстенә һәр сан саен редактор тарафыннан журнал укучыларының сорауларына бирелгән җаваплар урнаштырыла. Менә шуларның һәммәсен дә исәпкә алганда, «Шура» битләрендә генә дә Р. Фәхретдиневнең җиде йөзгә якын мәкалә һәм төрле характердагы язмалары дөнья күрә[1]

Димәк, шушы саннарны игътибарга алганда гына да, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди кебек кайбер галимнәрнең, Р. Фәхретдинев мирасы хакында сөйләгән чакта, әдип иҗатының иң әчтәлекле өлеше сыйфатында «Шура» журналын атаулары белән килешмичә булмый. Дөрес, әгәр бу галимнәр журналдагы каршылыкларның чыганаклары да баш мөхәррирнең табигатенә бәйле икәнлекләрен күрсәтсәләр, бәя тагы да төгәлрәк булыр иде.

Чыннан да, журнал материалларын карап утыра торгач, әллә нинди сәер хисләр туа: янәшә күмсәң, кабердә дә «рухлары» сугышып ятарлык бер-берсенә кискен каршы фикерләр, кушыла алмаслык юнәлешләр белән бергә практик дөрес фикер йөртү һәм файдасыз сүз куерту, киләчәккә өмет, якты хыял белән дөньядан ваз кичеп сыкрану, черегән динне яңартырга омтылган материаллар янында дөньяви культураны, алдынгы рус һәм Европа мәдәниятен идеаллаштырган публикацияләрне урнаштыру, искедән кискен йөз чөерү белән бергә урта гасыр чорларына гына хас күренешләрне күккә чөю һ. б. һ. б.

Журналны ябасың. Яңадан кайтып, беренче санны ачасың һәм баш редактор тарафыннан язылган «Мәсләк вә максат»ны укыйсың: «Шура» милләтне гыйлемле, мәгърифәтле итмәк хакында м ә ш в ә р ә т м ә җ л е с е улачактыр. Эстәдеке кемсә ошбу мәҗлестә сөйләр вә эстәдеке адәм дә тыңлар... Шәхсияттән вә гарызлардан саф улмак шарты илә, милләт мәнфәгате арзусилә язылмыш мәкалә вә фикерләр өчен «Шура» битләре һәрвакыт ачыктыр...» [1].

Димәк, редакторның вәгъдәсе буенча, «киңәш мәҗлесе» булырга тиешле дип исәпләнгән «Шура»га теләсә кем яза ала икән. Әйтергә кирәк, дәгъваның шактый четрекле һәм хыялый булуына карамастан, Р. Фәхретдинев ул вәгъдәгә үзенчә турылыклы булып калды: ахун һәм миллионердан алып, авыл хәлфәсе белән наборщикка кадәр журналда актив языштылар. Менә шушы «теләсә кем»лек һәм редакция тоткан юлның наив буталчыклыгы безгә материал җәһәтеннән бик бай, гаять катлаулы һәм искиткеч каршылыклы бер журнал исталек итеп калдыра. Аның төрле характердагы мәгълүматка бай булуы безне үзенә тарта, катлаулыгы кызыксындыра, ә каршылыклы табигате исә уйландыра; шуңа күрә без аны тәнкыйтьлибез, кайбер чакларда гел тискәре сыйфатлар белән характерлыйбыз, ләкин, берәр материал, бигрәк тә чорга хас каршылыклы фикерләр хакында мәгълүмат эзләгәндә, тагын үзенә мөрәҗәгать итәбез. Чөнки гасырыбыз башындагы татар җәмгыятенең, бигрәк тә ул җәмгыятьтә хөкем сөргән хаким идеология белән хаким культураның торышын, эволюция һәм үзгәрешен, казаныш һәм кризисларын турылап та, кыеклап та чагылдыра торган материаллар «Шура»да иксез-чиксез дәрәҗәдә күп. Гәрчә безнең өчен бүген төп өйрәнү объекты эшче-крестьян катламнарының тормышы, тарихи миссиясе булса да, без буржуаз җәмгыять тарихын да җентекләп өйрәнәбез, чөнки хаким идеология белән хаким культураны һәрьяклап белмичә, аңламыйча торып, хезмәт ияләренең дә тулы тарихын, ул алып барган көрәшне, кешелек ирешкән прогресстагы аның чын урынын билгели алмаячакбыз. Шушы күзлектән караганда, «Шура»да басылган материалларның фәнни объектив әһәмияте тагы да ачыла төшә, ягъни «Шура»ның тарихи чыганаклык — документальлек әһәмияте калкурак гәүдәләнә.

Моның шулай икәнлеген күрсәтә торган бер-ике генә мисалга кыскача тукталыйк (әгәр «Шура»да басылган материалларның исемнәрен санап чыга башласаң да, зур күләмле китап барлыкка килер иде) [2].

---

[1] Сүзлек: мәшвәрәт мәҗлесе — киңәшү, фикер алышу җыелышы; гарызлардан — мәкерле теләкләрдән,; арзусилә — максаты белән, теләге белән.

[2] Мәсәлән, 1959—1962 елларда шушы юлларның авторы тарафыннан «Шура»га төзелгән тулы библиографик күрсәткечнең күләме унбиш басма табак тирәсе булды; тулаем алганда, журналда — кайбер материалларны төркемләп биргәндә дә — дүрт меңнән артык исемдә публикация булган икән; әйтик, анда 1200 гә якын шигырь, хикәя һәм әдәби әсәрләр, филологиягә караган якынча 450 мәкалә, тарихка багышланган 500 эреле-ваклы хезмәт дөнья күргән; тәгълим-тәрбия һәм педагогика мәсьәләсенә багышланган материалларның саны да 400 дән артып китә...

XX гасыр башында татарларның игътибарын аерата җәлеп иткән, бигрәк тә күпчелек вак буржуаз һәм интеллигенция катламнарының зиһеннәрен чуалткан мәсьәләләрнең берсе милли аң, үз-үзеңне танып белү, шуннан чыгып милли әдәби тел мәсьәләләрен хәл кылу булды. Эре һәм либерал буржуазия вәкилләре исә халык тормышындагы гомум социаль-иҗтимагый мәсьәләләрне дә шулар белән алмаштырырга омтылды. Руханилар да тыныч ятмадылар: чишелергә тиешле проблемаларның кендеге сыйфатында алар беренче планга дини мәсьәләләрне өстерәп чыгардылар. Бу да, хаким сыйныфлар позициясеннән карaганда, гегемонлыкка ирешү юлындагы мөһим чараларның берсе иде. Нашир һәм редакторларның карашында «Шура» журналы шушы юнәлештә дә милләткә «хезмәт итәргә», хәзерге атамалар белән әйткәндә, сыйнфый конфронтацияне киметеп, милли, хәтта гомум төрки консолидацияне көчәйтергә тиеш иде. Баштарак журналның субъектив омтылышы шуңа кайтып калды. Ләкин журналда урнаштырылган материалларның объектив нәтиҗәләре киресенчә килеп чыкты.

Иң кискен бәхәсләр тудырган мәсьәләләрдән этногенез һәм үз-үзеңне милли танып-белү мәсьәләсе булды. Элекке «мөселманчылык» бердәмлеге психологиясе икенче планга күчеп, алга этник бердәмлек тойгысы килеп басуга иҗтимагый фикердә «син кем идең, кем булачаксың?» дигән сорау формалашты. Өч төп юнәлеш барлыкка килде:

— Болгарчылык, төрекчелек һәм татарчылык.

Һәр тенденциянең азмы-күпме җирлеге, тәгълүме-түгелме дәлилләре бар иде. Болгарчылык тенденциясе нигездә этногенетик концепцияләргә кайтып калган, күбрәк узган тарихка юнәлгән булса, төрекчелек һәм татарчылык юнәлешләре көн тәртибендәге иҗтимагый проблемаларга, шуннан чыгып, киләчәккә — перспективага адресланган иде.

Төрекчелекне теш-тырнагы белән яклаучы булып «Шура»да «Төрек угълы» дигән, Г. Ибраһимов сүзләре белән әйткәндә, «бер ходай бәндәсе» чыга. Аның фикеренчә, берниндн мөстәкыйль татар милләте юк һәм булмаячак, дөньяда «төрек» дигән бер генә милләт бар һәм аның үзәге — Төркия. Мондый коткыга иярүчеләр булмады түгел, әлбәттә. Журналдагы кайбер материаллар шуны күрсәтә.

Татарчылык юнәлешенә килсәк, ул да, бүген безгә тоелганча, гади реалистик тарихи концепция түгел, бәлки шактый катлаулы һәм каршылыклы юнәлеш иде: аның, читтән караганда, бер ягында «олуг Чыңгызхан» шөһрәте белән мавыккан, мәгәр, максатын ачыкласаң, татар буржуазиясе гегемонлыгы өчен көенгән милләтчеләр торды (ул чакта татар буржуазиясенә тәлинкә тотып, «мин дә татар!» дип лаф орган, соңра татар буржуазиясе «аяк сузгач», тар башкорт милләтчелеген байрак иткән Зәки Вәлиди шушы юнәлешкә идеолог булды).

Юнәлешнең икенче флангасында «татар» дигән исемнең тарихи шартлы атама икәнлеген аңлаган, тарихи этник тамыры исә болгар халкына барып тоташуын яхшы белгән, шуңа күрә «без кем» дип лаф оруларның мәкерле пропаганда икәнлеген ачык күрүчеләр торды. Бу карашны алга сөрүче булып, татарның бер конкрет төрки телле аерым милләт икәнлеген, башка төрки телле милләтләрнең дә мөстәкыйльлеккә хаклы булуын яклап Галимҗан Ибраһимов чыкты һәм ул озакка сузылган бәхәстә «төрекчеләрне» дә, халык тарихын «ханлык чоры шәүкәте» белән алмаштырырга омтылган «татарчыларны» да тәмам җиңеп чыкты.

Р. Фәхретдинев исә, «мәшвәрәт мәҗлесе» хакындагы вәгъдәсенә турылыклы булып, һәр өч юнәлеш вәкилләренә дә журналда урын бирде, үзе өчен дә тиешле һәм объектив нәтиҗәләр ясады. Моның шулай икәнлеген әдәби тел хакындагы дискуссия йомгагыннан да күрергә мөмкин.

Әдәби тел проблемаларына караган материаллар да өч төркемгә, ягъни юнәлешкә бүленә:

а) госманлы төрек теле нигезендәге гомум әдәби тел;

б) берничә төрки халыкның телләре кушылып ясалган корама әдәби тел;

в) территориаль милли тел (Идел һәм Урал буе татарлары өчен традицион, ләкин лексик яктан халыклаштырылган татар теле).

Шушы мәсьәләдә дә бер фикергә килер өчен Р. Фәхретдинев үзенең журналы

битләрендә мәгълүм «тел ярышын» оештыра; баштан ук саф төрекчелекне артык узындырмаган хәлдә, корамачылык тарафдарларына да, телне «тәмам тазартырга» омтылган пуристларга да, чын татарчыларга да журналда иркен урын бирелә, басылган материаллар хакында укучылар хөкеменә мөрәҗәгать ителә. Гәрчә Г. Тукай әлеге дискуссияне «тиле ярыш» дип мыскыллаган булса да, аның тарихи әһәмияте, Р. Фәхретдиневнең садә өметләренә каршы киләрәк, тарихи прогрессив нәтиҗәләр бирде: әдәби телне күпләгән гарәп-фарсы сүзләреннән арындыру мөмкинлеген ачу белән бергә, бу ярыш тормышка яраклы телнең бары территориаль халык теленә генә нигезләнергә тиешлеген раслады. Махсус референдум нәтиҗәсендә беренчелекнең саф татарча язган Мәҗит Гафурига бирелүе шушы тарихи объектив казанышның бәхәссез дәлиле иде. Р. Фәхретдинев исә, киң масса укучылар ихтыярын игътибарга алып, башта үзе идеал иткән корамачылыктан да, бер ара мавыккан төрекчелектән дә баш тартты. Вакыйгаларның замандашы булган Г. Сәгъди бу хакта болай ди: «татарчылыкның төрекчелеккә каршы гамәли яктан соңгы кискен өстенлеге (катгый галәбәсе) дә 1912 елларда булды. Моннан соң инде без шушы өстенлекнең тәэсире белән хәтта Риза шикелле төрекчеләрнең (өстик: һәм корамачыларның — М. Г.) тел-эслүбендә дә татарчылык процентының күп артканын күрәбез» [1].

Р. Фәхретдиневнең журналист һәм редактор-оештыручы буларак яңа дәвер әдәби телебез формалашуга, үсүгә керткән объектив өлешенең берсе менә шуннан гыйбарәт.

## V

Галимнең күп кенә мөһим мәсьәләләрне хәл кылганда тарихилык принцибы белән гамәл итәргә тырышуын аның милли этногенез өлкәсендәге фикерләреннән дә күрергә мөмкин. Югарыда бер ишарә ителгәнчә, Р. Фәхретдинев, Шиһаб Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов традицияләрен дәвам иттерел, татар тарихи фикерендә болгарчылык теориясен алга сөрүчеләрдән булды һәм бу юнәлештә тарихи белемебезне яңа фактлар, яңа фикерләр белән баетты. Казан татарлары монгол яулап алучыларның нәселләре дигән тамырдан ялгыш карашны ул кискен рәвештә кире какты. Аның инануынча, хәзерге Идел һәм Урал буе татарлары белән тарихта Чыңгыз яулап алучыларына тагылып йөртелә торган илбасар «татарлар» белән бернинди этник, ягъни милли уртаклык юк.

Галимнең тарих фәне каршына куйган төп таләбе — тарих белеменең бурычы ул хан-падишаларны, тәхет тирәсендәге ызгышларны тасвирлау түгел, ә киң катлам халыкның узганын өйрәнү дигән карашы [2] — чоры һәм җирлеге өчен шактый мөһим яңалык иде.

Тагын бер характерлы факт: күренекле татар тарихчысы, болгарчылыкның актив тарафдары Гайнетдин Әхмәревнең вафатыннан соң «Шура»да бастырган некрологта ул, мәрхүмнең хезмәтләрен бик югары бәяләп, татарда моңарчы бары өч кенә «чын тарихчы» булуын, аларның беренчесе Ш. Мәрҗани, икенчесе Х. Фәезханов, өченчесе исә Г. Әхмәрев икәнлеген әйтә.

Шуңа да игътибар итик: бу кыю һәм дөрес фикерне галим 1911 елны, ягъни буржуаз татар тарих белемендә З. Вәлиди, Г. Баттал иише «олуг дәүләтчелек» идеясе тарафдарлары активлашкан, аларның шаукымы киң таралып, «шөһрәтле Чыңгыз баба» хакында шапырынган җырлар, шигырьләр бер-бер артлы сибелеп торган вакытта аерата басым ясап әйтә, шуның белән үзенең позициясен ачык игълан кыла.

Р. Фәхретдиневнең халык тарихы турында кайгыртып та, күп очракта хосусый мәсьәләләр, яисә аерым шәхесләрнең тәрҗемәи хәлләре белән мавыгуын, халык массаларының тарихтагы чын урынын яктырта алмавын галимнең «Шура»да басылган күпсанлы мәкаләләреннән тыш, аның аерым китапларыннан,

[1] Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы. Казан, 1926, 170 б.
[2] «Шура», 1909, 19 сан, 578 б.

мәсәлән, «Мәшһүр хатыннар» хезмәтенән, «Мәшһүр ирләр» исемле циклда чыккан махсус монографияләреннән күрергә мөмкин.

«Мәшһүр ирләр» циклына кагылабыз икән, без Риза Фәхретдинев калдырган бай мирасның ориенталистика күзлегеннән дә зур кыйммәткә ия булуын күрәбез, чөнки бу циклда безнең автор, Ш. Мәрҗани традицияләрен дәвам иттереп, татар тарих белемендәге фәнни ориенталистиканың үсешенә зур өлеш кертте. Мәсәлән, ул шәрык дөньясындагы иҗтимагый фикер, фән һәм әдәбиятларның үсешенә зур тәэсир ясаган материалист философлардан Ибне Рөшд, Ибне Хәлдун, тирән фикер иясе, шагыйрь һәм язучылардан әл-Мәгарри, әл-Мөкаффәгъ, энциклопедист әдип һәм галимнәрдән Ибне Сина, Бируни, Гомәр Хәйям, Якут Хамави, әл-Мәкъризи, Зәмәхшәри, Фәхретдин әр-Рази, Ибне Тәймия, атаклы сәяхәтчеләрдән Ибне Баттута, Ибне Фазлан, Ибне Гарәбшаһ, Ибне Хәлләкян, теолог һәм дини эшлеклеләрдән Мөхәммәд, Әбүбәкер, әл-Гарәби, имам Газали, Гали Гомәр, Госман, Мөтәнәбби, Сәнүси, Мәһди һәм башка бик күпләр хакында бай мәгълүматлы китаплар, эчтәлекле зур мәкаләләр бастырды. Әлбәттә, кайбер шәхесләрнең, бигрәк тә аерым дини эшлеклеләрнең тарихтагы урыннарын билгеләгәндә, Р. Фәхретдиневкә характерлы каршылык һәм берьяклылыклар да чагылмыйча кала алмадылар. Әмма галимнең бу хезмәтләрендә бер урынга тупланган документаль материалларның ишлелеге, кайбер конкрет күзәтүләрнең тәплелеге дә бәхәссез иде.

Мәсәлән, бөек энциклопедист галим Әбүрайхан әл-Бирунинең эшчәнлегенә кагылганда Р. Фәхретдинев юл уңаенда «Бируни» нисбәтенең фарсыча «тышкы» мәгънәсендәге «бирун» сүзеннән ясалуын, димәк, Әбурәйханның шәһәр үзәген тәшкил итә һәм аксөяк феодал катламнар тора торган кальга-крепостьтан тышта яшәүче гади халык арасыннан чыгуын күрсәтә. Бу «кечкенә» детальгә игътибар итүнең сәбәбе шунда ки, нәкъ шушы фикерне күпкә соңрак Р. Фәхретдинев мәкаләсе басылып, дистәләрчә еллар узгач, академик И. Ю. Крачковский кабат әйтеп чыкты һәм совет ориенталистика фәнендә Крачковскийның фикере зур ачыш сыйфатында кабул ителде. (Монда сүз соңгы мөхтәрәм галимнең нинди чыганакларга нигезләнүен билгеләү хакында түгел, ә әлеге этимологиянең фәнни әһәмияте хакында бара.)

Гарәп дөньясының Гомеры булган тирән фикер иясе сукыр шагыйрь әл-Мәгарри хакында Европа һәм Россия галимнәре бик соңгарып беләләр, хәтта аны күп гомерләр белми торуларына гаҗәпләнәләр. Әл-Мәгарри хакындагы русча беренче фәнни хезмәтләр бары совет чорында гына басылып чыга. Хәлбуки, Россиядә әл-Мәгарри хакында язылган иң тәүге зур хезмәт — төгәл бер монография — Р. Фәхретдинев тарафыннан иҗат ителгән һәм революциягә кадәр үк татар телендә нәшер ителгән иде...

Татарча язылган ориенталистик хезмәтләрдәге мондый эреле-ваклы ачыш һәм табышларның бер Р. Фәхретдинев хезмәтләрендә чагылуын кыскача санап чыгар өчен дә аерым мәкалә язарга туры килер иде. Шулай да тагын бер мисалны күрсәтмичә узу мөмкин түгел.

1965 елны Төркиядә галимә Бәхрия Өчукның «Ислам дәүләтләрендә хатын-кыз хөкемдарлар» исемле китабы дөнья күрде. Хезмәт тиз арада инглиз, француз, гарәп, фарсы телләренә тәрҗемә ителде һәм 1982 елны академик Зия Бөниятов тәрҗемәсендә рус телендә басылып чыкты [1]. Б. Өчук хезмәтенә карата булган мондый кызыксынуның сәбәбе бар, әлбәттә: анда мөселман дөньясында хатын-кызлар һәрвакытта, һәр җирдә тәмам хокуксыз булган дигән берьяклы карашка бай фактик материаллар нигезендә тиешле төзәтмәләр ясала. Мондый принципиаль төзәтмәләрнең бер өлеше белән совет галимнәре дә килешәләр. Бу фактка мөрәҗәгать итүнең сәбәбе шунда ки, мөселман илләрендә һәрвакытта, барлык регионнарда да хатын-кызлар хокуктан бөтенләй мәхрүм ителгән дигән тулаем карашның барлык тарихи чорлар һәм барлык мөселман илләре өчен дөрес булып җитмәвен яңа заман дөнья әдәбиятында беренче мәртәбә Р. Фәхретдинев

---

[1] Бахрие Учок. Женщины-правительницы в мусульманских государствах. Изд-во «Наука», М., 1982.

әйтте һәм шушы фикерне раслар өчен үзенең чорында ук көчле яңгыраш тапкан «Мәшһүр хатыннар» исемле китабын бастырды (1903).

Әлбәттә, моннан чыгып, «Мәшһүр хатыннар»дагы концептуаль фикерләрнең һәммәсе дә кабул ителерлек дәрәҗәдә дип булмый. Сүз бары әлеге мәсьәләнең беренчеләрдән булып Риза Фәхретдинев тарафыннан куелуы, ягъни галимнең мәсьәлә актуальлеген аңлауда гомум ориенталистика күләмендә пионер икәнлеге хакында бара.

Р. Фәхретдиневнең тарихи ориенталистика өлкәсендәге эшчәнлеге хакында сөйләгән чакта тагын бер мөһим мәсьәләгә — аның мөселман илләре арасындагы мөнәсәбәтләргә карашына тукталу зарур. Чөнки моңарчы Р. Фәхретдиневкә уптым-илаһи рәвештә сугылган панисламист тамгасы да тагылып йөрде. Панисламизм, мәгълүм булганча, бөтен мөселман илләрен дин бердәмлеге нигезендә политик берләштерүне күздә тота торган, халыкларның милли-этник һәм конкрет тарихи мөстәкыйльлеген танымаган реакцион тәгълимат. Фәхретдинев чын панисламистларның дәгъваларын танымады. Аның фикеренчә: «һәрберенең махсус бер мәнфәгате, гадәт вә максуды, лисан вә шивәсе улан өч йөз миллион мөселманны — җәмигъ кавемнәрнең бер хөкүмәт идарәсенә җыелмаклары мөмкин улмаса кирәк...» Димәк, ди, ул шуннан чыгып: «Исламлар өчен гомум улан сәяси иттихад мөмкин улмадыгы хәтта боны хыялларга китермәк дөрест күрелмәдеге хәлдә, иҗтимагый иттихад мөмкин...» — дип нәтиҗә ясый. Чөнки мөселманнар арасындагы мөнәсәбәт башка диндәге халыкларга да зарар итмәгәндә генә тормышчан файдалы бердәмлек була ала[1].

Кайбер хосусый мәсьәләләрдә вакыт-вакыт мавыгып алуларны исәпләгәндә дә, Р. Фәхретдинев нигездә шушы реалистик һәм тарихи позициядә торды, абстракт рәвештә булса да, киң карашлы гуманистлык сыйфатын җуймады.

Моның шулай икәнлеген көнбатыш халыкларының тарихына багышланган материалларның «Шура»да шактый мул басылуы да раслый. Мәсәлән, рус культурасы һәм тарихы вәкилләреннән анда Л. Н. Толстой, Н. В. Гоголь, А. С. Пушкин, М. В. Ломоносов, И. А. Гончаров, М. Ковалевский, И. Мечников, Я. Брос һ. б. хакында материаллар бирелә, Е. И. Пугачев исә аерата кызыксыну тудыра. Шулай ук көнбатыш халыклары вәкилләреннән Аристотель, Демокрит, Сократ, Платон, Спиноза, Лейбниц, Бэкон, Ж. Руссо, Декарт, Гете, Жюль Верн, Эдиссон һәм башкалар хакында файдалы материаллар урнаштырыла. Димәк, Р. Фәхретдинев, кайберәүләр уйлаганча, дөньяны тарәйтып карамаган.

Шул ук вакытта галим мөселман илләре кичергән тарихи регрессны да күз йоммады: элекке ислам дөньясында, үзе сбразлы итеп әйтмешли, чын арысланнар хөкем сөрүен, яңа дәвердә исә «аларның урыннарында маймыллар утыруын» ул яхшы күрде. Регрессның сәбәбен исә мөселман халыкларының үз эчләрендәге иҗтимагый-дини шартлардан табарга тырышты, ягъни нәтиҗәне дөрес билгеләсә дә, сәбәпләрнең чыганагын идеалистларча өскорма факторлардан гына эзләде. Шуңа күрә, эзлекле идеалист позициясендә калганы хәлдә, Р. Фәхретдинев һәрвакытта диярлек дини фанатизм, клерикализм өйрәтүләрен кире какты, нәтиҗәдә тирән эчке каршылыктан котыла алмады.

Галимнең шушы киң колачлы белеме, ориенталистика өлкәсендәге зур эрудициясе һәм бер үк вакытта чикләнгәнлеге аның татар тарихына караган эшчәнлеге хосусиятларын да — отышлы һәм җитешсез якларын билгеләде дип әйтергә мөмкин.

## VI

Р. Фәхретдиневнең тарихчы буларак формалашуы, югарыда бер әйтелгәнчә, Диния назаратында казый булып эшләгән чорына туры килә. Чөнки назарат архивындагы меңләгән документлар, аның китапханәсендәге гарәпчә, фарсыча тарихи китаплардан файдалану аңарда тарихи чыганак дигән бер хикмәтнең фән

[1] «Шура», 1912, 12—13 саннар. Сүзлек: Лисан — тел; улан — булган; иттихад — союз, бердәмлек.

һәм тормыш өчен кодрәтен, көчен тирән аңлау мөмкинлеге тудыра, аңарда тарихи әсәрләр язу теләгеп уята. Һәм ул артык сузмыйча эшкә дә тотына. «Эзләр» яки «истәлекләр» мәгънәсендәге мәшһүр «Асарь» китабы шулай барлыкка килә башлый.

15 кисәктән торган беренче һәм икенче томнары басмада, соңгы өченче һәм дүртенче томнарының кулъязмада сакланып калган бу фундаменталь хезмәтнең беренче кисәге 1900 елда ук язылып бетә. Аның кереш сүзендә автор үзенең тарих белеменә карата булган мөнәсәбәтен, гомумән тарих фәне алдына куелган тормышчан бурычларны шактый этрафлы яза (басма вариантында автор фикерләренең зур өлеше чагылмаган — цензор В. Д. Смирнов галим фикерләренең иң мөһим, иң кыю һәм прогрессив өлешләрен эзлекле рәвештә сызып барган).

Нәрсәдән гыйбарәт соң бу «Асарь»?

Беренче карауга бу — татар халкының узган чорында яшәгән руханиларның биографиясенә бәйләнешле материалларны туплаган дини-биографик җыелманы хәтерләтә төшә. Ләкин өстән генә караганда, татар тарихының XVII—XIX йөзләрдәге каршылыклы хосусиятларын белмәгәндә, яисә белергә теләмәгәндә генә ул шулай булып тоела. Әгәр иске Рәсәй шартларында татарларның иҗтимагый тормышта барлык төр дөньяви институтлардан мәхрүм ителүен, патша хөкүмәтенең шундый эзлекле политикасы нәтиҗәсендә татар җәмәгатьчелегендә дөньяви феодалларның бик нык зәгыйфьләнү нәтиҗәсендә беренче чиратта рухани феодаллар өстенлек итүен исәпкә алсак, мәсьәлә икенчерәк төстә яктыра: «Асарь»дә соңгы фаза феодализм дәверендәге татар рухи культурасының (хәзер төгәлрәк әйтә алабыз: хаким рухи культураның!) торышы һәм эволюциясен төрле яклап чагылдыра торган материаллар тупланган.

Ни өчен «Асарь»дә хаким культура, хаким идеология тарихы гына өйрәнелә дип, Р. Фәхретдиневкә бәйләнү бүген урынсыз һәм мәгънәсез булыр иде. Беренчедән, иске дәвердә формалашкан автордан моны таләп итү бу таләпнең тарихилыгын юкка чыгара төшсә, язма культурадан мәхрүм ителгән халык массалары хакында язма истәлекләрне өйрәнүчедән таләп итү дә наив дәгъвага кайтып калыр иде.

Икенчедән, Р. Фәхретдиневнең гомумән татар тарихчысы буларак түгел, бәлки культура һәм мәгариф тарихчысы сыйфатында каләмгә тотынуын да онытмаска кирәк.

Шуларның һәммәсен исәпкә алганда, без «Асарь»не соңгы фаза феодализм дәверендәге хаким культурабызның, шул чорда хөкем сөргән идеологиянең тарихы буенча материаллар җыелмасы дип бәяләргә тиешбез. (Өстен катламнарның культурасын, рухи дөньясын белмичә торып, изелгән хезмәт ияләренең рухи культурасын аңлау мөмкин түгел — сыйнфый җәмгыятьтә хаким культура тоткан җитәкчел позициянең әһәмиятен тану ул марксистик тарихилык принцибының аксиомасы.

«Асарь»дәге һәр очерк тормышы яисә эшчәнлеге яктыртыла торган шәхеснең мөмкин кадәр төгәл исем-фамилиясе, үлгән һәм туган еллары буенча мәгълүмат бирүдән башлана [1]. Моннан соң автор объектның кайда укуын, кемнәрдән сабак тыңлавын, үзе кемнәргә дәрес бирүен,ниләр эшләп, нәрсәләр иҗат итүен бәйнә-бәйнә санап чыга; аның язган китапларына шактый төгәл аннотация урнаштыру белән бергә мәрхүмнән калган хатлар, аның тормышын, эшчәнлеген теге яки бу яктан чагылдыра торган документлар булса, шуларның тулы текстларын яисә мөһим өзекләрен күчереп чыга. Ягъни һәр очерк биографик документлар җыентыгын тәшкил итә. Җае килгән саен авторның ул шәхес хакындагы күзәтүләре, уңай яки тискәре хөкемнәре дә теркәлә бара. Шулай итеп, безнең алда фактографик язма белән бергә билгеле дәрәҗәдә концептуаль тикшерену дә барлыкка килә.

Хезмәтнең күләмен якынча күз алдына китерер өчен шуңа да игътибар итик: басылып чыккан 15 кисәктән торган беренче һәм икенче томнарда 1200 тирәсе төрле күләмдәге биографик счерклар тупланган булса, кулъязма килеш сакланып

---

[1] Хронологик принцип итеп, тәрҗемәи хәл иясенең вафат тарихы алына, барлык биографияләр шул тәртип буенча бер-бер артлы урнаштырыла.

калган өченче һәм дүртенче томнарда тагы йөзләгән тәрҗемәи хәллэр... Әгәр шуларга «Мәшһүр хатыннар» китабында теркәлгән, аннары «Шура»да һәм башка матбугат органнарында басылган, әмма «Асарь»гә кермәгән тәрҗемәи хәлләрне дә кушып исәпләсәк, Р. Фәхретдинев каләме белән язылган биографик очеркларның тулаем саны 1500 дән артып китәр иде.

Әлбәттә, бу биографияләрнең һәммәсе дә, автор үзе үк ишарә иткәнчә, тулылык, документальлек җәһәтеннән бертигез дәрәҗәдә түгелләр. Өстәп шуны да әйтергә мөмкин: тәрҗемәи хәлләре бәян ителгән шәхесләрнең дә һәммәсенең эшчәнлекләре тарихыбыз өчен бердәй үк кыйммәткә ия түгел. Шуңа да игътибар итик: беренче мәртәбә Р. Фәхретдинев тарафыннан язылып дөнья күргән, культура тарихыбыз өчен алыштыргысыз дәрәҗәдәге кыйммәтле булган мөһим биографияләр дә «Асарь»да дистәләп табыла. Әйтик, Болгар һәм Казан чорына караган Ягъкуб бине Ногман, Касыйм шәех ише әлгәрге чор шәхесләреннән алып, яңа дәвер мәгърифәтчеләребездән Габденнасыйр Курсави, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри, Шиһаб Мәрҗани, Габделгаллэм Фәезхановлар, шагыйрь һәм әдипләребездән Әбелмәних Каргалы, Шәмсетдин Зәки, Һибәтулла Салихов, Мифтахетдин Акмулла, Дәрдмәнд һәм башкаларга багышланган мәкаләләрне санап чыгу да җитәр иде. Боларның кайберләре культура тарихыбызда әлеге затлар хакындагы гомумән иң тәүге фәнни биографияләр булып торсалар, аларның эшчәнлекләрен өйрәнүне башлап җибәргән беренче гыйльми хезмәтләрне тәшкил итсәләр, икенчеләре алар хакында башка юллар аша туплаган белемнәребезне яңа мәгълүматлар белән баетты. Бер сүз белән әйткәндә, иске дәвер мәдәниятыбыз һәм әдәбиятыбыз тарихын өйрәнгәндә без «Асарь» материалларыннан башка фактографик төгәл һәм фәнни эзлекле рәвештә гамәл итә алмаячакбыз.

Бу катгый төстә әйтелгән хөкемне икенче характердагы материаллар белән дә куәтләп булыр иде. Мәсәлән, элекке вакытларда аерым шәхесләрнең — имам һәм мөдәррисләрнең карамагында булган, шуңа күрә патша хөкүмәте тарафыннан рәсми рәвештә танылмаган, димәк, исәпкә алынмаган бихисап күп эреле-ваклы мәктәп-мәдрәсәләребезнең тулаем санын барламыйча торып, халкыбызның мәгариф тарихын, мәгърифәтчелек фикеренең барлыкка килүен төгәл аңлап булмас иде. Әгәр «Асарь»да элекке мәктәп-мәдрәсәләребез хакында теркәлеп калган материалларны сөзеп алсак, безнең алга шактый кызыклы мәгълүматлар җыелмасы тупланыр иде. «Асарь»дән алынган шушы фактларга меңләгән кулъязмаларыбыздагы һәр китапның кайда күчерелүе хакындагы колофон (кулъязма паспорты) материалларын да кушып карасак, санның сыйфатка әверелүен конкрет мисалда күрер идек.

Шулай ук элек татарлар арасында язылган, күчерелгән күп санлы кулъязма китапларыбызның гомум корпусын булдырыр идек. Үзләре китап килеш мәгълүм, ләкин язылу тарихы караңгы кайбер әсәрләрнең авторларын ачыклау, язылган ел һәм урыннарын төгәлрәк билгеләү өчен дә «Асарь»да китерелгән мәгълүматлардан иркенләп файдаланып булыр иде. «Асарь» китабы фактографик кыйммәте, ягъни документальлек сыйфаты буенча файдаланудан тукталмаячак мәгълүматлар җыелмасы булып калуында дәвам итәчәк.

«Риза Фәхретдинев — тарихчы» дигән зур проблема буенча сүзне хәзергә шушы әйтелгән хәтлесе белән очлап, икенче мәсьәләгә күчик. Чөнки галимнең мәктәп-мәдрәсә тарихларына багышланган зур күләмле гомум хезмәтләрен, хосусый характердагы аерым мәкаләләрен анализлый башласак, тагы үзара килешмәс каршылыкларны ача-ача, яңа мәкалә яза башлар идек.

Төрки телле язма истәлекләрне җыюга, өйрәнүгә, матбугатта пропагандалауга багышланган хезмәтләрне терки барсак, татар, гарәп, фарсы-таҗик әдәбиятларына караган публикацияләрне, шулай ук әдәби тәнкыйть материалларын анализлап, бу катлаулы өлкәләрдәге Р. Фәхретдинев казанышларын, аның бәхәссез ялгышларын тикшеренергә тотынсак, яңа монография өчен бай җирлек туачак.

Бөтенләй икенче максат һәм икенче позициядән торып язылган аның теологик хезмәтләре дә безнең өчен билгеле дәрәҗәдә фәнни әһәмияткә ия. Аның бу өлкәгә караган әсәрләре бездәге дини реформация тарихын этрафлы һәм конкрет өйрәнер өчен бай материал бирә, хәтта дини реформациянең ни-

чек банкротлыкка төшүен дә «җанлы» материалда күрергә булыша. Фәхретдинев-теологның озак еллар дәвамында динне дәүләттән, политикадан аеру хакындагы садә лаф орулары — сыйнфый җәмгыять өчен мөмкин булмаган утопия белән мавыгуы да игътибарга лаек факт.

Икенчедән, аның дини-теологик хезмәтләрен тәнкыйди рәвештә анализлау бүгенге көн атеистик пропагандасы өчен дә кызыклы материаллар бирер иде, чөнки авторның үз хезмәтләрендә клерикализмны, суфыйчылык кебек дини фанатизмны фаш иткән сәхифәләре күп булганы шикелле, анда без ислам дине тарихы буенча башка кулланма һәм белешмәләрдә сирәк очрый торган, хәтта бөтенләй диярлек теркәлмәгән мәгълүматлар да табар идек. Әмма бу конкрет очракта бер мөһим шартны онытмаска кирәк: Р. Фәхретдиневнең дини эшчәнлеген аның дөньяви фәннәр өлкәсендәге иҗаты белән бутамау, ягъни ашлык бөртекләрен кибәк белән бергә ташламау шарт.

Кыскасы, безнең алда дөньяга карашы буенча да, калдырган мирасы җәһәтеннән дә гаҗәп каршылыклы, иҗаты белән бәхәссез казанышларга ирешкән, дини эшчәнлеге ягыннан төпсез сазлыкка баткан чын мәгънәсендәге трагик шәхес — ихлас хөрмәт белән объектив тәкъдиргә дә, ачы кызгану белән кискен тәнкыйтькә дә берьюлы лаек шәхес. Шуңа күрә аның шәхесе, кеше буларак үзенчәлеге хакында да берничә сүз әйтмәсәк, хөкемебез ачык, фикеребез төгәл булмас.

## VII

Риза Фәхретдинев, шәхес буларак, һәм бик гади, һәм гаять катлаулы иде. Урта буйлы, чандыр гына җыйнак гәүдәле, кара-кучкыл йөзле бу кешенең крестьяннарча гадәти кыяфәт-чырае, татарча кечкенә сакалы, безнең элекке урта хәлле агайлар кияргә яраткан кырпулы бүреге, камзулы, җиләне — һәммәсе дә табигый гадилекне бөркеп торган кебек тоелса да, асылда аның үтә нечкә фикерләүгә, фикердә исә киң колач белән йөзүгә сәләтле аң-зиһенендә бер дә туктамыйча катлаулы интеллектуаль процесслар бара иде.

Көндәлек тормышында үзен ул бик гади тоткан, затлы кием-салым белән һич тә мавыкмаганы, гел архаик кыяфәттә киенгәне хәлдә туганнарының, бала-чагаларының «урысча», ягъни европача киенүләренә һич тә каршы килмәгән; «Дин вә мәгыйшәт» журналы әһелләренең гел әзәрлекләп торуларына, башка «мөгътәбәр мөселман агай-энесенең» дә тәнбиһ-шелтәләренә карамыйча, балаларын гимназияләрдә укыткан, рус мәктәпләрендә, рус уку йортларында оештырылган әдәби кичәләргә җибәргән.

Кеше белән мөгамәләдә үтә йомшак, бер вакытта да тавышын күтәреп бәхәсләшмәс, кычкыру-җикеренүне белмәс, һич тә кызмас, иң каты ачуланган чагында да «һай... һай!..» дип сыкранудан ары узмас, җәмәгатьчелектә гаҗәеп йомшак холыгы белән танылган бу корректлы кеше шул ук вакытта фикер һәм идеяләр белән мавыгып яшәүгә, темпераментлы китап-мәкаләләр язуга, әрептәшләре белән принципиаль бәхәсләрне озак еллар дәвам иттерергә дә сәләтле иде. Дөрес, бәхәс һәм полемикада ул үзенең тактын, әдәбен югалтмый, үзе тугры дип тапкан позициясендә нык торганы килеш, оппонентларының фикерен тыңларга урын калдыра, хәтта үз фикеренә тәмам каршы килгән әрептәшләренә дә иркенләп сөйләргә, бәхәсләшергә үз журналында мөмкинлек бирә. Мәсәлән, «Шура»да чын идеалист Фәхретдиневнең иманына, идеалына бөтенләй каршы килә торган материализмны, хәтта революцион идеяләрне пропагандалауга багышланган мәкаләләрнең шактый күп басылуын редакторның шушы сыйфаты, ягъни аның фикер алышуга, киңәшүгә ихтирамы белән аңлатып булыр сыман [1]. Ахыр чиктә аның Ибне Рөшд, Ибне Хәлдун кебек материалистлар хакында, аларның төп концепцияләрен кабул итмәгәне хәлдә, эзлекле рәвештә ихтирам белән язуы да галимнең полемика мәсьәләсендә аерым фәлсәфи этикага ия булуын расласа кирәк.

[1] «Шура»да басылган моның ише материаллар хакындагы кайбер кыскача мәгълүматларны профессор Я. Абдуллинның махсус мәкаләсеннән дә күрергә мөмкин. Карагыз: «Казан утлары», 1983, 6 сан, 147—158 бб.

Һәрхәлдә, элек-электән үк Р. Фәхретдиневнең шәхесенә карата татар җәмәгатьчелегендә мәгълүм ихтирамлы карашның нык урнашуын шуларны исәпкә алганда гына аңларга мөмкин (хәтта иң үткен телле тәнкыйтьче Г. Тукай да, «Шура»да басылган кайбер материалларны теттереп сүккәне хәлдә, Р. Фәхретдиневнең адресына карата үзен тыйнак һәм әдәпле тота, күп вакытта аңлы рәвештә аның шәхесенә бәрелүдән тыелып кала). Галимгә карата мондый мөнәсәбәт, кайбер вульгар сүгенүләрне исәпкә алмаганда, революциядән соң да дәвам итте.

Соңгы вакытларда галимнең мирасына карата игътибарның көчәя төшүенә, аның хакта электән яшәп килә торган тулаем негатив мөнәсәбәтнең шик астына алына башлавына да төп этәргеч иң элек үзенең бай архив мирасы булды. Чөнки соңгы елларда аңардан калган архив материаллары белән якыннан танышу элекке дәвер рухи культурабыз тарихын өйрәнү юлында Фәхретдинев туплап калдырган материаллардан башка тулы канлы фәнни бер адымның да мөмкин түгеллеген күрсәтте. Икенчерәк төрле итеп әйткәндә, Риза Фәхретдиневнең язма истәлекләргә булган олы ихтирамы аның үз мирасына карата да объектив игътибарны таләп итте.

Татар мәгърифәтчелегенең тәмамланмаган процесс хәлендә кала килүе, ягъни аның актуальлеге гасырыбыз башында да көн кадагыннан төшмәве Р. Фәхретдинев эшчәнлегенең көчен, колачын, бу эшчәнлекнең уңай эчтәлеген тәэмин итте. Әмма буржуаз-демократик хәрәкәтне сыйнфый көрәш узып китүе, элек бар кебек тоелган «милли бердәмлекнең» күз алдында җимерелүе, боларның иҗтимагый аңы күптән формалашкан шәхес өчен аңлашылып җитмәве Р. Фәхретдинев эшчәнлегенең консерватив, хәтта ачык реакцион өлешен барлыкка китерде. Димәк, аның эшчәнлегендәге бу тирән каршылык абстракт фикер йөртүче шәхес белән конкрет законнар нигезендә үсүче, үзгәрүче иҗтимагый тормыш арасында туган конфликтка кайтып кала икән.

Шулай итеп, җыеп әйткәндә, тарихчы, археограф, журналист, педагог, әдип, ориенталист, теолог, дини философ Ризаэтдин бине Фәхретдиннең күпкырлы эшчәнлеге, бай мирасы, моңарчы бирәүләр тамгалап килгәнчә, гел тискәре сыйфатлардан, яисә, кайберәүләр тырышканча, тулаем уңай хосусиятләрдән гына тормый икән. Ул чыгарган басма хезмәтләр белән эшләп бетергән кульязма китапларда да, бергә җыеп, саклап калдырган документаль истәлекләрдә дә тегеяки бу карашны куәтләп чыгар өчен материаллар күп табылыр. Шуңа күрә Р. Фәхретдинев тирәсендә бәхәсләрнең киләчәктә дә булуы бик ихтимал. Тик бер мөһим шартны гына онытмыйк: узган чор культура вәкилләренең мирасларын өйрәнүдән безнең максат аларны күккә чөеп мактау, яки гел җиргә салып таптау түгел, ә тарихи дөрес аңлау һәм җәмәгатьчелеккә тәфсилле аңлату.

. . . . . . . . . . . .

## Әнвәр Хәйруллин

# ГАЛИМНЕҢ КУЛЬЯЗМА МИРАСЫ

Татар әдәбияты, мәдәнияты һәм иҗтимагый фикер үсешендә XIX йөз зур борылыш чоры булып тора. Бу чорда Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри кебек күренекле фикер ияләре, татар халкын гасырлар буенча дәвам итеп килгән торгынлык хәләтеннән куэгатып, тар, милли кысалар йомыклыгыннан чыгарып, гомумкешелек мәдәнияте белән якынрак таныштыру өчен үзләренең бөтен көчен, сәләтен һәм гомерен багышлаган фидакарь мәгърифәтчеләр яшәгәннәр. Алар һәртөрле эзәрлекләүләргә карамастан, халыкка турылыклы булып калганнар. Г. Курсави, чорына

күрә «коточкыч дәһри» саналган фикерләре өчен үлем җәзасына хөкем ителсә дә, качып котылып, халыкны һаман аң-белемгә өйрәткән. Ш. Мәрҗани, байлар һәм реакцион карашлы руханилар тарафыннан төрле каршылыкларга һәм кысрыклауларга дучар булса да, бөтен гомерен халыкны агартуга, фәнгә багышлаган. Х. Фәезханов та, үз чорындагы бөтен кыенлыкларны җиңеп, мәгърифәтнең үсү һәм чәчәк атуы өчен көрәшә. К. Насыйри шулай ук, милләтче байлардан, муллалардан төрле кимсетүләрне күп кичерсә дә, үзенең изге эшеннән туктамаган. XIX гасыр азагында менә шушындый үңдырышлы җирлектә, остазларының гаять авыр һәм мактаулы, күркәм һәм дәрәҗәле эшен дәвам итәргә дип, Риза Фәхретдинев мәйданга килә.

Татар халкының күпкырлы галиме, мәгърифәтче, философ, тарихчы Ш. Мәрҗани көнчыгышның урта гасыр галиме Ибне Хәлдунның «Мөкаддимә» («Кереш») әсәре үрнәгендә төзегән био-библиографик хезмәтен — «Вафият әл-әслаф вә тәхият әл-әхлаф» («Бабайларның үлеме һәм киләчәк буыннарга бүләк») исемле, гаять дәрәҗәдә кыйммәтле, алты томлык кульязма әсәрен безгә мирас итеп калдырды. Бу хезмәттә — борынгы грек философларыннан алып, мөселман илләренең, төрки халыкларның, Россиянең күренекле шәхесләре, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, галимнәр, язучылар, аларның эшләгән эшләре, язган әсәрләре турында тирән мәгълүматлар бирелә. Мәрҗанинең бу олы хезмәтен аның лаеклы алмашчысы, күренекле мәгърифәтче галим, язучы һәм журналист Риза Фәхретдинев дәвам итте. Аның күп томлы, танылган «Асарь» исемле хезмәтендә, тарихи эзлеклелектә һәм хезмәтләре дәрәҗәсе буенча борынгы Болгар чорыннан алып XX йөз башына кадәр булган бик күп шәхесләр турында кыйммәтле мәгълүматлар китерелә. «Асарь»нең беренче ике томы XX йөз башында басылып бик тиз таралып бетә, ә калган өч томы һәм барлык томнарның эчтәлеген тәшкил иткән тагын бер томы әле матбугатта басылмаганнар. «Асарь»не иҗат иткәндә Р. Фәхретдинев гаять күп чыганаклардан файдаланган һәм аларның барысын да туплап калдырган.

Р. Фәхретдинев — тарих, педагогика, тел белеме, әдәбият, философия, сәнгать, география, этнография, генеология, эпитафия, медицина, нумизматика, юриспруденция, халык авыз иҗаты, дин тарихы һәм башка төрле фәннәр белән тирәнтен кызыксынган, алар буенча төпле, тирән эчтәлекле хезмәтләр язган галим. Ул гарәп, төрек, фарсы, рус телләрен яхшы белгәнгә теләсә нинди чыганактан бик иркен файдаланган, шуңа күрә аның әсәрләре арасында гарәп телендә язылганнары да бар. Матбугатта басылган бик күп китаплары һәм мәкаләләреннән тыш, зур фәнни әһәмияткә ия булган 40 том басылмаган, кульязма мирас һәм аерым кулларда сакланып калган күп кенә язмаларны исәпкә алсак, аның чын мәгънәсендә Фән батыры икәнлеге ачык аңлашыла.

Бу юлларның авторына Р. Фәхретдиневнең югарыда атап узган кульязма мирасының 40 томы һәм аерым кулларда саклanучы байтак язмалары белән якыннан танышырга туры килде. Р. Фәхретдинев үзенең бөтен кульязма архивын һәм 2000 томнан артык тәшкил иткән шәхси китапханәсен үз вакытында Диния назараты архивына тапшырган булган. Гомеренең соңгы елларында, күп илләргә танылган галимнең кульязмаларын Вена Фәннәр Академиясенә сатуын үтенеп бик үгетләп йөрүчеләр булган. Ләкин, матди кысынкылык кичерсә дә, үз иленең патриоты булган галим бу юлга басмый. Көнчыгышны өйрәнүче күренекле галим, академик А. Н. Самойлович үтенүе буенча, кульязмаларның шактый өлешен СССР Фәннәр Академиясенең көнчыгышны өйрәнү институты Ленинград бүлеге архивына тапшыра һәм алар бүгенге көндә шунда саклаyалар.

Р. Фәхретдиневнең иҗатын өйрәнүгә җитди караш булмау сәбәпле, аның мирасы белән кызыксыну бары тик 60 нчы елларда гына башлана. Тарихчы галим Миркасыйм Госманов 1966 елда, әле аспирант чагында, Диния назараты архивында эзләнүләр алып барганда Р. Фәхретдинев фондына юлыга һәм бу турыда СССР Фәннәр Академиясенең Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институты җитәкчеләренә хәбәр итә. Соңыннан бу кульязмаларның 24 томы алар архивына алына. Хәзерге көндә әлеге фонд — СССР Фәннәр Академиясенең Башкортстан

филиалы архивында 7 нче фонд, 1 нче тасвирлама 1—24 берәмлекләр булып хисаплана. Кульъязмаларның сакланышы әйбәт, алар ачык һәм матур итеп язылганнар. Р. Фәхретдиневнең фәнни-иҗади эшчәнлеге турында дөрес һәм тулырак караш тусын өчен, әлеге 24 томлык кульъязма фондның кыскача эчтәлеге белән танышу да җитә.

Р. Фәхретдинев, нәселдән килгән пөхтәлек һәм тегәллек белән, мәдрәсәдә укыган елларында ук үзенең язмаларын тәпләп барган һәм күп төрле фәннәр белән кызыксынган. Ул елларда мәдрәсәләрдә төп фәннәр гарәп телендә укытылганнар. Башлангыч сыйныфларда гарәп теле өйрәтелгәнлектән, Р. Фәхретдиневнең кульъязмалары арасында гарәп теле грамматикасына багышланганнарын күп очратырга мөмкин. 1, 2, 8 һәм башка томнарда алар шактый урын алганнар.

Мәдрәсәләрдә бәлягать[1], мантыйк[2], кәлям[3], дини фәлсәфә, дин тарихы, фикыһ[4] фәннәрен укытуга җитәрлек игътибар бирелгән булган, һәм шуның нәтиҗәсендә югары сыйныф шәкертләре күп төрле мәсьәләләр буенча бәхәс алып барырга да өйрәнгәннәр. Сәләтлерәк кешеләр мәдрәсәдә шушы фәннәр буенча төпле гыйлем алып чыгып, соңыннан үзләре шул фәннәр буенча зур белгечләр булып җитешкәннәр. Р. Фәхретдинев тә бу фәннәрне нигездән өйрәнеп, конспектлар төзеп һәм җентекле анализлап барган. Болар турында мәгълүматларны без 1—6, 9, 13, 16, 17 һәм башка томнардан таба алабыз.

Р. Фәхретдинев яшьтән үк шигърияткә ярatkанга күрә, күп төрле билгесез һәм билгеле авторларның шигъри әсәрләрен күчереп алып барган һәм алар турында үзенең фикерләрен язып калдырган. Ул гарәп, фарсы, төрки телләрдәге шигырьләр белән бер-рәттән, күренекле татар шагыйрьләренең шигырьләрен күчереп, җыйнап барган. Әдәбият, тел, сәнгать һәм мәдәният мәсьәләләренә багышланган күп төрле язмалар, зур әдипләрнең иҗатларын һәм тормыш юлларын өйрәнүгә багышланган мәкаләләр, фәнни эзләнүләр Р. Фәхретдиневне бу өлкәдә дә зур белгеч итеп таныталар. Аның кульъязмалары арасында, бигрәк тә 2, 4, 8, 11 томнарда, исемнәре билгесез төрле әдипләрнең әсәрләре очраса, 4, 9, 10 томнарда исә Әбелмәних Каргалы, Һибәтулла Салихов, Утыз Имәни, Каюм Насыйри кебек күренекле шагыйрь һәм мәгърифәтчеләребезнең әсәрләре урын алган. «Асарь»нең матбугатта басылмаган өченче томын тәшкил итүче 12, дүртенче — өстәмә томын тәшкил итүче 14 һәм «Асарь»не язганда файдаланылган чыганаклардан тупланган 15 томнарда Гали Чокрый, Акмулла, Дәрдмәнд һәм башкаларның шигырьләре, хатлары, иҗади эшчәнлекләре һәм тормышлары турында язмалар бик күп.

Тарихчы галим буларак та Р. Фәхретдинев күп эш башкарган. Бу өлкәдә дә тирән белемле галим булганлыгын, аның борынгы язулы таңкалар (23 том) һәм кабер ташларыннан күчерелгән язмаларны (10 том) җентекләп өйрәнүе, борынгы Болгар чорындагы галимнәрнең әсәрләре белән кызыксынып, үзе дә зур күләмле тарихи хезмәтләр язуы ачык мисал булып тора. Ул яшь вакытында ук Болгар чорындагы галимнәрнең исемнәрен ачыклап, аларны теркәп барган (8 том). Соңрак Казан, Мәскәү, Уфа[5] шәһәрләренең һәм Диния назаратының кыскача тарихларын язган (9 том). Үзенең рухи остазы Ш. Мәрҗани әсәрләрен дә ныклап өйрәнеп, аларның күчермәләрен Р. Фәхретдинев үзендә булдырырга тырышкан. Шуңа мисал итеп, 10 томга тәпләнгән «Мөстафад әл-әхбар...» исемле тарихи хезмәтнең икенче томының тулы күчермәсен күрсәтергә була. Бу әсәрнең беренче томы Казанда ике тапкыр (1895 һәм 1897 елларда) ә икенче томы бер генә тапкыр (1900 елда) басыла. Димәк, галим аны басылып чыкканчы, кульъязма хәленнән, үзе язганча Һиҗри 1312, милади 1894 елда күчереп алган булып чыга һәм бу — Ш. Мәрҗанинең Р. Фәхретдинев иҗатына турыдан-туры һәм көчле йогынты ясавына ачык бер дәлил булып тора.

---

[1] Бәлягать — тел байлыгы, матур сөйләм күнекмәләре.
[2] Мантыйк — логика.
[3] Кәлям — догматик дини тәгълимат.
[4] Фикыһ — мөселман юриспруденциясе.
[5] «Уфа» сүзе — «Уба» (биек урын) мәгънәсендә йөри һәм ул шәһәр 1584 елда салынган,— дип күрсәтә Р. Фәхретдинев.

X гасырның күренекле гарәп сәяхәтчесе, борынгы Болгар дәүләтенә килгән Ибне Фазланның юлъязмаларын Р. Фәхретдинев беренче буларак татар теленә тәрҗемә итеп (18 том), тарихыбызны өйрәнүгә үзеннән зур өлеш керткән. XIII гасыр галиме Якут Хәмәвинең «Мөгъҗәм әл-Бөлдан» («Илләр сүзлеге») әсәренең беренче кисәге күчермәсенә дә (11 том) үз әсәрләрен язганда еш мөрәҗәгать иткән ул. Диния назаратының бөтен халыкка, «авыл тарихларын язып назаратка җибәрүләрен үтенгән мөрәҗәгате»нә җавап итеп язылган. Мөхәммәт Нәҗип Түнтәринең «Түнтәр авылы тарихы», анда булган мәчетләр, имамнар, бигрәк тә «Ишми ишан» — карагруһ Ишмөхәммәт Динмөхәммәтовның тормышы, реакцион карашлары турында тәфсилләп язылган язмалар (13 том), Троицкидагы мәчетләр тарихы (24 том) һәм башка бик күп чыганаклар — «Асарь»не язганда файдаланылганнар. Гаять күп чыганакларны өйрәнеп, Р. Фәхретдинев фәнебез өчен зур әһәмияткә ия булган «Болгар тарихы» дип аталган күләмле хезмәтен яза. Ләкин, кызганычка каршы, ике зур-зур кисәктән торган 16 нчы томның беренче кисәге, аңлашылмый торган сәбәпләр аркасында юкка чыккан. 1966 елда Диния назаратыннан алганда, ул вакыттагы СССР Фәннәр Академиясенең Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институтының директор урынбасары Ә. Харисов, Башкорт дәүләт университеты укытучысы З. Шакиров, Башкортстан Министрлар советы каршындагы дин эшләре советы вәкиле Ардуванов иптәшләр тәэзгән 24 томлык кулъязмалар исемлегендә бу — «Болгар тарихы» күрсәтелгән, ә СССР Фәннәр Академиясенең Башкортстан филиалы архивына кабул ителгән исемлектә күрсәтелмәгән. Шулай итеп, фән өчен гаять кыйммәтле тарихи чыганак эзсез югала. Бу — әлбәттә, бик сәер һәм аяныч күренеш.

Шул ук томның «Юаныч» дип исемләнгән икенче кисәге — эчтәлеге белән бик кызыклы. Р. Фәхретдиневнең чын мәгънәсендә күпкырлы галим булганлыгына ышаныр өчен, биредә ул күтәргән мәсьәләләрнең исемнәре белән генә танышып чыгу да җитә. Түбәндә күрсәтеләчәк һәр мәсьәлә буенча ул төпле һәм тирән мәгънәле фикерләр язып калдырган. Менә «Юаныч»та күтәрелгән кайбер мәсьәләләр: әхлак, тәрбия, тормыш-көнкүреш, гаилә, никах, дуслык, дошманлык, сугыш, тынычлык, хөкүмәт һәм аның җитәкчеләре, дәүләт эшлеклеләре, борынгы һәм бүгенге вакытларда ислам хөкүмәтләренең тәхет, мәркәз шәһәрләре исемлеге (алфавит тәртибендә), суд эшләре (казыйлар турында мәзәкләр белән), коллык, хөррият, ислам (гарәп) сәяхәтчеләре, шималь (болгар, Ә. Х.) төрекләреннән булган үз сәяхәтчеләребезнең сәяхәтнамәләре, шагыйрьләребезнең җырулары һәм шигырьләре (халык җырлары, Ә. Х.), зыяфәт — туй, кунак булу, кунак итү һәм боларның әдәпләре, ашау-эчү әдәпләре, тәмәке һәм аракының зарары, яхшы холыклар, бозык һәм яман холыклар, милләт, фәлсәфә һәм аның тарихы, галимнәрнең тәрҗемәи хәлләре турында әсәрләр, һава, кояш, дин турында, ысул җәдидә, шималь төрекләрендә гыйлем тәхсыйль итү рәвеше, хатирә дәфтәрләре, хикәятләр, кабер ташларындагы, язмалар, дөнья турында һәм башка язмалар...

Көнчыгышның Ибне Тәймия (17 том), Ибне Гарәби (13 том), Җәмалетдин Әфгани (9 том) кебек башка бөек шәхесләргә багышлап та Р. Фәхретдинев күп әсәрләр иҗат итә.

Татар халкының бөек уллары, мәгърифәтче галимнәр Г. Курсави һәм Ш. Мәрҗани иҗатлары, аларның тормышлары турында тирән мәгълүматлар, аларга язылган хатлар, мәрсияләр «Асарь»нең өченче томы исәпләнгән 12 томда, «Асарь»нең дүртенче — өстәмә томында (14 том) Мәрҗанинең Х. Фәезхановка язган хатлары, Мәрҗанинең үзенә язылган хатлар, аның турында истәлекләр, китапханәсенең аяныч язмышы турында язмалар бик күп. Р. Фәхретдинев үзенең иҗатында Ш. Мәрҗанигә шул кадәр күп урын бирә ки, аның кулъязмаларының 19 нчы томы тулысынча Ш. Мәрҗанигә багышланган. Биредә бу зур галимнең борынгы Болгар чорыннан килә торган нәсел агачы — шәҗәрәсе бирелә. Г. Тукай Мәрҗанигә багышлаган мәрсиянең күчермәсе, Х. Фәезханов язган хатларның күчермәләре, Мәрҗанинең тарихи эшчәнлеге турында, мишәрләрнең турыдан-туры борынгы Болгарлардан, ә башкортларның финнардан барлыкка килү-

ләре турындагы язмалар, Йосыф Дагыстани, Гали Чокрый мәрсияләре һәм башка төрле язмалар тупланган.

Ш. Мәрҗанинең Г. Курсави турында язылган «Тәнбиһ әбнаэ әл-гаср галя тәнзиһи әнбаэ Әбү ән-Насыр» («Габденнасыйр (Курсави) фикерләренең дөресле- ген заман кешеләренә искәртү») әсәре һәм Г. Курсавиның «Әл-иршад лил-гибад» («Кешеләрне туры юлга күндерү» әсәре турында Ш. Мәрҗани язмасы (21 том), Ш. Мәрҗанинең «Назурәт әл хак...» («Дөреслекне күрсәткеч...») әсәре хакында язмалар да (24 том) зур фәнни әһәмияткә ия булып торалар.

Кулъязмалар арасында берничә том (21, 22, 23 томнар) «Төрле хатлар»дан тора. Эчтәлекләре белән алар бик кызыклы һәм күп төрле шәхесләргә карыйлар. Мәсәлән, «Ишми ишан», Акмулла, Г. Чокрый, Ш. Көлтәси хатлары, мөфти Мөхәммәдьяр Солтановка язылган хатлар, доностар (15 том), Х. Фәезханов, Ш. Мәрҗани (14 том), Дәрдмәнд, Г. Гобәйдуллин, Вамбери (23 том) хатлары һәм башка бик күпләр «Асарь»не язганда файдаланылганнар.

Р. Фәхретдиневнең кулъязма мирасы 40 том күләмендә СССР Фәннәр Академиясенең Башкортстан филиалы архивында саклана дип әйтелгән иде инде. Берничә ел сөйләшүләр алып барганнан соң, 1980 елның июнендә тагын 16 том кулъязма әсәре Диния назаратыннан алынып, элеккеләре янына кушылды. Әлеге 16 томны Диния назаратыннан алуда Р. Фәхретдиневнең Казанда яшәүче кызы Әсма апа Шәрәфнең тырышлыгы зур булды.

Ләкин бу 16 томга әлегә кадәр фәнни тасвирлама төзелмәве һәм фәнни эшләнешкә керүенә комачаулык иткән кайбер сәбәпләр аркасында аларның тулы эчтәлеге яки тасвирламасы белән таныштыру мөмкинлеге булмаганлыктан, Диния назаратыннан алган вакытта карап чыгып, күчереп алган исемлеген генә тәкъдим итә алам. Менә алар: 1) Мәшһүр хатыннар, 2) Казан шәһәрендә булган ислам нәдвәсе (съезды — Ә. Х.), 3) «Асарь»нең 5 нче томы, 4) «Асарь»гә тәгальлекле (бәйләнешле — Ә. Х.) фиһрист (эчтәлек — Ә. Х.). Бу том — «Асарь»нең барлык томнарының эчтәлеген тәшкил итүче 6 нчы том, 5) Гарәп телләре вә аның галимнәре, 6) Һәр төрле мәктүбләр вә кәгазьләр мәҗмүгасы, 7) Ислам дине, 8) Ислам дине, 9) Ислам дине, 10) Ислам дине (русчага тәрҗемәсенең кулъязмасы), 11) Ислам дине (русчага тәрҗемәсенең машинкада басылганы), 12) Ибне Рөшд, Әбү әл-галя әл-Мәгарри, Имам Газали, Ибне Гарәби, Ибне Тәймия, Әхмәд Мидхәт, Шәех Җәмалетдин кебек көнчыгышның танылган галимнәре турында, 13) Болгар вә Казан төрекләре, 14) Мөхәммәд Хәсән Акчура тәрҗемаи хәле, 15) Һәртөрле мәүзугларда (темаларда — Ә. Х.) язылган кәгазьләр мәҗмүгасы, 16) әл-Бәлягы әл-мөбин (4 томның 1 нче томы).

Р. Фәхретдиневнең иҗади тормышын яктыртучы чыганаклар, әлбәттә, югарыда санап үтелгәннәр белән чикләнми, алар әледән-әле табылып торалар. Узган елны Диния назаратының китапханәсендә эшләп утырганда бер китапка юлыктым, тышына 97 номеры куелып, «Риза Фәхретдинев кулъязмасы» икәнлеге күрсәтелгән. Игътибар белән карый төшкәч, бу китапның башында һәм азагында барысы 16 бите Р. Фәхретдинев кулы белән язылган, ә китапның төп өлеше — Ш. Мәрҗанинең 1886 елда Казанда ташбасма ысулы белән басылган, «Әл-газбе әл-фурат вә әл-маэ әз-зәлал фи шәрхи әл-җәлал» («Җәлал» шәрхенә карата татлы һәм саф сулар» (дөрес фикерләр) исемле, татар укымышлылары арасында яңа фикер һәм карашлар тууына күп тәэсире булган, һәр битендә Мәрҗанинең үз кулы белән өстәмәләр язылган, бик сирәк очрый торган китабы икәнлеге ачыкланды. Р. Фәхретдинев бу китап турында фикерләрен, аннары «1886 елда Казанга баргач, Мәрҗани хәзрәтләреннән шул китабын бирүен үтенгәч, матбугатта басылып чыккан, хаталарын төзәткән беренче нөсхәсенә язып бүләк итеп бирде» дип язып куйган. Шуны раслап язылган бер кечкенә кәгазьдә Мәрҗани кулъязмасы да бар. Бу уникаль табыш — Ш. Мәрҗани белән Р. Фәхретдинев арасында нинди зур иҗади дуслык булганлыгына үзе бер дәлил булып тора. Фән аксакалы Мәрҗанинең, үзенә лаеклы алмаш булырлыгына ышанып, фәндә яңа адымнар ясый башлаган Р. Фәхретдиневкә хәер-фатихасын, изге теләкләрен юллавын ачыклый бу кыйммәтле чыганак.

Р. Фәхретдиневнең язмалары, кайбер әсәрләре халыкта кулдан-кулга күчереләп тә йөриләр. Шундыйларның берсе «1925 елның 11 нче гыйнварында Уфа шәһәр комитетына сайланган котлугъ татар егетләренә һәм гомумән бүген эш башында торучы иптәшләргә ачык мәктүб» дип исемләнгән. Бу ачык хатны Р. Фәхретдинев, Уфа шәһәр комитетының, «Диния назараты һәм назаратның архивы саклана торган таш биналарны кичекмәстән бушатырга» дигән боерыгы уңае белән бу архивның киләчәк буыннар өчен гаять әһәмиятле фәнни чыганак булачагын, аны ничек кенә булса да саклап калырга кирәклеген аңлатып, дәлилләп, 18 бит күләмендә язып мөрәҗәгать итә һәм шуның белән фән өчен бәяләп бетергесез әһәмиятле, 1963 һәм 1966 елларда Башкортстан Үзәк Дәүләт архивына, И-295 номерлы фондка тапшырылган 68250 берәмлек архив чыганагының бөтенләйгә юкка чыгуын булдырмый кала. Р. Фәхретдиневнең шушы олы хезмәте генә дә фәнни һәм гражданлык батырлыгы булып тора.

Р. Фәхретдиневнең күпкырлы фәнни эшчәнлеген җентекләп һәм тирәнтен өйрәнү, аңа лаеклы бәя бирү, фән өчен гаять кыйммәтле кулъязма мирасын өйрәнү — фәнни хезмәткәрләрнең изге бурычы һәм бу эш бик күп галимнәрне көтә.

# РИЗА ФӘХРЕТДИНЕВНЕҢ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ ХАЛЫКАРА ИМИНЛЕК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

## ДОКУМЕНТЛАР

Галим Р. Фәхретдинев совет власте елларында мөселман дөньясында талау сугышларына, колониализм режимына каршы зур активлык белән көрәш алып барган кеше. Бу көрәштә ул үзенең руханилар, дингә ышанучылар арасындагы авторитетына таянган һәм үзенең эшчәнлегендә һәрвакытта да совет дәүләтенең күренекле эшлеклеләренә мөрәҗәгать иткән. Түбәндә шуларны раслый торган берничә документ китерелә [1].

1925 елның 31 октябрендә Мәскәүдә СССРның Революцион Хәрби Совет председателе, Хәрби һәм Диңгез Эшләре буенча халык комиссары, Хезмәт һәм Оборона Советы әгъзасы күренекле полководец М. В. Фрунзе үлә. Шул көннәрдә Мәскәүгә ВЦИК (БҮБК) адресына Р. Фәхретдинев түбәндәге телеграмманы җибәрә [2]:

«ВЦИК, Кремль, Москва.

Выражаю глубокое соболезнование верующих мусульманских масс РСФСР по случаю смерти славного вождя армии, освободившей трудящихся СССР от гнета. Мы уверены, что рабоче-крестьянская армия выдвинет новых Фрунзе, которые помогут восточным народам в борьбе за освобождение». 4.XI. 1925».

Шул ук вакытта Р. Фәхретдинев мөселман дөньясының теләсә кайсы почмагында кабынган сугыш учакларын күзәтеп барган һәм мөселманнарның моңа каршы протестын белдерә килгән.

Бөек Октябрь Социалистик революциясенең йогынтысы астында гарәп илләрендә, шул исәптән Мисырда да, милли азатлык хәрәкәте башлана. Инглизләргә каршы Мисырга азатлык таләп итү дулкыны күтәрелә. Мисыр коммунистлары, социалистларының Каһирәдә, Искәндәриядә, Порт-Сәгыйттә беренче группалары барлыкка килә. 1922 елда Мисыр Коммунистлар партиясе төзелә. Илдә азатлык хәрәкәте көчәя. Бу хәрәкәттән куркып калган Бөекбритания дәүләте Мисырга

[1] Документларны җыйды һәм журнал өчен әзерләде — Мөхәммәт Мәһдиев.
[2] Чор һәм тел үзенчәлекләрен саклау өчен телеграмма текстлары оригиналдагыча бирелде.

протектораттан баш тарта. Әмма, Мисырда үзенең хәрби көчләрен калдыра. Англия капиталы да әлегә үзенең хакимлеген саклый. 1924 елның сентябрь-октябрь айларында Мисырның яңа хөкүмәте Англия кораллы көчләрен Мисырдан һәм Суданнан чыгармакчы булып хәрәкәт башлый. Бөекбритания 1924 елның ноябрендә Мисыр хөкүмәтенә ультиматум куя: Суданнан бик тиз генә Мисыр гаскәрләрен чыгаруны таләп итә. Мисыр хөкүмәте моннан баш тарткач, Бөекбритания хәрби хәрәкәт башлый, Мисыр гаскәрләренә каршы ут ача, Искәндәрия шәһәрендәге таможняны басып ала. Корбаннар, кан кою башлана. Р. Фәхретдиневнең телеграммасы:

«1924, 17 ноября в ВЦИК Советского Союза.

Мусульмане СССР глубоким возмущением следят за наглым поступком английских империалистов по отношению мирному египетскому народу. Выражая свой протест, призываем мусульман, порабощенных Англией колоний, теснее сплотившись дать отпор новому посягательству лордов на самостоятельность мусульман Египта, а мировой пролетариат — оказать активную помощь трудящимся Египта, борющимся за свое освобождение и независимость. Пусть знают империалисты всего мира, что недалеко то время, когда Восток поднимется, и настанет час расплаты».

Әмма, дөньядагы империализм бер үк максат, бер үк төс белән яши. Инглизләр Суданда, Мисырда башбаштаклык эшләгәндә француз империалистлары да тик ятмый. Алар да Сүрия халкының милли азатлык хәрәкәтенә каршы туплар, самолетлар әзерлиләр. 1925 елның 18 июнендә Сүриядә французларга каршы милли азатлык восстаниесе күтәрелә. Бу хәрәкәткә Сүриянең эшчеләре, феллахлары, милли интеллигенция катнаша. Баш күтәрүчеләр дүрт меңләп француз гаскәрен тар-мар кылып, берничә шәһәрне азат итәләр. Бу восстание гомумсүрия восстаниесенә әйләнә. 1925 елның 14 нче октябренда баш күтәрүчеләр Дәмәшкъ шәһәренә килеп керәләр. Ләкин француз генералы Садрай шәһәрне котчыккыч рәвештә бомбага тота. Баш күтәрүчеләр күп корбаннар биреп шәһәрне калдырырга мәҗбүр булалар.

Р. Фәхретдиневнең телеграммасы:

«Председателю ВЦИК Калинину; копия Наркоминдел, Кремль, Москва.

Последнее злодеяние французских генералов в Дамаске, известие о котором встречено глубоким возмущением мусульман СССР, является новым доказательством хищнического отношения империалистов к мусульманским народам. Акты зверства в виде бомбардировки мирного города, убийства женщин и детей французскими империалистами, мы уверены еще более укрепит объединение угнетенных народов Востока вокруг лозунга борьбы за освобождение и сближение с Советами и послужит скорейшей гибели групп, превративших Францию из страны прав человека — гражданина в страну убийц, грабителей.

Просим довести наше глубокое сочувствие сирийскому-арабскому народу».

Мөселман руханиларының Бөтенроссия съезды халыкара хәлнең аеруча катлаулы көннәренә туры килә. 1926 елның 25 октябреннан алып 4 ноябрена кадәр Уфада киңәшкән бу мәҗлеснең документлары, шулай ук Р. Фәхретдиневнең Совет хөкүмәтенә мөнәсәбәтен ачыклауга нигез була ала.

«Председателю ВЦИК тов. Калинину, Москва.

Всероссийский съезд мусульманского духовенства и уполномоченных приходов шлет председателю ВЦИК тов. Калинину искренний привет. Съезд пользуется случаем выразить от имени всех мусульман благодарность и преданность Советской власти, защитнице угнетенных народов Востока и обещает поддержать советскую власть в ее мероприятиях по укреплению завоеваний революции».

СССР Чит Ил Эшләре Халык Комиссары Чичеринга:

«Съезд заявляет перед всем миром, что советская власть, начертавшая на своем знамени защиту угнетенных народов от хищничества империалистических держав, является бескорыстной защитницей их во имя справедливости и гуманности. Съезд вполне уверен (что) мусульманские народы поймут, что их освобождение, культурно-экономическое развитие зависит от тесного объединения мусульманского мира с пролетарским миром во главе его советской власти.

Шундый ук эчтәлекле терерграмма Хәрби һәм Диңгез Эшләре Халык Комиссары К. Е. Ворошиловка да җибәрелә:

«Народному Комиссару по Военным и Морским Делам тов. Ворошилову.

Третий Всероссийский съезд представителей Мусульманского Духовенства и приходов приветствует в Вашем лице Красную Армию, являющуюся оплотом мирного труда и спокойной жизни трудящихся масс, всегда готовую отразить нападение врагов и их попытки помогать мирному строительству Союзных республик и осуществлению заветов великой революции».

Риза Фәхретдиневнең Мәскәүгә адресланган түбәндәге телеграммасы аеруча кызыклы: бу телеграмма Бөек Октябрь Социалистик революциясенең унъеллыгы уңае белән 1927 елның 6 ноябрендә җибәрелгән.

«Председателю Всесоюзного Центрального Исполнительного Комитета Михаилу Ивановичу Калинину, Кремль, Москва.

В знаменательный день десятой годовщины октябрьской революции, открывшей для угнетенных народностей бывшей Российской империи вообще и для мусульман в частности широкие перспективы и великие возможности... ЦДУМ приемлет за долг принести свои поздравления в лице Вашем правительству Союзных республик.

Истекшие десять лет доказали, что мусульмане Востока вообще и СССР в частности, взиравшие с надеждой и упованием на лозунги, начертанные на знамени первой в мире пролетарской республики не разочаровались в своих ожиданиях освободиться из тисков нравственной и физической эксплуатации империализма».

**Марсель Әхмәтҗанов,**

филология фәннәре кандидаты

# РИЗА ФӘХРЕТДИНЕВ ШӘҖӘРӘСЕ

Риза Фәхретдиневнең иҗатын киң планда һәм этрафлы итеп өйрәнү өчен аның тормыш юлын җентекләп тикшерү зарур. Теләсә нинди шәхеснең аңлы тормыш юлы аның биографиясе белән бәйле. Шуңа күрә без бүген, Р. Фәхретдиневнең биографиясен төрле яклап ачыклауга булган ихтыяҗны исәпкә алып, аның шәҗәрәсе хакында кайбер мәгълүматларга махсус тукталырбыз.

Нәрсә соң ул шәҗәрә?

Шәҗәрә дип нәсел-ыру, фамилия-гаилә тарихына караган язуларга әйтәләр. Шәҗәрәдә, гадәттә, ата-бабаларның исемнәре, яшәгән урыннары, эзлекле рәвештә буыннарның (ирләр ягыннан алмашынып килүләре күрсәтелгән була. Аның телдән һәм язма рәвештә яшәп килгән күп гасырлык традициясе бар. Татар халкындагы гадәт буенча һәркем үзенең атасы һәм анасы ягыннан җиде буынга чаклы бабаларының исемнәрен белергә тиешле булган.

Язма шәҗәрәләр — үзенчәлекле тарихи чыганаклар. Р. Фәхретдинев үзе дә бу жанр белән җитди кызыксынган: үз нәселен генә түгел, башка йөзләгән нәселләрнең дә шәҗәрәләрен өйрәнгән, аларны бер урынга туплаган һәм фәнни хезмәтләрендә алардан киң файдаланган.

Тикшерүгә нигез итеп иң әлек Р. Фәхретдиневнең үзе исән чакта бастырып чыгарган һәм кулъязма килеш архивларда, туганнарында сакланган шәҗәрә язу-

лары, шулай ук аның Казанда яшәүче кызлары Зәйнәп апа Фәхретдинева (1895), Әсма апа Шәрәф (1906), галимнең бертуган энесе Зыятдиннең улы Нәҗип ага Фәхретдиневләр (1898 елда туган) белән әңгәмәләр вакытында тупланган мәгълүматлар алынды.

Р. Фәхретдиневнең үз нәселе шәҗәрәсе беренче тапкыр аның «Асарь» исемле китабының икенче кисәгендә басылган [1]. Шул китапның тәртип буенча 73 һәм 90 номерлы биографияләрен язганда автор үз нәселе шәҗәрәсе кулъязмаларыннан киң файдаланган.

Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинградтагы фәнни архивында саклану-чы кәгазьләре арасында [2] Р. Фәхретдинев нәселе хакындагы шәҗәрәнең кулъязма вариантлары да бар. Кучермә нөсхә «Иске шәҗәрәләр (нәсел-ыруг язулары)» исемле генеалогик җыентыкның 18 битенә язылган [3]. Кулъязма шәҗәрә басма варианттан тулырак, ләкин аның эчтәлегенә каршы килми. Аны бу урында тулы килеш күчереп китү урынлы булыр.

## КУРМЫШ ШӘҖӘРӘСЕ

Тансар исемле кешенең углы Курмыш [4], Курмыш углы Бахшанды, Бахшанды углы Кайбула, Кайбула углы Җангилде.

Җангилде балалары монлар: Төмәкәй, Төмән, Килмәт, Бордык, Җанҗегет. Монлардан Төмәкәйнең бүген дә Зөя өязе Шырдан [5] авылында булганлыгы мәгълүм.

Җанҗегетнең йир-сулары урынына руслар Сембер [6] шәһәрен салганлыклары риваять ителенә.

Алтынчы дәрәҗәдәге Төмәкәй бине Җангилде балалары монлар: Бигәй (кыз), Ишкәй, Уразай, Әлкәй, Вәли.

Төмән бине Җангилде углы Бәйрәш.

Килмәт бине Җангилде углы Биймәт. Бордык бине Җангилде углы Җәнсәй. Җанҗегет [7] бине Җангилде балалары Сүкә, Сабира (кыз).

Йиденче дәрәҗәдәге Бигәй бинте Төмәкәй углы Мортаза. Ишкәй бине Төмәкәй углы Юлдаш. Уразай бине Төмәкәй балалары монлар: Сөбханкол, Бәйрәкә, Мөэмин, Мөхсин, Мөслим, Бәйрәш бине Төмән балалары: Бакый, Ишмәт. Биймәт бине Килмәт баласы Ишмәт, Җәнес. Сүкә бине Җанҗегет баласы Метри. Сабира бинте Җанҗегет кызы Бигәй (бу Бигәй Төмәкәй кызы Бигәй ителеп күрсәтелсә дә, монда бераз яңлыш булырга тиешле. Бигәйнең атасы Төмәкәй бине Җангилде булып, анасы Сабира бинте Җанҗегет бине Җангилде булган суратта, Төмәкәйгә, бертуганының кызы булганлыктан, никахлары дөрес булмаска тиешле, мәгәр дә чуваш вакытлары булса гаҗәп түгел, әгәр дә чувашлар арасында мондый хәл булса.).

Сигезенче дәрәҗәдәге Мортаза бине Бигәй углы Габдерәшит (Бөгелмә өязе, Яңа Иштерәк [8] авылында имам); Юлдаш бине Ишкәй — Бөгелмә өязенә Шырданнан һиҗрәт итеп, Кичү елгасы буенда «Кичүчат» [9] исемле авылны тәэсир кеше иде. Угыллары: Биккол, Бикмәт, Морат (Кичүчаты берлә Колшәриф [10] арасындагы «Морат тавы» дигән тау моңа мәнсүб [11]). Сөбханкол бине Уразай углы Бикбау. Бәйрәкә бине Уразай углы Курмыш. Мөэмин бине Уразай углы Ишәй. Хәсән

---

[1] Ризаэтдин бине Фәхретдин. Асарь. 2 җөзьә. Оренбург, 1901, 70—71, 83 б.б.
[2] Беренче мәртәбә М. Госманов тикшергән (131 фонд).
[3] 131 ф., 1 тасв., 50 саклау берәмлеге.
[4] Шәҗәрәнең башка вариантларында Кармыш дип тә йөртелә.
[5] Бу авыл бүгенге көндә Татарстанның Зеленодольск районына керә.
[6] Сембер — хәзерге Ульяновск шәһәренең иске исеме.
[7] Җанҗегет нәселе XVII—XIX гасырларда Татарстанның Тау ягы (Иделнең уң ягы) өлешендә Енайдаров фамилиясе белән танылган. Енайдаровлар хәрби хезмәт үтәп, берничә буын буенча генерал, майор дәрәҗәләренә ирешкәннәр. Риза Фәхретдиневнең Ленинградтагы архивында бу тармакның бер кыска гына шәҗәрәсе саклана (рус телендә): «Енайдар — Жанъжигит (генерал) — Суки (генерал) — Димитрий-Бектимер (майор, мирза) — Усман (прапорщ, мирза) — Махмут (прапорщ, мирза) — Валиша (умер в 1810—11 гг.) — Сагдетдин (умер в 1868 г., 59 лет) — Шамсутдин (47 лет)».

Шушы шәҗәрәдәге Сәгъдетдин — Казагыстанның халык артисты, композитор Латиф Хәмидинең әнисенең бабасы була.

Бине — улы.

Бинте — кызы.

[8] Яңа Иштерәк — Татарстанның Лениногорск районындагы татар авылы.
[9] Кичүчат — Татарстанның Әлмәт районына керә торган авыл.
[10] Колшәриф — Татарстанның Әлмәт районындагы авыл.
[11] Мәнсүб — мөнәсәбәтле.

бине Уразай углы Габдерәшит. Мөслим бине Уразай углы Салхә, Бакый бине Бәйрәш угыллары монлар: мулла Салих, Габди, Габдессәләм, Габдерәхим, Хәмит, Сәгыйть. Ишмәт бине Бәйрәш угыллары: Габбас, Габдерәшит. Ишмәт бине Биймәт баласы Фәйзулла. Зает бине Җансәй углы Гаделша. Метри бине Сукә баласы Шыгый. Бигәй бинте Сабир углы Мортаза.

Тугызынчы дәрәҗәдәге мулла Габдерәшит углы Таҗетдин әл-Иштерәки. Бикмәт бине Юлдаш углы Сөбханкол. Ишәй бине Мөэмин баласы Сөби... Салхә бине Мөслим баласы Әбеш. Мулла Салих бине Бакый балалары: Мәргубә, Мәхбүбә. Габди бине Бакый балалары: Маннур, Бикбау, Бәдри. Габдессәлам бине Бакый балалары: Габделгазиз, Габделгафур. Габдерәхим бине Ишмәт баласы Әхтәм. Хәмит бине Бакый баласы Хәбибулла, Габдерәшит бине Ишмәт балалары: Габделҗәлил, Габделкәрим. Фәйзулла бине Зает баласы Йәһүдә. Гаделша бине Зает баласы Курамша. Шыгый бине Метри баласы Әхмәди. Мортаза бине Бигәй углы Габдерәшит әл-Иштерәки».

Риза Фәхретдиневнең үз кулы белән язган бу шәҗәрәсендә галимнең әтисе һәм үзе күрсәтелмәгәннәр. Аның бу мәгълүматларын «Асарь»дә басылган һәм Нәҗип Фәхретдинев [1] кулында саклanучы вариантлар ярдәмендә тулыландырырга мөмкин. «Асарь»дә мәсәлән, мондый шәҗәрә схемасы китерелә: Сөбханкол бине Бикмөхәммәт бине Юлдаш бине Ишкәй бине Төмәкәй бине Янгилде бине Кайбула бине Кармыш («Асарь», 2 кисәк, 83 б.)

Икенче характер чыганаклар буенча Н. Фәхретдинев төзегән шәҗәрә түбәндәгедән гыйбарәт:

## БАБАЛАРЫМЫЗ

I Кармыш, II Хәбибулла, III Җангилде, IV Төмәкәй, V Ишмөхәммәт, VI Юлдаш, VII Бикмөхәммәт, VIII Сөбханкол, IX Сәйфетдин, X Фәхретдин.

Бу бабаларыбызның төп ватаны (шәҗәрәдә Юлдашка хәтле бабалар сызып күрсәтелгән.— М. Ә.) Казан губернасы Зөя өязе Шырдан авылыныкы булып, шул илдә дәфен кылынганнар [2].

Юлдаш бабабыз 1556—57 нче елларда, чукындырудан куркып, Шырданны калдырып китәргә мәҗбүр була. Бөтен гаиләсе берлән хәзерге Татарстан җөмһүрияте, Әлмәт районы, Кичүчаты авылына килеп, ике су арасына, әрәмәлеккә, чыбыкчатаклыкка, далага «Юлдаш» авылын-карьясын тәшкил (ягъни сала) итә. Бәгъзы мәгълүматларга караганда, аның берлән һиҗрәт кылучы Мөхәммәт тә булган. Моның авылының исме бу көндә «Мәмәт» дип йөртелә. Бу авыл Кичүчатка ике чакрым гына. «Безнең ерак бабаларыбыз Шырданнан күчеп килгәннәр»,— дигән, 70—80 яшьтә булган бер апа бүген дә Мәмәттә яши. Юлдаштан башлап Фәхретдин һәм бу ике арада булган бабалар барсы да Кичүчаты зиратына җирләнгәннәр. 1918 нче елга кадәрле авылның чын исеме «Юлдаш» булып, кемдер Кичүчатына үзгәрттергән. Безгә мәгълүм түгел.

Нәҗип бине Зыятдин Фәхретдинев.

Казан, 1976, 15.XI».

* * *

Нәҗип ага кулында саклanучы зур форматта эшләнгән икенче бер шәҗәрәдә Сөбханкол бабадан башлап бүгенге көнгә кадәр булган күп буыннар күрсәтелгән. Аннан күренгәнчә, алдагы шәҗәрәдә унынчы номер белән, туктап калган Фәхретдиннең (1818—1891) улы итеп Риза Фәхретдинев күрсәтелә [3]. Фәхретдиннең Ризадан (Ризаэтдин) башка Минһаҗетдин, Кәшшафетдин, Маһирә, Габделхә-

[1] Нәҗип Фәхретдинев (1898 елда Кичүчат авылында туган), Казанда яши.
[2] Дәфен кылынган — күмелгән.
[3] Нәҗип Фәхретдиневтәге шәҗәрәләрнең фотокүчермәләре Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы фәнни архивның «Татар шәҗәрәләре» фондында сакланалар.

мит, Мәүдүдә, Мәгъсүмә, (Ризаэтдин), Зыятдин, Маһирә, Салих, Хәмит исемле балалары була.

Фәхретдин ике мәртәбә өйләнгән була. Аның беренче хатыны, Ризаэтдиннең анасы, Иске Иштерәк авылының Мәһүбә Рәмкол кызы (1821—1873). Мәһүбә укымышлы семьяда үскән. Аның этисе Рәмкол бик күп кульъязма китаплар күчереп гомер иткән. Мәһүбә, 18 яшендә кияүгә чыгып, Кичүчатына килә, мәктәп ачып балалар укыта. Р. Фәхретдинев 5 яшендә әнисеннән укырга, язарга өйрәнә башлый.

Бу шәҗәрәнең тарихи дөреслеккә никадәр туры килүе хакында берничә сүз әйтеп китү урынлы булыр.

Татар шәҗәрәләренең борынгыдан язылып килгән үрнәкләре мәгълүм. Шулай да татар шәҗәрәләренең күпчелеге, XVIII гасырдагы билгеле тарихи сәбәпләр аркасында, искедән килә торган язма текстлары югалып, соңыннан яңадан язуга беркетелгәннәр. Шул сәбәптән аларның борынгы бабалар турындагы өлешендә кайбер исемнәрнең урыннары алмашыну, яки аерым буыннарның бөтенләй төшеп калу очраклары гадәти күренешкә әйләнеп киткән. Шушындый кимчелекләр Р. Фәхретдинев шәҗәрәсендә дә очрый. Аерым алганда шәҗәрә текстларында кайбер исемнәрнең урыннары алмашыну, яки бөтенләй искә алынмавы шуның бер дәлиле.

Иң төп баба булган Тансар — шәҗәрәнең Риза Фәхретдинев кулында булган вариантында гына билгеле. Ул исем Нәҗип Фәхретдинев нөсхәләрендә күренми. Курмыш яки Кармыш баба хакында хәбәрләр шәҗәрә язуларында күбрәк сакланган. Әсма апа Шәрәфнең әйтүенә караганда, аның этисенең кулында Кармыш әл-Болгариның бер кульъязмасы булган. Шуңа таянып, Риза Фәхретдинев үзен болгар нәселеннән дип санаган.

Кармыш баба үз ягының (Татарстан, Иделнең уң ягы) атаклы кешеләреннән булган, күрәсең. Аның исеме төрле нәсел легендаларында искә алына. Күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның тарихи хезмәтләрендә дә аның хакында хәбәрләр бар [1].

Аннан күренгәнчә, Кармыш баба үзенең улы Җангилде белән Тәтештән килеп Кармыш һәм Янгилде исемле авылларны (Чувашстандагы зур татар авылларын) корган булганнар. Кармыш бабаның Кармыш авылында нәселләре калган була [2]. Шушы ук регионда булган Татар Танае авылында атаклы Кармыш нәселенә кагылышлы бер шәҗәрә варианты мәгълүм [3].

Инде килеп Татарстанның көнчыгышындагы халыкның тарихына күз салыйк. Андагы Әлмәт, Лениногорск, Азнакай, Баулы районнарында, археографик материаллар күрсәткәнчә, күп кенә авыллар Татарстанның көнбатыш өлешеннән һәм Казан тирәләреннән килгән кешеләр тарафыннан нигезләнгәннәр. Бу авылларның нәсел язмаларында көнбатышта калган ата-бабаларының илләре, исемнәре хакында мәгълүматлар табарга мөмкин.

Лениногорск районы, Керкәле авылында 1980 елда Һади Галимовтан (1900 елда туган) күчереп алынган шәҗәрәдә дә Кармыш исеме телгә алына. Шәҗәрәнең легендасына караганда Кармыш бабаның атасы Казанда ниндидер бунт вакытында югалган. Кармышның әнисе улын урманда биләүсәдә тәрбияләп үстерә. Алар чукындырылудан куркып Керкәле тирәсенә килеп урнашалар. Керкәле авылында Кармышевлар нәселе дә булган. Бу нәселләр Керкәлегә килгәнче хәзерге Лениногорск районына кергән керәшен татарлары авылында — Федотовкада (Аналык) яшәгәннәр. Федотовка авылы Кичүчатына якын гына. Шуннлыктан Керкәле һәм Кичүчаты шәҗәрәләрендәге Кармышларны бер кеше итеп карау әллә ни гаҗәп түгел.

Китерелгән мәгълүматлардан нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин. Риза Фәхретдиневнең ата ягыннан нәселе Шырдан авылыннан килә. Ана ягыннан нәселе дә шулай ук Татарстанның Тау ягы (Көнбатыш) белән бәйле.

Инде килеп Риза Фәхретдиневнең милләте кем булу хакындагы кайбер бутал-

---

[1] Насыйри Каюм. Сайланма әсәрләр. II т. Казан, 1975, 36 б.
[2] В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты, Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, № 815 т. 8 бит.
[3] Күчермә автор кулында саклана.

чык мәсьәләләргә тукталыйк. Галим үзе исән чакта бу мәсьәләгә бик ачык җавап биргән була. Кызы Әсма апа Шәрәф бу хакта болай сөйли:

«Безнең әти,— без болгар төрекләре, болгарилар; татар исеме безнең халык өчен дөрес түгел, ул — монголларны аңлатучы атама,— дип әйтә торган иде. Безнең паспортларда башкорт дип язылган иде элек. Ул вакытта болай язуның безнең өчен бернинди аермасы юк иде. Чөнки башкортлар ул вакытта татардан аерылып каралмадылар. Казанда без үз ихтыярыбыз белән татар булып паспорт алдык».

Риза Фәхретдиневнең паспортына бәйле кайбер буталчыклар хакында искәрмәләр бирү дә бу очракта артык булмас.

Ул паспорт 1906 елның декабрендә волостной старшина тарафыннан Риза Фәхретдиневкә биш еллык срок белән бирелгән. Анда аның семья хәле һ. б. хакында кайбер мәгълүматлар бар. Әмма безнең өчен кызыклы ягы шунда ки, анда паспорт иясе башкорт милләтеннән һәм Кичүчат[1] авылы да тулаем башкорт авылы дип язылган булуында. Галимнең шәҗәрәсе һәм балаларының, туганнарының бу хактагы фикерләре әлеге паспортның хакыйкатьне никадәр төгәл чагылдыру дәрәҗәсен ачык күрсәтә. Шул ук вакытта паспорт хаталары моның белән генә дә чикләнми әле. Әйтик, анда Р. Фәхретдиневнең хатынының исем-фамилиясен буташтырып — Нурйыһан Әбделнасыйрова, 44 яшь дип язганнар. Чынлыкта аның исеме Нурҗамал Габденасыйр кызы Төхфәтуллина (1866—1946), ә яше 1906 елда 40 булган. Балаларның яшьләре дә паспортта дөрес күрсәтелмәгән. Мәсәлән, Әсма һәм Зәйнәп апалардагы семья архивы мәгълүматлары буенча 1906 елда Габдрахман (1887—1937) 19 яшьтә, Габделәхәт (1889—1938) 17 яшьтә, Габдерәшит (1892—1953) 14 яшьтә, Зәйнәп (1895 елның январь аенда туган) 11 яшьтә булганнар. Моның дөреслеге 1905 елда төшерелгән гаилә фоторәсеме белән дә раслана.

Шулай итеп, кечкенә генә паспортта унга якын хата-мәгълүмат. Димәк, мондый кәгазьгә ышануы да кыен.

[1] Кичүчат авылы милли яктан үзгәреш кичермәгән татар авылы. Кара: Татарская АССР. Административно-территориальное деление (на 1 января 1966 г.). Казань, 1966, 46 б.

# МУЗЫКА СӘНГАТЕБЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫГЫ

*Шушы елның январь аенда күренекле совет композиторы, татар балет сәнгатенә нигез салучы Фәрит Яруллинның тууына 70 ел тулды.*

*Фәрит Яруллин атаклы «Тукай маршы»н иҗат иткән талантлы музыкант Заһидулла Яруллин гаиләсендә туып, кечкенәдән музыка яратып, үзе дә фортепьянода уйнарга өйрәнеп үсә.*

*1930 елдан башлап Ф. Яруллин Казан музыка техникумында, 1933 елны — Мәскәү консерваториясе каршындагы рабфакта, тагын бер елдан соң татар опера студиясендә укый. Шул чорда ук Фәрит Яруллин виолончель һәм фортепьяно өчен соната, симфония, «Зөлхәбирә» операсының беренче кисәген яза. Бу вакытта инде аның «Комсомолка-партизанка», «Колхоз кызына», «Егерменче елларда» дигән лирик җырлары һәм романслары халык күңелен җәлеп иткән була.*

*Уку елларында композиторны Габдулла Тукайның «Шүрәле» поэмасы рухландыра. Бу кызыксыну Ф. Яруллинга шушы әкият-поэма нигезендә балет иҗат итәргә илһам бирә.*

*1941 елда Ф. Яруллин хәрби училищеда укый. Аннары, кулына корал алып, фронтка китә. 1943 елда композитор Фәрит Яруллин сугыш кырында һәлак була.*

*Сәнгатебезнең йөзек кашы булган «Шүрәле» балеты беренче тапкыр 1945 елда М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында куела. Тамашачылар аны туган илебезнең бик күп шәһәрләрендә һәм чит илләрдә алкышлап каршы алдылар.*

*Журналыбызның бу санында танылган сәнгать эшлеклеләренең Фәрит Яруллин турындагы истәлек һәм уйлануларын урнаштырабыз.*

## Йөрәк түрендә

Фәрит Яруллин...

Бу исем барлык музыка сөючеләр күңелендә горурлык һәм соклану хисе тудыра. Һәм шунда ук үзенең кабатланмас яктылыгы, үзенчәлеге белән сәнгатебез тарихына кереп калган беренче татар балеты искә төшә.

...1941 елның язы. Казанда әле генә ачылган опера һәм балет театрында зур кызыксыну белән яшь композиторның беренче зур әсәрен әзерләп йөриләр. Барысы да, бигрәк тә автор үзе һәм аның остазы профессор Г. И. Литинский дулкынлана. Яшь композиторга зур өметләр баглана. Ник дигәндә, ул бит беренче тапкыр татар

балетын язган! Бөтенесе дә сабырсызлык белән премьера көтә. Тамашачы ничек кабул итәр аны, ошатырмы?..

Ләкин бөтен якты өметләрне, шатлыклы дулкынлануларны башланып киткән Бөек Ватан сугышы ялмап ала. Фәрит Яруллин сугышның башыннан ук ил ирегә өчен алгы сызыкта көрәшә. Аның йөрәгендәге моң чишмәсе халкыбыз батырлыгына багышланган яңа әсәр — симфония булып яңгырарга тора. Тик кызганыч: күңелләргә күчеп тантана итәчәк бу симфония тәмамлана алмыйча, ак кәгазь битләренә төшә алмыйча кала. 1943 елның сентябрендә бөтен дөньяга танылачак талант иясенең гомере яу кырында өзелә.

Ләкин композитор өчен үлем түгел иде бу. Чөнки аның моңнары, аның үзенең якты образы безнең йөрәкләр түрендә. Аның үлемсез әсәре «Шүрәле»нең бөтен Җир шарында тамашачысы һаман арта, һаман саен күбәя бара.

Ул елларда әле туып кына килгән татар балетының гадәти булмаган шундый зур уңышка ирешүен ничек аңлатырга соң? Бу сорауга бер сүз белән генә җавап биреп булмый, әлбәттә. Шулай да, минемчә, бу уңышның сере иң әүвәл халкыбыз шагыйре Габдулла Тукайның шигъри әкият-поэмасындагыча тирән һәм мәһабәт халыкчанлыкта. Күңелләрне кечкенәдән үзенә тартып торган чын поэзия һәм халык тапкырлыгы белән тулы бу әсәр Фәрит Яруллин музыкасы белән бербөтен булып сәхнәгә күтәрелде, тагын да җанланып китте, баеды. Әлеге әкият инде күптәннән халык җанының бер кисәге булып яши иде. Хәзер ул сәхнәдәге моң һәм бию аша яңадан туды. Биредә халкыбыз зирәклеге, ягтылык һәм яхшылыкның усаллыкны җиңеп чыгуы тантана итә. Әсәрнең ифрат зур идея көче әнә шунда. һәм, әлбәттә, балет музыкасының һәркемне таң калдырырлык лирикага байлыгы, халкыбыз җырларына якынлыгы күңелне биләп ала. Шул ук вакытта бу музыка Европаның гомумбалет сәнгате кануннары буенча, профессиональ кул белән, оста симфоник телдә язылган. Былтыр белән Сөембикә биредә халык күңеленең сафлыгына, аның холкындагы иң яхшы якларга җыелма образ буларак иҗат ителгәннәр.

Ә Шүрәле кул астындагы көчләр өчен кискен, хәтта, тәнең белән тоя алырлык итеп, «кадап» ала торган интонацияләр тудырылган. Бу — композиторның сокландыргыч, моңа кадәр күрелмәгән табышы. Чыннан да, «Шүрәле» балетын карап, югарыда әйтелгәннәрне тойганнан соң, бар, онытып кара бу «урман сарыгын!» Юк, оныта алмыйсың син аны, гомерең буе оныта алмыйсың!

Бу балеттагы чын сәнгатьчә уңышларны һәм табышларны тиз генә сөйләп бирү мөмкин түгел. Тик шунысы хак: әсәр безнең балет сәнгатебезнең йөзек кашы булып тора!

**Рөстәм ЯХИН,**
композитор.

# Яшьлек хатирәләре

Егерменче елларның икенче яртысында Фәрит Яруллин белән «Агамалы Гали углы» исемендәге дүртенче татар-башкорт мәктәбендә бергә укыдык. Бу мәктәп Уфаның 1918—1919 елларны эшли башлаган татар гимназиясе нигезендә оештырыла. Барлык фәннәр рус телендә, ә татар теле һәм әдәбиятын З. Шакиров, Н. Исәнбәтләр укыттылар.

Минә бер вакыт мәктәбебезгә Сәгыйть Рәмиев үлгән икән дигән хәбәр килеп җитте. Бу хәбәр күктән таш төшкән шикелле булды, чөнки безнең укытучылар Рәмиев һәм аның иҗаты турында зур хөрмәт белән сөйлиләр иде. Зиратка оешкан төстә бардык. Укучылар арасында Рәхим Саттар белән Фәрит Яруллин да бар иде.

Мәктәптә әдәбият түгәрәге эшли, әдипләрнең әсәрләрен укыйбыз, тикшерәбез,

үзебезчә фикер дә йөрткән булабыз. Арабызда каләм тибрәтүчеләр дә җитәрлек, кулдан журнал чыгарабыз.

Бирedән күренекле кешеләр: СССРның халык артисткасы Зәйтүнә Бикбулатова, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Фәйзи Гаскәрев, Әхмәт Фәйзи, Фәрит Яруллин, Рәхим Саттар, рәссам Равил Гомәрев, медицина фәннәре докторы профессор Зариф Зәһидуллин, Казан педагогия институты доценты математик Әнвәр Әсәдуллин һ. б. чыкты. Миңа Фәрит белән ике ел бер класста укырга туры килде. Ул һәрвакыт арткы партада утыра иде. Шунысы әһәмиятле: ул чакларда Уфа мәктәпләрендә җыр дәресләрен укыту яхшы гына куелган иде. Безнең мәктәптә дә җыр дәресен бер апа белән бер абый кеше алып бардылар. Итальян халык көе «Санталючио», халкыбызның «Дисәнә», «Баек», «Каз канаты» кебек көйләрен өйрәнеп, хор белән җырлый идек. Фәрит исә күп вакытта ноталар язып утыра. Нота грамотасын әтисе өйрәткәндер, күрәсең, безгә укытучы нота грамотасын өйрәткәндә, ул аны күптән үзләштергән иде инде.



*Композитор Заһит Хәбибуллин белән Фәрит Яруллин (уңда).*

Фәритләр Гафури (элекке Никольский) урамындагы ике катлы агач йортның икенче катында тордылар. Зур гына бүлмәдә иске генә булса да саргылт төстәге рояль тора, ә Фәрит шул рояльдә уйнарга өйрәнә. Кайвакытларда мәктәптән туры безгә киләбез. Ул дәресләрне әзерләп бетерер-бетермәс пианинода төрле татар көйләрен уйнарга тотына, ә без, барча туганнар, аның уйнаганын сокланып тыңлыйбыз. Әлбәттә, Фәрит ул вакытта яхшы башкаручы да булмагандыр әле, ләкин моң, аһәң дигән нәрсә бар бит! Күрәсең, аның моңлы һәм тирән хис белән башкаруы безне шулай мавыктыргандыр.

Бу урында шуны да әйтеп үтмәкче булам. Әле, Уфага күчеп килгәнче үк Заһидулла ага үзенең атаклы «Тукай маршы» белән шәһәр халкына яхшы таныш була. Моның сәбәбе, бәлки, 1918 елның икенче апрелендә «Яңа клуб» залында татар халык шагыйре Габдулла Тукай хөрмәтенә Уфа татар музыка-драма җәмгыяте тарафыннан өч бүлектән торган зур кичә уздырылудадыр. Беренче бүлектә «Нур» труппасы «Музыкант» исемле бер пәрдәлек драманы уйнап күрсәтә. Икенче бүлектә Мәҗит Гафури, Сәгыйть Сүнчәләй, Зәки Баязитскийлар Тукайның хатларын һәм шигырьләрен укыйлар. Өченче бүлектә яшь җырчы Әминә Бәхтизина җырлый, аннары музыка мөгаллиме

немец Вильгельм Клименц җитәкчелегендәге «Саз» кыллы оркестры тарафыннан милли көйләр һәм «Тукай маршы» бик уңышлы башкарыла. Кичә Тукай рухына багышланганга мы, тамашачылар «Тукай маршы»н аеруча җылы каршылыйлар.

Тормыш җиңел түгел иде. Заһидулла ага ресторанда пианинода уйнап булса да, аз-маз табыш ясап, гаиләсен тәрбияләде. Тормыш авырлыгына карамастан, рухи төшенкелеккә бирелмәде. Ә бу хәл балаңны сәнгать юлында тәрбияләү өчен бик кирәк нәрсә бит!

1930 елны Фәрит гаиләләре белән Казанга күчеп китә. Миңа 1931 елның январь аенда Казанда булырга туры килде. Бу вакытта Фәрит Казан музыка училищесында Р. Л. Поляковның виолончель классында укый иде. Студентларның торaклары, «Школьная» тыкрыгында академик А. Е. Арбузов йорты белән күрше бинада иде. Миңа анда берничә тапкыр булырга туры килде. Фәрит гобойчы М. Батталов белән бер бүлмәдә торды. Әлбәттә, бүлмә салкын, ашау-эчү нормалы, ләкин күңелләре көр. Сәнгать кешеләре бит. Музыкада ямь табалар, киләчәкләре өметле икәнлегенә ышаналар иде алар.

**Хәсән ГОБӘЙДУЛЛИН.**

# Өч очрашу

Утызынчы еллар башында илебезнең байтак кына шәһәрләрендә ленинградлылар үрнәгендә эшче яшьләр театрлары (ТРАМ — театр рабочей молодежи) барлыкка килә. Казанда да ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты каршында шундый коллективлар оештырыла. Елга аръягында рус, ә Вахитов исемендәге комбинат клубында татар труппасы туплана. Татар труппасына кырыктан артык комсомол-яшьләр йөри. Артист булырга хыялланган яшьләр төп эшләреннән соң, клубка җыелалар. Дәресләр, репетицияләр шау-гөр килеп уза. Театр тарихы һәм диалектик материализм буенча лекцияләрне алар бирелеп тыңлыйлар. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистларыннан Хәким Сәлимҗанов нәфис сүз, Гай Таһиров хореография буенча дәресләрне ифрат та күңелле алып баралар. Бергәләп академия театры спектакльләренә йөрибез. Караган спектакльләр турында кайнар бәхәсләр куба. Тәҗрибәле, бай иҗатлы театрны бик җиңел генә «искелектә» гаеплибез, ә безнең коллектив яңа юнәлеш алган театр булачак, имеш.

Театрга музыка эшләрен алып бару өчен чакырылган Хәким Батыршин безнең өчен яңа җырлар иҗат итә. Без аның «Комсомол маршы», «ТРАМ маршы», «Беренче май» җырларын җырлыйбыз. Халык көйләреннән ул өйрәткән «Дулкын» көен дә бик ратабыз. Көннәрнең берсендә Батыршин репетициягә үзе белән бергә укучы ике егетне — Нәҗип Җиһанов һәм Фәрит Яруллинны алып килә. Нәҗип рояльдә, Фәрит виолончельдә уйный. Ачык хәтерлим, Хәким Батыршин белән Нәҗип Җиһанов ул заман өчен шактый купшы киенгәннәр. Ә Фәрит — ярлырак. Аның өстендә күе зәңгәр блуза, искерәк кара чалбар. Коңгырт чәчләре озынрак һәм бик куе. Ул куе чәчләр ничектер күпереп торалар. Фәрит аз сөйләшә. Режиссер һәм музыка җитәкчесе әмерләрен игътибар белән тыңлый, уйный. Тәнәфес вакытларында Нәҗип һәркем белән сөйләшә, шаярта, ә Фәрит читтә. Тик игътибар белән барысын да күзәтә. Әнә, тамашачы залының иң арткы урындыклардан соң буш калган урында ике егет акробатик күнегүләр ясыйлар, көч сынашалар. Ә бу почмакта Мөхәммәт Садри яңа шигырьләрен укый. Сәхнәдә Батыршин берничә кызга яңа җырын өйрәтә, ә рояльдән читтәрәк Фәрит виолончелен кулына тоткан да тын гына, моңсу гына утыра. Бу яңа коллективта мин исә иң яше, иң кечкенәсе, иң яңасы. Минем монда йөри башлавыма нибары берничә ай. Табигый хәл, мин Фәриткә дә, Хәкимгә дә, Нәҗипкә дә дәшергә кыймыйм. Репетицияләрдә булачак композиторлар белән күп тапкырлар

очрашсам да, Фәрит белән аерым сөйләшкәнебезне хәтерләмим. Бу театрдагы беренче очрашуда мин аны тирә-юньгә игътибар итүчән, уйчан-моңлы йөзле, аз сүзле музыкант итеп хәтеремдә калдырдым.

1932—1933 еллар. Татарстан радиокомитеты. Карл Маркс урамындагы 36 нчы йорт (хәзер бу бинада комсомолның Татарстан өлкә һәм шәһәр комитетлары урнашкан) — өч катлы зур матур бина. Мәрмәр баскычлар. Бу йортка республиканың иң яхшы музыкантлары, җырчылары, күренекле әдипләре, танылган драма артистлары килеп йөриләр. Монда симфоник оркестр, думбра квартеты, рус ир җырчылары квартеты, рус опера солистлары, Татарстанның иң күренекле җырчылары, халык музыкантлары дәртләнеп эшлиләр. Күз алдыгызга китерегез: ул елларда әле Казанда филармония юк, опера театры да юк, консерватория дигән сүз телгә дә алынмый. Барлык музыкаль көчләр радиода тупланган. Менә шушы зур иҗат коллективына Фәрит Яруллин килә. Ул пианист-аккомпониатор итеп чакырыла. Тагын искә алыйк. Профессиональ музыка әле күтәрелеп кенә килгән чор. Халык көйләрен җыю, аларны нотага салу, фортепианога кушылып җырлау яки төрле ансамбльләрдә уйнау өчен эшкәртүләрнең әле нибары беренче үрнәкләрен генә очратабыз. Әле нотага теркәлмәгән йөзләгән көйләрне Гөлсем Сөләйманова, Газиз Әлмөхәммәтов, Мәрьям Рахманкулова, Гайшә Камаева,Ситдыйк Айдаров, Мөхәммәт Сафин кебек танылган җырчылар, Фәйзи Биккинин, Мөхәммәт Яушев, Хәбибулла Әхмәдуллин кебек халык музыкантлары төрле кечкенә гармуннарда, скрипкада уйныйлар. Көй белән илһамланып уйнау — импровизация, әлбәттә, музыкаль сиземләүнең, музыкаль хыялның көчле булуын таләп итә. Фәрит Яруллин әнә шул ифрат үзенчәлекле иҗади эштә халкыбызның күренекле музыкантлары белән аралаша. Репетицияләр көндезләрен һәм кичке радиоконцертлар башланырга ике сәгать вакыт калганда уздырыла. Фәрит репетицияләргә кичекмичә килә. Җырчыларның, музыкантларның уйнаганнарын тыңлый. Алар белән бергә көйләрне ни рәвешле башкаруны билгели. Кайчакларда аларны нотага сала. Концерт программалары бик күп төрле. Бер концертта симфоник оркестр да, думбра секстеты да, вокаль дуэтлар да катнаша. Фәрит һәрвакыт программаларны бирелеп тыңлый. Үз вазифасын илһамланып башкара.

Бу елларда «Микрофон алдында радиотыңлаучылар» дигән концертлар да оештырыла. Радиодан бер атна алдан радиотыңлаучыларның катнашы белән концерт оештырылу хәбәр ителә. Концертта катнашырга теләүчеләр студиягә чакырылалар. Фәрит Яруллин бу концертларда пианинода уйный. Алдан репетицияләр үткәрелә. Музыкаль редакция җитәкчеләре килгән һәвәскәр җырчыларны, төрле музыка коралларында уйнаучыларны сайлап алалар, программа төзиләр. Аннан алар студиягә киләләр. Әлеге концертларның халык арасыннан талантлар табудагы хезмәте зур булды. Заманында татар, башкорт көйләрен моңлы җырлаган Гайшә Камаева, саф тавышлы Фәвия Хәсәнова, югары музыкаль белем алган җырчылардан Рәкыя Бәхтиева-Сәдриҗиһанова, Әминә Шәңгәрәева шул радиотыңлаучылар концертларында җырлаганнан соң профессиональ сәнгать юлына аяк басалар.

Эшче яшьләр театрында беренче очрашканнан соң бер елдан артык вакыт узган. Фәрит һаман аз сөйләшүчән. Ул миңа һаман нәрсә турындадыр уйлана төсле тоела, ә минем аны сөйләштерәсем, уйларын бүлдерәсем килә, юк, алай да түгел, уйларын беләсем килә. Аңа сүз кушар өчен җай эзлим, сәбәпләр табарга тырышам.

Ул елларда ашамлыкны местком алып өләшкән талоннар белән ала идек. Миңа местком берәр кило конфет алыр өчен талоннарны артистларга өләшү эшен тапшырды. Мин иң элек Фәритне күрергә тырыштым.

— Фәрит, конфет алырга телисеңме? Талон бирәм. Проломная урамындагы кибеттән алырга кирәк. Талон биримме?

— Ярый,— дип бер генә сүз әйтте Фәрит. Талонны кесәсенә салды да китеп барды.

«Менә ул рәхмәт әйтер, минем местком эшенә ярдәмемә игътибар итәр, тагын нинди талоннар барын сорашыр, шулай сөйләшеп китәрбез, ул үзенең моңсу уйларын онытып торыр»,— дип өметләнгән идем...

Тиздән Фәрит радиоконцертларга килми башлады. Аның Мәскәүгә китүен, кон-

серваториядә укырга теләвен ишеттем. 1935—1936 елгы концерт программаларында инде композитор Фәрит Яруллин исеме ишетелә башлады.

1940 елның көзе. Кояшлы матур көннәрнең берсе. Мин Бауман урамы чатындагы аптекага керәм. Кассага чиратка басыйм дигәндә таза гәүдәле, аксу-соры костюм, аның өстеннән соры затлы макинтош кигән бер кеше миңа дәшә. Карасам: Фәрит! Ул танымаслык булып үзгәргән, чибәрләнгән, элек тузгып, күпереп торган кое чәчләре хәзер хуҗасына буйсынып, артка таба таралган, ыспайланган. Тулы йөзе ничектер агара төшкән, яңаклары алсуланыбрак тора. Күзләрендә елмаю. Аның бөтен кыяфәте, үзен тотышы интеллигент булуын сөйли, бүгенгесенә шат, киләчәгенә нык ышаныч белән яшәвен раслый кебек. Ул бик ачык йөз белән миңа кулын суза. Исәнләшәбез, озак кына сөйләшәбез.

— Мин балет язып бетердем. Безнең театрда репетицияләр башланырга тора. Син репетицияләргә кил, яме?— дип саубуллашты да җәһәт кенә аптекадан чыгып китте. Мин соклануымнан, көтелмәгән очрашудан, Фәритнең шулай елмаеп, күтәренке рух белән сөйләшүеннән бер мәлгә югалып калдым. 1931—1933 елларда мин күп тапкырлар күргән, эштә, радиоконцертларда еш очрашкан аз сүзле, караңгырак чырайлы, моңсу, бик гади, дәресрәге, ярлы киенеп йөргән музыкант Фәрит — бүген ягымлы интеллигент! Шат рухлы чибәр егет! Фәрит — композитор! Беренче татар балетын иҗат иткән зур талант иясе! Сөендем, сокландым, әмма аның янына барырга, репетицияләргә йөрергә җөрьәт итмәдем. Репетицияләргә йөрмәвемә ифрат үкенәм... Фәритне башка очратмадым.

Зәйнәп ХӘЙРУЛЛИНА.

# Үткер күңел күзе

Артистлардан, җырчылардан, композиторлардан байтак кына сәнгать кешеләре 1939 елда Татарстанның хөрмәтле исемнәренә лаек булдылар. Бу хәл барыбызны да ифрат куандырды. Шул ук елны Татар Дәүләт опера һәм балет театры ачылды. Татарстан Композиторлар союзы оештырылды. Яңа композиторлар белән танышу, аларның әсәрләрен ишетү тормышыбызга яңа саф сулыш бөркеде. Онытылмас очрашуларның берсе минем өчен Фәрит Яруллин белән танышу булды. Ул минем күңелемә иң элек безнең яраткан тамашачыбыз булып керде. Билгеле инде, без сәхнәдә нинди омтылыш белән яшәвеңне, нәрсә әйтергә теләвеңне аңлаган, артист белән бергә, бер хисләр белән янган тамашачыны яратабыз. Сәхнәдәге вакыйгаларның барышы белән генә мавыкмаган, ә артистның катлаулы иҗатын күңел күзе белән күрә белгән тамашачы безнең өчен үтә кадерле. Фәрит Яруллин гади тамашачы гына түгел, күңел күзе үткер, кичерешләрне йөрәге белән тоя белүче җан иде. Фәрит безнең театр спектакльләрен даими карап баручы булды. Спектакль бетүгә ул безнең янга сәхнә артына керә. Иң элек безне котлый. Аннан сөйләшү китә. Фәрит театр белән генә түгел, башка сәнгатьләр белән дә нык кызыксына. Аларның бер-берсе белән бәйләнешләрен ачыкларга омтыла.

Музыка һәм драма артисты иҗатының үзенчәлекләре... Сөйләшүебез шул хакта. Ничектер бу проблемага без еш әйләнеп кайтабыз. Фәрит акрын гына, тоныграк тавыш белән сөйләшә. Сүз арасында паузалары зур. Уйланган, күрәсең.

Ул безнең театрдан ерак тормый иде. М. Горький урамы унберенче йорт ишегалдында беренче катта яшәде. Ә мин —шул ук урамдагы унҗиденче йортта. Күршеләрчә аларга кергәнем бар. Ул да безгә хатыны Галина белән кергәли иде. Очрашуыбызның берсендә ул миңа фортепианомы яки виолончель өченме, ачык хәтеремдә калмаган, инструменталь әсәр язуын сөйләде. Пианинода уйнап шул яңа әсәрнең темалары белән таныштырды.

Көтелмәгән дәһшәт — Бөек Ватан сугышы башланды. Һәм көтмәгәндә, әмма Фәрит Яруллин саубуллашырга килде. Мин аны Казанда калырга, китмәскә өндәдем.

— Сез талант иясе. Сезнең талант — ул ил, халык байлыгы. Хәзер үзем военкоматка барам, сөйләшәм,— дим.

Фәрит сабыр гына, әмма катгый җавап кайтара:

— Военкоматка мин үзем барам. Ил алдында безнең барыбызның да иңнәрдә бер үк җаваплылык.

...Кем уйлаган, бу сөйләшү, бу саубуллашу соңгысы булыр, дип.

1943 елда көтмәгәндә театрда Фәрит Яруллиннан хат алдым. Фронтовик хаты. Рус телендә.

«Хөрмәтле, кадерле иптәш Ильская! Сугышка кадәр әле танышып кына өлгергән, бик аз аралашкан кешедән, көтмәгәндә, хат алу, шик юк, Сезне гаҗәпләндерер. Без Сезнең белән танышканда, мин беренче татар балеты «Шүрәле»не тәмамлап кына бетергән идем. Ә хәзер, ике ел узганнан соң, тормышым тамырыннан үзгәрде. Сугышның кырыс мәктәбен үттем.

Чынында исә бик тә шикле тынып торудан — тынлыктан файдаланып, Сезне — татар сәнгатенең иң күренеклеләреннән берсен искә төшердем. Күңелдәгене болай ихлас ачып салуны, мондый сүзләрне Сезнең беренче генә ишетүегез түгелдер. Моңарга тагын Сезгә булган соклануымны һәм ихлас күңелдән Сезне якын күрүемне дә өстәргә тиешмен. Бик аяныч, күңелләргә рәхәтлек бирә торган танышлыгыбыз бик иртә өзелде. Гитлерчы кабәхәтләр башлаган нәләтләнгән сугыш өзде безнең танышлыкны. Көрәш дәвам итә. Өстебезгә килә торган фашист өерен юк итү өчен, Сезнең белән, кадерлем минем, яңадан кулга кул тотынышып эшләр өчен бик күп ватандашларым кебек мин дә вакытлыча каләмемне калдырып торам.

Барлык дусларга фронт сәламен ирештерегез. Бер минут вакыт табылса, аны миңа багышлагыз. Үзегез турында языгыз.

Сезгә баш июче Фәрит Яруллин».

Кызганычка каршы Фәрит Яруллинның иҗатын өйрәнүчеләр аның миңа язган хатларын алгач, аларны ничектер кире кайтармадылар.

Фәрит минем күңелемдә Киевне алу сугышында батырларча һәлак булган улым танкист-лейтенант Фуат белән бергә саклана. Улымны сагынган кебек, Фәритне дә өзелеп сагынам. Бергә булган кыска күрешүләрне кабат-кабат күздән кичерәм. Кешеләрнең хисләрен күңел күзе белән тиз, үткен күрә белүче, сизгер йөрәкле, кешеләргә шәфкать күрсәтергә һәрвакыт әзер торучы, сәнгатькә бөтен барлыгы белән бирелгән җан иде ул. Ә аның зур таланты булуын, сәхнәгә беренче тапкыр Л. Жуков һәм Г. Таһиров күтәргән «Шүрәле» балеты музыкасының һәр яңгыравы раслап, кабатлап тора.

**Фатыйма ИЛЬСКАЯ,**
РСФСРның һәм Татарстанның халык артисткасы.

# Ут эчендә

Авыр сугыш елларының төрледән-төрле борчулары, кайгылары вакытлыча Саратов шәһәренә эвакуацияләнгән Мәскәү консерваториясендә эшләү һәм студентларның укуларын дәвам итү белән аралашып барды. 1942 елның ахыргы көннәре иде. Көннәрдән бер көнне, көтмәгәндә-уйламаганда, мин дәрес алып барган класска аркасына биштәрен аскан хәрби киемдәге яшь бер кеше килеп керде. Талчыккан йөзенә карап, аңа бик озын юл мәшәкатьләре кичерергә туры килгәнлеген төсмерләргә була. Коңгырт-кара күзләрендә сакланып калган нур чаткылары, табигый һәм гаять үзенчәлекле елмаю... Шушы йөз сызыклары аркылы шундук совет яшьләренең иң яхшы, иң алдынгы вәкилләреннән берсен, ягъни татар композиторы Фәрит Яруллинны танып алдым.

Сугышның беренче көннәреннән үк диярлек хәрәкәттәге армиядә булган элекке укучым белән күптән очрашканыбыз юк иде. Очрашу шатлыгыннан дулкынланган Фәрит берникадәр вакыт сүз әйтә алмый торды, шуннан соң гына тотлыга язып: «Идел белән Кама арасында урнашкан частебыз командованиесе мине Сезнең янга ике тәүлеккә җибәрде»,— дия алды.



*Фәрит Яруллин — Ульяновск пехота училищесында курсант (алгы рәттә, уңнан беренче), 1941 ел.*

«Шүрәле» балеты, симфонияләре, аннары кечкенәрәк күләмдәге хезмәтләренең, әйтик, «Кара йөзләр» әсәренең эскизлары һәм җырларының язмышы белән кызыксына иде ул. Минем әүвәлге сорауларыма биргән кыска җавапларыннан әнә шул аңлашылды. Фәрит карамагында фәкать ике генә тәүлек булганлыктан, безгә вакытны бик тә нәтиҗәле файдаланырга, бер генә минутны да бушка уздырмаска кирәк иде.

Фәритне борчыган мәсьәләләр белән хәбәрдар булмаганга, аның сорауларына мин хәтта якынча да җавап бирә алмадым. Һәм озак уйлап тормастан, консерваториябезнең хәрби факультеты начальнигы А. Е. Гуторга киңәш сорап мөрәҗәгать иттем. Ул ничектер шунда ук безне кызыксындырган барлык мәсьәләләрне ээлекле бер тәртипкә салды, ашыгыч рәвештә Фәритнең хәрби округы командованиесе белән элемтәгә кереп, иҗат кешесенең хәлен аңлатып, аны консерваториягә күчерү буенча ризалык алды. Ләкин моны ахырга кадәр хәл итү өчен ике атнага якын вакыт кирәк булып чыкты. Ул арада Фәритнең Саратовка килеп китү максаты белән алган ялы һаман кыскара барды. Алай да без музыка турында сөйләшкәләргә вакыт таптык, билгеле. Аның киләчәккә булган иҗади планнары һәм фашист илбасарларын җиңеп кайтачагына ышанычы искиткеч зур иде. Ул миңа оркестр өчен язылган сюитадан өзекләр, киләчәктә һичшиксез булачак Бөек Җиңүебезгә багышлап, беренче мәртәбә ясаган шигъри тәҗрибәләре булган үз шигырьләренә иҗат иткән кантаталарын уйнап күрсәтте. Аннары Фәрит скрипка белән оркестр һәм виолончель белән оркестр өчен концертлар, иң беренче башкаручысы кызы Наилә булуын истә тотып, фортепиано өчен балалар пьесалары циклы, яңадан-яңа җырлар язарга теләгә барлыгын сөйләде. Үзе күптәнге дуслары Ә. Фәйзи белән Ә. Ерикәйдән яңа шигырьләр яздырып алырга да җыена иде. Композитор күп уйлана, хыяллана, хыяллана... Бу шулкадәр якын тоелган якты киләчәгебезгә олы ышаныч белән тулы канатлы хыяллар барыбызның да йөрәк түрендә. Бер сорау икенчесенә үрелеп барды: «Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов,

башка сәнгать әһелләре иҗатында, театрда, илебез һәм, әлбәттә, Казан музыкаль тормышында нинди яңалыклар бар?»

Сәгать төнге ике тулып узса да, сөйләшер сүзләр бетәрлек түгел әле. Әмма хушлашыр чак тиз килеп җитте. Зур хыяллар һәм максат белән янып яшәүче композиторны Саратовтан алып китәчәк поездга хәтле озаттым. Кызганычка каршы, Фәрит Яруллин белән соңгы очрашуыбыз һәм әңгәмәбез булды бу.

Әйе, авыр, катлаулы вакыт барысын да башкача хәл итте. Консерваториядән киткән чакыру кәгазе Фәрит кулына барып җитмәде. Ул хезмәт иткән часть ашыгыч рәвештә фронтка — алгы сызыкка җибәрелдә.

Тиздән консерваториябез яңадан Мәскәүгә кайтарылды. Өйдә мине Фәриттән хат, аның соңгы хаты көтә иде... Ул яктыдан-якты өметләр, Саратовта очрашуыбыз истәлекләре белән тулы. Шартлаулар, ут-төтен астында да аның күңелен оптимизм нуры яктырткан, кайткач, Җиңүгә багышланган беренче әсәрендә үк тамашачылар белән нинди тантаналы мажор дулкыннарга күмеләчәген язган. Патриот-композиторның бу хыялы тормышка ашмады. Тууына 70 ел тулган көннәрдә сөекле һәм алыштыргысыз Фәритебез алдында тагын бер кат баш иям.

Совет Татарстанының күренекле улы ядкарен мәңгеләштерү өчен без бик аз эшләгәнбездер кебек әле. Әгәр бу сүзләремдә күпмедер хата була калса, бу бары тик совет музыкасы дип аталган океанда аның зур дулкыннар булып тирбәлгән моңнары безнең өчен дә эшли, композиторны һаман югары күтәрә, дигән сүз.

Генрих ЛИТИНСКИЙ,
профессор, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе,
Татарстанның халык артисты.



# Фәрит Яруллин. «Шүрәле»

Ул көннәр минем хәтердә әле дә яхшы сакланган.

Менә минем кулда бер афишаның фотокопиясе. Татар халкының беренче балеты «Шүрәле»нең беренче афишасы ул. Балетның премьерасы 1945 елның 12 мартында булды.

Балетның авторы Фәрит Яруллин белән мин 1930 елда таныштым. Аның Казан музыка училищесында укыган еллары. Ул вакытта Казанда эшче яшьләр театры эшли иде. Мин башлыча академия театрында эшләсәм дә, биредә бию буенча дәресләр алып бардым. Театр тирәсендә тупланган яшь иҗат көчләре арасында артистлардан башка шагыйрьләр, музыкантлар да бар. Шул елларда Н. Җиһанов, Ф. Яруллин һәм флейтачы Батыршин үзенчәлекле трио оештырып, театр спектакльләрендә уңышлы гына чыгышлар ясый иделәр.

Фәритне мин тыйнак, оялчан, аз сүзле егет дип беләм. Ул күбрәк иптәшләрен тыңлый, инде бер дә дәшми калырлык түгел икән, тирән уйлап, бик төпле, акыллы бер-ике сүз әйтеп куя. Чынлыкта исә ул зур ихтыяр көченә ия булган түземле, эшчән, максатына ирешүчән бер кеше иде.

Аннары без аның белән Мәскәүдә очраштык. Мин бу чакта Зур театр училищесында укый идем. Ә Фәритнең консерватория каршындагы рабфакта укыган чагы.

Яңа гына оешкан татар опера студиясендә укучы казандаш дусларым янына еш килеп йөрсәм дә, ул елларда Фәритне күп очратырга туры килмәде. Күрәсең, ул төпле белем алу нияте белән, вакытын бушка үткәрмәскә тырышкан һәм иҗади эш белән дә актив шөгыльләнгәндер. Нәкъ шул елларда аның комсомол-яшьләр өчен язган патриотик хисле, моңлы матур җырларын республикабызның барлык авылларында яратып җырлыйлар иде инде.

1938 елны ТАССР Халык комиссарлары Советы Казанда Татар дәүләт опера театры оештыру турында карар кабул итә. Шул ук елны мин Мәскәүдән укуымны тә-

мамлап, яңа оештырылган театрга баш балетмейстер булып кайттым. Студияне тәмамлаган җырчылар да кайтып эшкә тотындылар. Яңа театрның яшь иҗат коллективы никадәр дәрт, ашкыну, шатлык белән эшли башлавын күз алдына китерү кыен түгел. Театрның үз бинасы, үз сәхнәсе юк иде әле. Зур драма театры бинасында татар операсын, беренче балетны куярга әзерлек барды.

Ниһаять, 1939 елның 17 июлендә яшь композитор Н. Җиһановның «Качкын» операсы белән театрның беренче сезоны ачылды. Татар халкы бию фольклорына бай булса да, һәм ул бераз өйрәнелеп, профессиональ югарылыкка куела башласа да, үзебезнең милли балетыбыз юк иде әле. Шуңа күрә композитор П. Гербельның «Кирәксез саклык» балетын әзерләп куйдык. Шул ук вакытта шагыйрь Әхмәт Фәйзи һәм композитор Фәрит Яруллин, Габдулла Тукай әсәреннән файдаланып, «Шүрәле» балетын яза башладылар.

Беренче адымнар, беренче тәҗрибәләр, беренче уңышлар иде бу. 1940 елны хөкүмәтебезнең Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уздыру турындагы карары безне тагын да куандырды. Декаданы әзерләүдә ярдәм күрсәтү өчен Мәскәүдән һәм Ленинградтан күренекле сәнгать осталары чакырылды. Шулардан П. А. Гусев— декаданың баш балетмейстеры, Л. В. Якобсон — «Шүрәле» балетын куючы, ә А. В. Лопухов актерлар белән характерлы биюләрне эшләүче итеп беркетелде.

Ул чагында мин декадада күрсәтү өчен әзерләнә торган «Алтынчәч» операсының балет картиналарын әзерләү белән мәшгуль идем. Шулай да «Шүрәле» балетыннан да читтә торырга туры килмәде. 1939 елның апрелендә Ф. Яруллинның укытучысы Мәскәү консерваториясе профессоры Г. И. Литинскийдан хат алдым: «Әхмәт Фәйзи белән яхшылап сөйләштем. Сезнең белән килешкәннән соң туган фикерләремнә ул хуплады. Шулай итеп, рольләр менә болай чиратланачак — либреттист Әхмәт Фәйзи, ә хореография сценариесенең авторы сез буласыз. Икенче майда өчәүләп — Фәйзи, Яруллин һәм мин Казанга киләбез. Әгәр анда очрашсак, яхшы булыр иде. Сәлам белән сезнең Г. Литинский».

Г. Литинский «Шүрәле» балетының музыкасын башта ук яратты һәм аның турында бик югары фикердә булды. Шул ук елны икенче бер хатында ул: «Композитор Яруллин беренче кисәген язып бетерде, хәзер икенче кисәген эшли. Бию мөмкинлекләре һәм тәэсирлелеге ягыннан музыка теләсә нинди мактаудан өстен»,— дип язды.

Композиторның да, либреттистның да мондый зур күләмле әсәрне беренче эшләүләре иде. Тәҗрибә җитмәве сизелеп тора. Либретто Г. Тукайның «Кышкы кич», «Көтмәгәндә», «Буран», «Суык», «Су анасы», «Бала белән күбәләк» һәм башка әсәрләреннән файдаланып язылган булып чыкты. Бер кат укып тикшергәннән соң, либреттоны Әхмәт Фәйзи, композитор Фәрит Яруллин, әсәрне сәхнәгә куючы Леонид Якобсонга балетны яңадан эшләргә киңәш бирелде. Билгеле инде, либретто үзгәргәч, музыка да шуңа яраклаштырып үзгәрә, күп урыннарын яңадан язарга кирәк була. Фәрит Яруллин үзен бик эшлекле, сабыр, уйчан тотты һәм эшне ахырына кадәр җиткерергә әзерлек белдерде.

Ул кунакханәдә яши иде, шунлыктан театр белән элемтәдә тору, язылган кисәкләрне тыңлатып карау, яңа фикерләр ишетү өчен барып-килеп йөрергә ара якын. «Шүрәле»не кую өчен махсус чакырылган талантлы балетмейстер Фәриткә теге яки бу киңәшләрен бирә, яңа музыка язарга, яки язылганнарны камилләштерергә кирәк булса, Фәрит һәрвакыт янибызда.

Горурлыгыбыз булган «Шүрәле» балеты җиңел тумады. Аның либреттосының өч варианты һәм Фәрит кулы белән язылган нота черновикларының аерым кисәкләре саклана. Димәк, ул өч тапкыр яңадан эшләнгән. Никадәр көч, түземлек, фидакарьлек кирәк булган аңа.

Балетны сәхнәгә кую да күп көч, зур мәшәкатьләр сорый. Беренчедән, балет труппасын 90 кешегә җиткерергә диган карар чыгарыла. Җаваплы партияләрне башкару өчен Ленинградтан килгән Нәгыймә Балтачеева, Габдрахман Кумысников һәм Исхак Рәхимов безгә зур булышлык күрсәттеләр.

Аннары бер бәхетле очрак безгә ярдәм итте: 1939—40 елларда Мәскәүнең Үзәк культура һәм ял паркы каршында эшләп килүче хореография театры зур популярлык казана. Илледән артык кешене берләштергән, югары профессиональ осталыкка ия булган коллективта заманыбызның атаклы балеринасы Е. В. Гельцер классик дәрес-

ләр алып бара. 1941 елның башында бу труппа Казанга килә, һәм безнең балет труппасы 90 кешегә җитә. Талантлы балалардан 60 кешелек хореография студиясе төзелә.

Барлык коллектив тугыз группага бүленә, һәм һәркайда тынгысыз иҗат тормышы, эш, өйрәнүләр башлана. Артистлар классик биюләр һәм халык биюләрен өйрәнәләр. Шул ук вакытта «Шүрәле» балеты авторлары әсәрнең икенче вариантын камилләштерү эшенә илһамланып тотыналар.

Ләкин ашкынулы өметләрне, башкалага барып имтихан тоту көннәрен күрергә туры килми. Бөек Ватан сугышы халкыбыз тормышын бөтенләй башка юнәлештә борып җибәрә. «Шүрәле» балетын да сәхнәгә кую мөмкинлеге өзелә.

Сугыш башланып бер ай да үтми, Фәрит Яруллин армиягә китә. Ульяновск шәһәрендәге пехота училищесына җибәрелә. Шул ук училищеда татар балетының Мәскәүдән килгән солисты Николай Суворов та укый. Соңыннан ул үзенең истәлекләрендә бу училищеда дүрт ай укуларын, төшке аштан соңгы ял вакытында Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетыннан яраткан вариацияләрен фортепианода уйнавын сөйли. Күрәсең, Фәрит иҗат эшеннән бервакытта да аерылып тормаган. Җае килгәндә, вакыты булганда балет музыкасын камилләштерүне дәвам иткән. Ләкин талантлы композиторга үзенең күренекле әсәрен сәхнәдә күрергә насыйп булмый. Ул 1943 елның сентябрендә немец фашистлары белән сугышта батырларча һәлак була.

Без, театр хезмәткәрләре һәм Фәритнең дуслары, бу югалтуны авыр кичердек. Ләкин аның эше ярты юлда туктап калмады, дуслары аның иҗат планын дәвам иттеләр, һәм 1945 елның 12 мартында казанлылар беренче тапкыр «Шүрәле» балетын карадылар. Бу беренче татар балеты, профессиональ хореографиягә нигез салган әсәр, кадерле иптәшебезнең якты истәлеге иде. Шуңа күрә дә без, аны сәхнәләштерүчеләр, бу эшкә зур саклык һәм үтә җаваплылык белән карадык.

Мин биредә «Шүрәле» балетының беренче тамашасын әзерләгән иптәшләрне искә аласым килә. Аннан соң аны күп көчләр уйнады, ә болар беренчеләр иде бит. Балетның беренче һәм өченче актын Л. А. Жуков, икенче актын мин куйдым. Оркестр белән И. В. Әүхәдиев дирижерлык итте. Художнигы Т. Н. Сперанский булды. Былтыр партиясен Б. Ш. Әхтәмов, Сөембикәне — А. Ф. Гацулина һәм М. А. Махно, Шүрәлене — В. Г. Романюк, ячы карчыкны — М. К. Карамышева һәм Таз ролен Г. Х. Таһиров башкарды. Музыканы оркестрга Ф. Е. Витачек салды.

Фәрит Яруллин татар милли балет сәхнәсенең уңышлы үсешенә нигез салган гаҗәеп талантлы әсәр иҗат итте. Аның бу хезмәте безнең илебездә генә түгел, чит илләрдә дә зур яңгыраш тапты. 1950 елны Ленинградның С. М. Киров исемендәге опера һәм балет театрында Л. В. Якобсон тарафыннан ул «Али-Батыр» исеме белән куелды.

1955 елда Мәскәүдә СССРның Зур театрында, 1959 елдан башлап Одессада, Киевта, Ригада, Чиләбедә, чит илләрдән Югославия, Албания, Румыния, Болгария сәхнәләрендә «Шүрәле» зур уңыш белән барды. Болгария башкаласы Софиядә Ст. Македонский исемендәге театрның «Шүрәле»не әзерләгән көннәрен хәтерлим. Мәскәүдә Луначарский исемендәге ГИТИСны тәмамлап, София театрында эшләгән Георгий Абрашев ун көнгә Казанга килеп, татар халкының фольклорын җентекләп өйрәнде. Мин аңа үземдә сакланган фотоматериалларны бирдем. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә әзерләнгән барлык биюләрне күрсәттем. Ул аерым бию хәрәкәтләрен кинопленкага төшереп алды. Шулай җентекләп, ихлас күңел белән эшләнгән спектакль Болгариядә зур уңыш казанган. Бу турыда газеталар бик җитди рецензияләр язып бастырганнар. Болгариянең сәнгать комитеты безнең дә кечкенә хезмәтебезне искә алып, «Шүрәле» балетын куюдагы ярдәмегез өчен, дип рәхмәт хаты җибәрде.

Кайчандыр безгә Ленинград һәм Мәскәү театрлары профессиональ балетыбызны булдырырга булышканнар иде. Инде без үзебез башка коллективларга ярдәм күрсәтерлек булып җитлектек. Татар опера һәм балет театры Рига, Одесса, Киев театр коллективларына «Шүрәле» балетын әзерләргә бик теләп ярдәмгә килде.

**Гай ТАҺИРОВ,**
Татарстанның халык артисты,
культура институты доценты, балетмейстер.

# УЙЛАП ЯЗСАҢ ГЫНА...

Рафаил абыймы?! Сугыштан соңгы елларда үзен әдәбиятыбызның ярсу чабыш атларыннан берсе итеп таныткан, мактау сүзләрен шактый күп ишеткән прозаикларыбызның берсе бит ул! Әдәби җыеннарда, әдәби сабантуйларда Рафаил абый муенына чигүле сөлгеләрне күп тапкырлар салганнар. Һәм шушы хәл бүгенгәчә дәвам итә. Нәрсә белән алдыра соң хөрмәтле язучыбыз? Шушындый бик табигый сорау алга килеп баса. Ләкин үз фикеребезне әйткәнче, башта кешенекен тыңлыйк әле. Алдыбызда «Социалистик Татарстан» газетасының 1962 ел, 15 апрель саны. Биредә Нил Юзеевның «Яңалык — тормыш тирәнлегендә» дигән мәкаләсе урнаштырылган. «Р. Төхфәтуллинның «Йолдызым» повесте прозабызның тормыш белән бәйләнеше ныгый баруын, язучыларның хакыйкатьне тулы тавыш белән сөйләү юлыннан үсүләрен күрсәтә»,— дип яза автор. Шунда ук болай дип тә билгеләп үтә: «Р. Төхфәтуллин әсәрләрендә тормыш каршылыклары образны басып, томалап китмиләр, ә чорның характерлы якларын, кешеләр арасындагы кешелекле мөнәсәбәтләрне, Гөлзифа характерындагы матур сыйфатларны ачарга ярдәм итәләр».

Менә тагын бер әдәбият белгеченең фикеренә тукталыйк. «Рафаил Төхфәтуллин илленче елларның башында «Таныш гөрелтә», «Җәйге челләдә», «Яңа магазинда» исемле хикәяләрен бастыру белән үк, әдәбият җәмәгатьчелегенең игътибарын җәлеп итәргә өлгерде. Беренче уңышлары белән дәртләнеп, ул яңадан-яңа әсәрләр яза һәм менә, ниһаять, үз вакытында каршылыклы фикерләр уятуына карамастан, укучылар тарафыннан җылы каршыланган «Авылдашым Нәби» исемле зур хикәя дөньяга килә. Шуннан соң тагын берничә хикәя, «Йолдызым», «Тамчылар ни сөйли?» дигән повестьлар языла. Аның китаплары Татарстан чикләрен узып, Мәскәү нәшриятларында басыла башлый, ә язучының исеме газета-журналлардагы тәнкыйть мәкаләләреннән соң, татар совет әдәбияты тарихын өйрәнүгә багышланган гыйльми хезмәтләргә дә килеп керә...» Бу юлларны «Социалистик Татарстан» газетасының 1966 ел, 5 июль санында Нур Гыйззәтуллин яза.

«Уңган кеше ничек үзенең тырыш куллары белән җирне эшкәртеп, ашлап, анда бәрәкәтле орлыклар чәчеп, үсемлекләрне карап-тәрбияләп чын бакча булдырса, Рафаил Төхфәтуллинны да үз кишәрлегендә озак еллар эшләп, иҗади бакча булдырган, анда игелекле җимешләр үстергән, аларны юмарт рәвештә халыкка өләшкән оста бакчачы дияр идем мин. Әдәбият бакчачысы». Бусын Шамил Бикчурин яза («Татарстан яшьләре», 1974 ел, 3 январь саны).

...Безнең Әлмәт якларының яшь язучылары, яшь прозаиклары беренче әсәрләрен Рафаил абыйга күрсәтәләр, дулкынланып аның каршына баралар. Рафаил абый «бара бу» дисә, бер дә шикләнмә инде. Димәк, әсәреңне теләгән җиреңә тәкъдим итә аласың.

Юк, Рафаил абый һәрчак «бара бу» дип кенә тормый. «Хикәяңне укып чыктым бит мин, әй»,— дип матур гына елмаю белән канәгатьләндергән чаклары да була аның. Рафаил абый берәүне дә бәреп ташлап тәнкыйтьләми, язган әсәреңне юкка чыгармый. Бу очракта да ул нәкъ үзе булып кала.

Ә Рафаил абый үзе тормышта йөрәк яраларын да, тән җәрәхәтләрен дә күп кичергән. Илебезнең азатлыгы өчен көрәштә алган яралары аны бүген дә булса борчый.

Кайвакыт аның белән шундый хәлләр дә була. Ул, башы сызлауга түзәр хәле

калмагач, поликлиникага бара, анда яңа врачка элэгэ. Ә врач, билгеле инде, башы сызлап килгэн авыруны башта рентгенга җибэрэ. Аннан килгэн рэсемне күргэч, врач шакката — авыруның үзеннэн дэ тирэнрэк хафага төшэ. Чөнки рэсемдэ талир тэңкэ зурлыгындагы мина кыйпылчыгының сурэте ап-ачык булып ярылып ята. Лэкин биредэ медицина көчсез шул. Ярчыкны операция юлы белэн алу мөмкин түгел. Ә дарулар? Корычка аларның да теше үтеп бетми. Мондый чакта Рафаил абый, гадэтенчэ, бер сигаретны икегэ сындырып, муштугына «Памир» мүкли. Рентген сурэтен хирургка истэлеккэ калдырып, экрен генэ өенэ таба атлый. Нинди дэ булса җиңеллек көтеп, ярдэм өмет итеп түгел, аптырагач, башы сызлауга һич чыдар эмэле калмагач кына килүе, врач егетне борчуы иде бит аның...

Әйе, тормышның шушындый авыр сынауларын татыган, туган һэр көннең бик кадерен белгэн эдип үз калэмдэшлэренэ карата усал да, кырыс та була алмый шул. Һэр елмаю, нэни генэ шатлыклар да үзенэ зур куенлыклар аша бирелгэнгэ, Рафаил абый аларның кадерен бик белэ, аларны күбрэк башкалар йөзендэ күрергэ тырыша. Башкаларга карата «йомшак» мөнэсэбэте энэ шуннан аның. Әмма моны Рафаил абый эдэби эсэрлэргэ талымсызлык күрсэтэ дип эйтеп булмый. Мыегы астыннан матур гына итеп елмаеп, эсэргэ карата мөнэсэбэтен бик аңлаешлы сиздерэ ул. «Син моны, энем, хэзергэ куеп тор, башкасын язып кара»,—дисэ, бу сүзлэрнең мэгънэсен бик дөрес аңлыйбыз без.

Язган эсэрлэрендэ язучының биографиясе дэ, шэхси тормышы да чагыла бит аның. Үзенең күргэннэрен, үз башыннан кичергэннэрен язучы эсэренэ кертмичэ һич тэ булдыра алмый. Рафаил абый тормышы да иҗат өчен бай җирлек.

Ул 1924 елның 1 гыйнварында Татарстан АССР Арча районы Яңа Иябаш авылында укытучы семьясында туа. Яңа Кенэр урта мэктэбенең 9 классын тэмамлагач, Донецк өлкэсендэге Горловка шэһэренэ китэ, ФЗӨ мэктэбендэ укый башлый. Бэрникадэр вакыт шахтада забойщик булып эшли. 1941 елның октябрендэ эвакуация белэн туган якларына кайта. 10 класста һэм бер үк вакытта кыска сроклы тракторчылар курсында укый. 1941 елның көзендэ фронтка китэ. Брянск, Орша, Рига янындагы каты сугышларда катнаша. Күрсэткэн батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены һэм медальлэр белэн бүлэклэнэ. Сугышларның берсендэ каты яралана һэм, демобилизациялэнеп, 1945 елның гыйнварында Яңа Кенэргэ кайта. Күп еллар буе район газетасында җаваплы секретарь булып эшли.

«—Брянск юнэлешендэге бер сугышта, мина кыйпылчыгы тиеп, кулым яраланды,— дип хикэяли үзенең герое Харис исеменнэн «Акбүз ат» повестенда.— Ярам алай эллэ ни дэ түгел иде, лэкин кесэмдэге бинт кисэгэ белэн генэ канын туктата алмадым. Саркый да тама, саркый да ага бирэ.

— Бар, йөгер тизрэк санротага! Әйбэтлэп бэйлэтеп кил. Живо!— дип комдив куып җибэрде.

Санротада канны тиз туктаттылар, аннары «бераз ял ит», диделэр. Яралылар белэн шыгрым тулы кысан өйдэ бер почмакка чүгэлэүгэ, изрэп йокыга киткэнмен. Март урталары иде бу. Сугышлар ул кадэр үк каты бармаса да, көн-төн дэвам итэ. Әле һөҗүм итэбез, эле кире чигенэбез. Ниндидер тактик маневр булгандыр инде ул, үзара шуңа юрый идек. Ә солдатка бу бик кыен. Ал-ял юк, җүнлерэк траншея, блиндаж казырга вакыт җитмэгэнлектэн, бер тамчы җылы эсэре күргэн юк. Полк кухнясының кайдалыгын еш кына белмибез, таба алмыйбыз да — авызга җылы ризык элэкми кала. Кар казып кына төшкэн окопларда ятабыз. Көндезен март кояшы елмаеп җибэрэ дэ, окопларыбыз кар суы белэн тула. Муеннан су эчендэ ята бирэбез. Ятмый да хэлең юк, баш өстеннэн җэйге черки урынына пуля очып тора. Ул арада пушка, минометлар гөрселдэшеп «сөйлэшэ» башлыйлар. Безнекелэр дэ ата, немецлар да. Ул да булмый, команда:

— Атакага эзерлэнергэ!

Һэм тиздэн, лачма су сеңгэн потлы шинельлэребезне сөйрэп, һөҗүмгэ күтэрелэбез. Көчэйгэннэн-көчэя барган пулемет-миномет уты бераздан безне кар өстенэ ятарга мэҗбүр итэ. Тагын шул кар окоплар, элемтэ юллары эмэллэргэ тотынабыз. Көндезлэрен март кояшы елмайса да, төннэрен чатнама суык. Безнең ул лачма су шинельлэр, тоташ боз булып, броняга эверелэ хэзер. Иелер хэл дэ юк, бөгелер хэл дэ юк. Атналар буе шушылай. Суык җилеклэргэ үткэн, күзлэр саташулы-уяулы, кер-

феккә-керфек кенә тигәләп ала. Әнә шуңа күрә дә, арт як аз гына коры идәнгә тиюгә, шундук изрәп төшкәнмен дә инде мин. Җылы иде бу кысан өйдә, шулкадәр рәхәт иде, җәннәт ләззәтләрең бер якта торсын.

Күпме йоклаганмындыр, иңбашымнан дер селкетеп уяттылар.

— Әйдә, сержант, подвода килде. Санбатка киттек,— диделәр.

Йокы белән аңкы-тиңке килеш:

— Нигә санбатка? Миңа комдив тизрәк әйләнеп кайтырга кушты, кайтасым бар,— дип карышып маташуымны санга да сукмадылар.

— Ярар, комдивың белән туйда үбешерсез,— дип, үрәчәле чанага, тагы кемнәрдер өстенә төртеп аударсылар да, кар туздыра-очыра чыжлатып китеп тә бардык. Санбатта ярамны тагын карап бәйләүгә, бу юлы инде машинага төяп, тагы озаттылар. Шулай итеп, туймас йокымнан һаман җүнләп айнымаган көйгә, җылы-йомшак госпиталь койкасына ук илтеп салдылар...»

Бу юлларны минем күп тапкырлар укыганым бар. Күпме укысам да, тетрәнеп укыйм. Болар инде язучының бай фантазиясе биргән продукт кына түгел. Әсәрдән китерелгән өзек язучының шәхси биографиясе булу белән бергә, фашист илбасарлар белән рәхимсез көрәшкә күтәрелгән меңнәрчә һәм күп меңнәрчә ил улларының язмышы да. Аларның чыдамлыгына, түземлегенә, тиңдәшсез батырлыгына ничек таң калмассың.

Инде килеп, «Акбүз ат» повестенда госпитальгә салып калдырылган Харисны без авторның «Бәр барабанны» дигән хикәясендә яңадан очратабыз. Сүз уңаенда шуны да әйтеп үтик, «Харис»— Рафаил абыйның бик яраткан исеме. Ул аны бигрәк тә үз исеменнән, ягъни автор исеменнән сөйләргә кирәк булган чакта кертә. Әлеге хикәядә исә бер язучыны нефтьчеләрнең Халыкара дуслык клубына очрашуга чакыралар. Шушы клубның «директоры» Камалетдинов әлеге ап-ак, тап-таза тешләрен тагын бер балкытып җибәрде.

— Яраткан язучыбыз һәм Ватан сугышы инвалиды буларак, без сезне дә, Харис иптәш, клубыбызның члены итеп күрергә теләр идек!— диде.

Һәм менә Харис, һәр сикәлтәгә йөзен чыта-чыта, автобуста бара. Һәр сикәлтә саен, гүя эчтә, бил турысында авыр бер таш кузгала... кузгала да, ниләрнедер тырнап-яньчеп, тагын аска төшеп китә... Нәрсә соң әле бу? Гадәттә ул үзенең бар сырхауларын үпкәсендәге осколокка һәм контузиясенә сылтый иде. Сылтар билгеләре дә ачык бит: йә күкрәк чәнчи, йә баш авыртуына чыдар әмәл юк... Ә бу юлы — мә бик кирәк булса!— билне битәрли башлады. Шул гына җитмәгән иде ди менә. Аз иде ди...

Кем белә, бәлки монысы шул контузия хикмәтедер әле. Бик мәкерле нәрсә бит ул контузия...

— Әй, төкерсәнә башына бар авыруларның,— дип дәвам итә автор хикәясен.— Иң мөһиме — игътибар итмәскә аларга. Медицина да бик яклый бит моны хәзер — кеше үз сәламәтлегенә үзе хуҗа, ди. Яраткан эшеңә никадәр тирәнрәк чумсаң, чирсырхаулар да синең тирәңнән читтәнрәк йөри, булганнары да аза алмый, ничектер, организмның әллә нинди яшерен көчләре уяна да, бар сырхауларны йөгәнләп ала, ди...

Дөрес бит бу, валлаһи, дөрес. Әнә рухланып-илһамланып язган көннәреңдә аның ник бер җире авыртсын! Күңеле дә гаҗәп күтәренке була. Инде менә ничәмә көн каләме туктабрак тора. Повестеның герое — үзе тудырган образга гашыйк булып йөргән Рәхимҗаны — авыр хәлдә калды. Үлеп сөйгән кызы бүтәнгә кияүгә чыкты. Эшендә дә уңышсызлыкка, күңелсезлекләргә юлыкты. Нигә болай булды соң әле? Аның Рәхимҗаны газаплы төстә әнә шул сорауга җавап эзли. Рәхимҗан белән бергә, автор да эзли.

Ах, автобус тагын селкетте, эчтәге кырлы-сырлы таш тагын кузгалды.

Гомер сукмакларының да әнә шулай һич көтелмәгән чокыр-чакырлары була шул. Повестен яза башлаганда Харисның шәхес һәм заман, мөхит җилкәне һәм заман җилләре турындагы уй-фикерләре шактый ачык хебек иде. Күрәсең, җитәрлек уйланмагандыр. Әнә бит үзенең ук Рәхимҗаны аны тагын уйга калдырды...

Бервакыт Ньютоннан сораганнар:

— Ничек син шулкадәр зур ачышларга ирешә алдың?— дигәннәр. «Мин алар турында көн-төн уйландым»,— дигән бөек галим.

Әйе, уйланырга, гел уйланырга кирәк. Уйланып язсаң гына укучыны уйландыра аласың. Ә эчтәге ул сырлы-кырлы ташның, ярчыкларның... төкер башына!

Рафаил абый әсәрләреннән алынган бу өзекләр чыннан да күп нәрсә турында сөйли. Әйе, үзе дә егет кеше ул безнең Рафаил абый, бик оптимист кеше.

Әдибебез язган чакта башваткыч сюжетлар кору бурычы да, моңарчы күрелмәгән персонажлар тудыру максаты да куймый. Ул утыра да матур гына хикәяли башлый. Аның шулай иплө генә, салмак кына хикәяләвен укучы да килештерә, язучыга тиз күнегә. Алар арасында аңлашу, теләктәшлек, дуслык мөнәсәбәтләре урнаша. Бу табигыйлык соңыннан шул дәрәҗәгә җитә, әгәр язучы менә шушында туктаса, калганын үзең сөйләп, үзең язып бетерер хәлгә киләсең. Чөнки аның геройлары үзебезнең арада, без аларны һәр көн күреп, аралашып торабыз. Алай гына да түгел. Әдипнең күп хикәяләрендә укучы нәкъ менә үзен очраткандай була. Кайчакларны Рафаил абыйга: «Фәлән хикәядә сез бит нәкъ менә минем тормышымны язгансыз. Ә бит без таныш та түгелләр. Барысын шул хәтле төгәл итеп каян белеп, кемнәрдән сораштырып бетердегез?»— дигән хатлар да килә.

Шулай шул, Р. Төхфәтуллин әсәрләрендәге персонажларны чын кешеләр итеп кабул итәсең, тормышны нәкъ шушы геройлар төсле тәмен-ямен белеп ярата башлыйсың. Шуңа күрәдер аның әсәрләрен үзебезнең илдә генә түгел, испаннар, французлар, англичаннар, немецлар һәм кытайлар да яратып укый. Аның «Җиләкле алан» җыентыгы шушы халыкларның да китап киштәләрен бизи.

Тәнкыйтьчеләр Р. Төхфәтуллинны тормыш сөючө, укучыларын да шуңа өндәүче, заманыбызның иң оптимист рухтагы язучыларыннан берсе итеп билгеләп үтәләр. Ә мин аларга өстәп: безнең Рафаил абый гөлләр, чәчәкләр турында язучы, дияр идем. Кайсы әсәрен генә алма, автор гөлләр-чәчәкләр турында сөйләмичә, аларны искә алмыйча калмый. «Карасана, веранда әйләнәсенә бакча гөлләре дә утырткан ич. Чалмабаш, дәлия, үрмәле гөлләр шау чәчәк атып утыралар...» («Елга аръягындагы йорт»). «Кыз, чәчәк кебек вакытында үз ишен табып, матур гына көн итә башлаган, картларны алмадай оныгы белән дә шатландырган иде» («Җәйге челләдә»). «Алмагачлар шау чәчәккә төренгән, бөтен табигать саф тереклек көче белән сугарылган язгы кояшлы көннәрдә, нур өстенә нур булып, дөньяга килде аларның уллары». («Таныш көй».) «—...Менә монысы бельфлер-китайка дигән алма була инде. Мичурин үзе чыгарган сорт. Бер-берсе куш йодрык кадәр була аның, үзе, язга кадәр сакласаң да, бакчадан гына өзеп алгандай, свежий тора... Монысы үзебезнең әнис... Ә кыяр өлгерде инде минем». («Күләгәдә».)

Мондый мисалларны язучының башка әсәрләреннән дә күп китерергә булыр иде. Алай гынамы? Рафаил абый гөлләргә, чәчәкләргә шулкадәр гашыйк, хәтта аның әсәрләрендәге героиняларының исемнәре дә «Гөл» белән башлана. Әдипнең повестьларын, хикәяләрен өстән-өстән генә карап чыкканда да мин «Гөл»ләрне күп очраттым. Гөлфия, Гөлҗиһан, Гөлниса, Үзгөлем, Гөлсем, Гөлзифа, Гөлүсә, Гөлчирә — барысы да Рафаил абый әсәрләренең героинялары... Әһә. Р. Төхфәтуллинның повестьларын, хикәяләрен укучыларның ни өчен яратулары беркадәр ачык хәзер! Аның сере менә нәрсәдә икән! Гөлләрне, чәчәкләрне кем яратмый! Алар турында кем укырга теләмәс!

Автор хәтта әсәрләренә исемнәрне дә «Бөтнек үләне исе», «Үзгөлем», «Давыл чәчәге», «Җиләкле алан», «Кыңгырау чәчәк» дип куя. Аларны кулга алу белән борынга чәчәк исе, бөтнек үләне исе, җиләк исе, бельфлер-китайка алма исе килеп бәрелә. Җанга рәхәт матур хисләр күңелне биләп ала.

Әле бит безнең халыкта «Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел» дигән сүз дә бар. Рафаил абыйның теле хакында да берничә сүз әйтәсем килә. Бу өлкәдә дә оста ул. Әйтсә, әйтә дә куя инде! Кайтарып сорарлыгыңны калдырмый. Шунда ук герой да күз алдыңа бөтен тулылыгы белән килеп баса, аның нинди ниятләр белән йөрүен дә бер сүз белән төшенеп аласың. Халык теле аңа, чыннан да, матур итеп тасвирлау, образларны тулысы белән ачу чарасы булып хезмәт итә. «Чыклы чиядәй иреннәре үзенә бик килешле җитдилек белән кысылган». («Таныш көй».) «Алар килеп кергәндә, башын сөлге белән кысып бәйләгән Гөлчирәттәй, аркасын җылы мичкә терәп, йон эрләп утыра, кәефе юклыгы әллә каян сизелә иде». («Китә казлар».) Нибары егерме ике сүздән торган җөмлә белән автор нинди җанлы күренеш бирә. Осталык инде бу!

Яисә: «Менә хәзер, беләктә көч, йөрәктә дәрт бар чакта аяк киенеп калмасаң, картлык көнеңдә ятарсың аннары... Суык мич башында черегән матчаң сынып төшеп, кайчан гына сытып үтерер икән дип...», «Кыскасы, Хөсәен абый әйтмешли, өй дигән саен өяргә дә өяргә кирәк иде...». Кыска-кыска гына җөмләләр. Ә шулар артында бөтен бер тормыш, яшәү мәгънәсе, психологик тирән кичерешләр ята.

Менә шушындый каләм остасы, олы язучыбыз Рафаил абыйга бу айда алты дистә тула. Үз юбилеен ул җиң сызганып эшләп каршылый. Авыл язучысы булып танылган әдибебез, авылга тагын да якынаю йөзеннән, бу көннәрдә тагын бер адым ясады, Әлмәттән шактый ерактагы бер авылдан йорт алып җибәрде. Анысын да, авылның уртасыннан, шәһәрдән килгән автобуслар туктый торган мәйданыннан түгел, ә иң читеннән: су коенып чыккан бәбкәләр черем итеп утыра, көтүдәге әнкәсен юксынып яшь бозаулар мөгри торган тигез болын янынннан.

Табигатьнең әкияттәгедәй матур почмагы бу. Язып алыйм дисәң дә тыныч. Ә язып куллар талганнан соң, беразга каләмеңне куеп торып, оныкларың белән уйныйм дисәң дә уңай. Киң арыш кыры бакча башыннан ук башлана. Менә шушындый җирдә Рафаил абый безне «Авылдашым Нәби», «Йолдызым», «Китә казлар» кебек яңа повестьлары һәм хикәяләре белән шатландырыр әле!

**Альберт ХӘСӘНОВ.**

## БЕР СОРАУГА — БЕР ЖАВАП

**Сорау:**

— Якындагы иҗат планнарыгыз турында берничә сүз әйтсәгез иде?

**Нурихан Фәттах:**

— Иҗат планнарының иң якыны да, киләчәктәгесе дә минем өчен — Тарих. Безнең халыкның тарихы шулкадәр бай, катлаулы һәм шулкадәр мавыктыргыч, бер «тәмен татыгач» аннан аерылу мөмкин түгел. Бүгенге укучыга минем менә шул тарихның аз-азлап булса да төрле чорын, төрле ягын тасвирлап күрсәтәсем килә. Мәсәлән, 1985 елда болгар дәүләте белән рус дәүләте арасында беренче солых килешүе төзелүгә мең ел тулачак. Ике дәүләт арасындагы беренче килешү — бу бик зур нәрсә, һәм бу хакта ни дә булса язганда яхшы булыр иде. Ләкин безнең тарих болгар белән яисә дала һәм күчмәләр белән генә дә чикләнми. Төрки тарихның моннан дүрт-биш мең еллык катламнарына да үтеп керергә була.

Хәзергә мин сөннәр (скифлар) чорын чагылдырган «Сызгыра торган уклар»ның икенче китабын язам. Иң якындагы иҗат планым — даладан, сөннәрдән, чиннәрдән котылып, башка чорга, башка катламга тотыну.

# Хәкимҗан Халиков

## Хисмәт белән кисмәк

«Суга бар»,— дип әнисе
Чиләк биргәч Хисмәткә,
«Суың кайда?!»— дип Хисмәт
Кычкырган, ди, кисмәккә.
Кисмәк исә кычкырган
Хисмәттән дә катырак,—
Хисмәт калган аптырап.

## Вакыты тар

Житез юрга чаба-чаба
Су эчәргә барганда:
— Атлан,— дигән ташбакага,
Кинәт туктап калган да.

Ә ташбака ачуланып:
— Юлыңда бул, бар!—дигән.—
Сиңа атланып торырга
Минем вакытым тар!— дигән.

Юрга исә нәрсә дисен:
— Үз җаеңны кара,— ди...
Ә ташбака су эчәргә
Әле һаман бара, ди.

## Тәкәббер әтәч

Бу әтәчме? Авылда
Иң матур әтәч булган,
Ә башында таҗ сыман
Кып-кызыл кәпәч булган.

Койрыклары тиң булган
Салават күперенә...
«Сугышма!»— дип хуҗасы
Әйтмәгән күпме генә.

Шаккаткан, ди, үзе дә,
Калган бер күзе генә.
Башындагы таҗның да
Калган тик эзе генә.

Колак каккан хәтта ул
Үзенең бар йонынnан.
«Ник сугыштым икән?»— дип
И үкенгән соңыннан,
Әмма инде соң булган.

## Ике карга

Ике карга басуда
Җим эзләп йөри икән,
Икесе дә бер-берсен
Гел күзләп йөри икән.

Шуңа күпме җимнәрен
Алар таптап үткәннәр.
Бер суалчан күргә
Кычкырышып киткәннәр.

— Минеке ул!
— Минеке!!
Бәхәс һаман кызган, ди...
Шул вакытта бер чәүкә
Җимне алып сызган, ди.

## Бәйләнчек ишәк

«Сыерның да
Мөгезе бар,
Үгезнең дә...—
Нindиләре
Генә әле
Мөгезнең дә!..»

Ишәк шулай,
Мөгез юк дип
Бездә генә
Үтә икән
Әнисенең
Үзәгенә.

Мөгез эзләп
Барган ди ул
Урманга да,
Бәйләнгән ди
Пошига да,
Боланга да.

«Ике мөгез
Нигә синең
Берүзеңә?!»—
Дип ябышкан
Бер үгезнең
Мөгезенә.
«Бирәсеңме,
Юкмы миңа
Берсен?!»—
дигән.
Үгез, ахры,
Ни әйткәнен
Белсен, дигән
Һәм ишәкне
Чөеп кенә
Ыргыткан ди.
Ә бәйләнчек
Шундый каты
Курыккан ди,
Куркуыннан
Начар холкын
Оныткан, ди.

Хәзер инде
Тыныч кына
Йөри, ди, ул,
Күргәннәрен
Әкият итеп
Сөйли, ди ул.

## Кызыклы хәлләр

*Халык авыз иҗаты гаять киң, тирән һәм катлаулы бер өлкә. Ул жанрлар төрлелеге белән дә колач җитмәслек иҗат мәйданы: бәетләр, җырлар, мәкальләр, әкиятләр, мәзәкләр... Санаган һәр жанр үз эчендә күп төрләргә аерыла. Әйтик, тылсымлы әкиятләр, җанварлар турында әкиятләр, көнкүреш әкиятләре... Хуҗа Насретдиң мәзәкләре, саранннар-юмартлар, байлар-фәкыйрьләр турында мәзәкләр. Тарихи шәхесләр, исемнәре мәгълүм булган шагыйрьләр, сәнгатьчеләр турындагы мәзәкләр...*

*Язучы, рәссам, артист белән булган кечкенә вакыйга телдән-телгә күчеп йөри, шомара һәм конкрет шәхес турындагы бу кызыклы хәл халык авыз иҗаты әсәренә әверелә, шул мәзәк халык арасында мөстәкыйль тормыш белән яши башлый.*

*Рус әдәбиятында шундый мәзәкләрне, кызыклы вакыйгаларны җыеп матбугатта бастыру гадәткә кергән эш. Әдәби журналда ул «литературные курьезы», театр журналында ул «театральные анекдоты» дип бирелә.*

*Татар халкы арасында әдәбиятчылар, сәнгатьчеләр турында таралган бихисап көлке мәзәкләр, моңсу хикәятләр бар. Әйтик, Тукай, Такташ, Сәйдәш, Тинчурин турында күпме мәзәкләр, кызыклы вакыйгалар телдән-телгә йөри, ләкин аларның күп өлеше ташка басылмаган әле. Күп өлеше инде басылмас та. Хөрмәтле аксакалларыбыз сирәгәйгән саен, без ул мөмкинлекләрдән мәхрүм була барабыз.*

*Исән шагыйрьләребез, музыкантларыбыз, рәссамнарыбыз, артистларыбыз турында да бүгенге көндә мәзәкләр туа тора, сөйләнә тора.*

*Ләкин бу «кызыклы хәлләр»не җыю шактый катлаулы, күләмле эш. Аларны берәмләп, бөртекләп, еллар буе җыярга кирәк. Шуңа күрә без журналыбызны укучыларга мөрәҗәгать итәргә булдык.*

*Хөрмәтле иптәшләр!*

*Һәр шәһәргә, һәр авылга артистлар, язучылар килә тора. Алар сезнең белән сәхнә аша да, турыдан-туры да аралаша. Шул очрашудагы мәзәк хәлләр турында, ишеткән-белгәннәрегезне, үзегез шаһит булган вакыйгалар турында язып җибәрсәгез, бик яхшы булыр иде. Мәзәкләр, вакыйгалар турында хәбәр иткәндә шәхесләрнең исемнәре төгәл язылсын иде. Авторның да исеме, фамилиясе, адресы тулы булуы зарури.*

*Түбәндәге адрес белән яза аласыз:*

*420066, Казан, Декабристлар урамы, 2. «Казан утлары».*

*Журналыбызда басыла торган «Кызыклы хәлләр»не редакциягә язучы Роберт БАТУЛЛА туплап бирде.*

*Редакция*

## Ватык микрофон

Фәйзулла Туишев гармунда озын-озак уйнарга ярата торган була. Бер-ике көй өчен генә ул сәхнәгә чыкмый. Бер-ике көй өчен генә ул радиога да килми... Ул чагында магнитофон тасмасына язып алу юк әле — турыдан-туры радио аша эфирга чыгасы. Бервакыт радиотапшыру барганда Фәйзулла абыйны һич кенә дә гармун уйнаудан туктата алмыйлар бит. Уйный да уйный бу. Мәскәү тапшырулары үкчәгә басып килә. Мәскәү вакытын алырга һич ярамый. Шуннан Фәйзулла абыйга сиздермичә генә микрофонны өзеп, Мәскәүне эфирга тоташтыралар. Фәйзулла абый эшләми торган микрофонга тагын ярты сәгать чамасы гармун уйный. Туктарга исәбе дә юк. Һаман уйный да уйный. Түземнәрен җуйган артистлар, техниклар хәйләләргә булалар. Көй арасында Туишевка:

— Фәйзулла абый, микрофоннар ватылды, халык сезне ишетми!— дигәч кенә атаклы музыкант уйнавыннан туктый.

## Револьверың хыянәт итсә

Шөһрәтле артист Шакир Шамильский «Бәхетсез егет»тә Закирны уйный. Сәхипҗамал Волжская Гайни ролендә була. Үтереш сәхнәсендә Шамильскийның револьверы атмый. Артист каушап калмый:

— Шул бәдбәхет хатынны да дөмектерә алмагач, синең ни кирәгең бар!— дип, револьверны тотып бер якка томыра да, Гайнигә таба янаулы атлый.

— Атып үтерә алмасам да, мин сине кулларым белән буып үтерәчәкмен!— дип, Шамильский Гайнине «буып үтерә».

## Соңрак кагылырмын

Драматург Тажи Гыйззәтнең яхшы актер икәне һәркемгә дә мәгълүмдер. Бервакыт Тажи абзый үз пьесасында уйнаганда, ялгышып, вакытыннан элек, сәхнәгә чыга. Сәхнәдәге актер башта аптырап кала, аның аптыраганын күреп, Тажи Гыйззәт эшне сизенеп ала. Ләкин сәхнәгә чыгылган, халык аннан нидер көтә. Сүзсез кереп, сүзсез чыгып китү пьеса логикасына туры килми. Уңайсыз хәлдән чыгу өчен теге актер сүз башлый:

— Я, ник кердең монда?— ди.

— Болай гына, хәл белеп чыгыйм, дигән идем,— дип Тажи Гыйззәт пьесада булмаган сүзләр сөйли башлый.— Ни хәлләрдә ятасыз соң?

— Без әйбәт ятабыз, ә менә син бераз алданрак кергәнсең бит әле,— ди партнер.

— Шулай икән шул, үзем дә сизеп торам. Алайса, мин соңрак тагын бер сугылырмын әле,— дип, Тажи ага Гыйззәт сәхнәдән чыгып китә.

## Сәйдәшнең батырлыгы

Кәрим абзый Тинчурин артык юаная башлагач, докторга бара. Доктор аңа аз ашарга, күп су коенырга, чи йомырка эчәргә һәм җәй буе велосипедта йөрергә куша. Тинчурин велосипед сатып ала да Салих Сәйдәшевне дә авылларга экспедициягә чыгарга үгетли.

— Мин яңа пьеса өчен материал туплармын, син көйләр җыярсың!— ди драматург.

Чыннан да болар Сәйдәш белән икәүләп, велосипедка атланып чыгып китәләр. Кайда елга, су очрый — түйганчы коеналар болар. Ашауны кысалар, чи йомырка гына эчеп яши башлыйлар. Күпме генә ябыгырга тырышса да Кәрим Тинчуринның авырлыгы кимеми, гәүдәсе нечкәрми. Экспедицияне тәмамлап, Казанга кайткач, Сәйдәшнең арыклыгын күреп, бөтен таныш-белешләре шакката:

— Салих, нәрсә булды сиңа? Әллә син больницада ятып чыктыңмы? Шыр сөяккә генә калгансың бит, бичара!— диләр.

— Әнә, Кәрим Тинчурин өчен ябыгып, ачка үлә яздым!— дигән Сәйдәш.

## Тавыклар — артистлар

Кәрим Тинчурин кайчакларда әллә нинди экспериментлар уздыра торган була. Бер тапкыр «Галиябану»ны уйнаганда ул сәхнәгә тавыклар, әтәчләр чыгара. Бәдри карт ишегалдында җим чүпләп, кытаклап йөрергә тиешле тавыклар тамаша залына очып төшә башлый. Пәрдәне ябып, тамашачылар белән бергә артистлар тавык куарга тотыналар. Спектакльнең рәте китә.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Язучыларның 29 ноябрьда узган ачык партия җыелышында шагыйрь һәм драматург Рөстәм Мингалимовның иҗат отчеты тыңланды. Әдипнең төрле жанрларда иҗат иткән әсәрләре турында шагыйрь Зөлфәт һәм театр белгече Р. Игъламов сөйләде. Фикер алышуларда А. Шамов, М. Садри, Мәхмүт Хәсәнов, Т. Миңнуллин, И. Юзеев, Р. Мөхәммәдиев катнашты. Чыгыш ясаучылар Р. Мингалимов иҗатына төпле анализ ясап, уңай бәя бирделәр.

## ТАТАРСТАН КОМПОЗИТОРЛАРЫНЫҢ V СЪЕЗДЫ

17—21 октябрьда Татарстан композиторларының V съезды булып узды. Анда катнашу өчен Мәскәүдән, Башкортстаннан, Мари, Мордовия, Кабарда-Балкар, Удмуртия, Чувашия автономияле республикаларыннан кунаклар килде.

Съездны кереш сүз белән ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе М. З. Яруллин ачты.

Дүрт көн дәвамында Казан консерваториясенең Актлар һәм Зур залларында композиторларыбыз соңгы елларда иҗат иткән төрле жанрлардагы әсәрләрдән төзелгән концертлар, Б. Мулюковның «Кара йөзләр» операсының язмасы тыңланды, алар буенча фикер алышулар оештырылды.

21 октябрьда съездның пленар утырышы булды. Анда ТАССР Композиторлар союзы идарәсенең отчет доклады белән идарә председателе М. З. Яруллин, ревизия комиссиясе отчеты белән Л. З. Любовский чыктылар.

Фикер алышуларда композитор Б. Г. Мулюков, музыка белгече Г. Я. Касаткина, Г. М. Корепанов-Камский (Удмуртия АССР), РСФСР Композиторлар союзы идарәсе секретаре К. Е. Волков, А. Г. Васильев (Чувашия АССР), РСФСР Композиторлар союзы идарәсе члены А. В. Медведев, Р. В. Сәлмәнов (Башкортстан АССР), Г. Г. Вдовин (Мордовия АССР), Х. Я. Карданов (Нальчик) һ. б. катнашты.

Утырышта КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев чыгыш ясады.

ТАССР Композиторлар союзы идарәсе һәм ревизия комиссиясе членнары сайланды. Идарә утырышында ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе итеп М. З. Яруллин сайланды.

Съезд эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Шагыйрьләр секциясенең 4 ноябрьда узган утырышы поэмалар турында дәвамлы сөйләшүнең чираттагысы булды. Анда соңгы ике елда «Казан утлары» журналында басылган биш поэма турында филология фәннәре докторы профессор Т. Н. Галиуллин доклад белән чыкты. Соңыннан фикер алышуда әдипләр һәм тәнкыйтьчеләр С. Хәким, Г. Ахунов, Ф. Миңнуллин, Р. Мостафин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Гатауллин, Зөлфәт һ. б. үзләренең кызыклы күзәтүләре белән уртаклаштылар.

Шагыйрьләр секциясе бюросы үзенең ноябрь аендагы утырышын Казаннан читтә яшәүче ике автор — С. Муллагалиев (Үзбәкстан) һәм Р. Газизовларның (Мамадыш) беренче кульязмаларын тикшерүгә багышлады. Аларның шигырьләренә җентекле анализ ясалып, кульязмаларны камилләштерү юлында күп кенә файдалы киңәшләр бирелде.

## РИЗА ИШМОРАТНЫҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

31 октябрьда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында күренекле драматург һәм сәхнә эшлеклесе Риза Ишморатка 80 яшь тулуга багышланган юбилей кичәсе булды.

Юбилей кичәсен кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов ачты.

Р. Ишморатның иҗаты турында филология фәннәре кандидаты А. Әхмәдуллин сөйләде.

Юбилярны республикабызның партия, совет һәм профсоюз оешмалары, хезмәт коллективлары, иҗат союзлары, культура учреждениеләре вәкилләре, күрше республикалардан килгән кунаклар котлады.

Юбилей кичәсендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

Соңыннан Татарстан сәнгать осталары катнашында юбилярның әсәрләреннән төзелгән концерт булды.

## БӨТЕНРОССИЯ СЕМИНАРЫНДА

Язучыларның Пицундадагы (Абхазия АССР) Д. Гулиа исемендәге иҗат йортында үткәрелгән яшь тәнкыйтьчеләрнең Бө-

тенроссия семинарында Татарстаннан яшь тәнкыйтьче Салих Маннапов катнашты. Аның иҗаты философия фәннәре докторы Ю. Б. Борев һәм «Советский писатель» нәшриятының әдәби тәнкыйть редакциясе мөдире М. Я. Малхазова җитәкчелегендәге семинарда тикшерелде һәм уңай бәя алды.

Бөтенроссия тәнкыйтьчеләренең традицион форумында семинар җитәкчесе буларак РСФСР Язучылар союзының әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме советы члены Ринат Мөхәммәдиев катнашты һәм республикабыздагы әдәби хәрәкәт турында чыгыш ясады.

## УФАДА ФӘННИ КИҢӘШМӘ

15—17 ноябрьда Уфада Идел — Урал буеның урта гасырлар археологиясенә багышланган фәнни киңәшмә булып узды. Төрле автономияле республикалардан һәм өлкәләрдән җыйналган археологлар, этнографлар, тел һәм халык сәнгате тарихы белгечләре Көнчыгыш Европа халыкларының урта гасырлар тарихына кагылышлы мөһим мәсьәләләрне тикшерделәр, бу тарихны өйрәнү өлкәсендә соңгы елларда эшләнгән ачышлар белән бер-берләрен таныштырдылар, фикер алыштылар. Киңәшмәдә Казан галимнәреннән А. Халиков, Р. Фәхретдинов, П. Старостин, Е. Казаков, Д. Вәлиева, Г. Вәлиева (Сөләйманова), Д. Исхаков, Ф. Хәкимҗанов һ. б.лар чыгыш ясадылар.

Р. Фәхретдинов Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге укытучылары һәм студентлары белән очрашты, аларга Болгар дәүләтенең тарихын һәм татар халкының этногенезы (килеп чыгышы) проблемаларын тикшерүнең барышы турында, шул өлкәдә ирешелгән уңышлар турында сөйләде.

## ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН ИҖАТЫНА БАГЫШЛАП

21 октябрьда язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Ул яшьли арабыздан киткән күренекле сатира-юмор остасы Фаил Шәфигуллин иҗатына багышланган иде. Язучының әсәрләре Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артисты Рәшит Сабиров башкаруында яңгырады. Ф. Шәфигуллин сүзләренә җырлар башкарылды.

## ТҮБӘН КАМАДА ДУСЛЫК КИЧӘСЕ

Биредә уза торган традицион «Җидегән чишмә» кичәләрендә Г. Бәширов, С. Хәким, Г. Ахунов, С. Садыйкова кебек күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре кунакта булып киткән иде инде. Октябрь азагында аның халыклар дуслыгына багышланган әдәби-музыкаль кичәсендә РСФСРның М. Горький, Башкортстанның С. Юлаев исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Нәҗар Нәҗми белән очрашу булды. «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе җитәкчесе, язучы Р. Хисматуллин шагыйрьнең иҗаты хакында сөйләде.

Кичәдә шагыйрьнең шигырьләре укылды, аның сүзләренә язылган җырлар башкарылды.

Нәҗар Нәҗми үзенең шигырьләрен һәм поэмаларыннан өзекләр укыды. Сорауларга җаваплар бирде.

Өлкән шагыйрь Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсе җитәкчеләре белән дә очрашты.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНЫҢ УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯЛӘРЕ

23 сентябрьдә Кукмарада «Казан утлары» журналының укучылар конференциясе булды. Районның Үзәк китапханәсендә узган бу конференциядә район игенчеләре, эшчеләр, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, әдәбият сөючеләр, районның яшь иҗат көчләре катнашты.

Журналның хатлар бүлеге редакторы шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов редакция коллективының эше, журналның иҗат планнары, танылган әдипләрнең һәм яшь язучыларның 1984 елда басылачак яңа әсәрләре белән таныштырды. Язучы һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин бүгенге әдәби проблемалар, М. Җәлил иҗатының «Казан утлары» журналында чагылышы һәм җәлилчеләрнең батырлыгы турында сөйләде.

Зур Кукмара сигезьеллык, Зур Сәрдек урта мәктәпләренең татар теле һәм әдәбияты укытучылары Зөфәр Гомәров, Хәтмулла Вәккасов, Кукмара беренче номерлы урта мәктәбе укытучылары Рахман Мөхәммәдиев, Нәсимә Афзалова, Кукмара эшче-яшьләр урта мәктәбе директоры Марат Фәйзрахманов иптәшләр чыгыш ясап, «Казан утлары»н тагын да эчтәлекле, бизәлешен матуррак итү турында файдалы фикерләр, киңәшләр әйттеләр, журнал авторларына уңышлар теләделәр.

4 октябрьда Әлмәтнең төзүчеләр Техника йортында «Казан утлары» журналының укучылар конференциясе булып узды. Анда сүз КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы һәм «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади элемтәләре турында»гы карарлары яктылыгында редакция алдында торган бурычлар хакында барды. Журналның баш редакторы Р. Харис, язучылар Ә. Гаффар, Г. Афзал, М. Мәһдиев, Ә. Маликов, К. Булатова журналның Татарстан нефтьчеләре белән дуслыгы турында сөйләделәр, сорауларга җаваплар бирделәр.

Журнал редакциясе коллективының һәм аның авторларының нефть темасын яктыртудагы зур өлешен искә алып, Шашин исемендәге «Татнефть» производство берләшмәсе һәм шәһәр Советы башкарма комитеты журнал редакциясен Мактау грамоталары белән бүләкләделәр.

11 октябрьда Брежнев шәһәренең «КамАЗ» Культура сараенда узган «Казан утлары» журналының укучылар конференциясенә йөзләрчә КамАЗчылар, әдәбият сөючеләр килгән иде. Журналның баш ре-

дакторы Ренат Харис, журналның авторлары — язучылар Аяз Гыйләҗев, Брежнев язучылар оешмасы җаваплы секретаре Разил Вәлиев, Газиз Кашапов бүгенге әдәби проблемаларны хәл итүдә журналның роле, басылган һәм басылачак әсәрләр турында сөйләделәр. Социалистик Хезмәт Герое Вазих Мәүликов, «Камгэсэнергострой» берләшмәсенең йортлар салу комбинаты начальнигының урынбасары Мәгъсүм Ибраһимов, халык депутатларының Брежнев шәһәр Советы башкарма комитетының культура бүлеге мөдире Шамил Закиров чыгыш ясап, «Казан утлары» журналында басылган әсәрләрнең заманыбыз күтәргән проблемаларын аңлатуда, хәл итүдә зур роль уйнаулары турында басым ясап әйттеләр.

27 октябрьда Мамадыш шәһәренең Культура йортында узган «Казан утлары» журналының укучылар конференциясенә күпсанлы әдәбият сөючеләр, укытучылар, яшь иҗатчылар җыелды. Журналның поэзия бүлеге редакторы шагыйрь Рәдиф Гатауллин, хатлар бүлеге редакторы шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов журналның иҗади тормышы, анда басылган яңа әдәби әсәрләр турында сөйләделәр, сорауларга җаваплар бирделәр, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

15 сентябрьдә шагыйрь Нәби Дәүли үзенең якташлары — Әлки районы Базарлы Матак игенчеләре белән очрашты. Ул үзенең иҗат кичәсендә төрле елларда язылган шигырьләрен укыды. Н. Дәүли сүзләренә язылган «Әлкием» җыры да (З. Гыйбадуллин музыкасы) башкарылды.

Шагыйрь үзенең иҗат планнары турында сөйләде, сорауларга җаваплар бирде.

29 сентябрьдә язучы Шамил Рәкыйпов Казан шәһәренең Химиклар сараенда Мәскәү районы укытучылары белән очрашты. Ул Бөек Ватан сугышында катнашкан төрле милләт хатын-кызларның батырлыгы, аларның интернациональ дуслыклары турында сөйләде, яңа әсәреннән өзекләр укыды.

30 сентябрьдән 2 октябрьга кадәр Татарстан Композиторлар союзы Саба районы авылларында музыка кичәләре уздырды. Авыл хезмәтчәннәренә РСФСРның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклеләре, композиторлар Х. Вәлиуллин, Ф. Әхмәтов үзләренең иҗатлары, бүгенге татар музыкасының казанышлары турында сөйләделәр. Аларның авыл хезмәтчәннәренә багышлап язган яңа җырларын Татарстанның атказанган артистлары Г. Сәйфуллин, М. Галиев һәм яшь җырчы Л. Хәсәнова башкарды.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Әдәбият , белеме өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен һәм сиксән яше тулу уңаеннан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты профессор-консультанты Мөхәммәт Гайнуллин, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 23 сентябрь Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Зәки Нурига, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 5 октябрь Указы белән, «РСФСРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм житмеш яше тулу уңаеннан М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының баш режиссеры Нияз Даутов, СССР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 22 сентябрь Указы нигезендә, Халыклар Дуслыгы ордены белән бүләкләнде.

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен шагыйрь Мөхәммәт Садрига, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 27 июль Указы белән, «РСФСРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Ләбибә Ихсановага, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 16 ноябрь Указы белән, «РСФСРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен драматург Диас Вәлиевкә, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 11 ноябрь Указы белән, «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе директоры Марат Габдрахманович Тажетдиновка, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 26 октябрь Указы белән, «РСФСРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең художество житәкчесе Илгиз Габидуллович Мәҗитовка, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 29 ноябрь Указы белән, «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

# «КУНАККА»

Кышкы авыл урамы. Кояш нуры күзләрне чагылдыра. Шыгырдап торган кардан үз дәрәҗәләрен белеп кенә карт белән карчык атлый. Карчыкның кулында бүләк — кызыл шакмаклы ашъяулыкка төрелгән кайнар бәлеш.

«Кунакка» дип исемләнгән бу картинаны рәссам Искәндәр Рафиков язган. Сюжеты гади булуга карамастан, әсәрнең мәгънәсе тирән. Рәссам монда кешене дә, табигатьне дә эмоциональ яктан һәм истә калырдай итеп күрсәтә алган.

Картинада карт белән карчык икесе берьюлы күзгә ташлана, аларны аерып булмый. Шулай итеп, җыйнап бирү алымы кулланып, рәссам аларның эчке дөньялары да якын икәнен оста күрсәтә. Картларның хәрәкәтләре аларның характерын ачарга ярдәм итә. Карчык нык басып, ышанычлы атлый, карт әз генә арттарак, башын ия төшкән. Мөгаен, аның характеры да йомшаграктыр. Гаиләдә дә карчык сүзе өстен бугай. Карчыкның йөзендә үткән еллар сагышы, шул ук вакытта аннан шатлык нурлары да бөркелә. Алдагы очрашу куанычыннан карт рәхәтләнеп елмая.

Рәссам картларның ягымлы образларын бик яратып сурәтләгән, аларга карагач, кешелекле кешеләр күз алдына килә.

Картинада яктылык бик мул. Аның нечкә күчеше, буяуларның ачык гаммасы тәэсирне тагы да көчәйтә. Кояш, өй һәм каралты-кура өстендә уйнаган нурлар, зәңгәрсу кар — барысы да яз якынлашуын күрсәтә. Ачык төсләр картинага бәйрәм күтәренкелеге бирә.

...Авыл темасын бөтен җаны-тәне белән яратып иҗат итүче И. Рафиков сәнгать дөньясына алтмышынчы елларда килде. Ә хәзер инде ул күп портретлар, тарихи картиналар һ. б. әсәрләр авторы. Ләкин аны гел рухландырып торучы бер тема бар: ул — татар авылы тормышы, авыл хезмәтчәне, аның катлаулы характеры, берьяклы гына аңлатып булмый торган эчке дөньясы. И. Рафиковның киң таралган әсәрләреннән «Кошчылар», «Колхоз председателе портреты», «Кызлар» тормышны яхшы белеп, кеше күңелен тирән аңлап иҗат ителгәннәр.

Рәссамны халыкның буыннан-буынга дәвам иткән гореф-гадәтләре дулкынландыра. Кешелеклелек, бүтәннәр язмышына, аларның кайгы-шатлыгына битараф булмау И. Рафиковның «Кунакка» дигән әсәрендә дә бик ачык чагыла.

Диләрә САДЫЙКОВА,
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** А. П. Бородинның М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында куелган «Князь Игорь» операсында төп партияне РСФСРның халык артисты, Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ренат Ибраһимов башкара.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)